ГАБДЕЛҖӘББАР КАНДАЛЫЙ

ГАБДЕЛҖӘББАР КАНДАЛЫЙ

шигырьләр һәм поэмалар

ГАБДУЛДЖАББАР КАНДАЛЫЙ

СТИХОТВОРЕНИЯ И ПОЭМЫ

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
1988

ГАБДЕЛҖӘББАР КАНДАЛЫЙ

ШИГЫРЬЛӘР ҺӘМ ПОЭМАЛАР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1988

ББК 84.(05)
К 19

Җыентыкны төзүче, текст һәм фәнни аппаратны хәзерләүче, кереш сүз авторы тарих фәннәре докторы

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ

Нәшрият редакторы

РӘИС ДАУТОВ

К $\frac{4702510000-287}{М 132 (03)-88}$ 138—88

© Татарстан китап нәшрияты, 1988

ГАБДЕЛҖӘББАР КАНДАЛЫЙ: БЕР ГОМЕРДӘ ИКЕ ЧОР

Шагыйрь Габделҗәббар Габделмәҗит улы Кандалыйның (1797—1860) исеме, иҗатының бер өлеше киң җәмәгатьчелеккә күптәннән мәгълүм инде. Шул мәгълүм өлештән генә чыгып та без шагыйрьнең язу осталыгына сокланып, аның әдәбиятыбыз үсешенә керткән бәхәссез кадалыгын ихлас күңелдән тәкъдир итә килдек.

Бер үк вакытта әлеге өлешчә белемебез нигезендә шагыйрьнең кайбер карашларын, үз чорында хөкем сөргән иҗтимагый шартларга мөнәсәбәтен ачыкларга тырыштык.

Ләкин, моны яхшы белгәнебез хәлдә, Кандалый шәхесенә һәм иҗатына бәйле мөһим сорауларның һәммәсен дә канәгатьләнерлек дәрәҗәдә чишә алдык дип әйтергә нигез юк әле. Мәсәлән, шагыйрь мирасының гомум күләме никадәр? Аның иҗаты кайчан, нинди иҗтимагый шартларда, ничек башланып, нинди үсү, үзгәрү һәм эволюция баскычларын узган? Үткәндәге әдәби процессыбызда нинди төенне тәшкил итеп, үзеннән нинди үрентеләр — юнәлешләр биргән? Әдәбият тарихыбызда иң элек «лирик шагыйрь», «мәхәббәт шагыйре» сыйфатында танылган (димәк, кем әйтмешли, үтә шәхси, хәтта бик тар интим мәсьәләләр тирәсендә чуалган) Кандалый иҗатының социаль-иҗтимагый әһәмияте бармы, булса ул нәрсәдән гыйбарәт, әсәрләрендә ничегрәк гәүдәләнгән? Үзеннән элекке мирасның кай ягын үстереп, аңа нинди яңалык китергән? Һәм, узганны бүгенге көндә танып-белү өчен Кандалый мирасының документальлек кыйммәте ни дәрәҗәдә?

Бу сораулар, әлбәттә, бүген генә туган сораулар түгел. Әсәрләренең беренче мәртәбә матбугатка чыга башлавына йөз елдан артык гомер узган шикелле, шагыйрьнең иҗаты да күптәннән бирле культура, әдәбият әһелләренең игътибарын җәлеп итә килгән, мирасы хакында шактый фикерләр әйтелгән.

I

Габделҗәббар Кандалый мирасының дөньяга чыгу һәм галимнәр игътибарын җәлеп итә башлау факты XIX йөзнең урталарына, ягъни шагыйрь үзе әле исән вакытка яки үлгәннән соңгы беренче елларга туры килә. Һәм бу башлангыч иң элек күренекле мәгърифәтчеләребезнең эшчәнлегенә барып тоташа. Мәсәлән, 1859 елда Салихҗан Күкляшев тарафыннан чыгарылган «Дивани хикәяти татар» дип аталган мәгълүм хрестоматиядә, автор исеме күрсәтелмичә, Кандалыйның бер шигъри парчасы басылган булса, алтмышынчы елларның башын-

да ук Хөсәен Фәезханов «Рисаләи-л-иршад» поэмасының хәзер фәнгә мәгълүм бердәнбер күчермәсен җентекләп өйрәнә һәм аның катлаулы текстына хашия — лексик аңлатма төзи («Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» поэмасын да эченә алган ул кулъязманы Х. Фәезханов 1862 елда болгар-татар кабер ташларын өйрәнер өчен Сембер якларында йөргәндә тапкан булырга тиеш). 1870 елда Рус география җәмгыятенең Оренбург бүлеге язмаларында И. Покровский бастырган татар һәм башкорт халык җырлары арасында Кандалыйныкы булуы шик тудырмый торган алты шигырь (200 юлдан артык шигъри текст) дөнья күрә *. 1880 һәм 1881 еларда Казан университеты типографиясендә шагыйрьнең «Мәгъшукнамә» дип исемләнгән әсәре, авторы күрсәтелмәгән хәлдә, аерым китап рәвешендә ике мәртәбә басылып чыга.

Әмма шагыйрь әсәрләрен фәнни планда махсус җыю, пропагандалау һәм үз чоры өчен текстологик җәһәттән югары сыйфатта бастырып чыгару эше иң беренче чиратта Каюм Насыйри исеме белән бәйле. Дөрес, мәгърифәтченең «Кырык бакча» китабында (беренче публикациясендә, 1880) шагыйрьнең кайбер әсәрләре аноним килеш басылалар (авторы исән чакта ук халыклашып өлгергән ул шигырьләрнең Кандалый иҗатына карауларын ачыклау ул чорда әле мөмкин түгел иде). Мәгълүм «Фәвакиһ-ел-җөләса фи-л-әдәбият» китабында исә мәшһүр «Сахибҗамал», «Фәрхи» әсәрләре һәм тагын башка шигырь текстлары (барлыгы 1502 юл) басылудан тыш, беренче мәртәбә шагыйрьнең тулы исеме аталып, аның иҗатына кыскача гына булса да фәнни бәя дә бирелә. Мәсәлән, моны галимнең: «Бу мәзкүр әбйатның имля вә иншасы байтак яхшы төзелгәндер. Шул җәһәтдән игътибар кылынды. Мәрхүм Габделҗәббар — шагыйрь адәм имеш»,— дигән кыскача ремаркаларыннан күрергә мөмкин.

«Фәвакиһ-ел-җөләса»да басылган текстларның гомум әһәмиятенә һәм сыйфатына килсәк, алар менә йөз елдан артык инде шагыйрь мирасын өйрәнү юлында әдәбият белгечләре өчен төп чыганакларның берсе булып хезмәт ителәр. Әйтик, әдипләребездән Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Җамал Вәлиди, Газиз Гобәйдуллин һәм Гали Рәхимнәр шагыйрь белән «Каюм бабай» китабы битләрендә очрашканнар, шундагы әсәрләрдән чыгып, ул мирасның кыйммәтен, әһәмиятен билгеләгәннәр. Өстәп шуны гына әйтергә мөмкин: К. Насыйри публикациясенең бу документальлек сыйфаты әле бүген дә үзенең көчен югалтмаган.

Шагыйрь мирасын фәнни күзлектән чыгып анализлаган беренче тикшеренүләрдән, иң әүвәл, әлбәттә, Җ. Вәлидинең «Татар әдәбиятының барышы» исемле хезмәтен (1912) күрсәтергә кирәктер. Китапта шагыйрьгә багышланган махсус бүлек булып, автор аны характерлы икърар белән башлап җибәрә: «Без тарихе әдәбиятымызда чын татарча нәзымләр язучыны эзләгәндә, иң элек, Габделҗәббар әл-Кандалыйга очрыймыз». Аннары галим, беренчеләрдән булып, Кандалый иҗатының төп үзенчәлекләреннән тел-стильдә һәм рухта чагылган табигый халыкчанлык, хатын-кыз хокукын күтәреп чыгудагы пионерлык, үзе сайлаган юлга гомер буе тугрылык сыйфатларын атап күрсәтә. Шулай ук Җ. Вәлиди, халык арасында киң таралган «Чәй бәете» белән «Уңмаган килен» сатирик шигыренең авторы Кандалый булу ихтималын әйтеп, аның мирасын барлау юлында тагын бер адым алга атлый.

Революциядән соң чыккан беренче татар әдәбияты тарихында да (1925) Кандалый иҗаты Гали Рәхим, Газиз Гобәйдуллиннар тара-

* Монда һәм алга таба кыскача телгә алына торган китапларның, публикацияләрнең тулы исемнәрен шушы җыентык ахырында бирелгән библиографик белешмәдән карагыз; анда безнең тараftан файдаланылган башка хезмәтләр дә теркәлгән.

фыннан шактый этрафлы карала. Дөрес, бу китапта Ж. Вәлидинең «Чәй бәете», «Уңмаган килен» хакындагы фикере җиңелчә аргументлар нигезендә кире кагыла. Моны шагыйрь мирасы хакындагы белемнең ул чакта әле бик чикләнгән булуы белән аңлатырга кирәк.

Егерменче елларның ахырында шагыйрь мирасын барлау юлында эшләр тагы беркадәр җанлана төшә: «Безнең юл», «Яңалиф» журналларында Кәрим Иртуган (Рахманкулов), Исхак Бәхтиев материаллары басылып чыга, Кандалыйның биографиясенә караган яңа мәгълүматлар фәнни хәрәкәткә кертелә. Кәрим Иртуган публикациясенә кереш итеп язган сүзендә Габдерахман Сәгъди, Кандалый мирасы хакында гомум фикерләрдән соң, шагыйрьнең җыентыгы төзелә башлау, аны баетыр өчен материаллар эзләү хакында хәбәр итә. Ләкин һәммәбезгә мәгълүм сәбәпләр аркасында бу башлангыч тәмамланмыйча кала. Иң кызганычы шул ки, Татарстанның Гыйльми үзәгендә һәм Г. Сәгъди кулында булган материаллар утызынчы елларның икенче яртысында эзсез югалалар.

Дөрес, утызынчы-кырыгынчы елларда да шагыйрьнең әсәрләре азлап-азлап хәрәкәткә кертелә тора: әдәбият буенча төзелгән дәреслекләрдә, хрестоматияләрдә моңарчы билгеле булмаган яңа текстлар басылып чыга.

Әдәбият белгече Бәкер Яфаров тарафыннан 1947 елда ук әзерләнеп беткән Кандалый шигырьләре җыентыгы да төрле сәбәпләр аркасында үз вакытында дөньяга чыкмыйча кала. Соңыннан, 1960 елда, бу материалларның беркадәресе Хатип Госман һәм Җәвад Алмазлар төзеп бастырган «Г. Кандалый. Шигырьләр» дип аталган китапта урын алды. Г. Кандалыйның шактый әсәрләре тупланган беренче мөстәкыйль җыентык булу өстенә, кереш мәкаләдә шагыйрь хакында яңачарак сүз әйтелү җәһәтеннән дә бу басма алга таба зур адым иде. Х. Госман тарафыннан язылган кереш мәкаләнең аерата игътибарга лаек моментлары итеп Кандалыйны тудырган чорга характеристика бирергә омтылуны һәм әдәбиятыбызга шагыйрь алып килгән зур яңалыкны — яңа герой мәсьәләсен куюны күрсәтергә мөмкин.

Шагыйрьнең әсәрләрен даими пропагандалау, элекке әдәби процессыбызда ул тоткан урынны ачыклау юнәлешендә эзлекле эшләп килгән галимнәребезнең тагын берсе — Мөхәммәт Гайнуллин. Аның тарафыннан югары уку йортлары өчен чыгарылган әдәбият дәреслекләрендә, хрестоматияләрдә (1957, 1968, 1975) Кандалый әсәрләре һәрвакыт диярлек тиешле игътибар үзәгендә була килде. Иҗтимагый хәрәкәтебез тарихында шагыйрь тоткан урын галимнең «Татар мәгърифәтчелеге әдәбияты» дигән китабында (1979) тагы да отышлырак билгеләнде.

Күптомлы «Татар әдәбияты тарихы» битләрендә урын алган Кандалый турындагы махсус бүлекнең барлыкка килүен (1985, 2 том, хезмәтнең төп өлеше Рәфис Әхмәтов тарафыннан язылган) шагыйрь иҗатын менә шулай дәвамлы һәм эзлекле рәвештә өйрәнүне нәтиҗәсе дип бәяләргә кирәк.

Соңгы елларда шагыйрь мирасын махсус белгечләкләр буенча өйрәнү юнәлешендә дә аерым тәҗрибәләр ясалды. Мисалга Кандалый әсәрләренең тел, стиль үзенчәлеген һәм поэтик техникасын өйрәнүгә багышланган Х. Р. Курбатов, А. М. Юсупова хезмәтләрен әйтеп үтәргә мөмкин.

Шагыйрь әсәрләрен халык арасында эзләү, табылганнарын фәнни хәрәкәткә кертә баруда Кандалыйның якташларыннан Х. Тазюков тырышлыгы игътибарга лаек. Мирасны туплау юлында махсус археографик эзләнүләр дә сизелерлек нәтиҗәләрен бирде. Әйтик, 1963 елдан бирле Казан дәүләт университеты каршында даими эшләп килә торган археографик экспедицияләр вакытында бу юлларның авторы

шагыйрьнең листәдән артык яңа әсәрен, шул җөмләдән, элек күпләргә билгесез «Рисаләи-л-иршад» һәм «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» поэмаларын янадан табып, фәнни әйләнешкә кертте. М. И. Әхмәтҗанов белән Р. А. Әхмәтов иптәшләрнең дә бу юлда кыйммәтле үз өлешләре бар. Бу табышларның гомум әһәмиятен һәм күләм-чамасын күз алдына китерер өчен мондый саннарны атау да җитә: әгәр 1960 елда чыккан чагыштырмача иң тулы китапта 2500 юлдан артык шигъри текст басылган булса, хәзер укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган җыентыкка, төрле характердагы вариантлары белән бергә, 8500 юл чамасы шигъри текст тупланган. Әйтергә кирәк, бу сан да әле соңгы сүз булмаска тиеш.

Кыскасы, галимнәрнең, әдәбиятчыларның күмәк тырышлыклары нәтиҗәсендә, иң мөһиме — Кандалыйның үз мирасы сизелеп ишәю аркасында, шагыйрь хакындагы бүгенге белемебез элгәрге белән чагыштырганда күпкә тәгәлләнә, байый төште. Бу хәл исә Габделҗәббар Кандалый туган һәм яшәгән мохитне, ул узган үзенчәлекле һәм катлаулы юлны, аның әдәби фикеребез үсүгә керткән өлешен, шул өлешнең мәдәни фондыбызда торткан тарихи урынын яңадан бер кат күз алдыннан кичерергә мөмкинлек бирә.

II

Габделҗәббар Кандалый 1797 елда элекке Самар губернасының Ставрополь өязе (хәзерге Ульянов өлкәсенең Иске Майна районы) Иске Кандал (хәзер — Иртуган) авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Шагыйрьнең туган елы хакында үзгә фикерләр дә бар. Мәсәлән, И. Бәхтиев язуынча, ул 1794 елда туып, 1862 елда вафат булган. Ләкин К. Иртуган белән Г. Сәгъди һәм күпчелек галимнәр «1797—1860» тарихына тукталалар.

Габделҗәббарның социаль чыгышына килсәк, монда бәхәс юк: руханилык кәсебенең алар нәселендә ерактан килүе иске шәҗәрә буенча да (Габделҗәббар — Габделмәҗит — Ибнейәмин — Биктимер — Ибраһим — Йосыф...) һәм шагыйрьнең үз сүзеннән дә төгәл раслана. Мәсәлән, мәгъшукасенә мөрәҗәгать итеп, ул болай ди:

Безем бу муллалык йирле.
Ки йите бабалин бирле
Килеп өзелмәгән бер дә!..

Кайбер мәгълүматларга караганда, Кандалыйлар нәселе элек Каракитә авылында (хәзер Татарстандагы Чүпрәле районы) яшәгән булган, Иске Кандалга шагыйрьнең ерак бабаларыннан берсе килеп урнашкан. Мәсәлән, Габделмәҗит Ибнейәмин улы шунда муллалык иткән, дан-абруй казанган. Габделмәҗитнең гадәти генә авыл мулласы булмыйча, шактый зур белемле, китап-әсәр язу, «шәрех-моталәга кыйлу» белән шөгыльләнүче галим кеше булганлыгын аның «Болгари» тәхәллүсен — әдәби псевдонимын йөртүе раслый. Габделҗәббар үзе дә соңрак үзен укучыларга: «Бу фәкыйре Габделҗәббари зәгыйф, бине Габделмәҗид Болгари, нәхиф»,— дип тәкъдим итә.

Башлангыч белемне Габделҗәббар үз атасыннан ала. Белемгә һәвәсе күренеп торган сәләтле улын Габделмәҗит хәзрәт тагын да зуррак мәдрәсәләрдә укытып, нәселдән килгән руханилык дәрәҗәсен ышанычлы кулга тапшырырга уйлаган булса кирәк. Шуңа күрә соңрак без Габделҗәббарны мәдрәсәдән мәдрәсәгә күчеп йөргән халдә очраттабыз. Иң элек Чистай якларындагы Мораса, аннары бер-бер артлы Кизләү, Күркәле, Кышкар, Шонталы мәдрәсәләре...

Йирле — җирле (нигезле, тәпле).

Кызу холыклы, туры сүзле, ачы телле, үзе хакында югары фикердә торган һәм, иң мөһиме, үз ирегең югары бәяләгән егет, күрәсең, мәдрәсәдәге ишләре белән еш кына төрткәләшеп яшәгән, мөдәррис-халфәләре белән дә көтелмәгән низагъларга кергәләгән. Һәрхәлдә, шагыйрьнең мәдрәсә тәртипләре, кара муллалар хакындагы сатирик шигырьләреннән, әче телле эпиграммаларыннан шундыйрак мәгънә аңларга мөмкин. Бер мәдрәсәне ул үзе кул селтәп ташлап китсә, икенчесеннән аның үзен сөргәннәр шикелле. Шуңа күрә «нигә мине тиз итсындың», «туган илем ерак калды», белем эзли-эзли «җәяү йөреп сыйрак талды» дип күрсенгән егет, табигатенә хас рәвештә, үзен куучыларга йодрык та янап ала:

Тарсынма бер дә, китармен:
Җен, Иблистән дә битәрмен,
Үз белгәнемне итәрмен,—
Ки әгъля-гъәршә ашкындым!..

Кусагыз да, һич уфтанмам,
Язуымнан да тукталмам;
Котылмассыз барыбер сез,—
Әле болай гына калмам:

Төреп чалма-чапанларны,
Йөрсәм кыр-япанларны,
Онытмам сез наданларны,—
Әлеп салмыйча һич калмам!

Куылган шәкертнең үз дошманнарын наданлыкта гаепләве дә нигезсез булмый. Шул елларда диярлек иҗат иткән шигырьләренең берсендә ул:

Нәчә еллар гомер сөрдем,
Даим мәдрәсәдә тордым,
Җаһиллегем бүген белдем,—

дип, мәдрәсәдә җитәрлек белем бирелмәвен әйтә. Шулай да бу егет үзенең тырышлыгы, сәләтлелеге белән мәдрәсә белемнәрен, бигрәк тә гарәп һәм фарсы телләрен нык үзләштерүгә ирешә. Шуңа күрә, мәсәлән, Күркәле авылы хәзрәте гарәпчә бик әйбәт белгән Габделҗәббарны, авыл картларының коткысына карамастан, мәдрәсәдән куарга ашыкмый. Ә Орыда укыган чакта исә, уку йортын тотучы мөдәррис Габделҗәббарның үзен башка шәкертләргә гарәпчәдән дәресләр бирү эшенә җәлеп итә. Истәлекләр буенча мәгълүм бу хәбәрләрнең дөреслеген шагыйрьнең үзеннән калган бәхәссез документлар да раслый: шәкертлек чорында иҗат ителгән «Рисаләи-л-иршад», «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» әсәрләре Габделҗәббарның гарәпчә белән фарсычаны да, классик төрки язма телне дә бик яхшы белгәнлеген күрсәтә. Бу хәл исә аңа бай традицияле Шәрекъ әдәбиятлары хәзинәлегенә ачкыч бирә.

Кайбер мәгълүматларга караганда, Габделҗәббар чувашча, мордвача да аңлаша алган; көндәлек практикада кирәк дәрәҗәдә рус телен дә үзләштергән.

Шау-гөр килеп торган үзенчәлекле мәдрәсә тормышы булачак шагыйрьгә, үзе дә вакыт-вакыт җыр-такмаклар чыгарып йөрүче үсмергә, безнең әдәби дөньябыздагы икенче бер мөһим башлангычтан — халык авыз иҗаты ширбәтеннән дә мул итеп татып карау мөмкинлеген тудыра. Хәзер төрле яклап исбат ителгәнчә, безнең борынгы шәкерт бабаларыбыз, кайбер тенденциоз әдәби әсәрләрдә берьяклы гына сурәтләнгәнчә, гел догалар гына укынып ятмаганнар. Алар җырлаганнар, көлгәннәр, авыр язмышларының кайгы-моңнары баскан чакта әрнеп-үксеп елаганнар да. Шәкерт бабаларыбызның шундый гел

Әгъля-гъәршә — югарыга, күккә.

үзгәреп торучан халәтләре язма культурабыздагы бер күренешне — хәзер бездә «Шәкерт дәфтәре» дип исемләнгән әдәби фикер, әдәби жыенын формасын барлыкка китергән.

Кешеләр белән мөнәсәбәттә актив табигатьле Габделҗәббар шәкерт тә мәдрәсәдәге әшнәләренең куен кесәләрендә саклана торган шундый дәфтәрләр белән якыннан танышкан, күпләп танышкан. Аларда теркәлгән җырларны хәтеренә сеңдерә барган, үз дәфтәренә күчереп алган, үзгәртеп язган, яисә аларны үзе иҗат иткән шигырьләрнең тукымасына ук кертеп җибәргән. Димәк, шагыйрь соңрак күрсәтеп, «мәдрәсәдә гомерем заигъ үтте» дип әйтсә дә, Иске Кандалдан алып Орыга кадәр ул күргән мәдрәсәләр чынбарлыгы аның өчен бөтенләй үк эзсез үтмәгән.

Орыда чакта үзе дә укыту эшләрен башлап җибәргән Габделҗәббар, атасы чакыруын истә тотып, вакыты җитүен дә аңлап, туган авылына кайтырга була. Һәм аңар, ничә еллар мәдрәсәдә уку нәтиҗәсен рәсми кәгазь ярдәмендә раслау өчен Уфага барырга, Диния нәзаратында муллалыкка имтихан тотарга туры килә. Мәдрәсә белемен алган ул чор татар укымышлысы өчен бу бердәнбер юл иде; сәүдә һәм хуҗалык кәсебен сайламасаң, акыл белән эшләр өчен башка юллар ябык иде... Туган авылына ул 1824 елда кайтып төшә, атасына варис буларак, Иртуганда муллалык вазифасын үти, Шәфигулла дигән кешенең кызы Гөлстанга өйләнеп, бер-бер артлы балалар үстерә башлый.

Тормыш, бер карауга, менә шулай әкрен генә җайга төшеп китә. Тора-бара Габделҗәббар хәзрәтебез икенче, хәтта өченче хатынга да өйләнә. Чөнки, аяда нәрсә күрсәң, очканда шуны алырсың, дигәндәй, Габделҗәббар да үз мохитенең тәртип-кагыйдәләреннән, рухани ата-бабалардан кала килгән гореф-гадәтләрдән азат була алмаган (шәхеснең мохиттән, традициядән азат була алмавын ул үзе дә ике-өч урында: «ки козгындин туар козгын, ки каргадин туар карга»,— дип икърар итә...)

Ләкин Кандалыйның тормышы бары тыштан караганда гына шулай «җайлы һәм майлы» булган. Чынлыкта тынгысыз егет Габделҗәббарның ир-атлык, картлык чоры да шундый ук дәрәҗәдә борчуда, бимазалыкта, хәтта трагик рәвештә авыр хәлдә узган.

Иң элек, кытыршы холыклы Габделҗәббар хәзрәт үз авылындагы һәм күрше-тирәдәге байлар, руханилар белән сыешып алмаган. Соңгылары аны динсезлектә, тәүфикъсезлектә гаепләгәннәр. Моңа нигез дә «җитәрлек булган»: уена ни килсә, шуны турыдан ярып әйтүче, чәй-мәҗлесләрдә үзен иркен тотучы, җае-ние чыга калса, хәмер-шәраб белән дә шаяручы, өстәвенә (ни хурлык!) «хатын-кызлар белән азып», аларны мәдехләп «бәет-әшгар» язучы кешене гаепләр өчен күпме кирәк соң?! Үзләре андый эшләрне теләсәләр дә эшли алмый торган, шуңа күрә ул теләкләрен эчкәрәк куып керткән һәм мондый сыйфатларын көчлелек галәмәте итеп күрсәтергә тырышкан ханжалар, икейөзле ялган тәкъвалар өчен Габделҗәббар ишеләр күзгә кергән черки, ашка төшкән чебен кебек була инде. Боларга йәнә андый эшләрнең «ярамаганлыгына» ихлас күңелдән ышанучы «авыл картлары» да өстәлә... Атасы мөгътәбәр Габделмәҗит Болгари хәзрәтләре вафатыннан соң (1840 ел) Габделҗәббарга юнәлгән һөҗүмнәр аерата көчәеп киткән: элекке яшерен чыш-пышлар, гайбәтләр — ачык гаепләүләргә әверелеп, дәрәҗә, тәэсир өчен төркемнәр — фиркъәләр көрәшенә кадәр үсеп җиткән.

Шул рәвешчә үзенә мәчет мөнбәре (кафедра) һәм мәхәллә (коллектив) тапшырылу «ышанычын акламаган», мәгәр шәхси мәнфәгатен җәмәгать интересыннан өстен куйган Габделҗәббарның «персональ эше» барлыкка килгән; махсус «комиссияләр» төзелеп, бер-бер артлы утырышлар оештырылган. Ниһаять, каныккан төркемнең тырышлыгы

нәтиҗәсендә аны «эшеннән азат итү» хакында карар чыгартуга ирешелә һәм объективлык хакына дип, бушаячак урынга Габделҗәббарның якын туганы — аның турун энесе Әбүбәкер Әхмәт (Әхмәтнең атасы Ибнейәмин, аның атасы Биктимер...) тәкъдим ителә. Тик, Кандалый дошманнарының үкенечена каршы, карар бер тавыштан гына уза алмый — Габделҗәббар тарафында нык торучылар да табыла. Бу җәнҗал хакында К. Иртуган материалларында мондый мәгънәле документ китерелә: «...йәнә шул ук мәзкүр Ибнейабин Биктимер угылының нәселендән шул ук мәзкүр мәсҗеддә имам булды Әбүбәкер Әхмәт угылы, 1841 елда июннең 14 көненлә мөнбәрә чыкды, хотбә укыды. Җәмәгать икегә бүленде, (Әбүбәкергә каршылар) кире чыгып өйлә (намазы) укыдылар. Кире чыккан (лар): Мәннаф Ногъман угылы, Хисаметдин Мөхәй угылы, Мөхетдин Уразай угылы, Рысмәт Арслан угылы (вә) карт мелла Габделҗәббар...»

Көрәш дәвам иткән, әлбәттә. Габделҗәббар тарафдарларыннан Мөхетдин Уразов башлап, бер төркем 1843 елны авылның икенче (югары) очына яңа мәчет салдырып, ягъни мәхәллә аерып, шунда Кандалыйны куюга ирешкән. Көрәш шактый катлаулы булган, күрәсең. Кайбер мәгълүматларга, мәсәлән, «Мәгъшукнамә» китабындагы ишарәләргә караганда, Габделҗәббар берара үз авылыннан китеп торганга да охшый (китап авторының үзен Түгәлбай авылы мулласы итеп әйтүе шуңа ишарәле шикелле). Болай эзәрлекләнү, үзенә күрә «өнсез калу» фактлары Кандалыйның шигырьләрендә дә чагылыш таба:

Ходаүәндә, яна бәгърем:
Бу йирдә юк бәнем кадрем,
Чыдарга калмады сабрем,—
Сабыр бирсен үзе алла!

Дошманнарының әләге аркасында Кандалый төрмәдә дә утырып чыккан. Бу хакта бер кызыклы документ И. Бәхтиев материалларында китерелә. Анда, Кандалый кулы белән суфи Аллаһиярның «Сөбәтел-гаҗизин» исемле әсәренә гарәпчә язылган шәрех китабы азагында, мондый сүзләр бар: «Зур авырлыклар күрергә, ике ел буена төрмәләрдә утырырга туры килде, шул вакыт мена шул китабны яздым». Ләкин кайчан һәм ни өчен төрмәгә керүе күрсәтелмәгән (И. Бәхтиевнең архивларда эзләнүе дә нәтиҗә бирмәгән). Ихтимал, аның шулай кардәшләре һәм дус-ишләреннән аерылган чактагы настроениесе үз шигырьләрендә дә чагылыш тапкандыр:

Әйа йил, сән беләрмүсән?
Туганларым күрәрмүсән?
Хәбәрләр килтерәрмүсән?—
Дәйүб сорам ки анлардин.

Әйа йил, сән китәр булсаң...
Туганымны күрәр булсаң,
Дога дигел ки безләрдин...

1848—1849 еллар тирәсендә Габделҗәббарның башына тагын зур кайгылар төшә: язу-каләмгә сәләтле, бәет-мөнаҗәт чыгаруга да маһир, шулары белән атасына аерата якын улы Садретдин солдат хезмәтенә алына. 25 елга. Картая барган, гаиләсенең, мирасының үзеннән соңгы язмышы турында да ешрак уйлый башларга мәҗбүр булган ата кеше өчен бу — зур хәсрәт иде. Әле кайчандыр «кусагыз да, һич уфтанмам», «атамның каргышын алсам» да, «үз белгәнемне итәрмен!» — дип әтәчләнгән егет бүген, үз улы — йөрәк пәрәсе — яныннан киткәч, туган илләреннән аерылгач, ил-җир, туган туфрак һәм кардәш-ыру дигән төшенчәләрне яңачарак аңлап, фиракъльк — аерылу турында бөтенләй икенче рухта фикер йөртә башлый:

Иляһи, хәсрәтем агыр,
Ничек итим икән сабыр?
Газиз балам фиракъендин
Яныц бетде йөрәк-бәгырь!..

*

Яфраклар йәш гомер икән,
Ботаклары бала икән;
Фиракълык бер бәля икән,—
Бәгырь өзгән туганлардин...

Кайчандыр күбрәк гыйш-гыйшрәт, кәеф-сафа турында мавыгып җырлаган, шул юнәлештә виртуоз осталык күрсәтеп, чын шедеврлар тудырган элекке җилбәзәк шагыйрь хәзер инде аерылышу темасы буенча да куркырлы энҗедәй ялтыраган, тирән мәгънәле, нечкә хисле шигъри юлларны тудыра:

Бәнем эчемдәге нарым
Дөньяга чыгарсам барын,
Эретеп су итәр карын,—
Сабырлык бирсәнә, алла!

*

Бу бала хәсрәте түкде
Кара сачларем башымдин,
Инешләр ташды йәшемдин,—
Җитешмәсме әҗәлләргә?!

Вакыт-вакыт хәсрәтле карт төшенкелеккә дә бирелә:

Каләмем дә тая инде,
Ки яза алмай турыдан;
Яна бәгърем, сула йөзем
Авырлыклардин, гуредан...

Әмма муллалык дәрәҗәсе өчен барган көрәш кайгысы гына, солдатка киткән бала хәсрәте генә изми Габделҗәббарны. Аның гомум гаилә тормышы, хатыннары өчәү-дүртәү, бала-чагасы бишәү-алтау (кайбер мәгълүматларга караганда уникәү!) булуга карамастан, башка яклары белән дә исән-имин түгел иде. Чөнки хискә бай, мавыгучан чуар күңел язгы күбәләк шикелле: чәчәктән чәчәккә оча. Яшь чакта төрле авылларда кагылып-очрап узган кызлары болай торсын, бер мавыгып җыр иткән Гөлстаннан (биш бала анасыннан) да күңел суынган... Дөрес, Фәрхиҗәмал исемле кызга күңеле төшеп йөргән чакларда ул мәхәббәт хисеннән канатланып, дөньяны селтәп ташлардай җилкенеп ала, үзенең иң матур «әбъятларының» (бәйт-шигырьләренең) бер көлтәсен язып ташлый. Өйләнә. Тик тагын әллә ничек... Ахырында эшләр аерылышу белән очлана. Иске метрика кенәгәсендә 54 яшьлек карт башына ишелеп төшкән бу күңелсез вакыйганың бер шаһите, ягъни хәлгъ-намә язуы — аерылышу документы сакланып калган: «Бән, Габделҗәббар ибне Габделмәҗид, Фәрхиҗәмал исемле хатынымны 1851 елда 3 гыйнварда хәлгъ кыйлдым. Имза: *Габделҗәббар ибне Габделмәҗид...*» Ни өчен, кайчандыр уттай кызып, Фәрхи өстенә ялкынлы шигъри юллар яудырган шагыйрь хәзер шулай, салкын су тамызгандай, сүрән генә ике-өч сүз бөртеге сызгалаган?!.

Яшь хатыны Хәлимәгә килсәк, ул, кайбер ярым ирониле җыр кисәкләрен исәпкә алмаганда, эзсез генә үткән шикелле... Әмма күңелдә җуелмас эз калдырганы, хәтта йөрәкләргә, бәгырьләргә тирән җәрәхәттәй уелып кергәне — ул Сахибҗәмалга булган гыйшык хисе иде. Бәлки, шул Сәхибкә багышланган җырлар, аның тарафыннан кабул ителмәгәч, шулай адресаты үзгәртелгән хәлдә, икенче чибәргә — Фәрхигә күндерелгәндер? Бәлки, аның Фәрхигә өйләнүе дә Сахибҗәмалга «үч итү», шул югалтуны тутыру өчен булгандыр?..

Юкса бит, шул кадәр көчле ярату белән өйләнгән гүзәлдән шулай җиңел генә аерылмас иде... 54 яшьлек ирнең андый эшкә баруы авыр чир — йөрәк чире нәтиҗәсе генә булырга мөмкин, ягъни яратам дип уйлауның ялгышлыгын аңлау, чын мәгъшукасы Сахибҗамалдан һич тә күңел суынмау бәласе... Борынгы бабайлар:

Яңа йарлар табак-табак аш китерә,
Иске йарлар күзләрдин йәш китерә,—

дип юкка күрсенмәгәннәр...

Хәер, күрсенү, үкенү дигәнең Габделҗәббарның үзендә дә җитәрлек:

...Ки бән дәхи сәнең кеби
Һәуаландым, и җанкәй лә.

Үземгә тапмадым тиңне,
Тиң эстәп кашкалы-миңле,
Юлыкдым аңлы да миңле
Җүләр йарга, и җанкәй лә.

Отыйм дигәндә — отылдым.
Тотыйм дигәндә — тотылдым,
Соңындин көчкә котылдым —
Ки биш ел соң, и җанкәй лә!

Җитмәсә Садретдин дә һаман читтә.

Чыгамын дәхи сахрага,
Йөрәгем утдай янганга,
Тәзәррыгъ кыйлам аллага,
Сорап сези, әйа балам!

*

Бәнем ошбу аһым-зарым
Җиде кат күкләргә ашды,
Фиракъ уты бәни басды,—
Иляһи, бир сабырлыкны!

Баласын өзелеп сагыну, уңышсыз дип әйтерлек хәлдә бимазалы узып киткән шәхси тормыштан туган канәгатьсезлек, агай-эне һәм мәхәллә тирәсендәге ыгы-зыгылар — һәммәсе бергә өстәлеп, бер җилкә күтәрә алмаслык йөккә әверелгән. Нәрсә соң бу тормыш дигәннәре, кеше аны ни өчен ярата?

Бу тәкъдир дигәнең нидер?—
Изеп, йәнчеп, орыр йиргә;
Бары тыкмасын гүргә,
Китермәсен әҗәлләргә.

Кеше диган дә мәгълумдыр:
Йыгерер, егылыр, торыр,
Башыны ташлара орыр,
Сөрекмим дип әҗәлләргә...

Әмма барыбер «сөренә» ул әҗәлгә... Бу хәл 1860 елның май аенда була. Шагыйрь үзе яраткан айда:

Каты ташдай йөрәкләрне
Бу май ае эретәдер...

...Шагыйрь җисеме дә әлеге май аенда эреп туфракка сеңгән җирдә бүген мәһабәт гранит кабер ташы тора. Ул таш Иртуган — Иске Кандал зиратындагы башка ташлардан нык аерыла. Аны шагыйрь вафатыннан соң йөз елдан артык вакыт узгач куйганнар.

Ә бу йөз ел эчендә...

Шагыйрьнең үзе исән чакта ук: «Ни язганым, ни дигәнем — җәелеп беткән илләрдә»,— дип әйткән сүзләре аклансын өченме, ул үлгәч

Ульянов өлкәсенең Иске Майна районы Иртуган авылы зиратында Габделҗәббар Кандалыйга куелган кабер ташы. *М. Госманов фотосы, 1985.*

ук аның яшь хатыны Хәлимәкәй мәхрүмнең кулъязмаларын, дәфтәр-китапларын, И. Бәхтиев сүзләренә караганда, «кайсын кая сатып, туздырып бетерә...» Тик, «бу гашыйклык бәетләрен олугълар укый уңгайда» дигән сүзләрне аклагандай, бер матур «бәетне» Оренбургтагы С. Кукляшев дәреслеккә керткән: ерак Петербургтагы Х. Фәезханов исә борчулы кичләрендә аның бер кулъязмасы өстенә иелеп, китаптагы авыр аңлаешлы сүзләрне чүпләгән...

Шагыйрь исемен аның үз якташлары да онытмаган. Тынгысыз, кор күңелле, шул ук вакытта гаять нечкә хисле, зур руханилар, көчле байлар белән якалашудан тайчанмаган, мәгәр бала-чага һәм хатын-калачны яртеп чикләвеккә йөрүдән дә тартынмаган, ... назлаган кешесен майдай эретеп, әрләгән бәндәсен кырыкка яра алган «Габделҗәббар бабай», «Габделҗәббар абзый» хакында, бергә икене кушып дигәндәй, риваятьләр, сөйләкләр, мәзәкләр чыгара башлаганнар. Ул йөргән сукмакларны әле бүген дә беләләр... Тик бер якташының да, бер замандашының да «Габделҗәббар абзый» хакында үз күргәннәрен, үз белгәннәрен истәлек итеп язып калдырмавы, «яңа эз» буйлап аның әсәрләрен җыймавы гаҗәбрәк... Шуңа күрәдер, бәлкем, әлеге Иске Кандал зиратындагы кабернең дә урынын белмиләр — баягы таш чама белән генә куелган...

Риваятьләр, мәзәкләр белән бергә, кайчандыр шагыйрь «йибәргән дәфтәрләр» дә авылдан авылга, өлкәдән өлкәгә күчә барганнар. Казан, Сембер җирләреннән тыш, аларны Оренбург белән Төмән якларында да, Рязань белән Сергач, Малмыж белән Әстерханда да күчереп язганнар. Дистәләп, йөзәрләп-йөзәрләп күчергәннәр; исемен-атын әйтеп тормыйча да язганнар, өзек-өлешләрен генә йолкып алып дигәндәй, теркәп куйганнар. Кулъязма мирасыбыз башыннан әллә ничә кат үткән афәтле җил-давыллардан соң да алар күпләп табылалар әле. Башы-ахыры юк, кирәкле кием-тышлыгы булмаган гап-гади куен дәфтәрләрендә — шәкерт дәфтәрләрендә...

Әмма аларны эзләү, табу, барлау белән шактый соңгарганбыз!..

Әлеге май аеннан соң егерме ел узуга аның бер китабы — «Могъшукнамә» басылып чыга, язучысының исеме күрсәтелмичә генә. Шуңа күрә моңарчы аны Кандалыйга тулысынча «бирергә» дә теләмидек, йәнәсе анда аның аерым шигырьләре генә кергән... Аннары К. Насыйриның «Фәвакиһ-ел-җөләсә» китабы. Бары йөз ел узгач кына беренче җыентыгы...

Никадәр популярлык көче һәм нихәтле игътибарсызлык галәмәте бу мәгълүматларда! Нәкъ шагыйрьнең үз иҗатында гәүдәләнгән тирән каршылык — бергә үрелеп үскән караңгылык һәм яктылык шикелле.

III

Габделҗәббар Кандалый мирасында гәүдәләнгән зур каршылыкның табигатен дөрес аңлар өчен безгә шул иҗатта яктыртылган темаларга мөрәҗәгать итү дә җитә, әлбәттә.

Биография материалларыннан күренгәнчә, гел мәхәббәт җырчысы сыйфатында танылган Кандалый үзе үк көндәлек гамәлендә чын-чынлап сөешеп яшәү белән сыеша алмый торган принципларны алга сөргән: өч-дүрт хатын асрагач, димәк, берсен әрләп, икенчесенә янап дигәндәй яшәгән, алай да барып чыкмагач, «юлыктым аңлы-миңле җүләргә» дип, кичә мактаган кызын бүген, никяхлы хатыны булгач, өйдән үк куып чыгарган. Үзе шунда ук тагын бер кызга ялкынланып, ихлас мәхәббәт шигырьләре багышлаган, кызның баш тартуын чын фаҗига сыйфатында кабул иткән...

Нәрсә бу, саташумы, әллә бер чир-сырхау галәмәтеме?

Сорауга җавап бирер өчен шагыйрьне тудырган чор, аны кеше буларак тәрбияләгән даирә-мохит, һәм шул заманда мәхәббәт дигән күренешкә карата яшәгән мөнәсәбәтне дә бераз күзалларга ихтыяҗ бар.

XVI йөзнең икенче яртысыннан алып XVIII гасырның ахырларына кадәр безнең иҗтимагый тормышыбызда, әдәби фикеребездә хөкем сөргән торгынлык, бер урында таптану һәм бу күренешләрнең тирән социаль-иҗтимагый сәбәпләре турында монда тәфсилләп сөйләргә хаҗәт юк. Чөнки алар хакында Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгарига багышланган хезмәтемдә шактый киң һәм әтрафлы язылган иде. Андагы гомум фикерләрне аныклап, биредә шуны гына өстисе килә.

Мәгълүм булганча, урта гасыр дөньяви Шәрекъ әдәбиятларында мәхәббәт темасы төрле яклап өйрәнелгән, үзләштерелгән темаларның берсе һәм нигездә, тәсаууф (суфичылык) тенденцияләренең вакыт-вакыт ерып керүләрен исәпләмәгәндә, кеше хисен тасвирлаган, гадәти җир балаларының шәхси-интим мөнәсәбәтләрен җырлау аша кеше дигән хикмәтле затның бәхеткә хокукын яклаган чын гуманистик юнәлеш иде. Мисалга Фирдәүси, Кол Гали, Низами, Хәйям, Хафиз, Нәвои, Фөзули иҗатларын, Ләйлә — Мәҗнүн, Фәрһад — Ширин, Таһир — Зөһрәләр хакындагы җыр-дастаннарны күрсәтергә мөмкин. Әмма соңрак, мөселман илләрендә социаль-иҗтимагый торгынлык урнашып, иҗтимагый-әдәби фикердә дә регресс башланып, беренче планга гел дини әдәбият, аның дәвамы булган суфичылык әдәбияты чыккач, мәхәббәт дигән төшенчә дә нигездән үзгәрә, бөтенләй икенче эчтәлек ала. Нечкәлекләренә хәтле төпченеп эшкәртелгән тәсаууф тәгълиматы буенча кеше бары «Аңар» — Аллага гына гыйшык тотарга, «Аның» белән генә кавышу өчен омтылырга тиеш. Тәмам төгәлләнгән тәсаууф өйрәтүе буенча гадәти бәндәнең үзе кебек үк җир кешесенә мәхәббәт тотуы — түбән хискә бирелү ул... Шуңа күрә кайбер суфи шагыйрьләрнең әсәрләрендә очрый торган «ялкынлы мәхәббәт», «шашып сөю», «йар белән кавышуга ашкыну» кебек абстракт гыйбарәләр генә түгел, хәтта «алсу яңак», «серле күзләр», «бөдрә чәчләр» шикелле конкретрак сыйфатлар хакында сүз барган чакта да әлеге образлар ярдәмендә Алла яки аның «кыяфәте» тасвирланган булуын онытмаска кирәк. Бу юнәлеш безнең җирлеккә төрки телле бөек суфи шагыйрьләрдән Әхмәт Ясәви, Сөләйман Бакыргани әсәрләре белән килеп керә, Казан ханлыгы чорының атаклы тәсаууфчысы Кол Шәриф иҗаты белән үстерелә, аннары Мәүла Колый эшчәнлегендә дәвам итә. Алардан соңгы эреле-ваклы шагыйрьләр, шагыйрь булып үк җитмәгән каләм әһелләре тарафыннан язылган шул рухтагы истәлекләрне санап тормыйм, бары фарсы-таҗик телендәге тәсаууф әдәбияты үрнәкләренең, бигрәк тә «суфилар кыйбласы» буларак танылган Шәех Фәридетдин Мөхәммәд Гаттар әсәрләренең гаять киң таралуын искәртеп узу белән чикләнәм. Шуңа күрә әлеге чорларга караган язма әдәбиятыбызда, төгәлрәк әйткәндә, «профессиональ» әдәбиятта (әгәр язмага теркәлгән халык иҗаты үрнәкләрен, янсә адашып-ялгышып кына дигәндәй тудырылган берән-сәрән истәлекләрне исәпкә алмаганда) чын дөньяви мәхәббәткә багышланган әдәби әсәрләр бездә юк дәрәҗәсендә дип әйтерлек иде.

Кайчандыр тәсаууф тәгълиматы белән бер мавыгып алган, аннары иске чүпрәк киеп, «арпа ипие» ашап, яланаяк йөрүләрдән баш тарткан, соңрак аң-белемнәрне, һәр «ике дөнья» өчен дә кирәкле фәнгыйлемнәрне олылаган Габдерәхим Утыз Имәни иҗатында да чын мәгънәсендәге дөньяви мәхәббәт гәүдәләнми диярлек. (Җәяләр эчендә искәртеп узыйк: шагыйрьнең Хәмидәгә багышланган мәрсиясен бу урында карап тора алмыйбыз: анда шәхси мәхәббәт, сөекле хатынга карата ирнең интим хисләре тасвирланудан бигрәк, инсафлы хатын, мәрхәмәтле ана, түземчән, тәүфикъле, изге гомер юлдашы сыйфат-



«Рисаләи-л-иршад» поэмасының башы (Хөсәен Фәезханов коллекциясеннән, ҚӨИ ЛБ № В, 318 кулъязма).

лары мактала. Ә инде Утыз Имәкинең ир-хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтләгәндә порнографиягә тартымрак бер-ике әсәр язуын искә төшерсәк, аларның барлыкка килү сәбәпләрен дә аңлатып була. Ул фактлар асылда бу күренекле фикер иясенең мәхәббәт темасын башкара алуы хакында түгел, бәлки, чын сөю турында язу тәҗрибәсен җуя язган әдәби традициянең вәкиле буларак, шул теманы эшкәртүдә примитивизм юлына басуы, ягъни чын сәнгатьчелектән тайпылып, натурализм сукмагына кереп китү галәмәте иде.)

Габделҗәббар Кандалый татар әдәбиятына үзенең мәхәббәт тематикасы белән анда менә шундый бушлык, традиция өзелүдән туган тәҗрибәсезлек хөкем сөргән заманда килеп керде һәм бер гомер эчендә сирәк очрый торган зур казанышларга иреште. Ләкин аның бу юнәлештә узган юлы да турыдан гына бармады. Чөнки ул, әгәр аның малай-шалай чакта әйткән (безгә өзек-өзек килеп җиткән)

аерым өйрәнчек шигырьләрен, эпиграмма кебек парчаларын исәпкә алмасак, чын-чыннан әдәби әсәр язу эшенә традицион иске әдәбият — суфичылык әдәбияты позициясеннән чыгып тотына.

Габделҗәббар Кандалыйның беренче житди әдәби тәҗрибәләре сыйфатында хәзергә аның ике поэмасын — «Рисаләи-л-иршад» һәм «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» әсәрләрен исәпкә алабыз. Аларның яшь автор каләменә карауларын, күчермәдә тарихы күрсәтелмәгән булса да, түбәндәге фактлар ярдәмендә расларга мөмкин. Күчермә китап XIX йөзнең башы өчен характерлы күгелҗем-яшькелт кәгазьдән эшләнгән. Кәгазьдәге «1816» дигән су билгесе (филигрань) материалның фабрикадан кайчан чыгуын күрсәтә. Димәк, кәгазь, сатып алучыга барып житеп, кулъязмага әверелеп өлгергәнче ике-өч ел узып китсә дә, бу нөсхә 1820 ел тирәсендә күчерелгән булып чыга. Ә инде зур күләмле, авыр формалы ике әсәрнең беренчесе язылa башлауга кимендә ике-өч ел, аннары ике әсәр дә редакцияләнүгә, карадан акка күчерелүгә, ягъни хәзер Ленинградта саклана торган күчермә тәгәлләнеп бетүгә янә ике-өч ел кирәк булганлыгын исәпләсәк, әлеге әсәрләрдән «Рисаләи-л-иршад»ның язылa башлау вакыты 1815—1816 елларга, ягъни Габделҗәббарның 17—18 яшьләр тирәсендәге чорына туры килә дигән сүз. Кыскасы, мәдрәсә чорында, аңы формалашып өлгермәгән егетнең чәбәләнгән, эзләнгән чорында туа башлаган ул.

Әсәрнең исеме үк — «Рисаләи-л-иршад», ягъни «Тугъры юлга күндерүче китап» (алга таба «Рисалә» генә дип йөртербез) — аның дини-әхлакый юнәлештә булган дидактик характердагы поэма икәнлегенә ишарә итә. Әйе, озын гына кереш, махсус исемнәр белән тәэмин ителгән 28 бүлек һәм иң ахырда йомгак сыйфатында китерелгән бер мөнаҗәттән торган әсәр тулысынча диярлек кешеләрне изге нияткә, яхшы гамәлгә, димәк, «чын мөселманлыкка» чакырган «нәсаих»тан, ягъни үгет-нәсихәтләрдән гыйбарәт. Моны әсәрнең йомгак өлешендә автор үзе үк ачык әйтә:

Нәсаих әйләдем, и йар,
Сәнең өчен язып әшгар,
Кабул итеп, дотып юл вар,
Еракка китмәгел найа.

Нәсыйхәтләр сәңа хуб бад,
Боның исмен идәрсәң йад,
Атап «Рисаләи-л-иршад»,
Язылган ошбу дүрт пайа.

Нәсихәтләр, табигый, поэманың кереш өлешеннән үк башланалар, һәм алар нигездә «тегe дөнья» өчен бу дөньяда ук әзерлек күрергә, җәһаләттән (наданлыктан) качарга, шуңа күрә зарур гыйлемнәрне өйрәнергә, димәк, яхшы укырга чакыра (моны мәдрәсәдә укучы Габделҗәббарның шәкертләр аудиториясенә мөрәҗәгате дип тә кабул итик). Фикер ачык әйтелгән:

Гыйлемлек хәсълидә улгыл,
Җәһаләтдин үзең йолгыл,
Нәчек улса, җәһед кыйлгыл,
Ки, зинһар, калмагыл надан...

Ки, зинһар, калмагыл надан,
Дога алгыл ата-анадан...

Укый күргел кичә-көндез,
Гыйлемлек хәсълидә тиз-тиз.

Әшгар — шигырьләр.
Юл вар — юл белән бар.
Хуб бад — хуп, яхшы булсын.
Дүрт пай — дүрт аяк (дүрт юллы шигъри строфа).
Гыйлемлек хәсълидә — гыйлем эстәү юлында.
Җәһед кыйлу — тырышу.

Бәнемдик калмагыл гаҗиз,
Җәһаләтдә улып гъишйан...

Җәһаләтлек — яманлыкдыр,
Бере аның надәнлыкдыр,
Болардин һич яман юкдыр,—
Гизәрсәң гәр зәмин-асман.

Бу әйтелгәннәрнең гадәти абстракт мәгърифәтчелек өндәмәләре булмыйча, гыйлем дигән нәрсәне суфиларча аңлауның нәтиҗәсе икәнлеген шул ук керештәге дөньяви тормышка, хезмәткә карата булган кире мөнәсәбәт ачык күрсәтә:

Иген икмәк — икрер икмәк,
Мәшәкъкать-лә михән чикмәк;
Гыйлемлек — мәкъсудә йитмәк,
Һәр ике дөнйада әйкан...

Җәһаләтдин ерак качкыл,
Голүмең бабедин ачкыл,
Сәнеңдик дөнйада кач кол
Җәһаләтдә ирер гъишйан.

Җаһилләр лөкъмәсен капмак,
Төмам михнәт беләк тапмак;
Урак урмак, печән чапмак —
Михәнләр эчрә сәргәрдан.

Шулай итеп, шагыйрь фикеренчә, кара эш белән иза чикмәс өчен, наданлыктан качып, белемлелеккә омтылырга кирәк икән. Бер үк вакытта болар безгә таныш мотивлар: Кандалыйның әлеккән билгеле әсәрләрендә дә аның хезмәткә, шул хезмәт белән шөгыльләнүче гади кешеләргә түбәнсетеп караавы яхшы мәгълүм. Димәк, аның бу карашы шактыйрт чакта язылган беренче әсәрләрендә үк формалаша башлаган икән (шуңа күрә 17—18 яшьләрдә әйтелгән «иген икмәк — михнәт чикмәк» формуласын хәтерләп алыйк).

Менә шулай авторның уй-фикерләрен кыскача гәүдәләндергән озын керештән соң Габделҗәббар, әлеге фикерләрен дәлилләр өчен, әсәренең «иллюстратив» өлешенә күчә. Беренче бүлек сабыйларга үгет-нәсихәтләр бирүгә багышланган:

Сабыйлык төш кеби улыр,
Егетлек коШ кеби улыр,
Къарилык буш-тәһи улыр,—
Кайа мәгърифәтә, йездан!..

Сабыйлыкда уен кыйлсаң,
Шәйатингә муйын сонсаң,
Күнелмәссең бөйлә улсаң,
Егетлекдә улып сәкран...

«Егетлек вакытындагы нәсихәтләр вә вәгазьләр» дигән икенче бүлек бик тиз узачак яшьлек чоры белән масаймаска, гомерне әрәм уздырмаска дигән фикердән башланып китә:

Гъишйан — матди тормышка алданучы.
Гизәрсәң гәр зәмин-асман — җир-күкне гиясәң дә.
Михән — михнәтләр.
Әйкан — ап-ачык.
Голүм бабы — гыйлемнәр ишеге.
Кач кол — күпме кол.
Сәргәрдан — иза чигеп йөрү.
Къарилык — картлык.
Тәһи — мәгънәсез.
Йездан — ходай, тәңре.
Шәйатин — шәйтаннар.
Сәкран — исерек.

Егетлек йыл кеби үткәй,
Къарилык фи-з-зәман йиткәй,
Бакып күр халеңи: ниткәй,
Фәсадәтдә үтеп рузгяр.

Шул рәвешчә, автор «җиһанга салмагыл мәйли», явызлык эшләмә, хәйлә мәкердән кач, йөзең күрке белән масайма, эшсез йөрмә, шайтан коткысына бирелмә, — кыскасы, фани дөньядан биз (тәрек әйлә) дигән иңе бер үк фикерләрне кырык строфа (160 юл!) буена туглый.

Әгәр калган бүлек һәм бүлекчәләрне дә шулай тәфсилләп күзәтә башласак, сүз бик озакка китәр иде. Шуңа күрә аларны төркемнәргә бүлеп, тулаем һәм кыскача гына характеристика бирү белән канәгатьләник.

Өченче бүлектә кызларга әдәп-хәя, сафлык һәм гыйффәт саклау хакында киңәшләр бирелсә, дүртенчесендә хатын-кызларның «тәмле телле» булуы мактала. Урынлы һәм дөрес куллана белмәсәң, ди автор, тел кешегә иң авыр җәрәхәтләрне ясарга сәләтле.

Ирләргә адресланган бишенче һәм булдыксызлар хакындагы алтынчы бүлекчәләрдә дөньяга хирыслык сыйфатлары кире кагыла, автор бу начар сыйфатларның татар халкы арасында киң таралган булуы өчен ачына:

Хосусән Болгари йирләр
Җиһанә хирсъ улып дәр-зар...

Хатыннарга махсус вәгазьләр укыгач (җиденчесе), ирләрен рәнҗетүче «яман хатыннар» турында сигезенче бүлекне яза. Соңгысының төп эчтәлеге «яман хатын — зиндан» ул дигән сүзләргә кайтып кала.

Тугызынчы бүлектә дөньяның тиз үтүе, шуңа күрә мәгърурлык белән мавыкмаска дигән идея алга сөрелсә, унынчысында алдаргыч шәйтанның сыйфатлары сурәтләнә. Унберенче бүлектән алып уналтынчыга кадәр дөрес юлда булу, явызлардан качу, нәфескә иярмәү, аллага сыгыну, сабыр булу һәм башкаларны тугъры юлга өндәү хакында үгет-нәсихәтләр әйтелә.

Унҗиденче бүлек «Пирлек вә къарилык вакытындагы хәлләр вә нәсыйхәтләр» дип аталып, анда элгәрге бүлекләрдәге кебек үк оста эшләнгән, образлы һәм үткен юллар бар:

Кил, и къари, вакыт бик тар,
Данмән зәгыйфлек артар,
Фәналеккә сәне тартар,
Кичә-көндез китеп дәрман.

Акарды сакалың, башың,
Саны йөзгә йитеп йәшең,
Ки вармы дүгелән йәшең,
Идеп тәүбә мин-әт-тогъйан?1.

Бүлекнең мәгънәсе начар юлда кичкән йөз ел гомердән гыйлемлектә, тугърылыкта узган егерме яшь артык дигән фикергә кайтып кала.

Кеше гафләттә торган чакта «кинәт» үлем килүгә багышланган унсигезенче бүлек, үзенең үтә мистик рухта булуына карамастан, гаять көчле язылган өлешләрнең берсе, чөнки монда әлеге мәсьәлә буенча элгәрге суфичылык традициясендә ирешелгән әдәби казанышлар, сәнгатьчә чаралар киң файдаланылган. Автор риторик сораулардан як-

---

Фәсадәтдә үтеп рузгяр — көннәр бозыклыкта үтеп.
Пирлек — картлык.
Къари — карт.
Фәналек — фанилык, бетү.
Мин-әт-тогъйан — азгынлыктан.

тив һәм оста файдалана. Кайбер алымнары белән Кандалый «Җөмҗөмә солтан» авторы Хәссам Кятибне дә хәтерләтеп куя:

Хәмакъәт арханын чолгап,
Йөгердең дөньяны болгап,
Кил, имди ахир, эшең тап,
Дөшәр сәфәр сәнең дәр-раһ!

Гөнаһың күп — имәс сани;
Юарга тәүбәләр къәни?!

. . . .

Къәни шаһлар, къәни ханлар?—
Җиһанда ирделәр анлар,
Къәмусе вирделәр җаннар,
Чизи алмадылар әз-ан!..

Къәни Муса, къәни Һарун?
Къәни Фиргъәуен вә Къярун?! —
Хода кучәр кыйлып барын,
Мәкянә һәрберен һиҗран!..

Дөньядан һичнәрсә дә ала алмыйча китүчеләрне санаган чакта хан-падишаһлар, Фиргавен вә Каруннар белән бер рәттән ислам дине пәйгамбәрләре пантеонына кергән Адәм, Нух, Идрис, Исхак, Йосыф, Муса һәм Һаруннарның саналуы дөнья куучы, мәгәр үзе дә бер көн үлем каршына килеп басачагын аңлаган укучы өчен, һичшиксез, гаять кискен, хәтта тетрәткеч дәрәҗәдә ачы булып яңгырагандыр. Һәрхәлдә, бүлекнең ихлас пафос һәм зур осталык белән язылганлыгын инкяр итү хәзер дә мөмкин түгел.

Менә шулай бер-бер артлы «тормыш мизгелләрен» узып, әҗәл зарурияген аңлаган укучыны автор калган бүлекләрдә (19—28) җан бирү, димәк, ахыр заман житү, теге дөньяда яңадан терелү, сыйрат күперен кичү, оҗмахка яисә тамугка керү, кайда нәрсәләргә дучар ителү кебек хәлләр белән «таныштырып чыга». Бу бүлекләрдә ислам дине өйрәтүләренең «теге дөньяга» караган төп моментлары традиция рәвештә яктыртыла, чөнки авторның әллә ни ирекле кылана алмавы алдан ук хәл ителгән. Шулай да бер мәсьәләдә, әйтик, хур кызлары белән очрашуны тасвирлаган чакта, шагыйрь үзен мөгътәбәр җәннәт әһеленнән бигрәк әдәптә авызлыксыз җир бәндәсе шикелле тота башлый... «Кызлар тематикасы»ннан йәнә аллага күчкәч, шагыйрь тагын традицион вәгазьчегә әверелә, җәһәннәм хакында язган мәгълүм әйберләрне кабатлаудан узмый.

Ләкин, теге дөньяга ясаган әлеге дәвамлы «экскурсиядән» бушап, яңадан бу «фанига» кайткач, ягъни әсәренең йомгак-нәтиҗә өлешенә, «Мөнаҗат» (мөнаҗәтләр) дип исемләнгән соңгы бүлегенә күчкәч, безнең алга яңадан шушы «гөнаһлы җирнең» кайбер сыйфатларын дөрес тота алган үткен күзле, ачы телле Кандалый килеп баса. Әлбәттә, монда да ул начарлыклардан качарга өндәүче, укучыларны изге юлга, күнел пакьлегенә дәшүче дидактик булудан туктамый. Бер үк вакытта әле генә үзе артык игътибар итеп тормаска чакырган реаль тормыштагы типик гаделсезлекләргә карата протест белдерүдән дә тыела алмый:

Хәмакъәт — ахмаклык.
Дәр-раһ — юлга.
Имәс сани — санарлык түгел.
Къәни — кайда.
Къәмусе — барчасы.
Чизи — һичнәрсә.
Әз-ан — шуннан (тормыштан).
Мәкянә һәрберен һиҗран — һәрберен (тиешле) урынга күчә торган (итеп).

Гаҗәб хәйрат, гаҗәб вәйа:
Нәзар кыйлсаң бу дөнйаһа,
Фәкъырә игътибар һич юк,
Идәрләр гъиззәти байа...

Реаль тормыш гаделсезлегенә карата шулай, декларатив рәвештә булса да, бер нәфрәт белдереп алгач, шагыйрь: «Нәсаих әйләдем, и бир», — дип, югарыда күрсәтелгәнчә, әсәренең исемен атап, поэмасын тәмамлый.

Дөнья һәм ахирәт мотивларын шулай үреп бару, шул рәвешчә кеше алдына «гыйбрәт көзгесе» кую, акы ак белемгә, саф әхлякка, тугъры иманга һәм гаделлеккә өндәү — дөнья әдәбиятында шактый киң таралган ысул ул. Бөек Дантеның «Иляһи комедия»сен искә төшерик. Сюжеты безгә Иран әдәбиятыннан кергән «Җөмҗөмә солтан» поэмасындагы идеягә дә игътибар итик. Кыскасы, дини сюжетлар, иляһи мотивлар белән файдаланып, бу «фани дөньяны» төзәтергә омтылу, матди тормышны тәртипкә салу юлында бары идеяне генә корал итеп алу, ягъни гаделсезлеккә җитү мөмкинлеген гел «иман пакьлеге»нә ирешүгә кайтарып калдыру — феодализм идеологиясе хакимлек сөргән чорлардагы шагыйрьләргә, әдипләргә, бигрәк тә тәсаувыф юлындагы каләм ияләренә хас, уртак сыйфат, гомум күренеш иде. Биредә мәсьәлә алымда түгел, ә максатта. Максатны кем нәрсәдә күргән — бу инде икенче проблема...

Ләкин шунысы да бар әле. Элгәрге фикер ияләренең — галим һәм әдипләрнең мирасларын тикшергән чакта максат һәм чараларны ачыклау гына җитми, бәлки **н ә т и җ ә л ә р н е д ә**, икенчерәк итеп әйткәндә, әсәрдән әсәргә, шәкестән шәхескә, буыннан буынга күчә барган, һәр күчеш саен үзгәрә, үсә бара торган төп эчтәлекне, төп кыйммәтне дә ачыкларга, истә тотарга кирәк. Элеккедән килә торган рухи дөнья ядкарьләрен бәяләгән чакта без менә шушы таләпне беренче планга куярга тиешбез. Чөнки максат һәм чаралар фикер ияләренең субъектив омтылышларын чагылдырсалар, әлеге нәтиҗәләр иҗтимагый фикер үсешенең объектив казанышлары, яисә чигенешләре хакында сөйлиләр.

Әгәр Кандалый иҗатының, дөресрәге, «Рисаләи-л-иршад» поэмасының әһәмиятен билгеләгән чакта мәсьәләгә шушы күзлектән карасак, гомум мирас фонында әлеге истәлекнең урыны дөресрәк табылып, аның объектив әһәмияте күренәчәк.

Мондый алым әсәрнең идея-эчтәлеген, иҗтимагый кыйммәтен билгеләүдә генә түгел, бәлки аның әдәби дәрәҗәсен бәяләү, шул дәрәҗәнең табигатен ачыклау өчен дә зарур. Моның шулай икәнлеген без шагыйрьнең башка әсәрләрен, җөмләдән әлеге Ленинград кулъязмасындагы икенче поэмасын күзәткәндә дә күрербез.

Сүз шартлы рәвештә «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» дип аталган зур күләмле әсәр, дөресрәге, аның сакланып калган өлеше хакында бара. Безгә тулы яки өлешчә килеп җиткән унбер бүлекнең эчтәлегенең «Рисалә»не тәмамлаганнан соң Габделҗәббар шәкертенең тагы да зуррак һәм җаваплырак эшкә тотынуын абайлап була. Чөнки бу инде, «Рисалә» кебек, чагыштырмача гадирәк дидактик әсәр генә түгел, бәлки төп сюжеттан яңа сюжетлар үсеп чыга торган күп тармаклы, реальлеккә якын вакыйгаларны риваятьләргә үреп бирә торган, автор чигенешләре белән тәэмин ителгән катлаулы эпик-фәлсәфи кыяфәттәге китап.

Хәйрәт — хәйран калу, аптырау.
Вәйа — вай дип әйтерлек.
Нәзар — карау, күз салу.
Гыйззәти байа — гыйззәтне байга.

Әсәрнең башыннан, урталарыннан һәм ахырыннан шактый өлеше югалганга күрә, аның автор тарафыннан куелган төгәл исеме сакланмаган. Шулай да әсәр үзәгендә тәкъвалек хакына шаһлыктан бизгән Ибраһим Әдһәм торуын һәм поэманың үзендә аның жанрына, исеменә карата ишарәләр булуын («Бер кәтабәт кыйссалардин әйләгел», «күрде кыйссадин бу фәкъир күп көтөб...») игътибарга алып, аны «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» дип атарга мөмкинлек табылды (кыскалык өчен алга таба «Кыйсса» дип кенә йөртелер).

Икешәр юллы бәйтләр — классик касыйдә (поэма) рәвешендә язылган «Кыйсса» зур күләмле эпик әсәрләргә хас салмак тондагы мөкаддимә — кереш (безнең күчермәдә керешнең икенче өлеше) белән башланып китә:

[illegible] тәсълийәдин фаригъ улам *,
Максадым сөйләмәгә шаригъ улам;
Бәгъзы йаран фәкъире, бәгъзы нас **
Әйләделәр бу гъәрибдин илтимас:
«Бер кәтабәт кыйссалардин әйләгел,
Һәр нә гъәҗаибдин улса, сөйләгел;
Төрки улсын ул кәтабәте шәриф,
Самигъең дили улса ирде ләтыйф».
Бу фәкъире Гъәбделҗәббари зәгъиф
Бине Гъәбделмәҗид Болгари, нәхиф,
Күрде кыйссадин бу фәкъир күп көтеб,
Деләйүр язмага аны җәмгъ итеб.
Нә [illegible] һәм нә күрдем бән фәкъир,
Язайым яхшы-яманыдин кәсир.
Ләкин идә ул ходаүндә мәдәд —
Ибтидадин интиһайә ул самәд ***.

Әсәрнең төп өлеше борынгы Бәлх солтаны Ибраһим Әдһәмнең (874—875 елларда үлгән) — Шәрекъ әдәбиятларында үзенең акылы һәм гаделлеге, диндарлыгы белән легендага әверелгән традицион геройның — хакыйкать эзләү максаты белән тәхетен, бөтен мал-милкен ташлап, иске-москыга төренеп, ил гизеп китүен тасвирлаудан башлана.

«Алла ризалыгы» өчен гъәриблектә шактый гомер кичергәч, ул бер көнне акылы һәм гадилеге белән падишаһлар арасында дан казанган хәлифә Һарун әр-Рәшид иленә юнәлә. Юлчы Һарун падиша яшәгән шәһәргә җитәрәк караңгы төшеп, шәһәр капкасы ябылудан төнне ул къәлга тышында уздырырга мәҗбүр була. Шунда аны төнге дозор тотып ала:

Кәлде дузур, дотды кич берлән бони:
«Нә кеши сән? Нә идәрсән бу дени?»

Начар киемле Ибраһимне карак (дөзд) дип уйлаган сакчы аны кулга алып, этеп-төртеп, падиша янына китерә. Һарун әр-Рәшид исә, сораша-белешә торгач, тоткынның зур акыл иясе [illegible] аңлый һәм, ялган сөйләп, шундый кешегә җәбер күрсәткәне өчен дозорның үзен суктырып, Ибраһим Әдһәмне табынга чакыра. Хикәя ителгән сюжетның мәгънәсе: патшага тугърылыклы булырга теләүче җәза алды, һәм аны патша үзе кыйнатды -- дөресме бу? Һарун белән

---

* Юлның мәгънәсе: (Алланы) мактау белән тыныч торудан азат булдым.
** Юлның мәгънәсе: бу фәкыйрьнең кайбер дуслары һәм кайбер [illegible].
*** Ике юлның мәгънәсе: ләкин автор үзенә ходайның [illegible] итә, чөнки ул (барлык) башлангычлар һәм тәмамлаулар өчен мәңгелек.

Шаригъ — юл башлаучы.
Илтимас — үтенеч.
Кәтабәт — [illegible]
Самигъең дили... ләтыйф — тыңлаучыларның күңеленә хуш.
Нәхиф — көчсез, хәлсез.
Көтеб — әсәрләр, китаплар.
Деләйүр — теләр.
Җәмгъ иту — җыю.
Кәсир — күп.

Ибраһим арасында шул рәвешчә бәхәс булып ала. Хәерче дәрвишнең акыллына, тапкырлыгына сокланган патша аны үз янында калырга һәм сохбәт-әңгәмәдәш булырга чакыра. Ләкин үзенең кем булуын, нишләп йөрүен яшермәгән Ибраһим Әдһәм Һарун әр-Рәшид тәкъдим иткән палудәдән дә баш тартып, дәрвишлек юлын дәвам иттерә, чөнки ул рәхәттән, ләззәттән ваз кичкән, чөнки ул хакимнәргә баш иеп яшәргә теләми...

Ибраһимның шөһрәте Йәмән мәмләкәтенә аның үзеннән элегрәк барып җитә: фәлән кәрван белән Ибраһим Әдһәм килә икән дигән хәбәр бөтен шәһәр халкын кузгата. Моны сизгән тыйнак дәрвиш, кәрваннан бүленеп калып, шәһәргә аерым гына керә. Изге кунакны каршы алырга җыенган халык аның хакында Ибраһим Әдһәмнең үзеннән сораша башлый. Ул исә, үзенең патша булганлыгын оныткангa, Бәлех шаһын шулай кызыксынып сорашуларына гаҗәпләнә кала. Изге солтанга карата шик белдергәне өчен әлеге халык Ибраһимны кыйнап ташлый. Шулай итеп, бу юлы ул үзен хөрмәтләүчеләрдән җәбер күрә...

Ибраһим Әдһәмнең тәхеттән ваз кичүенә күп еллар уза. Ул һаман ил гизеп, каңгырып йөри. Тамагы ачса, үз акчасына ризык сатып ала, акчасы булмаса, ризыкны агач башмакларына алышып ала, бушлай бирелгән ризыктан баш тарта. Чөнки иманын тимер тәңкәләргә сатканчы, Аллага сыену, Алла исемен олылап мөнаҗәтләр әйтү аның өчен кыйммәтрәк.

Көннәрдән бер көн Ибраһим Әдһәм бер зур мәҗлес өстенә килеп чыга һәм, аны-моны уйламыйча, әйванда (верандада) утырган казый янына килеп җайлаша. Йолкыш бәрәүнең үз янына утыруыннан гарьләнгән казый аны түбәндә торган ярлылар арасына куып төшерә. Ләкин шунда ук казый һәм башка хәлләләр җыелган әлеге әйванда бәхәс куба, беркем дә аны чишә алмый. Мәсьәләне бары теге йолкыш карт хәл кыла. Шуннан соң киң җәмәгатьчелек кенә түгел, хәтта әлеге тәкәббер казый да, дәрвишнең хакимлеген икърар кылып, башыннан чалмасын салып бирә. Хикәянең морале:

Къәдер-гъиззәт мал-милек белән имәс,
Һәм мәратибләр бозоргилән имәс *.

Моннан соң да Ибраһим Әдһәм дәрвишлектә гомер кичерүен дәвам итә. Һәрбер бәхәс купкан җирдә бу Гадел карт хәзер була, авыр фәлсәфи сорауларга да дөрес җавап бирә.

Әмма, кызганычка каршы, әсәрнең нәкъ шушы төшендә, сюжетның үзенә күрә кульминацион ноктасына ирешкән җирендә, текстның зур гына өлеше югалган. Хәзер 40 һәм 41 дип тәртип саннары сугылган кәгазьләр арасыннан иң кимендә берничә бит төшеп калганлыгы бәхәссез. Чөнки моңа кадәр Ибраһим хакындагы хикәя өченче затта сөйләнгән булса, моннан соң сүз беренче затка күчә, ягъни автор үзе персонаж рәвешендә сәяхәт итә һәм хикәяли башлый.

Өзелүдән соң сакланып калган текстта сүз бер Болгар җире кешесенең «тәгълим къәсде», ягъни белем алу максаты белән чит җирләргә барып чыгуы сөйләнелә. Шулай ил гизеп, төрле кешеләр белән очрашып йөргәндә, ул бер сөргеннәр (рәндәләр — качаклар) авылына кереп куна. Алар юлчының кем булуы, нишләп йөрүе хакында сорашалар, хәтта бәйләнә дә башлыйлар. Вакыйга түбәндәгечә сурәтләнеп китә:

---

* Юлның мәгънәсе: һәм мәртәбәләр зурлык (олысыманлык) белән түгел.
Палудә — җимеш суы кушып ясалган желе.

Рәндәләр ул кичә безне сәмгъ улып,
Собх улачак килде бонлар җәмгъ улып.
Диделәр: «Сезләр къәйу йирлек кеши,
Ошбу йирдә нә идәрсез, нә эши..?»

Сорауга каршы хикәяче үзенең Болгар җиреннән, Кандиле авылыннан икәнлеген әйтә:

Дидемез: «Болгари йирлекмез, фәлян,
Къәндил иллек, сүземездә юк ялан».

Рәндәләр исә, моңа ышанмыйча, Кандиле илгизәреннән «гъәләмнамә», ягъни таныклык кәгазе таләп итәләр. Ләкин таныклык булмый. Егетнең аягына кешән-богау салалар. Нәкъ шул вакытта, аның бәхетенә, бер бай сәүдәгәр килеп чыгып, «бони беләрем», дип, тоткынны йолып ала, аякка кешән салучының үзен сүктыра.

Бәладән котылган Болгар җире егете икенче вакыйгага күчеп, үзенең иске-моски киемдә килеш халык күп җыелган бер гаед намазында вәгазь сөйләүче имам белән бәхәскә керүен хикәя итә башлый... Ләкин тагын текст өзелә...

Моннан соң сүз нәфескә бирелеп дөреслеккә хыянәт иткән, гыйлемнән йөз чөергән һәм шунысы белән падишаһларга якынлашкан берәү хакында бара, аның әлеге начар фигыле хөкем ителә:

Галим үз къәдрене бәйгә тәрк идеп,
Симе-зәр чөн нәфсен тәхәррек идеп *,
Галим улмады кем, улды ул бә-зир,
Лик галим улды шаһә хассе вәзир **.

Хикәянең, ихтимал, бөтен әсәрнең фәлсәфәсе түбәндәге сүзләргә кайтып кала:

И бәрадәр, тәрке гъизз-у-җаһ ит,
Һәм сакыйнгыл, тәрке къәрбе шаһ ит:
Къәрбе солтан уладыр җанга бәля,
Улмагыл боның белән сән мөбтәля!

Ягъни: «И туган, шан-шәрәфне, югары дәрәҗәне ташла һәм үзең теләп шаһларга якынлыктан кач, (чөнки) солтаннарга якынлык — җанга бәла, андый бәла чиренә сабышма!»

Бу өзекнең әһәмияте, беренчедән, әсәр эчтәлегенең төп идеясен, автор фәлсәфәсен ачудан тыш, безгә дефектлы хәлдә килеп җиткән кулъязманың төрле әсәрләр өзегеннән түгел (хикәяләүче затлар алмашынуы шундый фикернең туусы да ихтимал), бәлки бер поэманың начар сакланган өлешләреннән гыйбарәт икәнлеген раслый. Өстәвенә, моннан соң китерелгән мөнаҗәтләр дә мәгънә һәм сюжет бердәмлегенә зарар китермиләр: аларда да сүз, нигездә, тугъры юлга төшү, гаделлек эстәү, моңа ирешү өчен байлыктан, властьтан баш тарту хакында бара. Мөнаҗәтләрнең берсендәге «Йа иляһи, ярлыка Габделҗаббари» дигән сүзләр әсәрнең соңгы өлешенә җитүгә ишарә итә.

Икенчедән, әсәрнең гомум юнәлешен, фәлсәфәсен чагылдырган әлеге «къәрбе солтан уладыр җанга бәля» фикере Габделҗәббарның үз оригинал уй-хыялы түгел, бәлки классик суфичылык әдәбиятында әллә кайчан, әллә ничә мәртәбәләр кабатланган традицион фикер. Төгәлрәк әйткәндә, монда өйрәнүчек шагыйрь югарыда исеме бер кат аталган бөек суфи Шәех Фәридетдин Мөхәммәд Гаттарның мәшһүр «Пәнд-намә»сендәге мәгълүм юлларны кабатлый:

---

* Юлның мәгънәсе: Алтын-көмеш өчен нәфесне аздырып.
** Юлның мәгънәсе: Ләкин ул галим шаһка лаек вәзир булды.
Сәмгъ улып — ишетеп.
Собх улачак — иртә белән.
Җәмгъ улып — җыйнаулашып.
Тәрк итү — ташлау, калдыру.
Бә-зир улу — түбән төшү.

Къәрби султан атәш-и сузан буд,
Ба бәдан әлфәт һәляк-и жан бул.

Ягъни «Солтаннарга якынлык ут кебек көйдерер, начарлар белән дуслашу җанны һәлак итәр».

Габделҗәббар шәкерт иҗатында Гаттар тәэсиренең эзләре шушы бер мисал белән генә чикләнми. «Кыйсса» гына түгел, «Рисалә»дә дә шундый эзләр ярылып ята. Мәсәлән, дөньяви нәфесне әрләүгә багышланган уничәнче бүлекнең ахыры болай тәмамлана:

Гъәҗүзи зән ки бу дари,
Бизәнеп зиннәти дари,
У къәри һәркемә карый,—
Һәлякәтдә вирәсәр җан.

Къәрилыкда бизәнүбән,
Җәуан кеби дөзәнүбән,
Йөрер сәни күзәдүбән,
Һәляк итмәк өчен бер ан.

Деләр бер көндә бер ирне,
Деләйүр таңда — дигәрне,
Юк идә, сачу зәһәрне.—
Кичәдер даре дөнйадан.

Ягъни: «Бу дөнья карт хатындыр (карчыктыр), ул дөнья малы белән бизәнсә, һәркемгә карый — җанга һәлакәт бирер өчен. Карт хатынча бизәнү белән, яшь кешедәй тезәнү белән, йөрер сине күзәтү белән,— бер вакытны һәляк итәр өчен. Ул һәр көнне (кичне) бер ирне теләр, таң аткач (иртәгесен) башкасын теләр; зәһәрен чәчә-чәчә (һәммәсен) юк итә-итә, ул шулай бу дөньядан кичәр».

Гаттарның «Пәнднамә»сендә әлеге фикернең сөземтәсе болайрак яңгырый:

Зал-и дунйа чун гарус-и араст-аст,
һәр ду рузи шуй-и дигәр хаст-аст.
Ләб бә пиши шуй-и хәндан маконәд,
Пәс һәляк әз-зәхми дәндан миконәд.

Ягъни: «Дөнья карчыгы бизәнгән киленчәк шикелле: һәр икенче көнне башка бер ир теләр. Ире алдында иреннәрендә елмаю булыр, аннары (ирен) теш җәрәхәтеннән (тешләп) һәляк итәр».

Әгәр заманасында безнең мәдрәсәләрдә киң таралып, фарсы теле буенча Сәгъдинең «Бостан»ы кебек ук дәреслек-хрестоматия хезмәтен үтәгән (шуңа күрә археографик экспедицияләр вакытында кайбер елларны дистәләп табыла торган) әлеге «Пәнд-намә» китабын игътибар беләнрәк актара башласак, андый уртаклыкларны күпләп табачакбыз; боларга турыдан-туры тәрҗемәләп күчерелмичә, иҗадирак рәвештә алынган фикерләрне дә өстәсәк, мисалларның саны бермә-бер артачак.

Әгәр безнең элекке мәдрәсә репертуарыбызда булган фарсыча башка тәсаууф китапларын да актара башласак, «Рисалә» белән «Кыйсса»ның өстәмә чыганаклары да ачылуга шик булмаячак. Моның шулай икәнлегенә «Кыйсса»ның керешендә Габделҗәббарның үзе ук ишарә ясый: «Күрде кыйссадин бу фәкъир күп кәтөб, деләйүр язмага аны җәмгъ идеб». Ә «бер кәтабәт... әйләгел» дип үтенгән дус-ишләре һәм укучылары исә автор алдына, аның чыганак-үрнәкләре башка телләрдә булуын белгәнгә күрә, «төрки улсын ул кәтабәте шәриф» дигән шартны да куйганнар икән...

Кыскасы, монда анализланган һәр ике поэма да ахыр чиктә суфичылык рухы белән тирәннән сугарылган, бер үк вакытта идея юнәлеше буенча әле мөстәкыйльлеге формалашып житмәгән яшь каләмнән чыккан өйрәнчек әсәрләр икән.

Әлбәттә, «Рисалә» белән «Кыйсса»да, аларның идея ягыннан чикләнгән әсәрләр булуына карамастан, охрави (ахирәткә бәйләнешлелек) мотивлар белән дөньяви мотивларның үзара үрелеп, ярышып барган моментлары да шактый. Мәсәлән, яхшы гамәллелек, аң-белем һәм гыйлем, бу дөньяда зарур булган кебек, «теге дөньяда» да кирәк булса, наданлык һәм җәһаләт, ачкүзлелек һәм бозыклык бу дөньяда ук зарарлы икән! Мисал өчен әлеге физик хезмәткә кимсетеп карау чагылган шигырьләрне искә төшерик. Әгәр шул мотив белән югарыда Гаттардан китерелгән соңгы мисалга тагын бер мөрәҗәгать итеп карасак (туймас нәфес, аздыручы көч символы итеп хатын-кыз — бозык карчык образы алынуын искә төшерсәк), соңгы дәвер Кандалыйның көндәлек тормышында һәм иҗатында гәүдәләнгән ике тискәре сыйфатның — кара муллаларча күп хатынлылык белән гади хезмәткә җирәнеп карауның — анар нарасый бала һәм шәкерт чагыннан ук сеңеп калган тәрбиядән килүен аңларбыз.

Әйе, гадәти дөнья интересларына, җөмләдән хуҗалык эшләренә җирәнеп карау — «фани дөньядан» йөз чөерү — тәсаувыф тәгълиматының төп идеяләреннән берсе булса, аның орлыклары башта Габделҗәббар шәкерт аңында да уңдырышлы җирлек таба. Чөнки атасының (Габделмәҗит Болгари хәзрәтләренең!) гел акыл эше белән шөгыльләнүен күреп үскән, шул мөнәсәбәттә китап белән эш итүчеләргә табигый хөрмәт хисендә тәрбияләнгән, уку чорында белем һәм сәләт ягыннан башка яшьтәшләреннән күпкә өстен торуын үзе үк яхшы тойган Габделҗәббар аңында әлеге «мажик» хезмәтенә карата тискәре мөнәсәбәт орлыгы гомергә житәрлек тирән тамырлар җибәрә.

Габделжәббар Кандалыйның көндәлек тормышта хатын-кызга карата сәеррәк мөнәсәбәте дә шул ук рухани гаиләсенең, суфичылык хөкем сөргән иске мәдрәсәләрнең тәгълим-тәрбияләре нәтиҗәсе дип карарга кирәк. Ояда ни күрсәң, очканда шуны алырсың дигәннәр. Моңа сәләтле кешеләрдә еш рак очрый торган эгоистик омтылышлар, үз интересын абсолютлаштыру сыйфаты да өстәлгән, әлбәттә.

Шулай итеп, бая алга килеп баскан сорауларның берничәсенә өлешчә җавап табылды шикелле. Ләкин бу «табылган» дип исәпләнгән җавапка каршы яңа сорау да калкып чыгачак:

— Алайса ни өчен андый «начар тәрбия»ле «эгоист» берәү (үз тәгъбиренчә әйткәндә, «үзсүзле мишәр»!) хатын-кызның гүзәллеген җырлауда, гашыйкның сөйгән ярга карата хисен олылауда, аның мәхәббәттә бәхеткә хокуклы булуын даулауда искитәрлек ихласлыкка, кабатланмас сәнгатьлелеккә ирешә алган?!

IV

Әмма хәзергә, әлеге сорауга җавап эзли башлаганчы, шагыйрьлек «җебе» кагылып өлгергән Габделҗәббар шәкерт алган гаилә һәм мәдрәсә тәрбиясендәге башка житешсезлекләргә дә тукталу зарур. Чөнки бу гомумрәк мәсьәлә шагыйрь үсеп чыккан мохитне төгәлрәк күзаллarга ярдәм итә. Ләкин, гомум мәсьәлә дигәч тә, материаллар эзләп читләргә китеп йөрмибез, бәлки шул ук «Рисалә» белән «Кыйсса»ны икенчерәк яссылыкта җентекләбрәк карый башларбыз.

Анализлана торган истәлекләрнең сәнгатьчә әдәби сыйфатлары да кызыклы. Югарыда китерелгән өзекләрнең кайберләреннән моны укучылар да беркадәре шәйләп өлгергәннәрдер инде. Шулай да, алда чыгарылачак нәтиҗәләр нигезлерәк булсын өчен, тагын бер-ике мәсьәлә буенча фактлар китерик

«Рисалә», югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә һәм автор үзе образлы итеп әйткәнчә, «дүрт аяк», ягъни дүрт юллы строфа белән язылган. Строфадагы һәр юл сигезәр иҗектән тора торган бу шигъри форма Кандалыйның башка әсәрләрендә еш очрый. Гомумән,

дүртьюллыклар белән эш иткәндә, шагыйрьнең иң яраткан рифмалау системасы ул, нигездә, *аааб, вввб, гггб*... рәвешендә янәшә строфаларны уртак рифма белән үзара «ябыштырып», ягъни бер «җепкә тезеп» барудан гыйбарәт (мондый «үтәли» рифманы шартлы рәвештә б-рифма дип атыйк). Вакыт-вакыт автор дүртьюллыкларга (яки аларның аерым төркемнәренә) «автономия» бирә, ягъни *еeек, әәәк* тибындагы рифмалардан да файдалана (ара-тирә дигәндәй *абаб*, яисә *аабб* рәвешендәге дүртьюллыклар да очрарга мөмкин, ләкин мондыйлары система түгел). Шундый ук эзлекле күренеш «Рисалә»дә саклана. Әйтик, поэманың кереш өлешендә әле саналган формаларның барысы да диярлек очраса, сабыйларга нәсихәт сыйфатында әйтелгән һәм 18 строфадан торган беренче бүлекнең баштагы ундүрт строфасы — *аааб вввб*, калган дүрте исә *гггд, еeед* шәкелендә оештырылган.

Егетләргә нәсихәт итеелгән 40 строфалы икенче бүлектәге дүртьюллыклар да, рифмалары буенча, түбәндәге дүрт төркемгә бүленә: *аааб* (1—5 строфалар), *вввд* (6—13), *ггги* (14—26), *дддр* (27—40). Поэманың башка бүлекләрен дә шулай анализлый башласак, бу системаның бөтен әсәр өчен характерлы булуы, димәк, Кандалыйга гомумән хас дигән әлеге форманың да егет чагында ук шагыйрь тарафыннан үзләштерелгән икәнлеге раслана.

«Кыйсса», югарыда бер күрсәтеп узылганча, бәйтләр — икеюллыклар ярдәмендә язылып, *аа, бб, вв* рәвешендә рифмаланган. Һәр юлы 11 иҗектән торган бу төр шагыйрьнең башка әсәрләрендә күп очрый.

«Кыйсса»дагы икеюллык строфаларның рифмалары махсус анализга мохтаҗ булмасалар да, «Рисалә»нен кайбер үзенчәлекләре игътибарга лаек. Мәсәлән, *аааб* тибында строфаның беренче өч юлындагы рифмалар һәр конкрет дүртьюллыкның индивидуаль бизәкләре булса, башка строфаларның да ахырларында кабатлана баручы б-рифма бөтен бүлек, яисә бүлек эчендәге строфалар циклын характерлый. Чама белән төрлеләндереп кулланган чакта мондый алым шигъри строфаларга кабатланмас бер төзеклек, эчке бердәмлек бирә. Моның шулай икәнлеген җитлеккән Кандалый-шагыйрьнең «Сахибҗәмал»ында күрергә мөмкин. Әмма «Рисалә»гә карата моны әйтеп булмый. Чөнки әлеге б-рифманың кирәгеннән артык җәлеп кылынуы һәм авторның форма белән чамасыз мавыгуы аны сүзләрдән ясалма, формаль рәвештә файдалануга, күп очракта аңлаешсыз һәм махсус үзгәртелгән сүзләргә мөрәҗәгать итүгә китергән. Мәсәлән, аның иң яраткан рифмаларының берсе — *ан* иҗегенә беткән сүзләр (*игълан, мәкян, имкян, заман, фәрман* кебек). Мондый рифма сүзләре урынлы һәм дөрес кулланылган чакта строфаларга үзенә күрә бер тәгәлләнгәнлек, әйтелгән мәгънәләргә ачыклык төсмере өстәгән шикелле була. Ләкин һәр бүлек, хәтта һәр бит саен диярлек телдә киң таралган, укыла торган әсәрдә дә кабатланып өлгергән *и җан, игълан, шәйтан; дәрман*нарга өстәлеп, *һәр ан, бер ан, ул ан, дәр ан* ише саф китаби формалар, *йәздан, тогъйан, гъишйан* кебек махсус аңлатуны сорый торган сүзләр дә системасыз хәлдә китерелә бирсә, әлбәттә, шигырь ясалка төс ала, монотон яңгырап, ялыктыра башлый. Мәсәлән, кереш белән 1—10 бүлекләрдә генә дә, ягъни якынча 200 ләп строфада, б-рифмада «җан» сүзе (*и җан, бер җан* рәвешендә) 11 мәртәбә, «ан» («вакыт», «чак» мәгънәсендә: *бер ан, һәр ан*...) исә 16 тапкыр, «шәйтан», «йәздан», «хәйран», «хосран» кебек сүзләр 5-6-шар кат кабатлана. Әгәр 4-әр, 3-әр, 2-шәр кабатланган сүзләрне санасак, «чылбыр» бик озакка сузылыр иде.

Кандалый яраткан икенче б-рифма *-ар* иҗегенә беткән сүзләр (*йар, дар, хар, нар, әшрар* кебек). Боларның кабатланганнарын саный башласак та, шул ук нәтиҗәгә килер идек. Җыеп әйткәндә, «Рисалә» поэмасының шигъри техникасында форма белән мавыгу үзен нык сиздерә.

Соңгы фикернең дәреслеген автор кулланган шигъри фигураларның башка төрләреннән дә күрергә мөмкин. Мәсәлән, «Рисалә»дә төгәл яисә өлешчә омонимик рифмалар актив файдаланыла. Кайчакларын чама сакланмау, әйтик, укучының текстка күз йөртү процессында кабул итү мөмкинлеген исәпкә алмау нәтиҗәсендә, ачык мәгънәле вәгазь-нәсихәт шигыре урынына башваткычлар килеп чыга:

Шәрафәтең шәр афәтә,
Кәмалатең көм аләтә,
Вирубән ошбу халәтә,
Соңында калма дәр-тогъйан...

Хәзерге телгә күчерсәк, ул бик гади: «Намусыңны усаллык-явызлыкка, осталыгыңны исә кимчелекле коралга биреп (алмаштырып), шушы хәлдә соңра азгынлык эчендә калма!»

Тагын бер шундый ук күренеш:

Сакыйнгыл, зиштә зән улма,
Къәһер-лән моште зән улма,
Кешигә суэн-зъэн кыйлма,—
Ки бәгъзы-л-зъэни фисыкъ гъисйан.

Мәгънәсе: «Саклан: начар хатын булма, каһәр (ачу) белән йодрык сугучы булма, кешегә (карата) начар вияттә булма,— кайбер нияттләр бозыклык һәм башбаштаклык ул».

Түбәндәге юлларны укыгач та башыңны кашып утырырга мәҗбүр буласың:

Иман ауәр кичәләрдә,
Сәнең дикен ничәләр дә
Кичәләрдә кичәләр дә,
Ки һиҗрәт берлә чук инсан.

Кыскасы, мондый башваткычларны «Рисалә»дә шактый табарга мөмкин. Кайчакларын шагыйрь уңышлы гына фигуралар тудырып та, вакытында туктый белмәү, чама белмәү аркасында, әлеге энҗе кебек ялтырый башлаган юлларны буяулы пыяла кыйпылчыклары белән күмеп калдыра.

Поэмаларның (бигрәк тә «Рисалә»нең) теле гаять чуар, ясалма, «урта белемле» укучы өчен дә аңлаешсыз. Өстәвенә анда, рифма интересыннан чыгып, элементар тел нормалары бозу фактлары да аз түгел. Менә характерлы мисал:

Шәйатин үзрә кем бака,
Ходауэндә аңа кака:
Баканларны уда яка,—
Белерсең кәнд үзең, и йар!

(*бака* — бага, карый; *кака* — кага, читкә тибәрә; *яка* — яга, яндыра).

Чү! Исрафил чала сури,
Къәбердин дорасән үри...

Янәсе: «Чү! Исрафил сурын кычкырткач, кабердән *урә* торасың».

Китәсән бер ерак юла,
Азыкың вармыдыр кула?

Ягъни: «Китәрсең бер ерак юлга, азыгың бармыдыр кулда?»

Шулай итеп, шигъри катлаулылыктан, ясалмалыктан тел бозуга хәтле барып җиттек. Игътибар иткәнсездер, «Рисалә» һәм «Кыйсса»

Иман ауәр — иман тот, иманлы бул.
Дикен — шикелле, кебек.
һиҗрәт — күчү, китү.
Чук инсан — күп кеше.

телендәге бихисап гарәпчелек, иранчылык өстенә, угызчылык, чыгатайчылык күренешләренә тукталып тормадык. Чөнки хикмәт монда башка телләрдән сүзләрне күп алу, янсә алмауда түгел, бәлки үз ана теленең элементар грамматик нормаларын саклау һәм сакламауда. Бу мәсьәләләрдә Габделҗәббар шәкерт (аерата «Рисалә» битләрендә) үзен бик талымсыз, артык ирекле тота.

Һәрхәлдә, жыеп әйтсәк, әлеге поэмаларда без талантлы, мәгәр тәҗрибәсез кешенең каләмен күрәбез. Купшылыкка, «искитәрлек матур» итеп әйтергә, шаккатырырга омтылу, гадәттә (гомум кагыйдә булмаса да), эчендә дәрте кайнаган, үзендә көч сизгән, ләкин шул мөмкинлекләрне ничек файдаланырга белмәгән сәләтле яшьләрдә күбрәк очрый. Еш кына авторның «бик тә» гыйлемле булып күренергә тырышуы ярылып ята: китаби гарәп-фарсы сүзләрен, катлаулы фәлсәфи атамаларны уңга да, сулга да сиптерә, куккә чөеп, җиргә дә сала... Яшь шагыйрь сүзләрне, гыйбарәләрне иң элек әсәрдәге конкрет мәгънәсе, шул мәгънәнең ачыклыгы, аңлаешлылыгы, ягъни эчтәлек аша тәэсир итү интересыннан чыгып түгел, бәлки ничек яңгыравы, ничек ялтырап, ничек уйнап алуы күзлегеннән карап куллана. Нәтиҗәдә — әлеге буталчык җөмләләр, башваткычлар һәм хәтта тел бозулар...

Бәхеткә, сәләтле һәм мин-минлекле, шул мин-минлеге аркасында һәр җирдә низагъларга кереп, бер мәдрәсәдән икенчесенә күчеп йөргән Габделҗәббарның каләме алга таба шомара бара, тәҗрибәсе күзгә күренеп арта. Моның шулай икәнлеген «Рисалә» белән «Кыйсса»ны чагыштырып караудан да күреп була. «Кыйсса»да тел чагыштырмача гадиләшә, төзекләнә төшә, фикерләр дә артык формаль рәвештә яңгырамый. Әмма барыбер «Кыйсса» да Кандалый иҗатында яшьлек чоры тәҗрибәсе булудан артык еракка китми әле.

Хәер, ир агасы булып җиткән Кандалый язган шигырьләрне укыганда да без ара-тирә сүз формалары, грамматик күрсәткечләрдән ирекләрәк куллану күренешләрен, яэма әдәбиятта сирәк әйтелә торган тактсыз гыйбарәләрне, кинаяләрне очраткалыйбыз. Ләкин монда инде аларны, гадәти талымсызлык нәтиҗәсе дип караудан бигрәк, Кандалый иҗатында баштан ук күзәтелгән билгеле бер тенденциянең (протестның) үзенчәлекле чагылышы дип тә бәяләргә кирәк (бу хакта сүз алга таба булыр).

Бер үк вакытта шуны да онытмыйк: әлеге беренче әсәрләрендә үк яшь шагыйрь әдәби осталык җәһәтеннән үзен чын талант иясе итеп таныта. Бу осталык һәм талантның яралгыларын «Рисалә»дән һәм «Кыйсса»дан күпләп табарга мөмкин. Алар арасында мәкаль һәм афоризм югарылыгына күтәрелгәннәре дә шактый. Мәсәлән:

Җәһаләтлек — яманлыкдыр,
Бере аның нaдaнлыкдыр...

Сабыйлык төш кеби улыр,
Егетлек кош кеби улыр,
Къарилык буш-тәһи улыр...

Моның ише канатлы гыйбарәләр, оста табылган образлар һәм отышлы шигъри фигуралар, әдәби чара буларак, шагыйрьнең алдагы иҗатында тагын да ишәя һәм камилләшә баралар. Югарыда без: «Иген икмәк — вирер икмәк, Мәшәккъәт-лә михән чикмәк»,— дигән юлларны мисалга китергәч, беренче юлы бик матур булып, икенчесенең мәгънәсе ошамавын әйткән идек. Сонра халык арасында язып алынган, «Габделҗәббар бабайга» нисбәт ителә торган парчаларда әлеге шөбһәсез отышлы беренче юлның ахыры: «Белеп иксәң, бирер күпләп»,— дип, мәкаль дәрәҗәсенә күтәреп үзгәртелә.

Очраклы күренешме бу? Безнеңчә, юк. Фикерне төрле яклап дәлилләргә мөмкин. «Рисалә»нең ахырыннан бер өзекнең өлешен кабат

китерик: «...Атап «Рисаләи-л-иршад», Язылган ошбу дүрт пайа». Мондагы шигъри строфа төшенчәсен бирә торган «дүрт пай» (аяк, бага-па) образы күпкә соңрак иҗат ителеп, Фәрхиҗәмалга багышланган мәшһүр циклда тагын шул ук мәгънәдә кулланыла:

Җәмал ләүхендә нәкъешең
Язылды охшатып айа,
Тәсең-буеңны мәдехләп,
Язылды ошбу дүрт пайа.

«Рисалә»дән тагын бер өзек:

Егетлек китәдер фәүри,
Йилә вирмә газиз дәүри,
Ки шәйтан салмасын җәүри,
Идеп әфгалеңә әзрар.

Шушы ук юлларның чак кына үзгәртелгән вариантын тагын әлеге циклда табабыз:

Егетлек китәдер фәүри,
Йилә бирмә газиз дәүри,
Ки итмә үзеңне җәүри,
Тотып фәсъләт һәуасындан.

«Рисалә»нең әле генә китерелгән шигыреннән соң мондый юлларны укыйбыз:

Җиһанга салмагыл мәйли,
Ки булгыл пакь, ләтъф зәйли,
Ки булма соңра дәр-вәйли,
Пошиманлар идеп бисйар.

Димәк, монда сүз ир-егетнең дөнья малына алданмыйча, суфиларча итәк-чабуын пакь-чиста тотып, соңра кайгы-хәсрәткә, зур үкенечләргә эләкмәве хакында бара. Һәм менә шушы дүртьюллыкның нык эшкәртелгән икенче редакциясен без Кандалыйның дөньяви мәхәббәткә багышланган башка бер шигырендә («Мәгъшукнамә», VI бүлекчә) очратабыз:

Җатка куйма мәйлеңи,
Куйсаң, күрерсән вәйлеңи,
Сакла, җаным, гъәйрeләрдин
Садрең илә зәйлеңи!

Һәр мисалда да элек «Рисалә»дә бер яңгыраган, мораль һәм рухи пакьлеккә, димәк, дини-суфилык идеалларына дәшкән шигырьләр соңрак, чак кына эшкәртелгән, үзгәртелгән хәлдә, яңадан яңгырыйлар. Бер карауга болар арасында артык үзгәлек тә юк сыман: бер үк сүзләр, бер үк сурәтләү чаралары, хәтта бер үк рифмалар. Әмма никадәре тирән мәгънәви, фикри үзгәлек монда! Әгәр «Рисалә»дә изге юлга дәшелгән егеткә гомере тиз узачагы искәртелеп, аның үзенә шайтан юлына кермәскә киңәш ителсә, Фәрхигә әйтелгән сүзләрдә аңар гашыйк егетнең дә форсаты узачаклыгы кисәтелеп, кызның үзенә өстенлектән (фәсъләт һәуасындан) масаеп «җә-

---

Фәүр — тиз, ашыгыч.
Җәүр — җәбер.
Әфгалеңә әзрар — үй-ниятләреңә зарарлар.
Фәсъләт һәуасындан — (башкалардан) өстенлек һавасыннан (өстенлекне сизеп һаваланудан).
Салмагыл мәйли — күңелеңне бирмә.
Ләтъф зәйли — күркәм итәк-чабулы (әдәпле).
Дәр-вәйли — кайгыда, хәсрәттә.
Бисйар — күп.
Садрең илә зәйлеңи — күкрәкләрең беләң итәк-чабуларыңны.

берләнмәскә», ягъни гыйшык бәхетеннән мәхрүм калмаска тәкъдим кылына.

Өченче параллель үрнәкләрнең «Рисалә» вариантында сүз, күргәнебезчә, фани дөньяга күңел бирмәү, егеткә шулай итәк-чабуын пакь һәм саф саклау, ягъни гадәти тормыш ләззәтләренә алданмау, шул юл белән охрави (ахирәтлек) бәхеткә әзерләнү кирәклеге хакында бара. Икенче редакциядә исә бөтен «җиһан»-дөнья бер «җатка», ягъни гашыйк шагыйрьдән башка бәндә кисәгенә әверелә дә, кызга сәлам авторыннан үзгә кешеләрдән күкрәкләрен дә, итәкләрен дә сакларга кушыла!

Менә шушы үзгәрешнең — күккә тагылган абстракт иләһилыктан гап-гади дөньявилыкка төшүнең, кешеләргә якын килүнең, ягъни тарихи сикерешнең ачык мисалы булган әлеге шигъри параллельләрне белмичә торып, безгә чын Кандалыйның ничек барлыкка килүен аңлавы читен иде. Икенчерәк итеп әйткәндә, без хәзер «Кандал мулласы» язган шигырьләрнең гадәти генә хис ташкыны түгел, бәлки иҗтимагый аң үзгәрүе нәтиҗәсендә туган искитәрлек зур сикереш икәнлеген тирәнрәк тә, әзлеклерәк тә аңлый алабыз. Чөнки әлеге үзгәреш Габделҗаббар поэзиясендәге дөньявилык һәм кешелелекнең гасырлар дәвамында хөкем сөреп килгән суфичылык, клерикализм догмаларыннан ничек котыла баруына, бу котылу юлының авыр, озак булуына күрсәтә. Бары шул үзгәрешләрне, дөресрәге, автор аңында кичкән үз-үзен ревизияләүне, аның сәбәбен, нәтиҗәсен яхшылап тойган һәм аңлаган чакта гына без хәзер гадәти булып яңгырый торган:

Сахибҗамал, чибәрем лә,
И матурым, сөйәрем лә,
И белмәдем нидәрем лә,
Сагышыңны мөдам итдем,—

дигән кебек юлларның фикри, тел-стиль гадилеге «күпмегә төшкәнлеген», янсә:

Сәба йиле, исәр булсаң
Парау атлыгъ нәфис җайга,
Сәламемне тикергәйсән
Сахибҗамал абыстайга!—

яше чын шигъри энҗеләрдән бездә бөек Кол Гали әдәби хәрәкәткә көртеп җибәргән җиләс җил образы белән моңлы халык җырларының ничек кушылуын, бергә үрелүен һәм шушы кавышуның әлгәрге тарихы ничә гасырларга сузылуын дөрес белә алырбыз

Шулай итеп, нәтиҗә чыгарып әйткәндә, яшь Кандалый поэмалары, әдәби тәҗрибәсез авторның өйрәнчек әсәрләре буларак, бер аерым иҗатның төрле чорларын билгеләү өчен генә түгел, бәлки бөтен татар әдәбияты тарихындагы охравилыктан дөньявилыкка күчә башлау кебек мөһим этапларны өйрәнү, аңлау өчен дә зарур һәм кыйммәтле истәлекләр икән. Икенчерәк итеп әйтсәк, «Рисалә» һәм «Кыйсса» поэмалары, конкрет шагыйрь иҗатының елга башы булулары белән бергә, гомум әдәбиятыбызда барлыкка киләчәк борылышның әлгәрге этабын характерлый торган кайбер галәмәтләрен үзләрендә чагылдыруы белән дә әһәмиятлеләр.

Игътибар иткәнсездер, һәр ике әсәрдә дә автор белән бергә без гел хәрәкәттә булдык: беренчесендә кешенең гомере буйлап сәяхәт иттек, хәтта «теге дөньяга» да экскурсия ясадык, икенчесендә Ибраһим Әдһәм, аннары «Кандилле иллек» егеткә ияреп, илләр гизеп, төрле фикерләр белән танышып йөрдек... Әгәр Кандалый фикердә

Мөдам итү — дәвамлы, чиксез итү.

шулай хәрәкәттә булу аркасында әкренләп охрави (үлемгә әзерләнә торган) идеаллардан дөньяви мәхәббәт (җир кешесенең индивидуаль бәхете) идеалларына күчкән булса, без дә, аның шул бәрәкәтле хәрәкәтенә ияргә-ияргә, әдәби әсәр язуны тел кыландыру, чәйнәлгән «хакыйкатьләрне» тугылау дип эшкә башлаган тынгысыз, мәгәр талымсыз егеттән ничек итеп чын сәнгать әсәрләре тудыру югарылыгына ирешкән шагыйрь үсеп чыгуын күрә башладык бугай. Икенчерәк итеп әйткәндә, без шагыйрьнең абстракт идеяләр сазлыгыннан котылып, конкрет кешегә якынлашуын, шуңа күрә яңа фикер әйтергә теләп көчәнүдән чын ихлас мәхәббәт җырлары тудыру бәхетенә ничегрәк ирешә башлавын күзәттек шикелле. Димәк, югарыда (өченче бүлек азагында) куелган сорауга да өлешчә җавап табылды сыман.

Әйе, өлешчә генә. Җавап чагыштырмача тулырак булсын өчен (абсолют төгәл җавап, ихтимал, бөтенләй булмас), безгә шагыйрь үскән һәм яшәгән социаль даирәне дә искә төшерергә кирәк.

Мәгълүм булганча, XVIII йөзнең соңгы чиреге белән XIX гасырның беренче яртысы феодаль крепостнойлык богавында яшәгән Россия халыклары тормышында, бигрәк тә икеләтә изелгән татарларның матди һәм рухи хәятында иң авыр һәм иң җаваплы чорларның берсе иде. Җирләре таланган, тел, рухи культура һәм дин-иманнары тапталган, димәк, кешелек дәрәҗәләре рәсми рәвештә инкяр ителгән татар хезмәт ияләре Е. И. Пугачев җитәкчелегендә башланган Бөек крестьяннар хәрәкәтенә, бәхәссез документлардан күренгәнчә, беренчеләрдән булып кушылалар һәм актив катнашалар. Бу еллар гаделлек һәм тигезлек турында өзелә башлаган өметләрнең яңадан уянган, ике йөз ел дәвамында икеләтә изелү аркасында сүрелеп өлгергән дәртләрнең дөрләп кабынган чоры иде.

Ләкин халык хәрәкәте канга батырылды. Тәхете тетрәнүдән коты алынган патша хөкүмәте киләчәктә күпмилләтле халыкларның тагын берләшүеннән саклык йөзендә мөселман «инородецларга» карата кайбер ташламалар ясарга мәҗбүр булды — Дини нәзаратын оештырды. Шул рәвешчә татарлар арасында иҗтимагый, рухи коммуникациянең кайбер шартлары үзгәрде, төгәлрәк әйткәндә, вөҗдан һәм иман мәсьәләсендәге гомуми һәм индивидуаль кимсенү хисе кими төште. 1812 елгы Ватан сугышы, аның нәтиҗәсе, ниһаять, 1825 елгы декабрь вакыйгалары әлеге үзгәрүләргә тәэсирсез узмадылар. Иң мөһиме, хуҗалык өлкәсендә капиталистик мөнәсәбәтләрнең элементлары барлыкка килүе һәм көчәюе, кешеләр арасында исә буржуаз мөнәсәбәтләр тернәкләнә баруы әлеге рухи дөньядагы үзгәрешләргә яңа импульс бирде: соңгы дәвер феодализм чорына хас дини йомылган иҗтимагый торгынлык нигезләрен рухи эзләнү хәрәкәте селкетә башлады. Дини реформация рәвешендә барлыкка килгән бу хәрәкәт милли аң уяну процессы белән бер тирәдәрәк атладылар. XVIII гасыр ахырында, XIX йөз башында иҗтимагый фикер мәйданына Габденнасыйр Курсави, Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгарилар килеп, аннары алар башлаган эшләрне Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезхановларның дәвам иттерүләре менә шул иҗтимагый мөһим, тарихи закончалыклы процессның нәтиҗәсе иде.

Тормышка буржуаз мөнәсәбәтләрнең килеп керүе шул дәверләрдә үк крепостнойлык тәртипләренә каршы, димәк, гади хезмәт иясенең кешелек дәрәҗәсен инкяр итүче һәм аны кол (ярымкол) дәрәҗәсендә тотуга корылган төзелешкә каршы хисенең тагы да көчәя төшүен тәэмин иткән иде. Боларның барысы да турылапмы, кыеклапмы җәмгыятьтәге алдынгы аңнарга кешенең шәхес буларак хөрлеге, фикер йөртергә хокукы һәм индивидуум буларак дәрәҗәсе хакында да уйланулар, борчылулар, эзләнүләр орлыгын сала. Аерым кешенең

хокукы, дәрәҗәсе хакында фикер тугач, аның шәхси бәхете мәсьәләсе дә шул ук әлләрдән бара. Кыргыйлыктан үскән кешеләр җенси сөю хисен шул шәхси бәхетнең бер өлеше итеп таныганнар, шуңа күрә гашыйклар үз мәгъшукларына табынудан оялмаганнар, хәтта моннан аерым бер тәм, ләззәт тапканнар.

Мондый процесс барлыкка килүне философик иҗтимагый фикер дә, эстетик әдәби фикер дә беренчеләрдән булып тоеп ала (тарихчылар гына соңрак аңлый). Аерма шунда гына: прогрессив фәлсәфә аны фикер итеп тоя, зарурыйлыгын аңлый, котылгысызлыгын аңлата (иң кимендә шулай эшләргә омтыла), әмма алдынгы әдәби эстетик фикергә килсәк, ул аны шәйли, сиземли, хуш күреп кабул итә, ярата, хисләргә тәэсир ясау юлы белән «коеп куйган» образлар аша фаңлозунг дәрәҗәсенә күтәреп пропагандалый, җыр итә, мавыгып җырлый.

Вәгазьче Габделҗәббар шәкерттән тора-бара шашкын мәхәббәт җырчысы Кандалый-шагыйрь үсеп чыгуын менә шундый аз өйрәнелгән закончалык нәтиҗәсе итеп карасак, баягы сорауның шактый өлеше тулылана төшә кебек.

Фикергә йомгак ясап, шуны өстәргә кирәк, «Рисалә» һәм «Кыйсса»ларны игътибар белән уку, аларны соңгы чор Кандалый иҗаты белән чагыштырып карау, бер яктан, әлеге ике поэманың шагыйрь иҗатын гомум аңлау өчен документаль кыйммәтләрен күрсәтсә, икенче тарафтан, чал әдәбиятыбызның яңару дәверендә охравилыктан дөньявилыкка, схоластик суфичылыктан иҗади эзләнүгә, шуның аша чын гуманизмга күчү кебек катлаулы процессның ничегрәк баруын аңларга ярдәм итте. Күренә ки, без моңарчы яхшы белгән, талантлы өчен тәкъдир иткән, дошманына карата пәкедәй үткен сүзле, дустына һәм сөйгәненә карта сандугачтай тәмле телле, нәфис өнле Кандалый кинәт кенә килеп чыкмаган икән. Тормыш шартларының нигезе (базис) үзгәрә бару процессында яңаруга йөз тоткан өскорманың күренеше сыйфатында үзенең элгәргесеннән — татар әдәбияты җирлеге традициясеннән үсеп чыккан шагыйрь ул. Шул ук вакытта шагыйрьне шагыйрь иткән сәбәпләрнең берсе — авторның кеше буларак шәхси сыйфаты икәнлеген дә онытмыйк. Габделҗәббар шәкертнең гел «юлда» булуы — кеше гомере буйлап та, чор һәм илләр буенча да сәяхәттә йөрүләре — аның баштан ук тынгысыз, эзләнүчән шәхес икәнлеге дә истән чыкмаска тиеш. Әйе, хәрәкәттә генә бәрәкәт!

V

Җитлеккән Кандалыйда да аның яшьлек чорына хас кайбер социаль-иҗтимагый чикләнгәнлекләрнең дәвам иткәнлеге хакында әйткән идек. Аларның берсе һәм иң мөһиме, шагыйрьнең хезмәт кешесенә, димәк, материаль байлык җитештерүче хезмәтнең үзенә карата өстәнрәк карауга кайтып кала. Икенче җитешсезлек — ул ир-хатын арасындагы табигый мөнәсәбәтләрне беркадәр шәрәли төшүдән гыйбарәт. (Нәкъ менә шундый сыйфатлар аның әсәрләрен бастырган чакта акланган һәм акланмаган кыскартуларга сәбәп булды, бу исә, үз чиратында, өйрәнелә торган иҗатны шомартуга, шуның аша аны берьяклырак яктыртуга китерде.) Андый җитешсезлекләрне аклап торуның кирәге юк. Әмма алар да, әгәр катлаулы шагыйрь иҗатын әтрафлап һәм тирәннән белергә теләсәк, өйрәнелергә, аңланырга тиешләр.

Бу кимчелекләрнең беренчесе югарыда биографик әлшартлар белән аңлатылган иде. Моңа хәзер шагыйрь аңының, хаким катламнар вәкиле буларак, табигый сыйнфый чикләнгәнлеге нәтиҗәсе икән-

леген дә өстәү зарур. Мәсьәләгә шулай сыйнфыйлык принцибыннан якын килсәк, шул ук вакытта проблемага чак кына югарыдан торып карасак, әлеге чикләнгәнлекнең гел субъектив сыйфат кына түгел, бәлки иҗтимагый күренешләргә карата үзенә күрә «объектив» мөнәсәбәт нәтиҗәсе булуы да ачыкланыр. Шагыйрь инануынча, «урак урып, печән чабып», көне-төне тиргә бата-бата тузан-туфракта аунауга караганда, йомшак сәкедә китап карый-карый, янсә гөжләп торган самавырдан чәй эчә-эчә сөйгән яр янында хозурланып утырулары, әлбәттә, яхшырак. Кайсы игенчең, ягъни мәсәлән, кайсы «мажигың», әгәр кулыннан килсә, шундый тормыштан баш тартыр иде? Икенчерәк итеп әйтсәк, гади игенчеләргә караганда байлар, руханилар яхшырак яшиләрме, әллә начарракмы?!

Сорауның, кем әйтмешли, болай җүләрләрчә куелуы очраклы түгел. Хикмәт шунда ки, **безнең** бүгенге позициядән бәяләгәндә һичшиксез гаделсезлек булган хөкем, хаким сыйныф вәкиле Кандалый өчен, әгәр **аның мәнфәгатеннән** һәм гомумән сыйнфый җәмгыятьтәге реаль мөмкинлекләрдән чыгып карасак, һичшиксез дөрес! Менә бу күренеш Кандалый реализмының, дөресрәге, аның иҗатында реализм принципларының чагыла башлавының бер үзенчәлеге иде. Ягъни ул тормышта нәрсә бар — шуны яза, үзе күргәнчә һәм бәяләгәнчә яза. Аны ялган сөйләүдә гаепләп булмый.

Ләкин шул ук вакытта бу әле зур, тулы дөреслек тә түгел, бәлки өлешчә генә дөреслек, чикләнгән һәм примитив дөреслек иде. Игенченең **ничек** эшләгәнен, ни хәлдә яшәгәнен генә күрү житеп бетми әле, аның ни өчен, нигә эшләвен, эшләргә мәҗбүр булуын аңларга һәм шундый хезмәттән башка торып булмавын да онытмаска кирәк. Әйтик, Кандалыйның документальлек дәрҗәсендә натуралистик төгәллек белән тасвирлаган «мажик михнәтенә» караганда Галимҗан Ибраһимовның «Табигать балалары»ндагы романтик планда яктыртылган игенче хезмәтендә тормышчан дөреслек, кешегә гаделлек күбрәк чагыла. Мәсьәләне шулай төрле яклап бәяләмичә, аны бары бер яктан, ягъни өлешчә генә яктырткан хәлдә дөреслек тә ярты-йорты, хәтта гарибрәк рәвештә килеп чыга.

Димәк, Кандалыйның «мажик хәлен» сурәтләвендә күренешләрне реалистик гәүдәләндерү омтылышы бар, әмма бәя бирү һәм аңлау тулы, төгәл булмагач, әлеге реализм да башлангыч хәлдә генә калган. Шул ук вакытта бу күренеш дөньяви татар поэзиясендә реализм принципларының чын-чынлап тернәкләнә, формалаша башлавының да галәмәте иде.

Тормыш чынбарлыгына менә шулай турыдан-туры якын килергә омтылу Кандалый иҗатында кайбер социаль мотивларның әлек күрелмәгән рәвештә калку гәүдәләнүен, кискенрәк яңгыравын тәэмин итте. Мәсәлән, гади крестьян (рухани дәрәҗәле лирик геройның, ихтимал, көндәше сыйфатында гәүдәләнгән «мажик» («кадан ир») образы шул заман чынбарлыгы өчен никадәр типик булган булса, аның шулай конкрет чаралар белән тасвирлануы да XIX йөз башы татар әдәбияты өчен шул кадәре үк зур яңалык иде. Мажикны тасвирлаганда *кер, тир, ертык кием, иске чабата, юешката, суган, торма, төгенле ызба, сасы ис* төшенчәләрен төп сурәтләү чаралары итеп куллану, мөнәсәбәтнең вакыт-вакыт артык тупас булуына карамастан, әлеге образга сәнгатьчә җанлылык, социаль конкретлык бирә. Автор позициясенең гаделсезлеген икърар иткән хәлдә, аның каләме белән тудырылган образның реалистик дөреслеген дә инкяр итү мөмкин түгел. Ул чор татар крестьянының ярлы һәм керле булуы гына түгел, бәлки надан, димәк, рухи, интеллектуаль культурадан мәхрүм хәлдә яшәве дә бәхәссез факт. (Гади хезмәт иясенең кешелек дәрәҗәсен, гражданлык хокукын тану ул әле аның интеллектуаль сыйфатын

механик рәвештә шомарту, идеаллаштыру булмаска тиеш.) Гади крестьянның дин тотуда «керәле-чыгалы» булуы («Намаз урнына йыр йырлар, Иман укы дисәң, мырлар»... һ. б.), «томаналыкны» нәселдән саклап килүе дә, мәсьәләгә объектив карасак, түбән катламнар өчен типик күренеш иде. Димәк, Кандалый безнең әдәбиятта крепостнойлык чоры татар крестьянының реалистик образын тудыруда беренче адымнарны ясаган сүз остасы икән. Үзенчәлеге исә шуннан гыйбарәт: тенденция-идея ягыннан бик үк гадел булмаса да, сурәтләү чаралары, тарихилык җәһәтеннән тулаем дөрес иде.

Крепостнойлык чорында икеләтә изелүгә дучар ителгән татар крестьяннарының авыр социаль чынбарлыгын, ирнең дә, хатынның да бер дәрәҗәдә үк коллык хәленә төшерелгәнлеген тасвирлауда шагыйрь кайчакларын зур гомумиләштерүләргә ирешә.

Әгәр ирнең хәле:

Гүйәки бер байар колы,
Байарның әмре аркылы
Эш эшләп, кабарып кулы,
Саладыр акча абрукка,—

рәвешендә гәүдәләндерелсә, аның хатыны да шундый үк өзлексез изелүгә дучар булган:

Эш эшләп унике аен,
Гомер буең, кышын йайен,
Сызып бетеп йөрәк маең,
Каның да калмый кашыкка...

(«Сахибҗәмал», III, 11, 6)

Рухи һәм мәдәни казанышлардан читкә тибәрелгән, хәтта мәхрүм ителгән гади татар крестьяннары чынбарлыгында хатын-кызларның хәле аерата авыр иде. Үзе тулысынча ислам дине өйрәтүләре тарафында булган, шуна күрә көндәлек гамәлләрендә «хатын-кыз — ярты кеше» дигән принципларны алга сөргән рухани Габделҗәббар хәзрәткә каршы буларак, реалистик аңы уяна башлаган шагыйрь Кандалыйның иҗатында хатын-кызларның әлеге авыр хәлләрен дөрес яктырту омтылышы киң урын алды. Гәрчә шагыйрь моны хатын-кыз бәхетсезлеге «надан иргә» кияүгә чыгу дип чикләнгән рәвештәрәк тәкъдим итәргә тырышса да, әлеге бәла-казаларның күп очракта ярлы тормыш белән бәйле икәнлеге ап-ачык иде. Чөнки теләсә нинди укучы көзге салкында туңып, җәйге эсседә пешә-пешә җир тырнау, урак урып, печән чабу белән шөгыльләнүче хатын-кызның бай кеше янсә хәлле рухани җәмгате булмавын уйлап тормыйча да аңлый ала. Өстәвенә, Кандалый ирләр белән хатыннар арасындагы хокук тигезсезлеге тудырган гарип мөнәсәбәтләрне дә ачык күрә һәм яшермичә күрсәтә. Аның инануынча, «надан ир» хөкем сөргән гаиләдә хатынның күргәне җәбер-золымнан гына гыйбарәт:

Тотып, чормап сач урмәсен,
Ашатды камчы җөрмәсен...

(«Сахибҗәмал», XII, 7)

Хәер, хатынның «Сөйәгеи тоз кеби уып, Ки борнын кан илә юып», аннары куып җибәрүдә «мажик» ирләргә «галим» муллаларның үзләре дә мул үрнәк биргәннәр. Чөнки гади крестьян үз хатынына иң ахыр чиктә хуҗалыгына кирәкле хезмәтчегә карган кебек караса (ач үлемгә тарымас өчен шулай карарга мәҗбүр булса), өч-дүрт хатын асраган мулла абзаң өчен алар бөтенләй «әрәмтамак» янсә, иң яхшысы, уенчык булып күренгәннәр. Һәрхәлдә залим ирдән күргән җәбер-җа-

фага түзә алмыйча: «Бер анфалит кеби кайтып, Ике битене саргайтып, Ике күзене акайтып» тол утыручы хатыннарның күпчелеге икенче кат өйләнү өчен матди хәле җитмәгән ярлы крестьяннардан түгел, бәлки хәллерәк катламнардан чыкканлыгы мулла булмаган кеше өчен дә ап-ачык.

Шулай итеп, шагыйрь Кандалыйның язганнары рухани Габделҗәббар хәзрәтнең табигый инануына да, көндәлек гамәлләренә дә каршы килә. Шагыйрь иҗатында гәүдәләнгән стихияле реализмның үзенчәлеге, документаль әһәмияте менә шуннан гыйбарәт

Ләкин «стихияле реализм» дигәч тә, шагыйрь иҗатындагы андый социаль элементларны тулысынча очраклы рәвештә барлыкка килгән күренеш дип бәяләргә ярамый. Чынлыкта әлеге «стихиялекнең» үзе аңлылык һәм максатчанлык, ягъни билгеле бер ышанычның, эчке иманның чагылышы иде. Ул иманның эчтәлеге исә Кандалыйның хатын-кыз да, ирләр кебек үк, мәхәббәттә тигез хокукка, шәхси бәхеткә лаек дигән карашыннан гыйбарәт. Шуңа күрә дә аның һәр әсәрендә шигырьлек мәгъшука (сөйгән кыз) белән мәгъшук (гашыйк ир) тигез хокуклы тарафлар сыйфатында гәүдәләнә. Әгәр үзләренең хатын-кызга карата мөнәсәбәтләрендә феодаль аңны калку гәүдәләндергән элекке татар яраннарының (рыцарьларының) җырларында «Мал биреп йарым димәк — шулдыр морад, Мал бирмәй йарым димәк — халыкына оят» фәлсәфәсе алга сөрелсә *, Кандалыйда кыз өчен калым түләү (кәләшне сатып алу) мотивы, йәисә мәгъшукагә башка берәр юридик һәм матди чаралар ярдәмендә ирешү омтылышы бөтенләй диярлек күренми. Шагыйрь, киресенчә, мал өчен кызыгып, бай иргә чыгуны дөрес дип санамый. Мәсәлән, *** («Колак тотып ишет, җаный...») шигырендәге:

> Кауышыйк инде бу айда...
> Ирадәң әллә байларда?...—

дигән сүзләрдән лирик герой үзен «ярлы» итеп күрсәтүе белән калым түләүче түгеллеген дә әйтә, бары байлык өчен иргә чыгучы кызларга карата үзенең тискәре мөнәсәбәтен дә белдерә. Шагыйрь бу ышанычын *** («Бән сезләрә бер сүземне...») дигән, моңарчы әдәбият фәнендә билгеле булмаган әсәрендә аерата калку гәүдәләндерә:

> Надан ир м а л ы н а к ы з м а,
> Алар сари кулың сузма,
> Каралык көенә йөзмә,—
> Ки булырсән гъисйан алла...
>
> Разый булып, ата-ана
> Бирәм дисә ки надангә,
> А л а р р и з а л ы к ы ө ч е н
> Г о м е р л е к х ә с р ә т ә к а л м а.

Шулай итеп, шагыйрь иргә чыгуда кыз балага ата-ана киңәшенә генә ияреп түгел, бәлки үз хисенә ышанып гамәл кылырга куша, малга кызыгуны исә алла ихтыярына каршы бару дип бәяли.

Шагыйрьнең инануынча, барган киявенә мәхәббәте сүрелсә дә, хатын-кыз тормышы зинданга әверелә:

> Ходa кушса ушал йарга,
> М ә х ә б б ә т д ә к а н с ә а нда,

---

* Бу хакта карагыз: М. Г о с м а н о в. Каурый каләм эзеннән.— Казан, 1984, 130—139 бб.

Анфалит — инвалид.

Ирадәң — теләгең, ихтыярың.

Кызма — кызыкма.

Сари — таба.

Гъисйан алла — монда: аллага каршы баш күтәрүче.

Дәкәнсә — бетсә.

Аның илә мосахибдән
Ки әфзаль зиндани, алла...

Әгәр язмышың шулай була калса:

Үз-үзеңә коны сүәлә,
Ки дәрман дәрдеңә эзлә,
Китәр юлыңны сән эзлә,—
Үзенә тиң бирүр алла.

Надан һәм мәхәббәтсез ир исә:

Өзелеп егълайу калсын.
Үзедик мәҗнүнне алсын,
Малы-мөлке ута янсын,—
Котылдырсын берүк алла!

Шагыйрьнең: мәхәббәт, шәхси бәхет ул малда түгел, ә чын хистә, һәм кеше хисен хөрмәтли белә торган галим, белдекле кеше белән сөешеп яшәүдә, дигән фикере кызны мәһәр ише никяхның матди интерес якларыннан баш тартуга чакыруында ачык чагыла:

Ки галимдән хәбәр килсә,
Атаң-анаң аңа бирсә,
Мәһәрә керәнләр салса,—
Аны кабул әйләгел, җаным!

*** (*«Бән сезләрә бер сүземне...»*)

Шулай ук Кандалый: мәхәббәт һәм тормыш кору мәсьәләсендә кыз үзе дә, язмышка буйсынып кына тормыйча, актив булырга тиеш, дигән фикерне эзлекле рәвештә алга сөрә. Әйтик, иҗатының чагыштырмача башлангыч чорында ук (мәсәлән, «Нисъф-ел-мөлякъәт...» шигырендә): «Атаң ятка биргәнне тоймый калма», мәхәббәтсез кешегә «Бармыйм дигән сүзеңне телдән салма»,—дип чакырган Кандалый соңгырак чор әсәрләрендә дә үз хокукын яклауда кызларга оялып-иманеп тормаска киңәш бирүен дәвам итә:

Оялмасана, я җаный,
Дигел анлара сән аный;
Оялып хәсрәтә калсаң,
Разый ирмәс сеңа алла...

*** (*«Бән сезләрә бер сүземне...»*)

Шагыйрьнең икенче бер әсәре исә мәгъшукасен оялып-итеп тормыйча үзенең кемне яратуын ата-анасына ачык әйтергә өндәве белән башланып китә һәм оялчанлык (монда: буйсынучанлык та!) бәхетсезлеккә сәбәп дигән фикер үткәрелә:

Китабларда бу сүзне күргәнем бар:
«Оялган кемсәнең ризкы булыр тар;
Икеләнеп, оялып корган эшләр
Сүтеләдер, сүреләдер!» — диешләр,
«Бирецез үк!» — дигел, бер дә оялма,
Сүзем будыр сәңа, җаным, багалма...

Шул рәвешчә иске дәвер татар кызын үз язмышына карата актив гамәлгә дәшү мотивы шагыйрьнең соңгы чор иҗат җимеше булган «Сахибҗамал» әсәрендә һәнә дә көчлерәк яңгырап, тагын да калкурак гәүдәләнә (XIX бүлекчәгә карагыз).

Кандалый кыз баланы ата-анасына карата гына түгел, бәлки мәхәббәтен тәкъдим итүче егеткә мөнәсәбәттә дә туры сүзле булырга дәшә:

Әгәр дә килмәсәң, алдап йөретмә,
Сәүмәгәнеңне бер дә эчдә тотма.

*** (*«Ки бән яздым сәңа, җанкам, ничә хат...»*)

Мосахибдән — иш һәм әңгәмәдәшлектән.
Афзаль — артык, яхшырак.
Сүзлә — сөйлә.

Боларның барысы шул чор татар әдәбиятына яңа тематика, яңа геройлар белән бергә мәхәббәт мәсьәләсен [illegible] яңа шагыйрь килүен күрсәтә. Шуны заманында яхшы тоеп алган Җ. Вәлиди Кандалыйның Габдулла Тукайга хәтле үк хатын-кыз хокукын яклап чыгучы иң зур шагыйрь булуын әйтә.

Әлбәттә, шагыйрь иҗатында йөз биргән бу яңарыш, үзгәреш җиңел генә, шома гына бармый, табигый ки, бара да алмас иде. Чөнки нинди талант ничек кенә иске кысалардан чыкмасын, шагыйрь аңында элекке тәрбиядән калган төшенчәләр, буталчыклар шактый иде. Шуңа күрә вакыт-вакыт аның яңа фикерләрне алга сөргән дөньяви эчтәлекле шигырьләрендә дә иске әдәбияттан, дөресрәге, тәсауыф поэзиясеннән килә торган сурәтләү чараларын очратырга мөмкин. Мәсәлән:

Кулым йитмәс, ки тотсам, йар, үзеңне,
Күзем йитмәс, ки күрсәм, йар, йөзеңне,—

дип башланган шигырь элекке «Алла гыйшкы» хакында лаф орган суфи шагыйрьләрнең әсәрләрен хәтерләтә. Ләкин соңрак, шулай беркадәре абстракт чаралар белән өретелгән строфаларны узгач, нәкъ җитлеккән Кандалыйча әйтелгән юлларга килеп чыгабыз:

Йөзең күрергә теләймен, үзеңне,
Билең кочып сүләшергә сүзеңне!..

Төгәл бер шигырьдә генә түгел, хәтта бер строфа эчендә дә шундый күчешләрне, ике дәвернең янәшәлеген — «өйдәшлеген» күрергә мөмкин. Әйтик, түбәндәге бер генә бәйтнең алдагы юлы, Алланы күздә тотып, суфилар традициясенчә әйтелгән булса, икенчесе, һичшиксез, җир кешесенә карата сөю хисен тасвирлый:

Вез гъәрибләр йөзеңне күрсәк иде,
Билең кочып, ләбеңне сурсак иде...

**** («Фиракъеңдин күземдә йәш корымай...»)*

Ниһаять, югарыда китерелгән мисаллардан «кыз язмышы» мәсьәләсендә ходайның нинди «позициядә торуы» да ачык түгел: бер урында ул язмышка буйсынучанлыкны алла инкярына каршы килү дип бәяләсә, икенче урында «ходай кушкан йаргә» мәхәббәт бетү мөмкинлеген дә исәпкә ала.

Шагыйрь иҗатында йөз биргән мондый эзлексезлек, буталчыклык аның «надан» белән «мажикны», «бай» белән «галимне», «бай надан» белән «ярлы галимне» буташында да чагылыш таба. Югарыда китерелгән мисалларның кайберләреннән күренгәнчә, Кандалыйның «наданы» ярлы һәм томана «мажик» та, мал-мөлекле белемсез байгура да була ала. Шулай ук аның тәһарәтле, намазлы галиме дә күл көче белән туенучы гадәти игенчегә әверелә:

Әгәрчә ир галим улса,
Хәлял кәсеб: иген иксә,
Возу кыйлып, намаз кыйлса,—
Ушал ирдер ки рәхманый...
Зирагъәтдән әгәр кайтса,
Тиз үк хәлялена әйтсә...

**** («Бән сезләрә бер сүземне...»)*

Гъәрибләр — монда: кимсетелгәннәр, өлешсезләнгәннәр.
Ләбеңне — иреннәреңне.
Возу кыйлу — тәһарәт алу.
Рәхманый — алла юлындагы (кеше).
Зирагъәт — игенчелек, иген игү.

Димәк, шагыйрьнең «мажик» дип сүккәне гел ярлы крестьян булмаган кебек, аның «галим» дип олылаганы да, кайчандыр кат-кат тукылганча, байлар («авыл буржуазиясе...») түгел икән. Қыска гына итеп әйткәндә, Кандалый әлеге төшенчәләр ярдәмендә күпчелек очракта белдексез һәм белдекле, «динсез» һәм «дөрес иманлы» кешеләрне күз уңында тота. Ягъни шагыйрь кешеләрнең кешелеклелеген, шәхес буларак кыйммәтен билгели торган критерий сыйфатында аның аңын, белемен, рухи дәрәҗәсен ала (рухи байлык сыйфатында динлелекне күздә тотуга һич тә гаҗәпләнмик: һәр заманның үз идеалы, үз иманы, үз бизмәне). Дөньяны танып белүдә, кешеләр арасындагы күренешләргә бәя бирүдә мондый рухи критерийларны беренче планга кую ул мәгърифәтчелек идеологиясе оешкан һәм хөкем сөргән дәверләр өчен хас иде.

Дөрес, Кандалыйның мәгърифәтчелеге шул тәгълиматның идеологларында чагылган максатчан фикер, системалы өйрәтү рәвешендә гәүдәләнми. Чөнки ул Курсави, Мәрҗаниләр шикелле теоретик гыйльми трактатлар, публицистик китаплар язмаган, әлеге фикерне Утыз Имәни, Акмуллалар төсле кәфис әдәбият, шигырь аша пропагандалауны да үзенә максат итеп куймаган (бары вакыт-вакыт кына аның аерым шигырьләрендә Утыз Имәни һәм Акмуллалардагы кебек үк «къил вә къаль»ләргә, ягъни схоластик сүз боткаларына каршы протест элементлары, йәисә «наданлык бәладер», «надан ир җангадыр агу» ише аксиоматик тәгъбирләр яңгырый). Чынлыкта, Кандалый, тормыш ләззәтенә ашкынучы хис иясе буларак, үз аңында оешкан, холкына муафикъ рәвештә тиз узылган әлеге теоретик фикерләрдән туп-туры гамәлгә күчкән. Шуңа күрә фикерне тәфсилләп нигезлисе урынга, кабалана-кабалана дигәндәй ашыгып, шашынып, аны әдәби образга — конкрет хөкемгә әверелдергән. Нәтиҗәдә аның мәгърифәтчелеккә карата булган позициясе трактат йәисә декларация рәвешендә түгел, бәлки тормышның уңай һәм тискәре күренешләренә карата мөнәсәбәт сыйфатында оешкан. Югарыда каралган хатын-кыз һәм шәхси мәхәббәт мәсьәләсендә дә без шундый мөнәсәбәтнең үзенчәлекле чагылышын күзәткән идек. Әгәр китерелгән мисаллардан Кандалый гуманизмының хатын-кыз җенесенә карата тарихи конкретлыгы бары мәгърифәтчелек идеясе тәэсире икәнлеге бәхәс тудырмаса, шагыйрь мирасында гәүдәләнгән түбәндәге фактлар әлеге идеянең шул иҗатта тоткан урынын, күләмен тагы да ачыграк күрергә ярдәм итә.

Югарыда хатын-кыз бәхете, хокукы мәсьәләсенә кагылышлы рәвештә шагыйрьнең алла ихтыярына мөрәҗәгать итүе һәм шул тенденцияне уздыруда каршылыклар җибәрүен күргән идек. Провиденциализм (бөтен күренешләр, хәлләр бары алла ихтыярыннан дигән ышаныч-иман) тәэсиреннән тәмам котыла алмаган, котылуы мөмкин булмаган Кандалыйда андый каршылыкның очравы гаҗәп түгел. Чөнки, әлеге провиденциализмның иске тәрбиядән килүе табигый булган шикелле, искене җимергән чакта яңалык өчен көрәшүчеләрнең үз ышанычларын куәтләү максатыннан ходай авторитетына апелляция ясаулары да закончалыклы күренеш. Әмма Кандалый сөю хисенең дәрәҗәсен билгеләүдә «мәхәббәт — ул ала кушкан эш», «сөю — пәйгамбәр сөннәте» дигән, иске карашлар өчен җитәрлек дәрәҗәдә кыю яңгыраган тезислар белән генә дә канәгатьләнми. Лирик геройның сөю хисләрен тасвирлаган чакта ул дөньяви кешегә — гадәти җир кызына булган мәхәббәтен Алла алдындагы бурычыннан өстен куя. Дөрес, моның кайбер мисаллары аерым әсәрләрдә бер карауга аллага ялвару рәвешендәрәк «гадәти» яңгырый:

Намаз артларыкдин, җаный,
Телимен алладин сәни...
*** (*«Колак тотып ишет, җаный...»*)

Шулай намаз, ягъни аллага коллык белән янәшә куелган мәхәббәт, тора-бара мәчеткә ук кереп китеп, андагы мөнбәрне — дини вәгазь кафедрасын — гыйшыклык хәлләрен игълан кыла торган трибунага әверелдерә:

Ишет хотбә гыйшыклык мөнбәрендән:
Бәйан идәм мәхәббәт гъанбәрендән.
*** («Ишет хотбә гыйшыклык мөнбәрендән...»)

Кешенең сөю хисен иң калку гәүдәләндергән «Фәрхи»дә әлеге мотив тагын да көчәйтелә төшә:

Күз-кашыны мәсжедә михраб идәм,
Суратене көзгедик махабб идәм!

Димәк, кызның күз-кашы мәчеттә кыйбланы, ягъни табына торган тарафны күрсәтүче урынга — михрабка, ә аның сурәте исә гадәти күзгә күренми торган серле җиргә (мәхәббка) — илаһи объектка әверелә. Хәтта хисләре белән мавыгып киткән шагыйрь моның белән генә дә чикләнми:

Һәм менә иналдерәсең ничә ел,
Гакълым алып, баша йитдең ничә юл.

Бу сүзем чын, сөйләшәмен алдамый:
Тәмам оныттыра яздың алламый!

Көн дә сагыш, төн дә сагышың тотып,
Бинамазым, бинийазым ут йотып.

Аллаһ әкбәр дип әгәр каксам колак,
Сурәтең күңлемә уладыр кунак!..

Аллама баш орсам иде бу кадәр,
Сәне маңа ул бирер иде мәгәр!..

Кыскасы, әле генә ярдәм сорап Аллага мөрәҗәгать иткән шагыйрь, аның кодрәтенә ышануга кул селтәгән мәҗүсидәй, сөйгәненең образын табына торган потка әверелдереп, шуңа сәҗдә итә.

Яшьлегендә гел дини тәрбия алган, «хак мөселман» буларак формалашкан, соңрак руханилык вазыйфасын үтәп яшәгән ир агасының гади жир кызы — крестьян кызы образын шул рәвешчә алла образына каршы куюы гадәти генә «юлдан язу» яисә «динсезлек» күренеше түгел, бәлки шагыйрьнең мәхәббәт хисенә, Кешенең шәхси, шитим бәхете мәсьәләсенә мөнәсәбәте, иҗтимагый позициясе чагылышы иде.

VI

Мәхәббәт хисен, аның көчен тасвирлауда шагыйрь ирешкән казанышлар хакында фикер йөрткән вакытта, аларның табигатен бары конкрет сөю хисе көченә, теге яки бу каләм иясенең әдәби мөмкинлекләренә кайтарып, шулар белән генә чикләп куярга ярамый. Шагыйрьнең мәхәббәткә карата булган мөнәсәбәте аның иҗтимагый позициясенә бәйле икәнлеген раслый торган дәлилләрнең башка төрләре дә бар.

Югарыда бер тапкыр искә алынганча, шагыйрь әсәрләрендә, мәсәлән, ирләр белән хатын-кызлар арасындагы мөнәсәбәтләр темасына кагылганда, беркадәре «тәртәдән чыгып китү», ягъни күренешләрне арттырып тасвирлау фактлары очраштыргалый. Шул ук вакытта кистереп әйтергә кирәк: Кандалыйда очрый торган андый детальләрдә, әгәр чикләнмәгән ханжалыкны, формаль тәкъвалыкны принцип итеп

Бинамаз — намазсыз.
Бинийаз — якты нурсыз (кыйбласыз).

алмасак, порнография бөтенләй юк. Мәгәр талымсызлык, чама хисен югалтып җибәрү күренешләре шактый. Шул ук вакытта сүз һәм әдәби чаралар сайлауда шагыйрьне әдәпсезлек белән эстетикасызлыкта гаепләргә дә ашыкмыйк. Чөнки мәсьәләгә тарихи планда житдирәк карасак, андый турыдан ярып әйтүләрнең күренеш һәм хәлләрне мөмкин кадәр тормышчан, реальрәк яктыртырга омтылыш нәтиҗәсе икәнлеген дә, шундый омтылышның аңлы рәвештә тормышка ашырылган булуын да күрүе кыен түгел. Мисал өчен «Мәгъшукнамә» китабының ахырында VIII бүлекчә сыйфатында китерелгән, «Чүсәнә абзый, чүсәнә» дип башланган шаян строфаларга мөрәҗәгать итик. (Искәртеп узыйк: «Мәгъшукнамә» китабын Кандалыйныкы түгел дип исәпләүчеләр, гадәттә, шушы бүлекчәгә өркеп карыйлар; ләкин әлеге шигырьнең өлеше һәм варианты «Сахибҗәмал» әсәренең ШАКД редакциясендә теркәлгән булуы мондый шөбһәне нигездән кире кага.) Ул строфаларда һәм аларның ШАКДда сакланган вариантларында очрый торган кайбер кинаяле гыйбарәләр, чыннан да, ирекләрәк яңгырыйлар. Ләкин, икърар итик, чытлык кызларның кыланышларын гаять калку итеп гәүдәләндергән ул шигырьләрдә тормышчан дөреслеккә хилафлык юк. Шулай да ни өчен Кандалый мондый кискенрәк алымга барган? Монда берәр тарихи объектив сәбәп, әлеге шигырьгә автор йөкләгән махсус мәгънә, аңлы тенденция юк микән?

Ислам дине ның таралган Урта гасыр мөселман халыклары әдәбиятында, җөмләдән татар язма поэзиясендә дә, бигрәк тә аның суфичылык агымы көчәйгән чорында, гадәти җир кешесенең үз ишенә булган мәхәббәте — кешечә дөньяви мәхәббәте,— югарыда әйткәнебезчә, гражданлык хокукыннан мәхрүм ителгән иде. Шуңа күрә ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәт кырыс регламентка салынып, «баш һәм муен», «хуҗа һәм хезмәтче» нисбәтендә каралган, шулай пропагандаланган. Әгәр ислам дине, башка диннәр кебек ук, гаилә дигән иҗтимагый институтта азмы-күпме «мөкаддәслек» галәмәте күрә икән, аны да ул бары мөселманнарны күбәйтүче, шулай ук «хуҗаларның» нәселен арттыручы, «хезмәтчеләрнең» дә санын киметмәүче бер чара рәвешендә таныган. Бу хәл исә, үз нәүбәтендә, гаиләнең ислам тарафыннан социаль категория сыйфатында танылуын тәэмин иткән. Шуңа күрә, мөселман руханиларының инануынча, гаилә нигезен «шайтани галәмәт» булган интим хисләр түгел, бәлки тормышчан зарурият тәшкил итәргә тиеш.

Бу әйтелгәннәрнең коры декларация түгеллеген раслый торган документлар да бар. Һәм ни кызыгы шунда, әлеге документларның бер күчермәсе югарыда аталган шигырьне эченә алган «Мәгъшукнамә» китабы теркәлгән кулъязмада — Иске Шәйморза дәфтәрендә (В нөсхәдә) дә китерелә.

Өйләнүче яшьләр өчен кулъязма циркуляр рәвешендә төзелгән, руханилар тарафыннан мәдрәсә укучылары арсында актив пропагандаланган, шуңа күрә кулъязмаларда күп очрый торган бу документ «Әдәбнамә» дип атала. Ул түбәндәгедән гыйбарәт (иң характерлы җирләрен генә күчерәбез):

«Әүвәл кыз куйныга барганда ике рәкәгать намаз кылсын, тәңре тәгаләдән теләкләрен теләсен... Андин соң кызның шәһадәт (имән — *М. Г.*) бармагыңны тотсын, кәлимәи шәһадәт берлән сүзләнсен, тәңре тәгаләнең боерыгыны сорасын: «Әүвәл тәңерең кем?» — дисен. Кыз әйтсен: «Барча галәмне яраткан бер вә бар тәңре!» — дисен. «Кем өммәтендин торырсың?» — дисен. Кыз әйтсен: «Мөхәммәд өммәтендин торырмын»,— дисен...» Моннан соң егет кызның кайсы диндә, нинди мәзһәбтә булуын ачыкларга тиеш.

Күрәсез, кәләш янына керүче кияү үзе генә укынып йөрү белән канәгатьләнмичә, хәзергечә әйтсәк, кызның политик карашларын, идео-

...огик позициясен һәм «гражданлыгын» аныкларга тиеш икән. Әгәр ...ыз сорауларга җавап бирә алса, никях — дөрес, юкса «ул кемсәгә бу кыз буш булыр». Монысы җитмәгәндәй, кыз, түшәккә менеп утырып, тагын: «Аллаһомма раббана аттина фиддөнья...» дип бер дога ...а укырга тиеш. Шуннан соң кияү йәнә «әдәб берлә бикәчнең уң кулындин, бармак очындин аз гына биегрәк тотып», тагын ... сораулары кабатлый, кочаклар алдыннан тагы бер дога укый...

Иә, шуннан соң бу «Әдәбнамә»не риялыкның, икейөзлелекнең «мораль кодексы» димичә ничек атарга мөмкин?! Шуны да кабатлап ...итергә кирәк, интим эшләргә әдәпсезләрчә тыкшынучы бу «әдәбнамә»нең бер хәрефе дә туй-никях хакындагы дини регламентларга ...ршы килми, бәлки аларны хуплый, көчәйтә генә...

Мәгълүм булганча, һәрбер күренешнең үз асылы, форма һәм ...толеген бергә туплаган «оригиналы» булган кебек, аның бары тыш... кыяфәтен генә төрле ноктадан төрлечә итеп күрсәтүче иярчен ...үләгәләре» дә бергә йөри. Дини өйрәтүләр белән дә шулай. Аның ...ярченнәре», гадәттә, өстәмә рәвештә соңрак туган, тора-бара за...нлы традициягә кереп киткән гореф-гадәт һәм йолалардан, имеш...мимеш һәм хорафатлардан гыйбарәт. Моның мисалын никяһка ...раган шәригать таләпләреннән дә күрергә мөмкин. Әйтик, өйләнешү ...ты вакытында никях уку, ягъни «иляһи сүз» белән яшьләрнең гамә... олылау эше, ислам диненең беренчел һәм, шул тәгълимат тари...ы күзлегеннән караганда, законлы таләбе булса, әле без танышкан ...Әдәбнамә» һәм андагы «имтиханнар» аның соңрак формалашкан ...ярчене һәм аның асылын комик хәлгә әверелдерә яза торган күлә... генә.

Комизм исә «Әдәбнамә»нең төп идеясендә түгел,— анысы белән ...л никях хакындагы дини өйрәтүгә каршы килми,— бәлки форма һәм ...масында. Игътибар итегез: анда сүз сугыш вакытында улҗа (трофей) рәвешендә төшкән, кайсы динне тотуы ачык түгел әсир, йәисә ...рамда табылган» билгесез кыз катына керү хакында түгел, бәлки ...нәүнең үзе кебек үк «хак мөселман» баласы белән шәригатьчә ка...шуы турында бара. Шулай булгач, нигә кирәк әлеге «имтихан» ...улар, никях түшәге өстендә кырык мәртәбә дога укулар? ... таләп...рне акылга муафикъ нормаль таләпләр дип әйтә алабызмы?!

Әлбәттә, мин дә өйләнешүчеләрнең аулак калуга ук бер-берсе ...тенә ажгырып ташлануларын пропагандаларга җыенмыйм. Ләкин ...сырлар буена хөкем сөргән риялы өйрәтүләрнең әһәмиятеннән күз ...марга да ярамастыр, чөнки, моны белмичә торып, әдәбиятыбызда гы...хәббәт тематикасы үзенчәлекләрен аңлый алмаячакбыз.

«Әдәбнамә» ише әйберләрнең әлеге таләпләре соңгырак туган ...ренеш дип әйтүдән чыгып, монда «асыл исламның ни гаебе?» — ...и әйтергә дә нигез юк. Чөнки өлгегә ярарлык «оригинал»ның үзе ...лмаганда, аның кәкре-бөкре «копияләре», чалышайган күләгәләре ... килеп чыкмас иде — буш җирдә үзеннән-үзе генә күләгә барлык... килми.

Алайса «беренчел һәм икенчел» йолаларга аерып торуның кирәге ...рсәдә? Болай аеруның узгандагы күренешләрне аңлау өчен мето...логик әһәмияте бар. Чөнки, тарихыбыздан яхшы беленгәнчә, дини ...кләүләргә, клерикализмга каршы күтәрелгән көрәш вакытында удар...рның беренчесе диннең асылына, аның беренчел өйрәтүләренә тү...л, бәлки соңрак туган «күчермәләренә» өстәмә һәм койрыкларына ...өбәлгән була (мәгърифәтче реформаторларның «диннең асылына ...йтырга», аны «соңгы катламнардан арындырырга» теләүләрен искә ...шерик). Дингә шулай «дини ревизия ясау» этабын узгач кына, ...ның чын асылын тәнкыйтьләргә, хәтта бөтенләй кире кагарга мөм...кинлек туа. Ягъни «динне соңгы катламнардан арындыру» омтылы-

шы — ул, гадәти генә чикләнгәнлек түгел, бәлки фәлсәфи чикләнгәнлек белән иҗтимагый кыюлыкның бергә укмашкан һәм узылуы зарури булган тарихи бер этабы да.

Язма әдәбиятлардагы мәхәббәт тематикасының дини чикләүләрдән котылу юлы да шундый зарури баскычлардан узарга тиеш иде, һәм ул узды да аларны. Никях хакындагы «Хак дини» өйрәтүләренең өстәмә койрыгы булган «Әдәбнамә»ләргә чын һәм олы мәхәббәт поэзиясенең формальрәк төрен гәүдәләндергән «Чүсәнә, абзый, чүсәнә» ише шигырьләр каршы куелды. Икенчерәк итеп әйткәндә, «Әдәбнамә»дәге тәкъвалыкка төрелгән ялган, рия һәм хиссезлек «Чүсәнә...» ише әсәрләрдәге шаян дәреслек, гадилек һәм күңелле кытыклый торган мутлык белән кире кагылды.

Димәк, без «тәртәдән чыгу» дип бәяләгән күренешләр дә, әгәр игътибар беләнрәк карасак, тормыш проблемаларының үзәгенә алып керәләр икән.

Мәхәббәт тематикасының «дини крепостнойлыктан» шулай шаян көлү, искелеккән ирония һәм сатира ярдәмендә котылырга омтылу фактларын дөнья әдәбияты тарихында күп табарга мөмкин. Мәшһүр Бокаччоның «Декамерон» китабы ничек тууын, нинди идея уздыруын христиан дине тарихын, Урта гасыр христиан әхлак нормаларын белгәндә генә аңлап була. Чөнки, бер яктан, җор, шаян, икенче тарафтан трагик яңгыраган, үзендә әдәпсезлек белән нәфислек һәмназлылыкны бергә кушкан әлеге әсәрнең бөтен пафосы чиркәүлекне кире кагып, җир мәхәббәтенә дан җырлаудан гыйбарәт. Француз, рус әдәбиятларына мөрәҗәгать итсәк тә, характерлы мисалларны шактый күрербез. Шунысы да мөһим: мәхәббәт тематикасына ирекле, мөстәкыйльлек даулаган дәвердә, реалистик сурәтләү алымнары белән бергә, натурализмга, аның дорфарак формаларына да юл куела, чөнки тәҗрибә азлыгы, реалистик чараларның нормага утырып җитмәве аркасында бөгел җибәрүләргә урын кала. Мондый житешсезлекләрне җиңү, реализм юлында чын сәнгатьчә югарылыкка күтәрелү, ягъни чама һәм хис микъдарын билгеләүдә оптималь нормалар табылу ул әлеге көрәшнең югарырак этапларында гына мөмкин.

Әлбәттә, искене инкяр итү, яңаны раслау ул көлү һәм иониягә генә кайтып калмый. Җир кешесенең гүзәллеген мактау, рухның гына түгел, җисемнең дә бәхеткә, ләззәткә хокуклы икәнлеген исбатлау өчен соклану, мәдхия җырлау юлын да сайларга мөмкин. Дантеның гүзәл Беатричега, Петрарканың Лаурага багышланган мәдхия-одалары менә шундый соклану һәм табыну юлының әдәбияттагы гәүдәләнеше иде. Моның тагын бер мисалын Көнбатыш Европа сынлы сәнгате тарихында күрәбез. Мәсәлән, Ренессанс дәверендә һәм аннан соң бөтен Европа сәнгатендә, кем әйтмешли, «шәрә ханымнар армиясе» тууын, җисми гүзәллекне беренче планга куйган шул теманың буыннан-буынга, илдән илгә күчүен алыйк. Әгәр бу күренешне гадәти «әдәпсезлек», ямсә эротик азгынлык нәтиҗәсе дип бәяләмибез икән, моның объектив сәбәпләре бар: әлеге бихисап «Венералар» иконачылык ярдәмендә пропагандаланган, шунысы белән гасырлар буена теңкәгә тиеп беткән Мәрьям-аналарның, Гайсаларның балавыз чырайларын, җансыз тәкъвалыгын кире кагу рәвешендә туганнар.

Бу уңай белән шуны да әйтеп узарга кирәк. Европа рәссамнарына дәвамлы рәвештә кеше бәдәненең гүзәллеген мактау, олылау һәм шуның аша кешенең җисми бәхеткә хокукын раслау эшендә борынгы юнан-грек сәнгате үрнәк, күчергеч хезмәтен үтәгән. Объектив сәбәпләр аркасында сынлы сәнгате бик берьяклы үскән (җанлы объектларны ясау традициясе тәмам өзелгән), шуна күрә тирә-юньне сурәтләгәндә бердәнбер чара рәвешендә бары сүз сәнгате генә калган татарларда әлеге үзгәрешләрне кичергән чакта үрнәк булып бары

фольклор — халык иҗаты әсәрләре, аның гади лексикасы гына хезмәт иткән. Чараларның шулай чикләнгән булуын тойган Кандалый үзе дә кеше матурлыгын чын-чынлап олылар, аның физик гүзәллеген күрәп, тоеп сокланыр өчен сүз сәнгатенең генә җитеп бетмәвен яхшы сизә. Шуңа күрә ул мәгъшукасының кыяфәтен рәссамнардан ясатуны хыял итә:

Йә сурәтең ясатырга
Барыйм микән лә нәкъкашка?

(«Сахибҗәмал», XVII, 1)

Әгәр улсамиде мокътад,
Сурәтләр кыйлмага остад,
Сурәтеңне ясатып һәфтад,
Итәрдем халкъара мәншүр.

Йә сурәт кыйлгучыларга
Сәнең өчен барыйм микән?
Сөеп йөргәнләрең, җаным,
Китә белмәс күз алдымдин...

(«Шәфгый», III, 5; V, 2)

Ләкин сөйгән ярның матурлыгын күрә белгән, чын гүзәллектән соклана алган Кандалыйга мәгъшуканың сынын шулай рәсемдә тудыру бәхете насыйп булмый. Шагыйрь сурәтне сүзләр ярдәмендә генә ясау белән канәгатьләнә, һәм бу юнәлештә ул традицион кара кашлар, алсу йөзләр, ак якутлар, нәргис күзләр ярдәмендә тасвирлап, гүзәл кыз рәсемен тудырудан тыш, аңа хәтле әдәбиятыбызда мисалы күрелмәгән кыю, тоеп сокланырлык конкрет образлар тудыра:

Иниләрең икән зурлар,
Кояштик бирәдер нурлар.
Тамаша калдылар хурлар
Бу халемезгә оҗмахда!

(«Сахибҗәмал», XXIII, 7)

Әгәр моннан 150 еллар чамасы элек табылган шушы сурәт-чагыштыруның хәзерге шагыйрьләребездән Рәшат Низамиев тарафыннан яңадан тудырылуын:

...Уйлый-уйлый көннәренең алгысын.
Әй, дәртләнеп селти егет чалгысын.
Кыз балага сабырлыклар бирсәнә:
Күкрәгендә ике кояш тирбәлә!—

исәпкә алсак (әлеге строфаның совет чорында моңарчы бер дә басылмавын онытмыйк!), Кандалый ирешкән казанышның әһәмиятен беркадәр аңларга мөмкин.

Югарыдагы мисалны зур казаныш үрнәге сыйфатында бәяләүнең икенче бер сәбәбе дә бар. Ул шагыйрь кичергән иҗади үсүнең, яңага таба үзгәрүенең эчтәлегеннән гыйбарәт. Моны аңлар өчен тагын «Рисалә»гә әйләнеп кайтыйк. Әгәр әдәбиятка таба беренче адымнарын ясаган Габделҗәббар шагыйрь шул поэмасында укучыларын җәннәттәге хур кызларыннан сокланырга чакырса, «Сахибҗәмал»да исә әлеге «илаһи» гүзәллеккә ия җәннәт чибәрләренең үзләрен җир кызының табигый матурлыгыннан сокландыра. Бер гомер дәвамында матурлык идеалына карата иман үзгәрү, кыйбла алмашыну процессы менә шулай тәгәл йөз сиксән градуска борылу белән тәмамлана!..

Нәкъкаш — рәссам.
Мокътад — житакче (әмер бирүче).
Остад — оста, остаз.
һәфтад — житмеш (мәртәбә).
Мәншүр итү — нәшер итү, тарату.

Мондый яңарыш исә Кандалыйдагы мәхәббәт концепциясенең эчтәлеге белән бәйле иде. Шагыйрьнең тоюы һәм яктыртуынча, мәхәббәт — ул матур сүзләр объектына әйләндереп [illegible] бер асрым вакыйга гына түгел, бәлки нәтиҗәсе һәр шәхеснең тормышы эчтәлеген билгеләп торган зур, хәлиткеч күренеш:

Бу язмакдин күңелнең туясы юк,
Сәне алмай күңелнең тынасы юк.

*** («Мәхәббәтне саңа салды ходаем...»)

Шагыйрьдә мәхәббәт хисенең дини ритуаллардан өстен куелуы, югарыда күргәнебезчә, Аллага ышанычка каршы куелуга кадәр барып җитә яза. Мондый фактларны бер «Фәрхи» әсәре өчен генә хас ялгызак күренеш дип карарга ярамый. Кандалыйда мәхәббәтне гомумән дини иманга каршы кую очраклары да бар:

Бу инәлүләрем таш да белерде,—
Урыс кызы д и н е н т а ш л а п кәлерде.

*** («Китабларда бу сүзне күргәнем бар...»)

Кандалый җир тормышының күренеше булган мәхәббәтне шул тормышның чиге—«нәтиҗәсе» булган Үлем кебек фәлсәфи зур категория белән чагыштырып карый, хәтта мәхәббәтне үлемнән өстенрәк куя:

Гыйшыклык мисаледер яхшы гөлдер,
Алалмасаң, ахыры бер үлемдер...

(«Магъшукнамә»)

Черел бетсә дә һәм җисмең,
Сахибҗамал дәйүб исмең,
Сылу чабың, матур исмең
Кала сөйләргә телләрдә.

(«Сахибҗамал», II, 9)

Мәхәббәтне болай «мәңгелек категория» итеп карарга омтылу Кандалыйның Бәдига исемле бер кызга багышланган шигырендә гаять образлы һәм көчле әйтелгән. Мәсәлән, Зөләйханең Йосыфка, Сәйфелмөлекнең Бәдигыльҗамалга, Мәҗнүннең Ләйләгә, Фәрһадның Ширингә булган олы сөюләре, аларның мәхәббәт юлындагы аһ-зарлары хакында язгач, шагыйрь үзендәге хиснең көчен дә шул олы мәхәббәтләр дәрәҗәсенә күтәреп бәяли:

Кя мән дәхи бу арага тезелдем,
«Бәдигам!» — дип өзелдем лә, өзелдем!

*** («Сөйгәнемә инанмасаң, Бәдига...»)

Бу гашыйклык чабы китде
Сарапул берлә Самарга;
Йосыф берлә Зөләйхатик
Атымыз калды санарга.

(«Сахибҗамал», XVIII, 3)

Болай бер шәхси мәхәббәт нисен дөнья әдәбиятларындагы зур гашыйклар дәрәҗәсенә күтәрү, асылда шагыйрьнең үз мәхәббәтен олылау максатыннан килеп чыккан булса да, ул ахыр чиктә һәр конкрет мәхәббәт хөрмәткә, алкышка лаек дигән фикерне үткәрүгә хезмәт итә. Чөнки җенси сөю хисе ул гадәти генә маел омтылышы түгел, бәлки көчле хис белән бер-береңә тартылу аша ике җанның рухи кушылуы, берләшүе, ары таба бер бөтенгә әверелүе дигән сүз:

Күз карашын җан эчендә җан идәм,
Шәгъләсене тән эчендә кан идәм...

Шәгъләсене — яктылыгын, нурын.

Шагыйрь аңындагы мәхәббәткә карата булган менә шундый тирән мәгънәле гомум мөнәсәбәт аның конкрет әсәрләренә кабатланмас сыйфат — мәхәббәт лирикасында чын әдәби шедеврлар тудыру мөмкинлеген бирде. Әйтик, мәгъшукасын иң матур, иң ягымлы сүзләр белән мактый, олылый, иркәли, эретеп җибәрер дәрәҗәдә назлый алуда шагыйрь искитәрлек хис юмартлыгы күрсәтә, гадәти сүзләрдән — җыр, җырдан исә тәгәл бер симфония лейтмотивы оештыру югарылыгына ирешә:

Ай гынам ла, көн генәм лә, гөл генәм,
Җан гынам ла, тән генәм лә, көн генәм!
Җәүһәрем лә, гәүһәрем лә, нур гынам,
Сәрвием лә, җәннәтем лә, хур гынам!..
Ташламачы, ай йөзем лә, гөл йөзем,
Тыңласана, кич ходайчөн, бер сүзем!..
Гүзәлем лә, кояшым ла, күз генәм,
Ташлама са, беләсең лә, сер генәм!
Назигем лә, үзогем лә, гүзәлем,
Фәрхи, айгыл, ничек итеп түзәлем?!

Матур сүзләрне өсте-өстенә өеп хис «ябырылдыру»да, гашыйкның мәгъшукасына булган ихлас омтылышын җыр югарылыгында гәүдәләндерүдә шагыйрь Сахибҗәмалга мөрәҗәгатендә аерата виртуозлык күрсәтә. Элек ул мактауны үзеннән, дөресрәге, сылу кыз сыйфатының үз күңеле аша ничек кичүен тасвирлаудан башлый:

Гөлем бул, гөл йыгачым бул,
Йә былбыл-сандугачым бул,
Бу дәрдемгә гыйляҗем бул,
Сахибҗәмал абыстай ла!

Сәнең илә аем-көнем,
Сәнең илә көнем-төнем,
Сәнең илә төшем-өнем
Үтәдер, и абыстай ла!

Шул рәвешчә, үз халәтен тасвирлаган шагыйрь аны шундый хәлгә төшергән чибәрнең күркәм сыйфатларына күчә:

Йөзең алсу кызыл гөлтик,
Йаңакың кызыл алматик;
Кызыл алма кеби кызны
Нәсыйб итәр микән алла?

Кашың кара тумышыңдан,
Битең һәм якты гөлбостан,
Сәнеңтик зифа җан дустдан
Аермасын кәрим алла!

Йөзең нур хури гыйльмандан,
Сүзең хуб хури вилдандан,
Үзең сылу йәш угъландан,—
Матур кыйлмыш ушал алла!..

Күзең җаным зыйасыйдыр,
Күзеңнең тутыйасыйдыр,
Үзең бәгъ‍рем парәсыйдыр,—
Ничек итим лә, ух алла!..

Сүзең шекер илә миннәт,
Йөзең дә ай кеби зиннәт,

Айгыл — әйткел: әйтче.
Гыйляҗ — дәва, чара.
Кәрим — олы, бөек.
Хури гыйльман, хури вилдан — оҗмахка кергән кешеләргә хезмәт итүчеләр.
Ушал — шул, шушы.
Зыйа — яктылык, нур.
Тутыйа — күз даруы.
Миннәт — канәгатьлек, шекераналык.

Үзең дә хур кеби,— һиммәт
Идебдер зөлҗәлял алла!

И бәгырем мивәсе, җаным,
И кызлар шивәсе, җаным,
Итәкдә сөйәсе, җаным,—
Итәр микән хәлял алла?

И белмисең, Сахибҗәмал,
Гыйшыклык халь икән яман,
Сагышың берлә һәр заман
Торамын бимәҗал, алла!

Мондый юлларны яза алган шагыйрьнең мәхәббәте никадәр ихлас, сөю куәсе нихәтле көчле икәнлегенә шикләнеп булмас сыман.

Кайвакытларын шагыйрь үзен биләп алган әлеге хиснең сихер яше тылсымлы көчкә ия булу ихтималын да кире какмый:

Йә тылсымләме сөйдердең?—
И яндырдың ла, көйдердең!
Кырык төенне төйдердең,
Катып бирдеңме йә ашка?!

(«Сахибҗәмал», XVII, 3)

Әмма ләкин аның бу олы, серле мәхәббәте мәгъшукасы тарафыннан кире кагылып, трагик рәвештә өзелә. Бимәҗаль — чарасыз калган шагыйрь, үзенең Сахибҗәмаленә карата булган олы хисләрен тасвирлаудан туктап, кабул кылынмаган мәхәббәтенең серен, табигатен тагын бер кат ачыкларга теләгәндәй, бер яктан патетик әйтелгән, икенче тарафтан, зур фаҗигагә дучар йөрәкнең иңрәве сыман трагик яңгыраган сорау куеп, әсәрен тәмамлый:

И белсәң ирде хикмәтне:
Гыйшыклык дәрдме, рәхмәтме?
Вә йа къәһәрме, зәхмәтме —
Салындырмы залял алла?!!

Әйе, нәрсә ул мәхәббәт: бәла булып ябышкан чирме, күктән иңгән рәхмәтме, бәхетме, йәисә алла җибәргән җәфамы, бәла-казамы — къәһәрме, зәхмәтме, залялмы?!.

Габделҗәббар Кандалый моннан 150 еллар чамасы элек, сакалына чал кереп өлгергән вакытында тагын бер сөеп, көеп әйткән бу сүзләр бүген дә актуаль яңгырыйлар, һәм ул куйган сорау әле хәзер дә,— гәрчә шуннан бирле дөнья әдәбиятында мәхәббәт хакында меңләгән-меңләгән әсәрләр язылып, әлеге сорауга күпләгән акыл ияләре тарафыннан җаваплар эзләнсә дә,— һаман да ачык килеш кала килә...

Кандалыйның әдәбиятыбызда тоткан бер мөһим урыны, безнеңчә, аның Мәхәббәт дигән гаҗәп хикмәтле, серле һәм олы күренешне әдәби фикер урталыгына төп э д ә б и г е р о й сыйфатында куя һәм соклангыч итеп гәүдәләндерә алуыннан гыйбарәт.

Мәсьәләгә шушы яктан якын килгәндә генә без шагыйрь мирасының төп фәлсәфәсен — ул иҗатның әдәби процессыбызда, мәгърифәтчелек дигән иҗтимагый хәрәкәтебездә тоткан конкрет тарихи урынын дөрес билгели алачакбыз. Чөнки Мәхәббәт дигән нәрсә, элекке мулла-мунтагайлар тукыганча һәм хәзерге ала-кола ханжалар, кызыллы-яшелле мещаннар раслаганча, гадәти гыйшык-мыйшык һәм мәел азгынлыгы түгел. Кандалый чорында исә ул тагын шәхеснең хискә, димәк, хисләргә бәхеткә хокукы да дигән сүз иде...

Зөлҗәлял — югары, бөек.
Мивә — җимеш.
Шивә — наз, нәзакәтлек.
Бимәҗал — көчсез, чарасыз.

Шулай итеп, Галделҗәббар Кандалый иҗатында барлыкка килгән әлеге гүзәллек идеалындагы иман алмашыну ул, теләге буенча серле абстрактлыкка юнәлсә дә, чара һәм нәтиҗәләре ягыннан ханжалыкка барып тоташучы охравилыктан тәмам йөз чөерү, реаль дөньявилык позициясенә күчү дигән сүз иде. Бу хәл исә үз әһәмияте белән бер аерым иҗатның гына казанышы түгел иде. Бу үзгәрешләр асылда бөтен язма әдәбиятыбызда гадәти кеше мәхәббәтен тасвирлау, олылау буенча әлек мисалы күренмәгән реалистик конкретлыкка, сәнгатьчә нәфислеккә, самими ихласлыкка, димәк, чын гуманистик биеклекләргә ирешү нәтиҗәсе дә иде. Әдәбиятта барлыкка килгән мондый процессны, әлбәттә, иҗтимагый-социаль алшартларыннан аерым куярга ярамый.

Югарыда яңгыраган бер фикер — «Сахибҗәмал» әсәренең төп герое сөю хисе, мәхәббәт дигән сүзләр очраклы гына әйтелгән, ялгыш ычкынган купшы гыйбарә түгел. Габделҗәббар Кандалый ул, шагыйрь буларак, һәр җилфердәгән итәк артыннан олагып китүче примитив җилбәзәк тә, кыска вакытка теләсә кинди хатын-кызны бер «эләктереп» алуын принципка әйләндергән «татар Дон Жуаны» (Г. Рәхим охшатуы) да түгел. Ул күпкә катлаулы һәм трагик шәхес. Бер үк вакытта аның катлаулыгы үзенең искитәрлек гадилегеннән килә. Ул, тормыш һәм гамәлләрендә үзенчә садә кеше буларак, шигырьләренә үзенең чын сөйләгәннәре белән бергә аңар артык кагылышы булмаган башка кызларның да исемнәрен керткән. Әйтик, аның Әминә дигәннәре сабакташ егетнең сөйгәне булса, аңа багышланган шигырьне Габделҗәббар әлеге иптәше исеменнән язган. Җәмилә белән Рабиганең, хәтта Фатыйманың да шагыйрьнең үз сөйгәннәре булуы расланмый. «Фәрхисәрур» исеменең реальлеге бик тә шөбһә тудырган кебек, «Бәгъидә» исеменең барлыкка килүе дә зур аңлашылмаслык нәтиҗәсе (*** («Ки бән яздым сәңа, җаным ничә хат...») дигән шигырьгә бирелгән искәрмәгә карагыз). Бәдига дигән чибәргә багышланган әсәр исә, чын гашыйкның өзелеп инәлүеннән бигрәк, кызны читтәнрәк күзәтүче шагыйрьнең мәхәббәт хакында гомумән фикер йөртүен, әлеге кыздан бераз көлеп алуын хәтерләтә. Гомумән, шагыйрь әсәрләрендә очрый торган һәр хатын-кыз исемен дә шагыйрьнең үз мәхәббәтенә бәйләргә нигез җитми. Алар Кандалый әсәрләренә төрле сәбәпләр аркылы килеп кергәннәр, кайберләре очраклы исемнәр.

Хатыннарны өчәү-дүртәү итеп асраса да (әйе, Габделҗәббар хәзрәт көнкүрештә, югарыда әйтелгәнчә, полигамчы — күпсөяр булган), шагыйрь Кандалыйның чын мәхәббәте бер генә — Сахибҗәмал! Шагыйрьнең беренче хатыны Гөлбостан абыстай, ихтимал, өйләнешкән чакта гына егет кешене бераз мавыктырган, шуңа күрә исеме иренең бер-ярым шигырьләрендә генә очрый. Хәлимәкәйгә багышланган шигырьләрнең дә халыкта киң таралмавы шундый ук нәтиҗәгә нигез бирә. Әмма әдәби яктан иң көчле әсәрләренең берсендә чын-чынлап табыну объектына әверелгән Фәрхигә килсәк, монда мәсьәлә катлаулырак, һәм ул махсус карауны сорый.

Югарыда бер әйтеп узганымча, Фәрхи туташ исемен эченә алган әлеге шигырьләрнең башта Сахибҗәмалга адресланып язылган әсәрләрдән, аннары, мәхәббәте тәмам кире кагылгач, Сахибкә ачу итеп, икенче чибәргә, Фәрхигә, «гыйшык тоткан» һәм шуңа өйләнергә ниятләп йөргән вакытта (уңышсыз мәхәббәт газабыннан акылсыз гамәлләр барлыкка килү киң таралган күренеш) шагыйрь тарафыннан адресаты һәм беркадәр структурасы үзгәртелү нәтиҗәсендә пешкан булуы ихтималга якынрак. Киресенчә булганда, олы яшьтәге Габделҗәббарның кайчандыр үзе мәчет михрабы итеп табынган Фәрхиен аерып җибәрү факты аңлашылып җитми. Сахибҗәмалга багыш-

лаган әсәрләрендә: «юлыкдым аңлы-миңле җүләр ярга...», «отыйм дигәндә отылдым...», «соңыннан көчкә котылдым,—ки биш ел соң...»— дигән ачы үкенүле сүзләре әлеге ялгышка, әлеге дуамал өйләнү һәм асрылышуга ишарә булса кирәк. Юл уңаенда шуны да искәртеп узыйк: Фәрхинең ничек йоклый алмый ятуын күз алдына китерүче шагыйрьнең (I, 11—13) һәм Сахибҗәмал белән җәннәттә кавышуын тасвирлаучы (XXIII, 6—8 строфалар) авторның мәхәббәт актын сурәтләүдә олы ирләрчә «уртак» фикер йөртүе һәр ике әсәрнең дә нигезендә бер үк хис һәм кичерешләр ятуына ишарә итә. Кандалыйның бу әсәрләрне язган чакта күптән өйләнгән ир агасы булганлыгын раслый торган башка факторлар да бар. Мәсәлән, кызның киреләнүен, йәисә икеләнүен бетерә алмыйча җәфаланган шагыйрь, аның агасы белән җиңгәсенә мөраҗәгать итеп, әгәр тегеләр сөйгәнен күндереп бирсәләр, үзенең элекке хатынын (бәлки хатыннарының берсен) аерачагы хакында вәгъдәләр бирә:

Әгәр тәзвиҗ идәрсәм кардәшеңне,
Хәлегъ идәм хәлялемне соңыннан.
*** («Карарым калмаең яздым сәламең...»)

Бу фактларның һәммәсе Сахибҗәмалга һәм Фәрхигә күндерелгән әсәрләрнең яшь җилбәзәк Габделҗәббар тарафыннан язылган шигырьләр түгел, бәлки ир агасы Кандалый каләменнән чыккан шәхси трагедия авазлары икәнлеге хакында сөйләсә кирәк.

Шушы әйтелгәннәрнең һәммәсен исәпкә алсак, «Сахибҗәмал» әсәренең төп герое, исеме аталган чибәр кыз булудан бигрәк, шул кызга карата туган хис — Мәхәббәт дип танысак, бу әсәрнең жанры хакында барган бәхәсне (поэмамы, түгелме дигән бәхәсне) икенчерәк югарылыктан торып хәл кылырга мөмкин шикелле — бу әдәбиятчыларыбыз алдында торган киләчәкке бурыч.

Шагыйрьнең бер кешегә багышланган әсәрләрен икенче берәүләргә адреславы, димәк, принципта талымсызлык күрсәтүе мәсьәләсенә килсәк, аны Кандалыйда күп очрый торган үз-үзен кабатлаулар күренеше белән икенче урында карарбыз.

Кандалый иҗатында гәүдәләнгән трагизм исә ул, безнеңчә, беренчедән, шагыйрьнең идеалы белән реаль чынбарлыкның, шул ииҗездә сүзләр белән гамәлләрнең бәрелешүенә барып тоташса кирәк. Чөнки тормышында, конкрет гамәлләрендә рухани мохит җимеше сыйфатында полигамчы (күпсөяр — күп хатынлы) булган Габделҗәббар хәзрәт хисендә, идеалында моногамчы — берсөяр һәм чынлап та сөя белүче шагыйрь Кандалый иде.

Икенчедән, чын гыйшыклык хисенә сәләтле, гадәти җир мәхәббәтен иләһи җыр югарылыгына күтәрә алырлык югары зәвекъле, нечкә күңелле эстет шагыйрьнең табигатьтән килә торган эчке гүзәллегенә аның тышкы кыяфәте — физик зәгыйфь үк булмаса да, чыраеның ямьсезлеге туры килми иде. Сахибҗәмалның озак иңәлдерүләрдән соң бер күнеп, аннары биргән вәгъдәләреннән кире кайтуы («Эшем дә йитде чигенә, Сахибҗәмал кире чигепә...») шагыйрьнең шушы тышкы сыйфатына бәйле булса кирәк. Һәрхәлдә, мөңләгән шигъри юлларның берсендә дә, ялгышып кына булса да дигәндәй, лирик геройның үз кыяфәтенә (физик көченә, ирләрчә матурлыгына) ишарә итмәве әлеге ямьсезлек хакындагы хәбәрнең (И. Бәхтиев җыйган мәгълүматлардан) дөреслеген куәтли төшә.

Шул рәвешчә өзелеп, ихлас күңелдән сөйгән яр аның чын мәхәббәтен кире кагу нәтиҗәсендә шагыйрьнең үз мәгъшукасы хакындагы

Тәзвиҗ идәрсәм — никяхлап алсам.
Хәлегъ идәм — аерам, талакъ итәм.

шэхси көенүләре мәхәббәт турында гомумән уйлануларга, борчылуларга — олы кайгыга әверелә. Күп очракта Кандалыйның гомумиләштергән рәвештә фәлсәфи фикер йөртүләргә күчүе аның күңелендә шәхсилек белән гомумилекнең шулай бәрелешүен, укмашуын, хәтта буталуын барлыкка китерде. Шуңа күрә шагыйрьнең Сахибҗәмалга булган көчле мәхәббәтен тасвирлауга багышланган төп әсәр сөю хакындагы әлеге фәлсәфи сорау белән тәмамланган шикелле, мәхәббәтнең сере-табигате турында гомуми уйланулар рәвешендә язылган әсәрләр дә Кандалыйда шактый. Мисал өчен аның «Бәдре-лямигъ дилбәрә...», «Бер тамаша бу гыйшыклык...», дип башланган шигырьләренә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Мондый әсәрләрдә гадәти җир мәхәббәтенең иң бөек хис, иң изге күренеш икәнлеген раслау омтылышы фикерләүдә, тасвирлауда җәлеп ителгән зур авторитетлардан — пәйгамбәрләр мөнәсәбәтеннән, Зөләйхаләр язмышыннан күренә. Шагыйрь күңелендә бу ике башлангычның үрелеп бергә яшәве мондый аерым фактлар белән генә чикләнми, бәлки аның бөтен иҗаты буйлап сузылып бара. Шуның өчен алшартында конкрет шәхси мәхәббәт хәсрәте яткан Кандалый шигырьләре үзенең әлеге гомумилеккә ирешкән сыйфаты белән халыкта киң популярлык казана, хәтта әлифба-әлифба белән бөтенләй фольклорлашып, халыклашып бетә. Гашыйклардан мәгъшукаләргә җибәрелгән һәр хатта диярлек Кандалый шигырьләренең юлларын, йәнсә ул тапкан, эшкәрткән мактау сүзләрен табарга мөмкин. Шул рәвешчә һәр гашыйк өчен аның шәхси уй-хыяллары аларның үз кичерешләренә әверелеп, аның сагышлары башкаларның да уртак моң-зарлары булып яңгырый. Мондый процесс нәтиҗәсендә Кандалый гыйшкы белән бергә аның зарларын үзләренә юаныч яки «тел ачкычы» итеп алган гади укучыларның сөю хисләре дә Йосыф — Зөләйха, Сәйфелмөлек — Бәдигыльҗамал, Мәҗнүн — Ләйлә, Фәрһад — Ширин мәхәббәтләре дәрәҗәсенә күтәрелә.

Әдәбиятка Кандалый алып килгән яңалык — яңа тематика, яңа герой, яңача сөю хисе дигән, бер карауга үтә шәхси, интим күренеш — шәхес бәхете, аның бәхеткә хокукы, шуларның һәммәсе аша кешенең җәмгыятьтәге дәрәҗәсе дигән зур киңлекләргә алып чыкты.

VII

Чикләнгән әдәби кысаларда беренче адымнарын ясаган Габделҗәббар-шәкертнең карашыннан кеше язмышын, шәхес бәхетен аңлауда табигый халыкчанлык, чын гуманизм югарылыгына Кандалый-шагыйрьнең ничек ирешүен тирәнрәк күзаллар өчен, безгә, ниһаять, ул иҗатка нигез булган традицияләрдәге прогрессив башлангычларга мөрәҗәгать итү зарур.

Беренче әсәрләрен ясалма телдә язудан башлаган шагыйрь әдәби эшчәнлегенең соңгы чорында халык теленнән аерылмаслык дәрәҗәдә гади итеп язу югарылыгына күтәрелде. Бу юнәлештә шагыйрьгә төп таяныч булып халык авыз иҗаты әсәрләре хезмәт иткәнлеге бәхәссез. Халыкча кыска, образлы һәм йомры итеп әйтергә омтылуның кайбер үрнәкләрен без «Рисалә»не анализлаган чакта күргән идек. Әмма, югарыда әйткәнебезчә, ул чор әсәрләренең теле өчен, кайбер аерым-аерым якты чаткыларны исәпкә алмаганда, гомумән, «караңгылык» — аңлаешсызлык хас иде. Шуңа күрә дә «Рисалә» белән «Кыйсса» актив әдәби репертуарга керә алмыйча калалар. Безнеңчә, әсәрләренең шушы хосусиятен тиз тоеп алган автор үзе үк, шул тәҗрибәдән чыгып, кыйбласын үзгәрткәнгә, халык арасында популяр булырдай әсәрләр язарга игътибарын юнәлткәнгә охшый. Гарәп, фарсы һәм әдәби төрки телләрне мәдрәсәләрдә үк яхшы үзләштергән, димәк,

шул телләрдәге әдәби әсәрләрне күп укыган Габделҗәббар Ләйлә һәм Мәҗнүн, Фәрһад һәм Ширин, Таһир һәм Зөһрә, Сәйфелмөлек һәм Бәдигыльҗәмал кебек мәшһүр гашыйк-мәгъшуклар хакындагы дөньяви әсәрләргә йөз бора. Шулардан Кандалый үзе өчен төп өйрәнү, ияру үрнәге сыйфатында халкыбызда иң күп таралган истәлекне, XIII йөз башыннан бирле әдәби репертуарыбыздан төшмәгән бөек әсәрне — Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын сайлый һәм аңа карата булган үз мөнәсәбәтен бөтен иҗаты, гомере буена саклап кала.

Шагыйрьнең Кол Галидән өйрәнә башлавын аның яшьлек чорына караган әсәрләреннән ук күрергә мөмкин. Мәсәлән, «Нәзъме Йосыф» һәм «Нисъф-ел-мөлякъәт...» шигырьләре поэтик формалары буенча да, аерым мотивлары, сурәтләү чаралары ягыннан да шундый әсәрләрдән. Боларга «Уникe күркә...» дип башланган парчаны һәм Кандалыйныкы булуы ихтимал «Мәдех кыйлсам, охшайурсән...», «Кәҗә бәете» әсәрләрен кушып карасак, дәлилләрнең саннары тагын да ишәя төшә *.

Бу аталган мисаллардан «Нисъф-ел-мөлякъәт...» шигыре аерата игътибарга лаек. Аны әтрафлап анализлау безгә, беренчедән, яшь Кандалый ияргән үрнәкне төгәлрәк ачыкларга ярдәм итсә, икенчедән, аның каләменнән чыккан шигъри «хатның» башкалар тарафыннан да ничек эшкәртелүен, үзгәрүен, ягъни фольклорлашуын күрергә мөмкинлек бирә (истәлеккә бирелгән аңлатмаларны карагыз). Өченчедән, бу әсәрен язган чакта Габделҗәббар үзе дә шәкертләр репертуарындагы башка төр китаби фольклор истәлекләреннән файдаланган икән. Мәсәлән, әлеге шигырьнең 22 строфасында «хатасыз һич кем булмас хакъдин үзгә» дигән бер юл бар. Ул — кулъязма китапларның колофоннарында, ягъни текстның бетем өлешендә кулланыла торган махсус формуладан үзгәртеп алынган. Укучылардан күчермәдә китүе ихтимал хаталар өчен алдан ук гафу үтенү нияте белән языла торган, Кандалыйга хәтле үк киң мәгълүм булган әлеге формула болайрак яңгырый:

Хат хатадыр, хатасын орма йөзгә,
Хатадин хали ирмәс хакъдин үзгә...
Хата ирсә — каләм илә сыйаһы,
Фәкыйрь язгучының күпдер гөнаһы...

Соңгырак чор Кандалый иҗатындагы Кол Гали йогынтысын өйрәнгән чакта андый тәэсир күренешләрен ике төргә бүлеп карарга мөмкин. Беренче төр сыйфатында әлеге истәлектәге кайбер сурәтләү чараларының Кандалыйда демонстратив рәвештә турыдан-туры файдаланылуын (юлларны, строфаларны чак кына үзгәртеп, үз текстына кертеп җибәрүләрне), шулай ук әсәр геройларын төгәл атап, охшаш вакыйгалар, ситуацияләр хакында ачык хөкем йөртүләрне алырга кирәк. Мисалларны бер-бер артлы китерә башласак, сүз озакка китәр иде. Шуңа күрә монда, югарыда исемнәре аталган шигырьләрдән тыш, *** («Й белмисең, шөйлә булдым...»), *** («Сәлам яздым сиңа,

---

* Университетта укый башлагач, Җәвад Алмаз җитәкчелегендә «Кыйссаи Йосыф» китабының Ардашир күчермәсе буенча курс эше язып йөргәндә, миңа укытучым Якуб ага Агишевтан (1899—1972) Йосыф китабына шарж рәвешендә язылган, элекке Пенза ягы мәдрәсәләрендә киң таралган шаян шигырьләрне ишетергә туры килгән иде (Зөләйханең көянтә күтәреп суга барулары, хатынына ачуланган пәйгамбәр Йосыфның сукачы татарга әверелеп, «җүнсез» хатынын көянтә белән тәртипкә чакырулары һәм башкалар). Кызганычка каршы, шул вакытларда, аннан соңрак та, форсатның кадерен белмәү аркасында, әлеге шигырьләрнең текстларын язып алмаганмын. Калган эшкә кар ява дигәндәй. Якуб аганың аларны кәгазьгә теркәп кую хакындагы нияте дә тормышка ашмыйча калды.

Хали ирмәс — азат түгел.
Сыйаһ — кара, язу карасы.

сәрвиҗәмалем...»), *** («Сөйгәнемә инанмасаң, Бәдига...»), *** («Сәламулла күземнең карасыйга...», ***(«Колак тотып ишет, җаный...»), *** («Мәхәббәтне сәңа салды ходаем...») ише аерым әсәрләргә, аларга бирелгән аңлатма һәм искәрмәләргә махсус күрсәтү белән канәгатьләнибез. Ләкин характерлы бер-ике мисал китерү дә артык булмас.

Кандалый өчен иң көчле мәхәббәт — ул Зөләйха гыйшкы:

Исем китәр ки сән әбызтутыйга:
Бәне салдың Зөләйханең утыйга.

Шулай ук безнең шагыйрь өчен матурлык идеалы булып Кол Гали тудырган образ, иң зур мактау сүзе булып сөйгәнен Зөләйхагә охшату, тиңләштерү хезмәт итә:

Сачең охшый Зөләйханең сачена...

Матурлык исмене алдың,
Хәланкъ әчрә дан алдың,
Зөләйха урнына калдың,—
Фида җаным сәңа, җаный!

Кандалыйга Кол Гали ясаган тәэсирнең икенче төрен борынгы шагыйрь тудырган кайбер образларның системалы рәвештә кабатлануы, үстерелә-үстерелә кулланылуы тәшкил итә. Конкрет мисал рәвешендә сәба (сәбах) җиле — иртәнге җил образын алырга мөмкин. Кол Галидә ул җил сөекле улыннан аерылган, олы хәсрәттән сукырайган карт атага алла кодрәте белән баласының исәнлеге хакында хәбәр китерүче иляһи зат сыйфатындарак тасвирлана һәм, әйтергә кирәк, сәнгатьчә көчле, матур тәкъдим ителә. Башта сәба җиле ходайдан Йагъкубка хәбәр илтер өчен рөхсәт ала, ул карт атага улының исен китергәч, бәхетле ата аңар мөрәҗәгать итеп, үзенең чиксез шатлыгын әйтә:

Сәбах йиле халикъга зари кылды,
Фазле берлә халикъ аңа дәстүр вирди,
Бәширдән ук көн шуйлә борун кәлди,—
Йосыф йесин Йагъкуба кәлтүрер имди.
Искәдисә, халикъга шөкер кылды...

Әйдүр: «Бәнем Йосыфымның йеси кәлди,
Сәбах йиле кәлтүрди»,— дәйүр имди.

«Акрын искел, сәбах йиле, нә утәрсәң,
Сән, хәкъикъәт, Йосыфымдан ис дотарсән,
Җәрахәтем уңармага сән йитәрсән,—
Сон исәли, бән мөфәррәх улдым имди!»

Кайчандыр шулай бер янгырап алган хәбәрче җил мотивы, изге ата белән пәйгамбәр бала кавышуын иляһи көч ихтыярына бәйләүгә хезмәт иткән сәба җиле образы Кандалый иҗатында аерата мөһим урын биләде. Дөрес, ул образ тәүге мәртәбә Габделҗәббар-шәкерт әсәренә («Рисалә», XVIII, 7) үлем якынлыгын хәбәр итүче галәмәт сыйфатындарак килеп керә: «Сәба йиле килеп һәббәт, Нә вар наим күреп һәйбәт, Бу гәз сәңа килеп нәүбәт, Ки тәнһа калма сән дәрфан» *. Әмма соңрак шагыйрь иҗатында барлыкка килгән кискен

* Мәгънәсе: Иртәнге җил килеп исеп, кемнәр йокыда ятуын яхшы күреп, ул чак сиңа чират житеп, син фанилыкта (ваемсызлыкта) ялгыз калма.
Халикъ — яратучы; Алла.
Дәстүр вирди — рөхсәт бирде.
Шуйлә — шулай.
Йесин — исен (*йес* — ис).
Искәдисә — искәнде исә, исәп, исен сизеп.
Нә утәрсән — нигә (тиз) узасың.
Ис дотарсән — ис китерәсең.
Уңармага — төзәтүгә, дәвалауга.
Мөфәррәх — шат, сөенечле.

борылыш нәтиҗәсендә, ул образ әлеге серлелектән арынып, гади җир кешеләренә якын, хәтта аларның телләрен белүгә, серләрен аңлауга, хәлләренә керүгә сәләтле дөньяви күренеш — кеше өчен кадерле иртәнге җиләс җил рәвешендә гәүдәләнә. Шул ук вакытта сәба җиле күңелгә хуш гадәти һава күренеше генә дә түгел, ә илләр-җирләр гизеп йөрүче, шуңа күрә ераклардан яхшы хәбәрләр китерүче аерым бер сыйфатка ия җил ул:

Сәба йиле кеби исдең
Ки сәхраларда, илләрдә...
(«Мәгъшукнамә»)
Сәба йиле йөрер галәмне сүтеп,
Ки илдин илгә йөгерер үтеп-сүтеп...
Сәба йиле йөрер галәмне гизеп,
Җанкаем, торам хәбәрең көтеп...
(«Фәрхи»)

Шулай илләр, сахралар, галәмнәр гизеп йөрүгә сәләтле сәба җиле, ихтыяҗы чыга калса, безнең татар авылларына кагыла, конкрет кешеләр белән очраша, гашыйкларның йомышларын үти:

Сәба йиле исәр булса,
Түгәлбай атлыгъ илләрдән...
(«Мәгъшукнамә»)
Соңра: «Сәндин, дидем, и баде сәба,
Тагын барсаң кире ул Борнай таба,
Илтимасым ошбу сәба йиленә:
Бер хатым бар, илтсә Борнай иленә!..»
(«Фәрхи»)
Сәба йиле, исәр булсаң
Парау атлыгъ нәфис җайга,
Сәламемне тикергәйсән
Сахибҗамал абыстайга!
(«Сахибҗамал»)

Шул ук вакытта Кандалыйның сәба җиле гашыйклар арасында арадашлык итүче «өченче тараф» сыйфатында гына калмый, бәлки вакыт-вакыт аларның берсе белән кушылып китә яза, йәисә ихтыяҗларын үтәүдә аларның актив «хезмәттәшенә» әверелә:

Ирәм багындамы үсдең?
Йөрәгем бәгъренә кисдең,
Сәба йиле кеби исдең
Ки сәхраларда, чүлләрдә!..

Утырып сәба йиленә,
Очардым Парау иленә,
Куеп кулымны биленә,
Кысып Сахибҗамалемне...
(«Сахибҗамал», II, 4; XXI, 1)

Шулай итеп, Кол Галидә иляһи бер көч сыман серлелеккә өртелгән, шунысы белән абстрактлыгы көчәйгән, мәгәр матур тасвирланган сәба җиле Кандалыйда конкрет җирләрдә, конкрет мәгъшукларның теләгән маршрутлары белән йөрүче «үз сәбасы»на — үзенчә бер «матди» гәүдәләнгән әдәби геройга әверелә.

Шулай да игътибар итик: башта мәхәббәт шигырьләрендә нигездә гашыйклар арадашчысы рәвешендә үзләштерелгән, чарланган сәба җиле образы шагыйрьнең картлык көнендә аңар тагын да якынрак төшә, бала кайгысында интеккән хәсрәтле карт ата өчен иң якын сердәшкә әверелә. Улын өзелеп сагынган чакта туганнардан аерылышу темасына мөрәҗәгать иткән автор һәр «сәбах эчрә», һәр таң саен:

Баде сәба — сәба җиле.
Илтимас — үтенеч.

— Әйа йил, сән китәр булсаң...
Туганымны күрәр булсаң,
Дога дигел ки безләрдин,—

дип, үзенең иске дустына ялвара, шул рәвешчә җил образы яңа функцияләр исәбенә байый.

Мисаллардан күренгәнчә, борынгы язма истәлектән алынган, яңа психологик шартларда яңача трактовкаланган образда халык авыз иҗатыннан килә торган төсмерләр, әдәби чаралар аз түгел. Әйе, Кандалый борынгы шагыйрь яңгыраткан фикерләрне, шигъри сурәтләрне, анализның баш өлешендәге кайбер мисалларда чагылып киткәнчә, механик күчереп алу белән чикләнми. Ул үзе кабул иткән андый детальләрне иҗади үзгәртеп, сәнгатьчә үстереп ала. Мәсәлән, борынгы болгар-татар шагыйрендә егеткә гашыйк патшабикә Зөләйха «кол малаеның» чәчләрен тарап, энҗеләр үрсә *, Кандалыйда сөйгән ярның чәчләрен татарча «майлап тарап үрү» белән галим ир шөгыльләнә («Сахибҗамал», VIII, 9).

Безнең шагыйрь, кызга мөрәҗәгать итеп: «Сурәтең дөшемә керер. Дөшем эчрә күзем күрер»,— дип язса, укучы Зөләйханең төш күрүләрен искә төшерә **. Шулай ук Кандал авылы җырчысының:

Кашыңны әйләде кара,
Ачык итде ике ара.
Һиляльә охшашы вара,—
Чигелмеш, и ниһайәти...
Кашың кара сызылмышдыр,
Дешең — йенҗү, дезелмешдер...
(«Мәгъшукнамә», II, 22, 24)

дигән тасвирында да «Йосыф китабы» стиле, сурәтләү чараларын тануы кыен түгел.

Сахибҗамалның сүз тыңламыйча надан кияүгә чыгып, «маҗик» ирениән күрәчәк ихтимал җәфалары хакында сөйләгән чакта шагыйрь үзе кыздан инчек көләчәген хыял итә:

Ийбәрермен язып, көлеп:
«Менә, Сахиб, кияү сайла!»

Бу юлларны укыган чакта, изге төш күргәнлеге өчен Йосыфны ыргытучы кенче агаларының шәфкать сорап ялварган малайга: «Ялган төшең ярдәм бирсен!» — дигән мыскыллы җаваплары искә төшә ***.

Мондый сизелер-сизелмәс дәрәҗәдә нык яшерелгән «эчке» уртаклыктан тыш, Кандалыйда үрнәк әсәрдән кабул ителгән детальләрне фольклорча әйтелгән шигъри юллар белән үреп, халык авыз иҗаты исәбенә баетып биргән очраклар да шактый. Әйтик, түбәндәге ике бәйтнең беренчесендә кайчандыр Кол Гали кулланган сурәтләү чаралары сизелеп торса, икенчесендә халык җырларыннан алынган буяулар өстенлек итә:

Тулан айдик йөзең матур икәндер,
Ике битең кояш кеби икәндер.
Кашың кара сызылган күз өстендә,
Яңа айдик һауада — күк өстендә.
(«Фәрхи»)

Икенче бер урында Кол Галидән килә торган сурәтләү чараларын:

Кызыл алтын йаңакларың,
Ләгъле-мәрҗан дудакларың,—

* Кол Гали, 1983, № 549.
** Шунда ук, № 369.
*** Шунда ук, № 78 һәм № 80 — вариантлар.
Дудакларың — иреннәрең.

дип, иҗади үзгәртеп алып, шунда ук строфаны нәкъ үзенчә — типик Кандалыйча — турысын әйтеп тәмамлау үрнәген күрәбез:

Дил алырдай көчакларың,
Кайу берсен язам, җаный?!
(«Шәфгый»)

Шагыйрьнең Кол Гали мирасына мөнәсәбәттә халык авыз иҗатына таянуын күрсәтә торган тагын бер характерлы факт бар. Кандалый, әйтик, үзенең мәгъшукасенә гыйшык мәсьәләсендә Йосыф — Зөләйхаләрдән үрнәк алырга чакырып бер парча яза:

Сәлам яздым саңа, җаным, хәкъикъәт,
Йосыф — Зөләйхадән алгыл нәсыйхәт.

Һәм шунда ук, әлеге юллардан соң, нәкъ шул мотивка багышланган халык җырыннан да бер куплет күчереп куя:

Су буйларында ике сал,
Берсе генә каен, берсе тал;
Бән әйткәнгә ышанмасаң,
Йосыф — Зөләйхадин гыйбрәт ал.
*** («Сәлам яздым саңа, җаным, вәзидә...»)

Мондый фактлар (аларның күләмен-санын бермә-бер арттырырга мөмкин), әлбәттә, Кандалый мирасында халык иҗаты тоткан урын мәсьәләсенә карата махсус игътибар сорый. Шул ук вакытта югарыдагы мисаллар Кандалыйның халык иҗатына кеше бәхетен, аның мәхәббәттәге хокукын гуманистик планда аңлаган Кол Гали мирасы аша килүен дә күрсәтсә кирәк. Фольклор байлыгына шул яссылыкта якынлашкан шагыйрь иҗатының зур өлешендә мәкаль һәм әйтемнәрдән, җыр һәм мөнаҗәтләрдән актив файдалана, образлы, кыска һәм йомры итеп әйтү юлында халыктан өйрәнә. Мәсәлән, халыктагы «сайлаган — сазга, очраган базга» дигән фикер сюжеты шагыйрьдә мондый конкрет кулланылыш үрнәкләрен таба:

Баралсаң мәндин артыкка ярый ла,
Сәнектик сайлаган сазга тарый ла!
*** («Сөйгәнемә инанмасаң, Бәдига...») һәм
*** («Сәламулла күземнең карасыйга...»)

Бу сайлавың гакыл әзга,
Ки сайлаган кеше — тазга,
Йә төшәдер лә ул базга,—
Батып чыкмас, и җанкәй лә!
(«Сахибҗамал», XX, 8)

Халыктагы «ана күңеле балада, бала күңеле далада» мәкале дә Кандалыйда үзгәртелә-үзгәртелә кулланыла, ягъни оптималь вариант эзләүгә хезмәт итә:

Аның эстәгәне бер кыз баладыр,
Карап торсаң, аның күңле даладыр...
(«Мәгъшукнамә», I, 7)
Мәгъшукым бәнем бер кыз баладыр,
Ышанмагыл, аның күңле даладыр...
(Шул ук әсәрнең II нөсхәсендә)

Шигырь текстларында — «эреп сарка йөрәк маем» (вариантта: «эридер лә йөрәк маем») ише чын халыкча гап-гади, ачык, «Сөйгәнең төз кеби уып, Ки борнын кан илә юып», йәисә «җанымның эченә генә куяр идем, сыярмусән» ише фольклорча тыгыз, экспрессив юлларның мул очравы, һичшиксез, авторның мәкаль-әйтемнәргә игътибарлы булуын, шулардан эзлекле рәвештә өйрәнүен раслый торган факт.

Дил алырдай — җанны алырдай.

Югарыда бер әйтеп узганча, Габделҗәббар мәдрәсәдә укып йөргән чакта ук шәкерт дәфтәрләре дигән бездәге феномен күренеш ярдәмендә халык авыз иҗаты әсәрләре, бигрәк тә яшьләр репертуарында актив кулланылган мәхәббәт җырлары белән якыннан танышкан, аларның эчке рухларын, шигъри техникаларын үзләштерен үскән:

Сәнең буең Ак Иделнең камышы,
Сүләгән сүзләрең былбыл тавышы,—

дигән бәйттә *** («Бу хатымны кабул итеп аласың...») халык җырларыннан алынган образлар өстә үк ап-ачык ятсалар:

Күзе — нәргис, кашы — кара,
Нигдәй булыр бара-бара?!—
*** (*«Үсеп бара ла бер җаный...»*)

дигән шигырьдә китабилык белән фольклорча башлангычның өлешләрен аеруы бик үк җиңел түгел. Түбәндәге шигырьдә исә ике башлангычның шундый береккәнлеге тагын да калкурак гәүдәләнә:

Бу бала хәсрәте түкде
Кара сачларем башымдин,
Иңешләр ташды йәшемдин!..
*** (*«Бу бала хәсрәте түкде...»*)

Образлар тудыруга, фикер оештыруга шул рәвешчә халыкчанлык анча якын килү шагыйрьгә «Туган илем ерак калды, Җәйәү йөреп сыйрак талды...», «Сачең кара ирер төндик, Сачең ара йөзең көндик...», «Сәнең дәрдең бәңа дәрмандин артык, Сәңа йар булганым солтандин артык», «Кулың — ястык, сачең юрганым улсын» ише гади һәм мәгънәле, шулай ук «Мәхәббәт йебе киселсә, Әгәр салкын йиле иссә», «Хиялы тарихның нәкъеше улды, Сүзе — дилдә, хыялы күздә калды» кебек һәм матур, һәм катлаулы юллар иҗат итү мөмкинлеген бирде.

Язма әдәбият тәҗрибәсен дә, халык иҗаты серләрен дә шулай яхшы үзләштерү нәтиҗәсендә Кандалый кайчакларны күз белән күреп, тән белән тоярлык дәрәҗәдә калку образлар тудырды:

Ки ак йакут кеби балкып,
Ике садрең тора калкып,
Көйә күлмәк утдин балкып —
Нури алдың, галямәти!
*** (*«Сәлам язды сәлам артын...»*)

Җанлы сөйләм теленең нечкәлекләрен тирәннән тою, үз нәүбәтендә, гап-гади сүзләр ярдәме белән дә аптыраган күңелнең эчке халәтен төрле яклап чатылдыруга юллар ачты. Мисалга «Сәхибҗамал»да төрле урында төрле максатлар белән кулланылган шигъри юлларны алыйк:

И-и, и генә лә, и генә.
Ни булды мәңа, ни генә?
Буласы кеше бий генә,
Булып калдым ла кол гына.
(*XV, 1*)

И-и, и генә лә! И генә!
Ни булды мәңа, ни генә?
Эшемдә юк ла кей генә,
Никадәр язамык хатлар!
(*XVI, 5*)

Дәрдең — хәсрәтең, чирең.
Нәкъеше — сурәте, бизәге.
Дилдә — күңелдә; җанда.
Садрең — күкрәгең.

И-и, и генә лә! И генә,
Эшем дә булды чи генә!
Сәбәб кенәсе ни генә?
Бәйан итсә, и жанкәй лә!

(XX, 13)

Бу нидән булды чи генә?
Эшем дә йитде чигенә,
Сахибем кире чигенә,—
Исем китәр, и жанкы лә!

(XX, 14)

Фольклорча фикер йөртү, сүзләрдән виртуоз файдалана алу шагыйрьгә көтелмәгән гиперболалар тудырырга ярдәм итә:

...Тәмам дүрт ел елап-сыктап,
Ки заигъ иттем әукъатлар.
И бу дүрт ел! И бу дүрт ел!
Ки һәр сагъәте дә дүрт ел!..

(XVI, 1, 2)

Димәк, бер елда 8760, дүрт елда исә 35 040 сәгать булса, шуның һәр сәгатенә тагын дүртәр ел туры килсә...

Җиде генә гап-гади сүз ярдәмендә оештырылган никадәре кыю, яшерен мәгънәле гипербола!

Мондый юлларны иҗат итәр өчен техник яктан дөрес итеп шигырь яза алу гына җитми әле... Монда, әдәби сәнгатьтән тыш, чынчынлап сөя белү, сөя алу сыйфаты да зарур. Кандалый талантының бер хосусияте менә шундый ихласлыктан гыйбарәт.

Габделҗәббар Кандалый иҗатында фольклор традицияләре тоткан урынны дөрес күзаллар өчен, ниһаять, аның шигырьләренең формасы, стиле һәм сәнгатьчә техникасы мәсьәләләрен дә этрафлап өйрәнү зарур. Әмма без бу урында андый махсус филологик проблемаларга киненнән тукталып тормыйча, бер характерлы күренешкә генә кыскача кагылып узу белән канәгатьләнәбез.

Кандалый күпчелек шигырьләрен үзе яшь чакта ук яхшы үзләштергән ике үлчәмдә язарга яраткан: һәр берәмлеге унбер иҗектән торган бәйт (икеюллык) һәм юллары сигезәр иҗекле дүртьюллык (үзенчә әйткәндә: «дүрт пай», йәисә «робагый»). Шулардан безне беренче нәүбәттә сигезәр иҗекле дүртьюллыкларның эчке структурасы кызыксындыра. Халык иҗатында, мәгълүм булганча, кыска җырларның эчке төзелеше 2+2 формуласына туры килә (строфаның аналогия булдырыр, настроение тудырыр өчен әйтелә торган гомумирәк мәгънәдәге беренче яртысы һәм җырның төп әчтәлеген тәшкил иткән соңгы икеюллыгы). Кандалый халык җырларының шушы сыйфатын киң файдаланып, 2+2 формуласы буенча төзелгән строфалардан тыш, әлеге алымны йәнә дә үстерә төшеп, 1+1+2, йәисә 2+1+1 формулаларын да тудыра. Шуңа күрә аның күпчелек шигырьләрендә строфалар үзара бер-берсенә йомшак «ябыштырылган» шикелле, зур күләмле әсәрләре эчендә дә строфалар көлтәсеннән торган цикллар арасындагы оешканлык күзгә бәрелеп тормый. Шагыйрь иҗатындагы фольклор традициясеннән килә торган менә шушы хосусият Кандалый әсәрләренең халыкта аерым бүлекләргә, хәтта строфаларга сүтелгән хәлдә таралуына киң мөмкинлек биргән, икенче яктан, шул ук күренеш, әлеге «өлешләрдән» йәнә бер «бөтенне» оештырырга омтылу аркасында, шагыйрь әсәрләре күчермәләрендә төрле «вариантлар» барлыкка килүне тәэмин иткән. Шуңа күрә без шагыйрь мирасындагы кабатлану, вариантлылык күренешенә Кандалый шигырьләренең халыктагы яшәеш хосусияте дип карарга да тиешбез.

Әукъатлар — вакытлар.

Шул ук вакытта андый кабатланулар, вариантлар тууга шагыйрьнең үз позициясе, аңлы гамәле дә зур өлеш керткәнгә охшый. Беренчедән, үзен профессиональ әдип булудан бигрәк, шигырь язарга «мәҗбүр ителгән» мәхәббәт корбаны рәвешендә сизгән Кандалый элек бер тудырылган образларын, шигъри юлларын, тәгәл строфаларын, хәтта строфалар циклын яңа әсәрләрендә икенче, өченче тапкыр да теләгәнчә файдаланган. Шагыйрь үзе дә, иҗатының шушы хосусиятен яхшы аңлагандай, үз-үзен кабатлау белән гомумән мәхәббәт хакында «күп язуы» сәбәбен аңлатырга тырыша:

Язамын күп, эчемдин гамь бушар дип,
Бу күп сүз эчрә бер сүзем ошар дип...
**** («Ки бән яздым саңа, җаным, нича хат...»)*

Икенчедән, Кандалый, чуар күңелле мавыгучан ир-ат буларак, ягъни бу сәбәп белән игътибарын җәлеп иткән чибәрләргә (мәсәлән, Фатыймага, Җәмиләгә, Бәдигагә) тиз-тиз шигырь-мәдхия, мәхәббәт мәктүбе оештыруга иренмәгән, кайчакларда иптәшләре өчен дә шундый көйле хатларны язудан — заказ үтәүдән баш тартмаган... Шуңа күрә ул кайбер әсәрләрен электән үк әзер строфаларны яңадан сиплау, чак кына үзгәртеп, эстамплар язу юлы белән оештыру ысулыннан киң файдаланган. Язылган һәм язылачак текстларга карата булган мондый ирекле мөнәсәбәттә профессиональлек аңыннан бигрәк үзешчәнлек хисе, фольклорча иҗат башлангычы өстенлек итүен күрүе кыен булмаса кирәк. Башкачарак итеп әйткәндә, эшчәнлегенең башлангыч чорында әдәби профессиональлеккә дәгъва иткән («Рисалә» һәм «Кыйссаларны китаби кагыйдәләр белән оештырып, авторлыгы кат-кат ачык әйткән) Кандалый иҗатының җитлеккән шагыйрь буларак, чын сәнгать осталары кодрәтенә ирешкән дәверендә үзен калам белән кәсеп итүче дип түгел, бәлки халык авыз иҗаты поэзиясының бер вәкиле сыйфатындарак хис кылган булырга тиеш. Шуңа күрә, аның соңгы дәвер әсәрләре тәмам халыкчан телдә язылган кебек, аларда авторлык дәгъвалары да бөтенләй юкка чыга (шигырьләрдә шагыйрь исеменә ишарәләр очрый икән, болар укучы өчен конкрет гашыйк җырчының үз адресын күрсәтүеннән ары китми — алар бары **безнең өчен** генә авторлык күрсәткечләре).

Бер үк вакытта шагыйрь үзен тудырган, тәрбияләп үстергән мәктәп традицияләрдән дә тәмам аерылып китми шикелле. Сөйгәне Сахибҗәмалга аның саф ана телендә: «И матурым, гүзәлем лә, Ничек түзәлем лә? Өзеләдер үзәгем лә...» дип, чын халыкчан һәм шагыйранә мөрәҗәгать иткәне, хәтта бер мәлгә тупас надангa әверелеп: «...Кеше сүзенә Бакып хур булма, и дура!» — дип мишәрчәләп тә сүгә алганы хәлдә, теле ачылган иске язма әдәби стильне дә бөтенләй ташламый. Мәсәлән, Сахибҗәмал хакында ихлас сокланып, ихтимал, үзе өчен генә иҗат иткән бер әсәре — *** («Бәдре-лямигъ дилбәрә гыйшык тотыпмык бинәва...») дигән, иске классик әдәбиятыбыз таләпләреннән бәяләгәндә бәхәссез шедевр дәрәҗәсенә күтәрелгән шигыре шуны раслый. Димәк, шагыйрьнең халыкчан гади итеп язуы, «мажикча» сүгенеп җибәрүе гадәти стихиялек күренеше, йәисә «ничек булдыра алса», шулай гына язу нәтиҗәсе түгел икән!

Җыеп әйткәндә, бу китерелгән фактларның һәммәсе бергә шагыйрь мирасының төп сыйфаты — Габделҗәббар Кандалый иҗатының халыкчанлыгы хакында сөйли. Шул ук вакытта бу халыкчанлыкның башкалар тарафыннан оештырылган, эшчәнлекнең беренче адымнарыннан ук Кандалый тарафыннан кабул ителгән әзер тәгълимат түгел, бәлки эзләнүчән иҗат процессында экренләп чарланган стихияле, иҗтимагый үсештәге зарури, бер үк вакытта тарихи чикләнгән, димәк, тормышчан табигый демократизм икәнлеген истә тотарга кирәк.

Әгәр моңарчы аерым-аерым анализланган материалларны бер «җепкә» тезеп, тарихи югарылыктан бөтенесенә берьюлы караш ташласак, аларның эчке бәйләнешләре төгәлрәк ачылып, моңарчы «шәхси, хосусый» дип билгеләнгән сыйфатларның — гомумилеккә, «җирлелык» дип билгеләнгән күренешләрнең билгеле закончалыкларга барып тоташкан булуын күрербез. Чөнки Гаттар һәм башка суфилар шәкерте сыйфатында укучыларын регламентланган рухи пакьлеккә, авызлыкланган дини тәкъвалыкка өндәү аша охрави бәхеткә «тугъры юл күрсәтеп» мәйданга чыккан яшь шагыйрь соңра андый идеаллардан тәмам баш тарта, кеше бәхетен бары дөньяви чынбарлыкта, шәхси хөрлектә, табигый хис, сәламәт бәдән ихтыяҗларының канәгатьләнүендә күрә башлый. Боларның һәммәсе үзара тыгыз бәйләнгән объектив шарт-сәбәпләрдән килеп чыккан иде. Гамәлләр юнәлешен билгели торган андый шарт-сәбәпләрдән нигезне тәшкил итүче беренчесе — ул XVIII һәм XIX гасырлар чигендә социаль-иҗтимагый хәятыбызда йөз биргән гомум прогресстан — буржуаз мөнәсәбәтләр тернәкләнүдән, шул җирлектә азатлык өчен барган көрәш хәрәкәтенең яна сыйфатларга ирешүеннән, элеккегә караганда кинрәк катламнарда демократик идеаллар канат җәюдән гыйбарәт иде.

Икенче шарт-сәбәпне Габделҗәббарның гаилә һәм мәктәп-мәдрәсәдә, ягъни үзе кеше буларак формалашкан мохиттә алган тәгълимтәрбиясе белән оешкан дөньяга карашы, инанулар үзенчәлеге, аларның әлеге алшартларга мөнәсәбәттә эчке конфликтлар аша үзгәрүе, яңаруы тәшкил иткән иде. Шул ук вакытта табигый эур талантка ия шагыйрьнең иҗтимагый-интеллектуаль сизгерлеге, зирәклеге, киһаять, көчле темпераментына бәйле тәэсиргә бирелүчән кытыршы холкы, мин-минлеге бергә кушылып, әлеге үзгәрү һәм яңаруның үзенчәлеген, индивидуаль кыяфәтен билгели торган өченче шарт-сәбәпне дә барлыкка китерде.

Болардан беренче факторга махсус тукталып торуның артык хаҗәте юк хәзергә — ул хакта югарыда беркадәр әйтелде инде. Шуна күрә, икенче моментка кагылып, элегрәк ясалган кайбер хөкемнәргә ачыклык кертергә дә ихтыяҗ бар.

«Рисалә» һәм «Кыйсса»ларны анализлаган чакта күренгәнчә, яшь шагыйрь рухи камиллеккә ирешүне гел ахирәт интересларына гына кайтарып калдырмый. Вакыт-вакыт тормыш гаделсезлекләрен, социаль тигезсезлек күренешләренә дә ризасызлык белдерә. Шул ук вакытта, «Рисалә»дәге яшь авторның суфичылыгы да чикләнгән һәм формаль иде. Моны җәннәттә хур кызлары белән кавышуны сурәтләүдә ачык күрәбез. Суфичылык тәгълиматы буенча, кешенең җир өстендәге бурычы — «теге дөньяга» әзерләнү, ә теге дөньядагы бәхете исә алла белән очрашу (дидар күрешү), хәтта аның белән «берләшү» дип аңлатыла. «Рисалә»дә исә бөтен максат җәннәт хурлары белән гыйш-гыйшрәт түшәгендә хозур итүгә кайтып кала. Дөрес, ортодоксаль ислам дине буенча да «хак мөселманны» җәннәттә хурлар көтә. Ләкин андый өйрәтүләрдә чама югалмый, натурализмга юл куелмый. Кандалый исә «Оҗмахта хурларның сыйфаты вә бәяне» дигән бүлектә әлеге тәтәйләрнең тышкы кыяфәтләрен, интим мөнәсәбәт вакытындагы сыйфатларын бәндәләрчә натуралистик тасвирлауга 11 строфа (44 юл) багышлый. Әмма нәкъ шуннан соң килә торган һәм «Ходай тәбарәкә вә тәгаләнең дидарын мөэминнәр күрмәк» дигән «хак мөселман» өчен төп максатны, идеалны хикәяләүче бүлектә нибары өч кенә строфа (12 юл) бирелгән. Өстәвенә, бүлек төссез, бөтенләй фикерсез килеп чыккан. Моннан соң сүз җәһәннәмгә күчә, аннары җир өстенә кайта.

Шулай итеп, яшь Кандалыйның суфичылык идеяләренә иярүе аның шул тәгълиматны нигезле рәвештә үзләштерүе нәтиҗәсе түгел, бәлки традиция һәм тәрбия тәэсиренә бәйле икән. Бер үк вакытта «теге дөнья»ны да ул үзенчәрәк, дөньявичарак күзаллаган.

Габделҗәббарны бу елларда, күрәсең, тәсауыф әдәбиятында сурәтләнгән гаделлек хакындагы купшы сүзләр, нык яшеренгән социаль демагогия дә җәлеп иткән булса кирәк. Фаразның дөреслеккә якын булуын «Кыйсса»ның идеяләре күрсәтә. Матди байлыктан ваз кичеп, дәрвишлек юлын сайлаган Ибраһим солтан, Эльдорадо эзләгән кебек, утыз-кырык ел ил гизеп йөреп тә, әллә нинди нәтиҗәләргә ирешә алмый: бер җирдә аны җәберләүчене кыйныйлар, икенче җирдә үзен тотып яралар, өченче урында мәсьәлә коры сүз, буш бәхәстән узмый. Нәтиҗәдә — кире кагу бар, раслау юк дәрәҗәсендә. Чын суфичыл әдәбиятта, мәгълүм булганча, «раслау» бик нечкә һәм эзлекле рәвештә эшкәртелә, шуңа күрә дә ул гасырлар буена кеше аңын били килгән.

Кыскасы, яшь Кандалыйда суфилык идеясе җитәрлек дәрәҗәдә көчле булмый. Шуңа күрә соңрак, реаль тормыш киртәләре белән турыдан-туры бәрелешкә кереп, китаби өйрәтүләр һәм шәхси омтылулар арасындагы аерманы ачыграк күрә башлагач, элекке нык булмаган суфичыл идеяләр нигездән үк җимерелә.

Шуның белән бергә Габделҗәббарның үзенә генә хас шәхси сыйфатларын — хислелек һәм көчле темпераментлы, дөньяга тәнкыйть күзе белән карый алу зирәклегенә, фикерләрен турыдан ярып әйтә алу сәләтенә ия, үз-үзенә нык ышанган көчле шәхес булуын да истән чыгармыйк. Уңышсыз кайнар мәхәббәт, үзе янып сөю, ләкин сөйдерә алмау, көенү, бәхет турында уйлау, кеше гомеренең тиз узучанлыгын тирән тою — боларның һәммәсе бергә җыелып, «Рисалә» һәм «Кыйсса»ларда вәгазьчелек юлы белән иҗат итә башлаган шагыйрьне соңрак бөтенләй икенче якка борып җибәргән. Шәхси бәхетсезлеге аша чын бәхетнең нәрсәдән гыйбарәт икәнлеген тоеп аңларга тырышкан шагыйрь элгәредән яшәп килә торган бәхет хакындагы өйрәтүләрдән йөз чөереп, тормышка, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә үзенчә — яңача карый башлаган.

Әлбәттә, шәхси башлангычка болай тәртеп күрсәтү белән мин Кандалый иҗатындагы үзгәрешләрнең, зур борылышның табигатен субъектив тойгы белән генә чикләргә җыенмыйм. Сүз бары тарихи зарур борылышның конкрет шәхес аңында — алдынгы фикер гәмәлләрендә актив хәрәкәт рәвешендә гәүдәләнүгә сәбәп булган этәргеч факторлар хакында гына. Әлеге борылышның үзенә һәм асылына килсәк, ул иң элек XVIII—XIX йөзләрдә череп таркалган крепостнойлык тәртипләрен кысрыклый-кысрыклый социаль-иҗтимагый тормышыбызда урнаша барган буржуаз-демократик мөнәсәбәтләр дигән сүз иде. Яңа мөнәсәбәтләр яңа фикерләр тудырган кебек, бу фикерләрне яңа әдипләр үзләренең яңа геройлары, кеше хакындагы яңа концепцияләре аша уздырырга тиеш иделәр. Габделҗәббар Кандалый, шагыйрь буларак, бездәге шул яңарышның күренекле һәм гаять үзенчәлекле бер вәкиле булды да.

Буржуаз-демократик мөнәсәбәтләр китерә торган мондый яңалыкларның объектив закончалыклы күренеш икәнлеген яхшырак аңлар өчен безгә андый этапларны иртәрәк узган җәмгыятьләрнең тарихында булган мәдәни һәм әдәби күренешләргә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Югарыда Данте (1265—1321) һәм Бокаччо (1313—1375) исемнәре телгә алынган иде. XIX йөз башы татар шагыйре иҗатын өйрәнгәндә XIII—XIV гасыр итальян әдипләре мирасына мөрәҗәгать итүдә акылга сыймаган бернәрсә дә юк. Халыклар һәм илләр конкрет социаль үсеш баскычларына төрле чорларда менгән кебек, әдәби фикер

яшәешендәге үзләштерелүе зарур казанышларга да милли әдәбиятлар, конкрет халыкларның социаль үсеш дәрәҗәләренә муафикъ рәвештә, төрле чорларда ирешәләр. Объектив шартлар аркасында феодаль формация югарылыгына соңрак күтәрелгән, ул үсеш этабын озаграк узган Россия халыклары җөмләсендә татарларга да капиталистик тәртипләр, Көнбатыш Европаның алдынгы илләренә караганда, биш-алты гасырга соңгарып ирештә. XV йөздән башлап безнең җирлектә барлыкка килгән идеологик торгынлык, рухи дөньядагы регресс (ихтимал, Идел буйларын XIV гасыр ахырында Аксак Тимер яулары җимереп, талап, таптап киткәннән соң аерата көчәйгән кире процесс...), икеләтә изелү хөкем сөргән XVI—XVIII йөзләрдә «иң югары» ноктасына җитү аркасында, әдәби фикеребезне хәтта XIII—XIV гасырда ирешелгән дөньявилык дәрәҗәсеннән дә түбәнгәрәк төшереп җибәргән иде. Борынгы чор суфи шагыйрьләреннән төрки телле Әхмәт Ясәви (1166 елда үлгән), Сөләйман Бакыргани (1186 елда үлгән), фарсы-таҗик телендә иҗат иткән тәсауыфчыларның иң күренекле вәкилләреннән Шәех Гаттар (1142—1220) әсәрләренең XV—XVI йөзләрдән алып XIX гасыр урталарына кадәр татар дөньясында, бигрәк тә мәктәп-мәдрәсәләрдә төп әдәби репертуарга әверелә язуы (кайбер төбәкләрдә тәмам әверелеп бетүе!) әлеге регресс күренешенең бәхәссез дәлилләреннән санала ала. Шулай булгач, XIX гасырның беренче яртысында, җирлегебездә капиталистик мөнәсәбәтләр туа барган чорда иҗат иткән татар шагыйре мирасын XIII—XIV йөзләрдә яшәгән, Италиядә буржуаз мөнәсәбәтләр урнаша башлаган заманда әдәбиятка яңа геройлар, кеше хакында яңа концепцияләр алып килгән Данте һәм Бакаччолар белән чагыштырып карау бер дә очраклы түгел.

Бу чагыштыруның, тышкы охшашлыклар эзләүгә кайтып калмыйча, әдәби фикер үсүдәге эчке закончалыкларны исәпкә алудан килеп чыгуы түбәндәге фактлар белән раслана. Әгәр Данте тудырган Беатриче образы, элекке традицияләргә оппозиция рәвешендә, реаль җир кызын олылау һәм шул чибәргә табыну аркылы шагыйрьнең үз мәхәббәтен тасвирлауга хезмәт итсә, Кандалыйның Сахибҗамалга багышланган әсәрләре дә гадәти авыл кызына кайнар сөю, үз хисен бөтен дөньяга ачыктан-ачык игълан кылырга омтылу нәтиҗәсендә туган. Әгәр Бокаччоның «Декамерон»ы үзенең шаянлыгы һәм туры сүзлелеге, вакыт-вакыт әдәп чамасын югалта язган хәлдә сөю хисенең нәфислеген дөньявича дөрес яктыртуы белән җир мәхәббәтен раслаган, шуның аркылы аскетизм идеяләрен кире каккан булса, Габделҗәббар Кандалый да, Бакаччо кебек үк, диннең асылына кагылып тормаган килеш, элек дини тәгълимат монополиясендә калган мәхәбәт (Алланы сөю!) идеясен күкләрдән җиргә төшерә, җәннәт кысаларыннан тышка чыгарып, сәба җилләренә утыртып, салам түбәле авыллар буйлап очырып җибәрә!..

Әдәби фикеребезгә Кандалый алып килгән бу яңалык, гомум социаль-иҗтимагый тормышта башланган зур үзгәрешләрнең язма традициядәге чагылышы, ягъни бербөтеннең өлеше булган кебек, шагыйрь үзе дә фикер иясе, хәрәкәт вәкиле сыйфатында ялгызак күренеш түгел иде. Аның яшьлек чоры Габденнасыйр Курсави (1776—1812), Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгарилар (1754—1834) актив иҗат иткән, шулар эшчәнлеге нәтиҗәсендә торгынлык («иҗтиһад мөнкарыйз») фәлсәфәсе җимерелә башлаган, кеше аңына — хөрлек, гамәленә аңлылык таләп итүе уртага куелган катлаулы һәм кызыклы заманга туры килде. Дини иман ул шәхси инану булганда гына ихлас ышаныч югарылыгына күтәрелә ала, дигән өйрәтү нәкъ шушы елларда формалашкан, шуңа күрә динне рәсмилектән, ягъни дәүләттән аеру мәсьәләләре дә уртага куелган иде. Кандалый иҗатының җитлеккән чорында, шагыйрьнең вәгазьчелектән тәмам йөз чөереп,

кешенең шәхси дөньясы зур объекты иткән соңгы этабында, ижтимагый көрәш мәйданына Шиһабетдин Мәрҗани (1818—1889), Хөсәен Фәезхановлар (1828—1866) чыкты. Чак кына соңрак аларның эстафеталарын Мифтахетдин Акмулла (1831—1895), Каюм Насыйрилар (1825—1902) күтәреп алдылар. Шул рәвешчә абстракт теория кыяфәтендә нисбәтән тар даирәләрдә башланган фикердәге әзләнүләр киң җәмагатьчелек дөньясына чыгып, алдынгы акылларны биләп алды, конкрет ижтимагый хәрәкәткә әверелеп, практик нәтиҗәләрен бирә башлады...

Дөрес, бу җәмагать эшлеклеләре белән Кандалый арасындагы бәйләнешләр аерым конкрет фактлар рәвешендә өстә генә бүлтәеп ятмыйлар. Аларның һәммәсен мәгънәви уртаклык — эчке рухи уртаклык бер җепкә терки. Ул уртаклык гомум социаль прогресска бәйле төп ижтимагый бурычтан — Кешене аңлау, Кешенең тормыштагы урынын, хокукын һәм вазифасын билгеләү, дәрәҗәсен тану бурычыннан гыйбарәт иде.

Әгәр Кандалыйны Утыз Имәни белән чагыштырып карарга теләсәк, Габдерәхим хәзрәтне без тормыш искелеген тәнкыйтьләү процессында үзенең фикерләү һәм язу стильләре буенча шул искелекнең эчендә — чорларны бүлеп тора торган т а р и х и с ы з ы к н ы ң «теге ягында» кала биргән хәлдә күрәбез. (Заманында Галимҗан Ибраһимов та Шиһабетдин Мәрҗанине, аның тышкы, формаль консервативлыгын күздә тотып, шулай дошман крепосте эчендә диверсия оештырган яңалык тарафдары, кыю көрәшчегә охшаткан иде.) Әмма Габделҗәббар хәзрәт «Рисалә» һәм «Кыйсса»ны Утыз Имәни платформасында (дөресрәге, шул тирәдәрәк торып) эш башлаган булса, «Фәрхи», «Сахибҗәмал» һ. б. күпчелек әсәрләрен иҗат иткән вакытларында әлеге с ы з ы к н ы ң бире ягына чыккан иде инде. Бу күренеш исә Габделҗәббар Кандалый иҗатының бер гомер дәвамында төгәл ике чорны иңләп алуын барлыкка китерде.

Кандалый белән Мифтахетдин Акмулла иҗатларының эчке бәйләнешләренә килсәк, монда да уртаклыкның бер үк вакытта бик катлаулы һәм гаять гади булуын күрербез. Әгәр башлангыч чор мәгърифәтчелек идеологлары күтәреп чыккан шәхеснең рухи иреке, кеше дәрәҗәсе проблемалары Кандалыйда индивидуумның хис һәм интим тормыштагы хокукы, бәхеге яссылыгында каралып, бәхет турындагы традицион өйрәтүләр кире кагылган, алар урынына мәхәббәт хакында яңа концепция тәкъдим ителгән булса, адәм баласының шәхсән иреккә хаклылыгын берниндн шик астына алмаган Мифтахетдин Акмулла кешене гомум ижтимагый тормыштагы хөрлеккә чакырды.

Шул рәвешчә, Утыз Имәнидә иман ирекләге төсендә, Кандалыйда хис һәм шәхси хөрлек сыйфатында гәүдәләнгән идеяләр бергә кушылып, Акмуллада яңа баскычка күтәрелде — кешенең шәхси ирекге, хөрлеге аның гражданлык бурычы, активлыгы белән бергә үрелде. Моны Кандалыйда «сөйгән йар» сыйфатын, интим хис халәтен тасвирлау өчен кулланылган сурәтләү чаралары һәм образларга Акмуллада гел ижтимагый эчтәлек йөкләнүеннән дә күрергә мөмкин. Әйтик, Габделҗәббар гәүһәр, җәүһәр һәм якутларны сылу кызның бит-кыяфәт күркәмлеген күз алдына китерү өчен кулланса, Акмуллада әлеге гәүһәр-җәүһәрләр ярдәмендә гакыллы сүз, хикмәтле фикер төшенчәләре гәүдәләнә.

Кандалый гаувас (водолаз) образын сөю ләззәтенә ирешү — бәхеткә чуму идеясен бирү өчен ала:

Иляһи, ошбу матурга
Нәсыйб ит бергә ятырга,

Үбеп агъзыны татырга,
Кн куйнында булып гауваc!
*** («Сурәтең дөшемә керер...»)

Шул ук образга мөрәҗәгать иткән Мифтахетдиндә мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани, хакыйкать диңгезенә чумып, мәгънәләр җәүһәре җыючы гаувас сыйфатында алга килеп баса:

Казанда бер фазыйль чыкды алмас булып...
Мәгани җәваһирен кулга әлгән,
Хәкаикъ диңгезендә гаувас булып...*

Әдәби чаралардан файдаланудагы уртаклык һәм аларга йөкләтелгән бурычлардагы мондый чермалыкларны очраклылык нәтиҗәсе дип игълан итәргә ашыкмыйк. Әгәр «Рисалә» авторы әсәр ахырында тормышта хөкем сөргән социаль гаделсезлекләр хакында:

Гаҗәб хәйрат, гаҗәб вәйа:
Нәзар кыйлсаң бу дөнйайа,
Фәкъирә игътибар һич юк,
Идәрләр гъиззәти байа **,—

дип күрсәтсә, Акмулла үзенең социаль эчтәлеге буенча программ характерлы бер шигырен шундый ук фикер һәм образлар белән башлап җибәрә:

Гаҗәб: һәр кем гъәни булса,
аңа хөсне дидар әйләр,
Фәкыйрь мескенгә пәрва юк,—
мөзәлләт берлә зар әйләр ***.

Бу фактларның гадәти охшашлык кына түгел, бәлки беренче шагыйрьнең икенчесенә тәэсир итүе мөмкинлеген күрсәтә торган башка кыек дәлилләр дә бар. Мәсәлән, югарыда бер әйтелгәнчә, Акмулла шигырьләренең 1935 һәм 1986 еллардагы Алма-Ата басмаларында «Сахибҗамал» әсәренең өзекләре Мифтахетдингә ялгыш нисбәт ителгән. Безнеңчә, мондый буталчыклык соңгы чор публикаторларының теләкләренә караганда, Акмулла шигырьләреннән эшләнгән кайбер күчермәләрдә Кандалый әсәрләренең дә бергә бирелүенә күбрәк бәйле. Бу хәл үз нәүбәтендә Габделҗәббар әсәрләренең Мифтахетдингә танышлыгы файдасына сөйләсә кирәк (әгәр «Сахибҗәмал»дан алынган әлеге өзекләрнең Акмулла кулы белән күчерелгән булуы ачыкланса да гаҗәп түгел).

Ниһаять, ике шагыйрьнең әдәби телгә мөнәсәбәте дә бик характерлы. Әгәр Кандалый яшәп-иҗат иткән чорындагы күпчелек әсәрләрен җирле сөйләмгә максималь якынлаштыру дәрәҗәсендә халыклаштырган булса, Акмулла да, үз аудиториясе үзенчәлеген — Урал арты төрки халыклары арасында гамәлдә булган тел чуарлыгы күренешен игътибарга алып, катнаш телдә язган, шунысы белән әдәби телне демократлаштыру юлын үзенчә гамәлгә ашыру чарасын эзләгән иде.

Кандалый белән Каюм Насыйри арасындагы рухи бәйләнешкә килсәк, монда артык күп сөйләп торуның хаҗәте юк. Мәгърифәтче галим, «Фәвакиһ-ел-җөләса» китабында «Сахибҗәмал» әсәренең беренче фәнни басмасын эшләгән чакта, Габделҗәббарның, югарыда бер әйтелгәнчә, чын шагыйрь икәнлеген махсус билгеләп, мондый нәтиҗә

---

* Акмулла. Шигырьләр.— Казан, 1981, 59, 70, 74, 75 һ. б. бб.

** Строфаның мәгънәсе: Гаҗәп хәйран (калырлык) гаҗәп үкенеч (хәл): әгәр бу дөньяга карасаң, фәкыйрьләргә һич игътибар юк, ә байларга кадер-хөрмәт итәрләр.

*** Акмулла. Шигырьләр: 128 б. Строфаның мәгънәсе: Гаҗәп: әгәр берәү бай булса, аңар якты чырай күрсәтерләр: фәкыйрьгә исә һич иминлек (химая) юк,— кимсетелгән килеш зар итәр ул.

чыгара: «Татар теле диган телемезнең һәм нәрсәдән мәзкүр шигырьләр вә әбйатлар, вә мәкальләрдән башка мөнәсәбәтле нәрсәләр табылмады» (579 б.). Димәк, «Сахибҗамал» теле Насыйрига кадәрге әдәби татар теле — халык сөйләшенә якын язма тел өчен үрнәк булып, мәкальләр теле белән бер дәрәҗәдә тора икән!

Әгәр демократ галимнең бу икърарын, ул таянган фактик материалларга соңгы елларда әдәби хәрәкәткә кертелә килүче башка әсәрләрнең дә тел-стиль үзенчәлекләрен күшып карасак, шулай ук тел өлкәсендә шагыйрь кичергән эволюцияне эзлекле рәвештә исәпкә алсак, әдәби телебез тарихы хакындагы белемебез төгәлләнә, анык-лана төшәчәк. Моңарчы бездә хөкем сөргән караш — яңа дәвер әдәби телебезне халыкчанлаштыручы сыйфатында бер Габдулла Тукайны гына исәпләү, йәисә андый миссияне бары Каюм Насыйрига гына кайтарып калдыру да зур тарихи процессны аңлауда гы белемебез житмәүнең яки фактик материалларда артык «төпченергә» теләмәүнең нәтиҗәсе иде. Тарихи эзлекле булсак, әдәби телебез халыкчанлашу юлында Насыйри эшчәнлеге билгеле бер этапны, ә Тукайлар иҗаты исә нәтиҗәне тәшкил итә. Чынлыкта иске язма телебездән җанлы халык сөйләшенә нигезләнгән яңа дәвер татар әдәби теленә күчү процессы иң элек Габделҗәббар Кандалый иҗатында башланды. Һәм ул процесс, крепостнойлык төзелеше җимерелү чорына туры килгән, социаль аң рәвешендә системага әверелгән омтылыш буларак, Кандалый иҗатында ук төгәлләнү дәрәҗәсенә җитә язган нәтиҗәләренә дә ирешә.

Каюм Насыйри исә шушы башлангычны күтәреп алды, аны үстерер, куәтләндерер өчен кулыннан килгән барлык чараларын күрде. Галимнең киң колач җәйгән публицистлык эшчәнлеге, әдәби әсәрләре, тел өлкәсенә караган махсус хезмәтләре — һәм исә дә әлеге гомум башлангычның икенче яссылык һәм югарылыктагы дәвам итүе иде.

Ләкин XIX гасырда бездә милли коммуникацияне әдәби тел даирәсендә дә нормаль тәэмин итә торган төп чараның — вакытлы матбугатның бөтенләй булмавы, шулай ук мәдрәсәләребезә хөкем сөргән традицион тәртипләрнең көчлелеге тәү башта аерым иҗат һәм эшчәнлекләрдә гәүдәләнгән әлеге прогрессив башлангычка тиз арада киң канат җәеп, тирән тамыр җибәрергә мөмкинлекләр бирмәде. Шуңа күрә ул тенденция тәмам җиңеп чыга алмыйча, иске омтылышлар белән бәрелеп, буталып, бер өскә чыгып, шунда ук иткәрәк кысрыкланып дигәндәй, яшәвен дәвам итте. Крепостнойлык җимерелү чорында барлыкка килгән әлеге халыкчанлашу тенденциясе яңадан куәтләнеп, бөтенләй җиңеп чыксын өчен иҗтимагый тормышта демократлашу процессының яңа баскычка күтәрелү шарты зарур иде.

Ул зарур шартны 1905 елгы революция туудырды. Шул революция җимеше буларак әдәби мәйданга чыккан Габдулла Тукай иҗатының башлангыч, ягъни әле «күз... зренле, йөз дә саф һәм пакь түгел» чорында, иске традицияләр тәэсиренә бирелеп, ә әрләрен катнаш телдә язды. Әмма әлеге революция казанышлары нәтиҗәсендә туган татар вакытлы матбугаты ныгып өлгергәч, ягъни милли консолидация өчен көчле коммуникацион чаралар барлыкка килеп, «саф, ачык күзләр белән, чын аң белән» эшләү мөмкинлеге барлыкка килгәч, халыкчан әдәби телебезнең җәүһәрләре булган «Шүрәле» һәм «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш», «Туган тел» һәм «Милли моңнар» тудылар.

Шулай итеп, татар халык сөйләм теленең урта диалектына нигезләнгән яңа әдәби телебез формалашты. Әгәр Тукай житәкчелек иткән бу катлаулы процессның узган йөзнең 80—90 елларында

Исмәгыйль Гаспринский эшчәнлеге тәэсирендә бөтен Россия төркиләре дөньясында киң таралган гомумтөрки «корама» тел нигезенә оппозиция рәвешендә барлыкка килүен, җиңеп чыгуын һәм бу көрәш дәвамында ориентир итеп халык теленең конкрет диалекты сайлануын исәпкә алсак, монда да Тукайга Кандалый тәҗрибәсен үрнәк итү мөмкинлеге бар иде. Һәрхәлдә, Г. Тукайның 1907—1909 елларда, нәкъ үз иҗаты башындагы «корама» телләлек чиреннән арынган вакытында, «Габделҗәббар әл-Кандалый әфәнденең шигырьләре»н яшь чактан ук «бик яратып», аларны «аңларга» теләп, хәзергечә әйтсәк, анализлап, укуын кат-кат искә төшерүе * очраклылык түгел, бәлки үзе татыган тәэсирне икърар итүнең кинаяле билгесе иде. Кандалыйда очрый торган кайбер талымсызлык, дорфалык күренешләренең әлеге истәлекләрдә хаклы рәвештә тәнкыйть ителүенә килсәк, бу инде бер үк вакытта Кандалыйдан соң татар әдәбияты ирешкән реалистик принципларның казанышы да, Тукай эстетикасына хас дәрәҗәнең чагылышы да иде.

Кандалый — Тукай сюжетына тукталган чакта һәр ике шагыйрьнең дә борынгы истәлекләрдән бер үк чыганакка — Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабына мөрәҗәгать итүләрен, шул истәлекнең поэтик һәм техник казанышларыннан иҗади файдалануларын онытмыйк. Кандалый яшьрәк чакта «Нәзъме Йосыф», *** («Нисъф-елмәлякъәт...») шигырьләрен (ихтимал, «Кәҗә бәете»н дә) язган булса, Тукай да иҗатының башлангыч чорында борынгы болгар-татар шагыйренә ияреп, шул дәвердәге башка әсәрләренә караганда гади телле «Дустларга бер сүз» (1905), «Яз галәмәтләре» (1906), «Бәхре сани» («Кечкенә генә бер көйле хикәя»нең өлеше, 1906) шигырьләрен тудырган иде.

Халык авыз иҗаты мирасына мөрәҗәгать иткәндә дә Кандалый белән Тукайның юллары еш очрашкан. Мәсәлән, Габделҗәббарның *** («Сәнең башың ирер мисле пудаука...») дигән шаяруы белән Тукай каләменнән чыккан «Егет илә кыз» шигыренең дә бер үк халык юморыннан файдаланып иҗат ителгәнлеге шик тудырмый. Кандалый халык җырларын иҗади үзгәртеп алуда, аерым дүртьюллыкларны үз текстына кертеп җибәрүдә тапкырлык күрсәткән шикелле, Тукай да үзенең мәшһүр «Авыл көйләре» циклында халык җырларыннан файдалану һәм өйрәнүнең яңа төрләрен тапкан иде.

Кандалый иҗатында стихияле төстә башланып киткән, мәгәр системалы рәвештә дәвам кылган һәм бездәге хатын-кыз эмансипациясенә хезмәт иткән фикерләрнең Тукайда аңлы омтылыш, төзек идея буларак үстерелүен исәпкә алсак, тагын бер кызыклы нәтиҗәгә киләбез. Ул — XX йөз башында, башка мөселман халыклар белән чагыштырганда, татар хатын-кызлары ирешкән зур иҗтимагый, мәдәни казанышларның «елга башында» Кандалый эшчәнлеге дә тора дигән нәтиҗәдән гыйбарәт.

Кандалый белән Тукай иҗатларындагы эчке уртаклык болар белән генә чикләнми. Әйтик, Тукай иске мәдрәсәләргә карата болай ди:

Күп яттык без
Мәдрәсәдә,
Аңламадык
Бер нәрсә дә;
Селкенмәдек
Таш төсле без.
Җилбер-җилбер
Җил барсә дә...

---

* Габдулла Тукай. Әсәрләр. Биш томда. 4 том.— Казан, 1985, 33 б.; 5 том, Казан, 1986, 25 б.

Бөек шагыйрьнең бу хөкеме тематикасы белән генә түгел, хәтта шигырьнең ритмикасы буенча да кайчандыр Кандалый тарафыннан бер яңгыратылган иде:

> Нәчә еллар гомер сөрдем,
> Даим мәдрәсәдә тордым,
> Җаһиллегем бүген белдем,—
> Йөрепмез гъәфләтә һәр ан.
>
> *** (*«Бәйан итәм ки бән сөзгә..»*)

Ике чордагы башка-башка шартларда яшәгән, тормыш юллары, иҗат тематикалары нигездә бер-берсенә туры килми торган ике шагыйрьнең дә иске татар мәдрәсәләренә карата шулай бер төрлерәк фикер йөртеп, бер төсле кырыс хөкем чыгарулары очраклы гына түгел, әлбәттә.

*

Шулай итеп, бер яктан, «Рисалә»дән алып «Сахибҗәмал»га кадәр Кандалый узган конкрет юлга, икенче тарафтан, Утыз Имәни иҗатыннан башлап Тукайга кадәр әдәби фикеребез кичергән үзгәрү һәм үсү процессына гомуми бер караш ташладык. Нәтиҗәдә язма традициябез тарихында Кандалый тоткан конкрет урынны әтрафлырак һәм төгәлрәк күзаллау мөмкинлеге туды. Бер сүз белән җыеп әйткәндә, Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари, Шәмсетдин Зәки, Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Гали Чокрый, Мифтахетдин Акмулла һәм башка күпләгән шагыйрь һәм әдипләребезнең уртак тырышлыгы нәтиҗәсендә үскән, баеган, камилләшкән, шул рәвешчә Урта гасырлардан Яңа заман югарылыгына күтәрелгән, Габдулла Тукайның фидакяр иҗатына традицион нигез булып хезмәт иткән әдәби фикеребез тарихында шагыйрь Габделҗәббар Габделмәҗит улы Кандалыйның мирасы, үзенең зурлыгы, иҗтимагый әһәмияте белән төгәл бер дөньяны, кабатланмас әдәби сыйфаты һәм чын оригинальлеге җәһәтеннән сүтелмәс олы төенне тәшкил итә икән.

*

Шагыйрь мирасын мөмкин кадәр һәрьяклап барлау, әсәрләренең табылган, аныкы булуы расланган хәтлесен әдәби һәм фәнни хәрәкәткә кертү бурычын алга куйган бу китап егерме елдан артык эзләнү, материаллар туплау нәтиҗәсендә шушы кыяфәтен алды. Ләкин бу килеш тә ул күләме буенча төгәллеккә, текстларының матбугатка әзерләнү сыйфаты, принцибы җәһәтеннән (бу хакта искәрмә һәм аңлатмаларга бирелгән гомуми керештән карагыз) камиллеккә дәгъва итәргә җыенмый. Кандалый әсәрләренең, югарыда бер күрсәтелгәнчә, халыкта яшәү үзенчәлеге (тиз сүтелү, яңадан «җыелу», җиңел фольклорлашуы һ. б.), шулай ук шагыйрьнең күп язу, тиз язу, язылып беткәннәрен, махсус җыеп, теркәп тормыйча таратып-өләшеп җибәрү гадәте — һәммәсе бергә ул мирасның чын күләме турында категорик хөкемнән сак булуны таләп итә. Чөнки киләчәктәге эзләнүләр дәвамында моңарчы билгеле шигырьләрнең яңа күчермәләре, сыйфатлырак вариантлары, хәтта бөтенләй билгесез әсәрләренең дә текстлары табылу ихтималы бик зур. Әгәр киләчәктә яңа әсәрләр ачылып, мирасның күләме арту белән бергә, аның хакта моңарчы әйтелгән фикерләргә дә төзәтмәләр керсә, бер дә гаҗәп түгел.

Бу китапта укучылар хөкеменә тәкъдим ителә торган мирасның фактик күләме элгәрге басмаларга караганда сизелеп артуына кил-

сәк, ул бер генә шәхеснең (мәсәлән, бу юлларны язучының) тырышлыгы нәтиҗәсендә хасыйл булмады. Шуңа күрә Казан дәүләт университетының археографик экспедицияләренә ел саен катнашкан, халык арасында кулъязма мирасыбызны барлау, җыю эшендә актив ярдәм иткән экспедиция әгъзалары — ярдәмчеләрем һәм шәкертләрем алдында мин үземне бурычлы сизәм.

Соңгы елларда китап өстендә эшләү вакытында үзләре тапкан материаллар хакында хәбәр итүләре, шәхси коллекцияләрендә, архивларында саклана торган күчермәләр белән таныштырулары өчен каләмдәшләремнән Шакир Абиловка, Марсель Әхмәтҗановка, Рафис Әхмәтовка зур рәхмәтләремне әйтәм (алардагы материалларының нәрсәдән гыйбарәт икәнлеге һәр конкрет истәлеккә бирелгән библио-текстологик эшкәртмәләрдә күрсәтелде). Катлаулы текстларының мәгънәләрен, тарихи реалийләрен ачыклауда, яисә башка шәһәрләрдә саклана торган күчермәләрдән копияләр алдыруда күрсәткән булышлыклары өчен Җәмил Зәйнуллинга, Нурия Гәрәевага һәм Ульяновтан Фарук Галимовка рәхмәтләр күндерәм.

Кулъязманы редакциягә әзерләү һәм редакцияләү процессында текстларның тарихи дөрес укылышын аныклауга, шул рәвешчә төгәлсезлекләрне киметүгә сизелерлек өлеш керткән өлкән шагыйребез Әхмәт ага Исхак, нәшрият редакторы Рәис Даутов алдында да бурычлы булып калам.

Миркасыйм Госманов

Казан — Васильево — Казан.
1966—1977—1987.

ШИГЫРЬЛӘР

I

* * *

Гыйлемлек нурани җәүһәр
Ки мөэминләр содурында;
Һәуа бер аждаһа кеби
Чыгар җисмең къөбурендә.

Гыйлем сахибе һичбер дә
Черемәс — үлсә дә — гүрдә,
Тереклекдә җире — түрдә,
Булыр мәҗлес хозурында.

Һәуа сахибе зурланыр,
Кәсеб итәргә хурланыр,
Зәмимә берлә болганыр,
Булыр нәфесе зурында.

Нурани җәүһәр — нурлы (нурдан барлыкка килгән) җәүһәр.
Содурында — күкрәгендә.
Һәуа — монда: эрелек, тәкәбберлек.
Җисмең къөбурендә — тәнең каберендә.
Сахиб — хуҗа, ия.
Җире — урыны.
Хозурында — каршында, алдында.
Зәмимә — бозыклык, начар эш.
Булыр нәфесе зурында — нәфесе көчләвендә булыр.

* * *

Сачәк бер вакыт атадыр,
Коела, йиргә ятадыр;
Кибәдер — корып катадыр
Көзенә керсә яриида.

Гомер дәхи шулай үтәр,—
Сачәк вактың үтеп китәр,
Йөзеңнең рәүнәкъе бетәр,
Йәшендән керсә кайгыга.

Рәүнәкъе — нуры, яктысы.

* * *

Иляһи, бу асыл кошны
Тубай агачына кундыр,
Иляһи, мин сабырсызны
Сабырлык юлына күндер!

Каләмем дә тая инде,
Ки яза алмай турыдан;
Яна бәгърем, сула йөзем
Авырлыклардин, гуредан.

Языйм микән, җитәр микән?
Язу файда итәр микән?
Бу кайгулар бетәр микән,
Гомерлеккә китәр микән?! [1]

Тубай (туба) агачы — җәннәт агачы.
Гуредан — горедан (русча — горе): кайгыдан.

* * *

Бәйан итәм ки бән сезгә,
Гаеп итмәңез сез безгә:
Гыйлемлек булмады бездә,—
Йөрепмез гъәфләтә һәр ан [1].

Нәчә еллар гомер сөрдем,
Даим мәдрәсәдә тордым,
Җаһиллегем бүген белдем,—
Йөрепмез гъәфләтә һәр ан.

Бәйан итдем ки халемне,
Сарыф итдем, и, малымны,
Хисабламадым алдымны,—
Йөрепмез гъәфләтә һәр ан.

Йөрәкләрем булып бирйан,
Гомер үтде, булып гирйан,
Даим булдым үзем гъөрйан,—
Йөрепмез гъәфләтә һәр ан.

Һаман тордым үзем кышда [2],
Торып чыга идем тышка,
Гомерләр үтде күп бушка,—
Йөрепмез гъәфләтә һәр ан.

Чыга(р) идем даим юлга,
Тота(р) идем китаб кулга,
Эшем калды бәнем юлда,—
Йөрепмез гъәфләтә һәр ан!

Йөрепмез гъәфләтә һәр ан — һәр мизгелне йөргәнбез (баргаб[ыз]) гъәфләткә таба.
Бирйан — көйгән, куырылган.
Булып гирйан — елауда булып.
Гъөрйан — ялангач, шәрә.

* * *

Бу илләрдә[1] торып калсам,
Ярамас кызга күз салсам,
Атамның каргышын алсам...—
Качыйм тизрәк бу илләрдин!

Арысландай егет-иргә,
Батып бетсә дә кан-тиргә,
Чит илләргә, ерак җиргә
Качу әүля бу илләрдин.

Сөеп бу илгә килсәм дә,
Ки юрга кеби җилсәм дә...
Бөтен вөҗүдем, ил, сәндә,—
Нигә тиз мине ятсындың?..

Туган илем ерак калды,
Җәяү йөреп сыйрак талды,
Тагы бигрәк йөрәк янды...—
Әзәлдәген ник азсындың?

Бу илнең һич чиге юкдыр,
Биниһайә адәм чукдыр;
Бере ач юк — бары тукдыр,—
Нигә соң миңа тарсындың?

Тарсынма бер дә, китәрмен:
Җен, Иблистән дә[2] битәрмен,
Үз белгәнемне итәрмен,—
Ки әгъля-гъәршә ашкындым!

Әүля — артык, яхшырак.
Вөҗүдем — барлыгым, бар булган-беткәнем; монда: бөтен күңелем.
Әзәл — башы һәм ахыры булмаган чиксезлек, мәңгелек; монда: яратылыш, тәкъдир.
Чукдыр — күптер.
Әгъля-гъәршә — югарыга, күккә.

Миңа бердер: кая булсам,
Багъ алмадай пешеп тулсам,
Ки соңрадин шиңеп сулсам...—
Шуның чөн сиңа гъэрсендем.

Кусагыз да, һич уфтанмам,
Язуымнан да тукталмам,
Котылмассыз барыбер сез,
Әле болай гына калмам:

Төреп чалма-чапанларны,
Йөресәм кыр-япанларны,
Онытмам сез наданларны,—
Элеп салмыйча һич калмам!

* * *

Ки кяшки дөньяга килмәгәй идем,
Бу хәсрәтләрне бән күрмәгәй идем!

Язарга бән каләм алдым камышдин,
Йөрәккә кан утырды ла сагышдин.

Йөрәккә ут төшәдер яна-яна,
Бу хәсрәтдин булам микән дивана?

Мәгәр төшәр идем утның эченә,
Вәли сабыр итәмен хакъ эшенә.

Кяшки — әгәр дә.
Вәли — ләкин («вәләкин»нең кыска варианты).

* * *

Бәнем эчемдәге нарым,
Дөньяга чыгарсам барын,
Эретеп су итәр карын,—
Сабырлык бирсәнә, алла!

Нә кадәрле языйм дисәм,
Язарга сүзләрем калды;
Нигәдер халләрем китеп,
Язарга кулларым талды.

Мөнаҗәтләр язарга да
Зиһенләрем таралгандыр.
Күп хәсрәтләр күрер өчен
Газиз башым яралгандыр.

Нар — ут, ялкын.

* * *

Ходауэндэ, яна бэгърем:
Бу йирдэ юк бэнем кадрем,
Чыдарга калмады сабрым,—
Сабыр бирсен үзе алла!

Йэтимлек гъэрбэте йитде,
Дэхи эгъзалэрем кипде,
Бу хэсрэт гомремэ китде,—
Сабыр бирсен үзе алла!

Бэнем ошбу аһым-зарым
Җиде кат күклэргэ ашды,
Фиракъ уты бэни басды,—
Иляһи, бир сабырлыкны!

Фиракълыкдин яна бэгърем,
Сабырсыздин китэ һушым...
Озын булса эгэр гомрем,—
Иляһи, бир сабырлыкны!

Надан кеше көтү көтэр,
Галим кеше Бохар китэр...
Бэнем гомрем шулай үтэр,—
Иляһи, бир сабырлыкны!

Ходауэндэ — йа хода, ходаем,
Йэтимлек гъэрбэте — монда: интегу, ятимлек каңгыруы.
Фиракъ — аерылу, аерым яшэү.

* * *

Моңаеп сайрыйдыр кошлар
Асыл җәй фаслы булганда,
Моңаеладыр безгә дә
Мөбарәк айлар тулганда.

Йәшел чирәм бу җәй чагы —
Безем илнең Ирәм багы [1],
Тәмам җәннәт кеби шул ан,
Гүзәл мәхбүб булу [2] тагы!

Бу май әгъраф [3] имәс, җәннәт,
Утыру монда бик һәйбәт;
Бу җәй сафа мәкянедер —
Күңелдә калмыйдыр гъилләт.

Гөлстан мәүсиме кәлде,
Мәй эчмәк нә гъәниматдер,
Каты ташдай йөрәкләрне
Бу май ае эретәдер.

Бу егетлек, имеш, бер көн —
Йомып ачканчы бер күз дә [4]...
Күрәм хәзер өрәкләрне,
Күмелгәнләр [5] иде көздә [6].

Шул ан — шул вакыт, шул чак.
Мәхбүб — сөйгән яр.
Сафа мәкянедер — рәхәтлек урыныдыр.
Гъилләт — чир, кимчелек; бозык уй.
Мәүсим — вакыт, чор.
Нә гъәниматдер — а) ганимәт (казаныш) түгелдер; б) никадәр ганимәттер.

Кыш үтде, зәмһәрир кичде,
Хәрарәт тапды һәр инсан,
Бөрешкән Котлыбай, Ихсан...—
Күренә ал, кызыл йөздә.

Бәһар мәүсиме гәр кәлсә [7],
Агачлар укыйлар сәна.
Бөек шадлык бу көн бәңа,—
Бу шадлык күрнә һәр сүздә.

Хәрарәт — җылылык, эсселек.
Бәһар — яз.
Сәна — мактау (монда: аллага мактау уку).

* * *

Сарып башка кара өрпәк,
Киеп пәжи кара күлмәк,
Гүйә маластаулы чүлмәк [1]
Йөрисең, и Җәмиләкәй.

Табалсаң — чабата ярый,
Буе булыр ике карый [2],
Булыр ярты аршын бары —
Баш-үкчәсез, Җәмиләкәй.

Камыл эчендә лапырдап,
Юеш балчыкта чапырдап,
Йөрисең лә сән аһылдап,
Җыеп көлтә, Җәмиләкәй.

Оек-чабата кигәләп.
Йөрерсең катутка тигәләп,
Сырышыр тагы тигәнәк
Киемләргә, Җәмиләкәй.

Тавышлар бетәр карылып,
Тәнең туфракка ярылып [3],
Чебеш чыгар да ярылып [4]
Кул-аяктан, Җәмиләкәй.

Кара гарәп кеби бите,
Тузан-туфрак булыр бите,
Иренләр, күзләрең чите,—
Ябыкканга, Җәмиләкәй [5].

Әгәр корсак та күтәреп,
Йөрсәң санымны [6] китәреп,
Кич улай [7] өйгә җитәлеп
Дүнәлмәссең, Җәмиләкәй.

Өрпәк — бөркәнчек, бәләкәй шәл.
Пәҗи — мошко, киндер.
Карый — монда: карыш.
Катутка — каты утк[illegible]: каты үләнгә, чүп үләнгә.
Йөрсәң санымны китәреп — дәрәҗәңне (кадереңне) төшереп.
Дүнәлмәссең — дүнә алмассың, әйләнеп кайта алмассың.

Килеп, лап-лоп итеп басып,
Йөрерсең төнлә каранып[8],
Өеңдә искеләр[9] сасып,
Катып кунар, Җәмиләкәй.

Ашыгып, ашыңны пешми
Ашарсың, чашкага төшми;
Иренеп, аягың чишми
Ятарсың, и Җәмиләкәй.

Ки көз көне дә кыш көне —
Мужикның бар да эш көне;
Буламы елда биш көне
Тыныч, эшсез, Җәмиләкәй?

Җәен жарга тәнең пешеп,
Дәхи дә кыш көне өшеп,
Битең, ботың[10], башың шешеп,
Катып-туңып, Җәмиләкәй.

Кадерсез шул кадәр йортта,
Кичә, көндез дә һәм иртә
Агыр эш эшләп биретә —
Кара къолтик, Җәмиләкәй[11].

*

...Кием ясап киендереп,
Сөеп, үзең сөендереп,
Утыртып түргә мендереп,
Итәрләр бер газизәкәй.

Абыстай, ди-ди, сүз башда,
Тотып үзеңне күз-кашда,
Йөретеп җәйдә дә кышда,
Йөрерләр, и Җәмиләкәй...

Сасып, катып кунар — юылмаган килеш икенче көнгә калып.
Жарга — эссегә, кызуга.
Бирета — имгәтә, гарипләндерә.

ӘБИАТЕ

ЧӘЙ БӘЙАНЫНДА [1]

Җиһан эчрә ул алланың
Ләзиз нигъмәтләре чукдыр,
Вәләкин бу безем йирдә
Бу чәйдик һичбере юкдыр.

Бу чәй кеби дәуа юкдыр,
Гаҗәб хасыйәте чукдыр,
Әгәр ачлар эчәр булса,
Белерсән: барчасы тукдыр.

Ки җәй фаслында бер ирне
Һауа сукса хәрарәтдән,
Эчәр булса бу чәйдин ул,
Котылыр ул мәзъәррәтдән.

Шита әййамидә дәхи
Бөрудәтләнсә бер инсан,
Самаварлә чәй эчәрсә,
Бөрудәте китәр шул ан! [2]

Хасыйәте чәй

Хәуасындин дәхи аның
Йокыны мөндәфигъ әйләр,
Белер моны мөҗәррибләр —
Хәкыйкать чәй эчән байлар.

Ләзиз нигъмәтләре — тәмле ризыклары
Чукдыр — күптер.
Хәрарәтдән — эсселектән.
Мәзъәррәтдән — зыяннан, чирдән.
Шита әййамидә — кыш көннәрендә.
Бөрудәтләнсә — суынса; өшесә; салкын тидергән булса.
Шул ан — ул мизгелдә, шул чакта.
Хәуасындин — өстенлегеннән; монда: үзенә хас сыйфатыннан.
Мөндәфигъ әйләр — ташлар, кире кагар, монда: йокысы ачылыр.
Мөҗәррибләр — тәҗрибә итүчеләр, сынап караучылар.



«Чәй бәете»нең беренче басмасы (К. Н а с ы й р и, Кырык бакча, К
1880, ташбасма).

Самавардыр дәхи мәтълуб;
Къәлебләрдә ирер мәхбүб,—
Самаварлә чәй эчсәләр,
Эчәнләрә ирер мәргуб.

Самавар съәуте дилкәшдер,
Мисале сайрайан кошдыр;
Килеп ултырса сөфрәгә,
Кунакның күңле бик хушдыр [3].

Нә дәклү нигъмәтең чукдыр,
Самаварлә чәең юкдыр,
Кунак чәһрәсе ачылмас,
Һәмишә күңле сыныкдыр.

Әгәр чәеңне килтерсәң,
Ачылыр багъдагы гөлдик,
Ләтыйф сүзләрене сүзләп,
Утырыр мисле былбылдик.

Иляһи, сән аермагыл
Бу чәйдин без зәгыйф колный;
Эчәрсә чәй бетәр булса,
Алырга вирәсән полный!

Чәйнең шартлары

Бу чәйнең шартлары вардыр,
Бәҗа килтерәсән аный,
Бәйан идәм сәңа бер-бер,
Колак салгыл моңа, җаный.

Аның шартларының бере
Самавардыр ирер мәзкүр,
Йәнә янында бер мәхбүб
Утыра — ул ула мәнзур.

Мәтълуб — таләп ителгән (нәрсә).
Къәлебләрдә ирер мәхбүб — күңелләрдә сөйгән (кеше) булыр.
Мәргуб — теләп алган (кеше, нәрсә).
Самавар съәуте дилкәшдер — самоварның тавышы [illegible]лыдыр.
Сөфрәгә — ашъяулыкка, табынга.
Чәһрәсе — чырае, йөзе.
Пол — акча.
Бәҗа килтерәсән аный — аны урынына китерсәң.
Самавардыр ирер мәзкүр — әлеге самовардыр.
Ула мәнзур — күз алдында була.

Шәрайәтдин дәхи аның
Мөсаффа һәм була балың,
Ки чын кясәгә салубән
Көмеш кашык илән алың!

Ушал балыңны измәгел
Чынаяк эчрә сән суда,
Әгәр изсәң аны суда,
Чәеңне кыйласән худа [4].

Суы булсын аның яхшы:
Шималә каршы акган су;
Гаҗәбләнмә бу сүзләргә —
Эттыйбадин бу гөфтегү.

Дәхи лимун салыр булсаң,
Аның къәдре, бәс, әгълядер:
Лимун илә чәй эчелсә,
Эчәнләрә күп әүлядер.

Бу шартлар берлә эчсәләр,
Ула мәсрур, ула хушхаль,
Къәму гъәмләр китәр андин
Ки шадан әйләйүбән филхаль.

Моны идән кеше имля
Ирер үз урныйда мелла,
Гөнаһларыны гафитеп [5],
Вирә мәкъсудыни алла [6].

Шәрайәтдин — шартлардан.
Мөсаффа — саф, чистартылган, ягъни кәрәздән суыртылган.
Худа — худо (русча); начар.
Шималә каршы — төньякка каршы.
Эттыйбадин бу гөфтегу — табибләрдән (врачлардан) бу әңгәмә.
Әгълядер — югарыдыр.
Әүлядер — өстендер.
Ула мәсрур, ула хушхаль — шат була, хуш күңелле була.
Къәму гъәмләр — барлык гамьнәр, кайгылар.
Ки шадан әйләйүбән филхаль — шатландырып шунда ук.
Моны идән кеше имля — моны имля иткән (язган, төзегән) кеше
Гафитеп — гафу итеп.
Вирә мәкъсудыни алла — алла теләгәннәрне бирә.

* * *

Иляһи, барча галәмне
Яратдың кодрәтең берлән;
Нәҗат кыйл рәхмәтең берлән
Бәңа дөшкән җәфалардин.

Сәбах эчрә ки йилләрдин
Киләдер илгә илләрдин.
— Хәбәр кәтәм туганлардин,—
Дәйүб сорам ки анлардин.

— Әйа йил, сән беләрмүсән?
Туганларым күрәрмүсән?
Хәбәрләр килтерәрмүсән? —
Дәйүб сорам ки анлардин.

— Әйа йил, сән кая исдең?
Нәчә сахра үтә кичдең?
Туганымны кайда күрдең?—
Дәйүб сорам ки анлардин.

— Әйа йил, сән китәр булсаң,
Фәлян йиргә йитәр булсаң,
Туганымны күрәр булсаң,
Дога дигел ки безләрдин.

— Әйа йил, исмәгел бик тиз,
Бәнем халем итеп йиткез,
Вәләкин һич карар кыйлма,—
Әманәтдер ки безләрдин.

— Әйа кош, сән күрәрмүсән?
Фәлян җирдән кәләрмүсән?—
Туганымны күрәрмүсән?—
Дәйүб сорам ки анлардин.—

Нәҗат кыйл — коткар.
Сорам — сорыйм.
Карар кыйлма — тукталма.

— Әйа кош, сән бармы балаң?
Атаң берлән дәхи анаң?
Вәсъил итеп йөрәрмүсән?
Фиракъмүсән ки анлардин?

Туганың сагына, дигел,
Сагынып, саргая, дигел;
«Туганым, сән кайда?» — дигел,—
Дога булсын ки безләрдин.

Нәгяһ бән сахрага чыксам,
Нәчә төрле йыгач күрсәм,
Ул ук катларына барсам,
Хәбәр сорам ки анлардин:

— Әйа йыгач, йәшең күпме?
Түгелгән йимешең күкме? [1]
Бәгремдик сагышың күпме? —
Дәйүб сорам ки анлардин.—

Нәчә йимешләрең үсде?
Нәчә яфракларың дөшде?
Ботакларың кемләр кисде?!—
Дәйүб сорам ки анлардин.

Яфраклар йәш гомер икән,
Ботаклары бала икән;
Фиракълык бер бәля икән,—
Бәгырь өзгән туганлардин.

Йыгачлардик нә чыкмагай?
Сачаклардин нә булмагай?..
Бу дәрдемә дәуа тапмай,—
Дәйүб кайтдым ки анлардин.

Языйм микән, йитәр микән?
Ушал кайгу бетәр микән?
Ушал кайгу, ушал хәсрәт
Күңелләрдин китәр микән?!.[2]

Вәсъил итеп йөрәрмүсән — очрашу эзләп йөрерсеңме.
Фиракъмүсән — аерым торасыңмы, аерылгансыңмы.
Нәгяһ — бердән, кинәт; монда: кайчак.
Йыгач — агач.
Дәрдемә — хәсрәтемә, авыруыма.
Ушал — шушы.

* * *

Ки әүвәл ибтида итдем —
Хода исмене йад итдем,
Ки һәркем исми йад итсә,
Вирә максудыни алла.

Сагынмакдин бәет яздым,
Газиз балам, әйа, сезгә;
Мөлякъәт кенена тиз дә
Ирештерсен үзе алла.

Сары сугып, кызыл йөзем
Ки саргайды, ике күзем;
Ходай бирсен бәца түзем,—
Ирештерсен үзе алла.

Фиракълык яндыра бәгърем,
Кәбаб кыйлды тәмам садрем,
Карарым калмады, сабрем,—
Күрештерсен үзе алла!

Йөрәгем садпарә улды,
Ки фиркъәтдин яра улды,
Газиз балам ерак улды,—
Янамын наре хәсрәтдин.

Сези [1] бу эткәгез сагънып,
Елайдыр юллара багып,
Балакай дип, йәше агып,
Елап кәтә сәбилләрдин.

Ибтида итдем — башладым.
Мөлякъәт кене — кавышу, күрешү көне.
Фиракълык — аерылышу, аерым тору.
Кәбаб кыйлды — куырды.
Садрем (садрым) — йөрәгем.
Садпарә улды — йөз кисәк булды, йөзгә телгәләнде.
Фиркъәт — аерылу, аерылышу.
Наре хәсрәтдин — хәсрәт утыннан.
Сәбил — юл.

Иляһи, хәсрәтем агыр,
Ничек итим икән сабыр?
Газиз балам фиракъендин
Янып бетде йөрәк-бәгырь!

Каләм алсам, язып булмый,
Мөкъәддәрдин узып булмый,
Фиракъеңне хисаб итсәм,
Еламый һич түзеп булмый.

Чыгамын дәхи сахрага,
Йөрәгем утдай янганга,
Тәзәрригъ кыйлам аллага,
Сорап сези, әйа балам!

Бу кадәр моңлы зар берлән,
Бу кадәр игътизар берлән,
Бу кадәр интизар берлән
Сорыйм сези, әйа балам!

Агар су тирәсе таллы,
Гъәжаиб яфрагы баллы...
Ходаем кодрәте илә
Бу гъәмне къәлбемә салды.

Озак бергә торалмадым,
Йөзең күреп туялмадым,
Ерак йиргә китеп баргач,
Гомергә хәсрәтең калды!

Мөкъәддәр — язмыш, тәкъдир.
Тәзәрригъ кыйлам — ялварам.
Игътизар — үтенү, ялвару.
Къәлбемә — йөрәгемә, күңелемә.

* * *

Бу бала хәсрәте түкде
Кара сачларем башымдин,
Икешләр [1] ташды йәшемдин,—
Җитешмәсме әҗәлләргә?!

Бу тәкъдир дигәнең нидер?—
Изеп, йәнчеп, орыр йиргә;
Бары тыкмасын ук гүргә,—
Китермәсен [2] әҗәлләргә.

Кеше дигән дә мәзълумдыр:
Йөгерер, егылыр, торыр,
Башыны ташлара орыр,
Сөренмим дип әҗәлләргә.

Фиракълык хале мөшкел халь,
Яна бәгърем, уты сүнмәс;
Бу хәсрәтдин кеше үлмәс,
Ирешмәсә әҗәлләргә [3].

Мәзълум — золымланган, изелгән, җәбер ителгән.

* * *

Ерак йирдә газиз башың,
Янында һич юк юлдашың,
Мөшкелдер сәнең тормышың,
Сабырлык булсын юлдашың.

Пароходлар төшкән чакда,
Газиз балам, сәне көтдем;
Әткәң-әнкәңне калдырып,
Туган илдән ерак китдең.

* * *

Тагын азрак [бән] язаем, йитәрме,
Бу хәсрәтләр йөрәкемдән китәрме?

Балакаем, сәңа һич юк бүләгем,
Қауышмакда хәер-дога теләгем.

* * *

Кызыл гөл булмаса иде,
Кызарып тулмаса иде;
Шул айрылу белән үлем —
Икесе булмаса иде.

* * *

Көләрмен мин, елый дошман
Бәнем бәхтем ачылганда,
Йөрәгенә төшә[р] хәсрәт,
Утый бездә басылганда.

* * *

Сәламдин гайри сезләргә сүзем юк,
Моны язган: сүзе монда, үзе юк.

* * *

Иген икмәк бирер икмәк,
Белеп иксәң, бирер купләп.

* * *

Кунак булдык түреңездә,
Зикер әйтик үзеңезгә:
Иман нуры йөзеңезгә,
Нур балкысын йөзеңездә!

* * *

Әгәр багында булса гөл эрйасы,
Кайчан булгай чырагының зыйасы.

* * *

Кил, и талиб, гыйбрәт илән күзең ач,
Мәххәббәтсез кешедән бик ерак кач!
Әгәр үткәрмәсәң анда сәламәт,
Колың риза улмас рузый кыямәт.

Гөл эрйасы — гөлләр клумбасы, чәчәклек.
Чырагының зыйасы — шәмнең яктысы, нуры.
Талиб — укучы, шәкерт.
Рузый кыямәт — кыямәт көне.

* * *

Туганлык кадрене белсә — туган ул,
Әгәр белмәсә — бер ачы суган ул!

* * *

Килсен җөмлә берлә түрә вулыстаң,
Курыкмыймын мин вә дәхи урыстан!

* * *

Йакутлар табыладыр вакыт берлән,
Вакытлар табылмайдыр йакут берлән.

* * *

И кояшым, чыгармусән болытдин?
Алырмусән бәне бу ялкын-утдин?!

II

* * *

Тотынышып кулың кулга,
Үзең кергән сары тунга,
Кая киттең болай, хәзрәт,
Абыстайны салып унга?

Үзең түргә [1] утыргансың,
Ауызыңны тутыргансың,
Тәгәл кәефне коргансың,
Абыстай утырып уңга.

Синең өчен тавык чалган,
Суган, балтырганын салган,
Сән әйткәч, чакырып алган,
Егермесен сатып унга.

Качырма сән бу форсатны,
Чәеңә сал бауырсакны,
Тутыр бик яхшы корсакны,
Икенче калмасын соңга.

Сәңа атап тавык суйгач,
Ашап-эчеп тамак туйгач,
Кесәгә ун тиен кунгач [2],
Чәй эчеп тән буе кунма.

Ләкин, мулла, онытма сән,
Бу ашларга кызыкма сән,
Ки алдыңа [3] сызыкла сән;
Мужиклар да бизәр соңра [4].

Сауыт-саба ышылдамас,
Бу коймаклар чыжылдамас,
Дәхи хәлвә хышылдамас,
Ки акча юк, диңди, онга.

Абыстай да сөйми башлар,
Катанны да өстенә ташлар,
Чытык йөзләр, түбән кашлар,—
Чакырмыйлар нигә шунда?

Торып иртә битең югач,
Ашык-пошык намаз кыйлгач,
Берәр ашка баруны сән
Үзеңә зур бәхет сандың [5].

Абыстай берлә [6] икәүләп,
Мужикның сыртып игәүләп,
Тавык, күркә, казын ашап,
Ки кайтып йокыга талдың.

Тавык төштә тары күрә,
Сәнең дә ашларың керә,
Йокында сөйлисең нигә:
— «Абыстай, чык, кеше керә!»

Чакыручы түгел икән,
Бу бары төш кенә икән [7].
Күп ашап саташып шулай
Төшеңдә сөйлисең икән...[8]

*

Катаң бозга катып беткән,
Ки чаңгыдай шуып киткән,
Абыстайны да сән сөйрәп
Кай арада барып җиткән?!

*

Агайга сән сада салдың,
— Өйдәме?[9]— дип, хәбәр алдың,
Икәү бергә йөреп ашка,
Гомергә көлкегә калдың!

Сандың — санадың, исәпләдең.
Сада салдың — тавыш салдың, хәбәр җибәрдең.

* * *

Киез итектә һич зарар юк —
Казандин алуга кигән.
Шакирҗан, бик һауаланма:
Үзең тычкан итен йигән!

* * *

Бу сүзне кара «Мишкят»дин,
Яки сора ишек катдин.

* * *

Күркәләнең[1] картлары,
. . . . .лары
Бу Кандалый[2] шәкертен
Куркытырсыз, әкертен!

Йигән — ашаган.

* * *

Бүген без утырдык хушлап,
Ишан сагышын сагышлап [1],
Сезнең рухыңызга багышлап,
Теге якта Урайкинда [2].

Ишан хәзрәтне мәдехләп,
Ишан сохбәтен сагышлап,
Ки мәрхүмләргә багышлап,
Гүләйт итдек Урайкинда [3].

* * *

Алдар Чумай — агадин ага,
Ник йөри ягадин яга?
Ишан биргән, имеш, сага,
Шуның өчен йиңел чаба.

* * *

Әгәр эчсә кызыл кандик винаный,
Яңымдин китмидер сукмый-кыйнамый.

Мәдехләп — мактап.
Сохбәт — сөйләшеп утыру, әңгәмә.

* * *

Тра-ля-ля-ля, тра-та-та,
Сбижий бинек вә кайнар су
Сырхауларны тарата.

* * *

Сәлам улсын сезә, мелла Рауилә,
Ки ултырсаң да йар илә,
Бу угъланның сорауилә
Безгә күндер пырауилә [1].
17 маhи рәҗәб [2] *Габ-р Кандалый.*

* * *

Сән тәнауел [1] биррәли,
Онытмадыңмы ани?
Хастә тайдин башка итне
Тапмадыңмы, йа гъәни?! [2]

* * *

Че хушемән мийайәд тарильдә орех.
Вә ин ләм йөэкәл булырса грех.

Бинек — себерке (русча «веник» тән).
Сорауилә — соравы илә (белән).
Маhи рәҗәб — рәҗәб ае.
Тәнауел биррәли (тәнавел бир әле) — ашарга, ризык татырга бир әле (кунакка чакыр әле).
Гъәни — бай, хәлле кеше.

* * *

Дийә кат[1] ки:— Читек кимә,
Гаед[2] елда ике килә;
Мона угълың йитеп килә,—
Аңарга калсын ул мирас.

Бабаңдан калмыш атаңа,
Атаңнан соң дәхи сәңа.
Ки сәндин калсын угълыңа,—
Нәселгә калсын ул мирас...

* * *

Мажик дигәндә без динлек,
Нә деньясы, нәдер динлек?
Аны йар әйләмәк шинлек
Сәнең кебек матур затка...

Нә деньясы, нәдер динлек — ни деньясы (байлыгы) юк, нәрсәсе дин өчен (бар)?
Шинлек — кимлек, түбән төшү.

* * *

Бу юха ла, бу юха ла, бу юха [1],
Гүйә охшады ла имрәти Нуха;
Пылута ла, пылута ла, пылута,
Гүйә охшады ла имрәти Лута [2].

* * *

Къәләмгөл атлыдыр карчык,
Хөбәйбәнең йөзе ачык:
Киленне хурлыйдыр: «Малчук,
Гөлестанны, бар, алып чык!»

* * *

Әфзале нисани булдичә,
Хөснине хурлыйдыр Хәдичә;
«Къәдичә — къөндичә»,—
    Диеп әйтә Хәлимәкәй.

«Килсен, дигәндә, бедняшка,
Утыралмыйдыр, йоклашка,
Кимерә коры муклашка»,—
    Диеп әйтә Хәлимәкәй.

Имрәти Нуха — Нухның хатыны.
Пылута — плута (плутовка): алдакчы, мәкерле.
Әфзале нисани — хатыннарның иң яхшысы.
Бедняшка — бедняжка (русча): мескенкәй.
Йоклашка — йоклый ашка.

* * *

Мажик кия аршын ярым чабата,
Чабатасын кия-кия таң ата.

* * *

Уникe күркә бер әтәчне кайчан җиңмәс?
Әтәч дәхи күркә берлә бер тиң ирмәс,
Алай да һәм анларга серен бирмәс,
Артка чигеп: «Ки-крик!» — дип кычкырыр имди.

* * *

Каләм әйтер: караң улса, тагын яз,
Абыстайга укырга булмасын аз.
Каләм әйтер: тагын әзрәк язасы,
Абыстайның китә төшсен мазасы.

* * *

Фатыйма, сән, сеңелем,
Бүген әллә нишләгән:
Тышы күгән камырының
Эче генә пешмәгән.

* * *

Ашап карачы бер кашык ашымны,
Кара кашларың ашады башымны.

* * *

«Мөхәммәдия» [1] алып кулга,
Даим кызлар көйләр микән?
«Мөхәммәдия» каты серле,
Сезең берлән сөйләр микән? [2]

* * *

Әгәр, җаным, барыр булсаң наданга,
Сәлам салып, ябып куяр арангa.

Күгән — көйгән.

* * *

Сәнең башың ирер мисле пудаука,
Колакларың гүйә торыр ылаука,

Күзең елтырыйдыр сулы чиләкти,
Авызың җәйрәгән иске иләкти [1].

Нәсыйб булып, ала калсам, җанашым,
Савыт-саба, табаклар да кирәкми! [2]

* * *

Йа сакалым, сән юк идең, бән хуб идем,
Кызларның каршысында мәхбүб идем.

И сакалым, сәнлә булдым бичара:
Кая барсам, андин кызлар кача ла!

Пудаука — пудовка: бер пот ашлык сыя торган зур чиләк (үлчәү итеп кулланылган).

Ылаука — [illegible] (лавка).

Мәхбүб — сөйкемле.

Сәнлә (сәнең илә) — синең беләә.

II

* * *

Ки бән алдым каләмемне
Язаем дип сәламемне,
Яза белмим кәлямемне,—
Кем илткәй бу сәламемне?

Кызыл гөлдер сәнең [1] йөзең,
Кызыл йакут сәнең [2] ирнең,
Төшемдә агъзыма тирден [3],—
Кем илткәй бу сәламемне?

Атаң улдыр фәлян атлы,
Сүзеңдер шикәрдин датлы,
Нәчек тугъмыш [4] бу сыйфатлы? —
Кем илткәй бу сәламемне?

Әйа җаным, нечкә билем,
Үзең зирәк, үзең гыйлем [5],
Үзең уткен дә бик дилем [6],—
Кем илткәй бу сәламемне?

Буш сүзләргә [7] колак салма,
Бәнем күз йәшемә калма [8],
Гомергә хур булып калма,—
Кем илткәй бу сәламемне?

Әгәр калсам сәне алмай,
Кулымны буйныңа салмай [9],
Гомерлеккә булыр ай-вай,--
Кем илткәй бу сәламемне?!

Кәлям — сүз, сөйләм.
Тирден — тиерден, тидерден.
Бик дилем (бик тәлим) — бик күп.

* * *

Нигә булган бу Шонталы?
Минем йөрәкне тырнады:
Мин өйләнгәнче тормады,
Китеп барды бу кыз иргә.

Нигә юкка моңайдым мин?
Кямиләмдин соңайдым мин.
Үз илемне нахак ташлап,
Ки тап булдым бу ят җиргә.

* * *

Әйа җаным, кызыл алма,
Ки бәндин гайригә варма;
Сәнең кебек матур җарны
Кайчан нәсыйб итәр алла?

Кашынданмы, күзендәнме? —
Сийакың кыйлды дивана;
Җиһанга киләне вармы
Сәнендик матур кыз бала?[1].

Сийакың — тәртибең, әдәбең, манераң, монда: кыяфәтең.

НӘЗЪМЕ ЙОСЫФ

Хакъ тәгалә язып әгәр сәне алсам,
Тәкъдир [1] кыйлып, ки куйныңа керә калсам,
Ләбләреңдин сурып үбеп ләззәт алсам,—
Ул ләззәти гомерлеккә китәр имди.

Һиляля охшар сәнең кашларың бар,
Йенҗүйә биңзәр сәнең дешләрең бар,
Гаҗәб зиба [2] кара җефәк сачларең бар,—
Һич кемсәнә сәңа тиңдәш булмас имди!

Тулган айга охшар сәнең йөзләрең бар,
Бал-шикәрдин татлы сәнең сүзләрең бар,
Зөһрә йолдыз кебек сәнең күзләрең бар,—
Кыяфәтең фәрештәгә биңзәр имди [3].

Хакъ тәгалә гашыйк кыйлды бәне сәңа,
Фазле берлә[н] [4] үзе бирсен сәне бәңа;
Хөкме берлән бирер булса сәне бәңа,—
Бер ходайда һич мохтаҗым калмас имди.

Бер ходайдин бән сорыймын сәне даим,
Теләкләрне кабул кыйлсын бер ходаем,
Сәнең өчен эреп сарка йөрәк маем,—
Фазле берлән сәне бәңа бирсен имди!

Әйа җаным, гайәт күркәм сәнең йөзең,
Нәзар кыйлсам, ала алмыйм сәндин күзем,
Кичә-көндез телләремдә сәндер сүзем,—
Бер ходаем сәни бәңа бирсен имди!

Хакъ тәгалә язган микән сәне алырга,
Сәне алып, рәхәтләрдә бер калырга,

Ләбләреңдин сурып үбеп — иреннәреннән суырып үбеп.
Һиляля охшар — яңа туган айга охшар.
Йенҗүйә биңзәр — энҗегә охшар.
Фазле берлән — рәхмәте, мәрхәмәте белән.
Нәзар кыйлсам — карасам.

Ике садрең өсләренә кул салырга,—
Дөнья-ахирәт бергә булсак кәрәк имди!

Әйа жаным, ике күзем, йөрәк бәгърем,
Зифа буең күркәйтәдер ике садрең;
Әгәр алсам, белер идем сәнең кадрең,—
Кичә-көндез хезмәт кыйлып йөрем имди.

Әйа жаным, ике күзем, кызыл алмам,
Сәндин гайре кемсәне һәргиз алмам,
Сәндин гайре кемсәгә күз дә салмам,—
Сәндин башка һич кемсәгә бакмам имди!

Диванага әйләнәдер [6] газиз башлар,
Күземдин агадыр канлы йәшләр,
Бу сүзгә йомшар иде каты ташлар,—
Бу йомшару һич тә сәндин кәлмәз имди.

Имди безгә кауышырга вакыт йиткән,
Әл дә безнең гомеремез заигъ уткән;
Кайда бар сәүгән йарын ташлап киткән? —
Кауышуны жәһед итү кәрәк имди!

Ике садрең — ике күкрәгең.
Хезмәт кыйлып йөрем — хезмәт кылып йөрермен (йөрер идем).
Һәргиз — һичкайчан, һич тә.
Әл дә — әле дә.
Жәһед итү — тырышу.

* * *

«Нисъф-ел-мөлякъэт» [1] — дәйүбән, нурлы йөзем,
Ак чырайлы кыйгач кашым, кара күзем [2],
Кабул итеп укысана ошбу [3] сүзем,—
Мисрагъ [4] саен сәне мәдех кыйлам имди.

Мәдех кыйлсам, охшатырга оҗмах хурый,
Хур мислендин балкыйдыр йөзең нурый [5],
Җәмалеңә төшәр булса күзем турый,—
Шул заманда сабрым карар кыйлмаз имди.

Сәлам яздым, җаныем, сәне мактап,
Сән дә бәне яманлама, хәтер саклап;
Сән дә бәне яманласаң, үзең ятлап,
Бу дөньяны ташлап китү кирәк имди (...) [6].

Ник сикертден, җаныкәем, әй, кашыңны,
Әйләндердең бәнем газиз, әй, башымны?
Һич дә бән тыя алмыйм күз йәшемне,—
Һич такъэт тоту [7] мөмкин дәгел имди.

Диванага әйләнәдер газиз башлар,
Күземдин агадыр канлы йәшләр;
Бу сүзләргә йомшар иде каты ташлар,—
Бу йомшау сәндин һич дә кәлмәз имди [8].

Егълый-егълый кан урнашды бәнем күзгә,
Ышанмыйсыңмыни, җаным, шушы сүзгә?
Күрмәймүсән: сары тулды нурлы йөзгә? —
Бу сүзләргә ышанырга кирәк имди!

Бәне сәүми диеп әйтсәң, телең корыр,
Бәне ташлап ятка китсәң, ходай орыр;
Җәһед ит: эшең уткәч эчең борыр,—
Бер ахмакга атаң биреп куяр имди!

Мисрагъ — юл, шигырь юлы.
Мәдех кыйлам — мактыйм.
Җәһед ит — тырыш; монда: ашык.



*** («Нисъф-ел-мөлякъәт» дәйүбән, нурлы йөзем...») шигыре кулъязма-
сыннан өзек (КДУ, ФК КБ, № 2450 т. кулъязма).

Имди безгә кауышырга вакыт йиткән,
Әл дә безнең гомеремез заигъ уткән;
Қайда бар сәүгән йарын ташлап киткән? —
Қауышуны җәһед итү кирәк имди [9].

Атаң ятка биргәнне тоймый калма,
Үгет бирәм, җаныкәем, яхшы аңла,
Бармыйм дигән сүзеңне телдин салма [10],—
Бу үгетне яхшы аңлап торың имди.

Бу сүземне тыңлагыл [11] колак салып,
Ятка бирү охшар микән, сәүгән калып? —
«Йөрсә иде эчендә утлар янып!» —
Шулай дип къәһре дога кыйлам имди.

Сәнең буең, җаныкәем, зифа үсә,
Бәнем йөрәк-бәгыремне шулар кисә;
Һич исемдин чыкмыйсың көндез-кичә,—
Һич тә такъәт тоту мөмкин дәгел имди!

Сәнең буең, җаныкәем, зифа үссә,
Бәнем йөрәк-бәгыремне шулар киссә,
Иртә торсам, сәнең якдыйн җилләр иссә,—
Шул җилләрдин исәнлегең сорыйм имди!

Сәнең өчен бәнем эчем утлар яна,
Бәнем йөрәк-бәгыремне чолгап ала,
Қауышуны, җаныкәем, теләп кара,—
Бер ходаем кабул итмәс микән имди?! (...) [12]

Торсам иде бу дөньяда сәне алып,
Сәнең өчен йөримен көеп-янып;
Һич бүтәнгә йөрмимен күңел салып,—
Бу күңелдин кайгы кайчан бетәр имди?!

Әгәр килсә яучыга сәңа ятлар,
Үзең сакланмасаң, сәне кем[ләр] саклар?
Үзең саклансаң, сәне хода саклар,—
Бу сүзләрне яхшы аңлап торың имди! [13]

Бу сүзләрне тота күрмә, җаным, ялган,
Сәнең кебек бар биргәнне тоймый калган —

Заигъ уткән — әрәм үткән, бушка үткән.
Къәһре дога — каргышлы дога.
Аңлап торың — аңлап тор, аңлап торчы.
Бар биргәнне тоймый калган — сөймәгән кияүгә биргәнне тоймый калган бар.

Шул буладыр үз башыны [14] суга салган,—
Бер баргачдин кайту мөмкин дәгел имди!

Суга киткән нәрсәне булмый алып,
Сән дә дәхи шулай булма, тоймый калып;
Гомрең буе йөрерсең көеп-янып,—
Бу үгетләр исеңә төшәр имди.

Сәүгән [ярлар] калып ятка, әй, баруың,
Андин артык утка кереп, әй, януың [15],
Көнен-төнен кайнар, җаным, әй, саруың! —
Гыйшык уты һич сүрелми янар имди.

Гыйшык уты янар, һич сүрелмидер,
Дөнья-галәм күзләргә һич күренмидер;
Үлгәндин соң тәүбә кабул булынмыйдыр,—
Бу гыйшыклык бар шунарга мисаль имди (...) [16]

Бәне сәүсәң, җаныкәем, үзең белеп,
Бергә йөрсәк иде икемез уйнап-көлеп,
Яныңдин йибәрмәсәң үзең сөреп,—
Бәне сәүгәнең шундин белелер имди.

Әйа җаным, сылукаем, кызыл алма [17],
Бән бик матур кыз диеп һауаланма,
Сәүгәнеңдин аерылып утка янма,—
Бу мәгъшукның эше бик яман имди!

һауалану җаиз ирмәс сезгә-безгә,
һауалансаң, нәзар кыйл Гъәзазилгә;
Хатасы һич кем булмас хакъдин үзгә,—
Күзе күргәнләр шундан белер имди (...) [18]

Әгәр барсаң, бәне ташлап, сән ятларга,
Башың төшсен сәнең яманатларга [19]! —
Шуны язып йибәрсәм имди хатларга,
«Менә къәһр дога төшде!» дирсең имди.

Барган ирең торсайде чыбыркы тагып,
Көне-төне торса иде алып-чагып,
Сукъган йирең чыкса иде кара ипып,—
Шул викытда бән исеңә төшәрем имди [20].

һауалану — эреләнү, тәкәбберләнү.
Җаиз ирмәс — дөрес түгел, ярый торган түгел.
Нәзар кыйл — кара.

Китерерләр сәне эшкә иртә торып,
Көне буе йөрерсән урак урып,
Ахры бер көн бетәрсең кибеп-корып,—
Ул чакларда егълау файда бирмәс имди (...) [21]

Шулай бетәсең, җаныем, кибеп-корып,
Һаман эшкә йөртерләр к...нә тибеп;
Егъларсың төп йортыңа көндә килеп,—
Ул чакларда егълау файда бирмәс имди (...) [22]

Буйларыңны охшатамын зифа талга,
Тел[ләр]еңне охшатамын сөчек балга [23];
Бер генә алып сөйәр идем [сәне] алга,—
Аулак йирдә күрү мөмкин булса имди.

Көмеш йөзек кийәсең, әй, кулыңа,
Ука яка сапкансың, әй, муйыныңа,
Бер генә кич керә калсам, әй, куйныңа,
Бу дөньяда һич хаҗәтем калмаз имди! (...) [24]

* * *

Гөлстан чәчәк атканда,
Тулы ай йирә батканда,
Ки уйлап аны ятканда,
Килеп баса Гөлстаным.

Гөлстан — исме бик матур,
Үзе гурничада ятыр;
Укырга, эшкә дә батыр,—
Аны алмый йөрәк түзмәй.

Даны тоткан бөтен илне,
Диләр: — «Булыр бу кем килне?
Җилеп җилфердәтә җилне,
Ничек беркемне дә сөзмәй?» [1]

Гөлстан гөлчәчәк аткан,
Ике бите эчкә баткан,
Аның гыйшык уты тоткан —
Балык кеби суда йөзмәй [2].

Гөлстан илләре кайда?
Диләр: — «Яхшысы — Кытайда!»
Йөзең нуры кем ул айда? —
Чагыла күзләрем түзмәй.

Гөлстан, төп гөлем булгыл!
Мәнемлә бер генә кунгыл!
Сафалар шәрабен сонгыл,
Ки сөзгечтән дә һич сөзмәй!

Сонгыл — сон; кулыңны сонып, сузылып бир.

* * *

Тəмам яндырды, көйдерде
Сəнең бу чын сəлам хатың;
Сулар агызга китерде
Гүзəл, сылу, матур атың.

Ҡауышыр көн булырмы бер?
Хатың еш яз, ки саргайтма!
Телə хакъдан күрешергə,
Шəкерт чагымда картайтма!

Ки шау-шу, мəдрəсə гөрли,
Мəнем къəлбем сəне уйлый;
Гашыйкың һич йокы күрми,
Яна кич-төнлəре буйлый.

Ерак йирдə имəсмен мəн,
Дəгел Шам йə Мəдинəле [1],
Нəчек барыйм, нəчек күрим:
Эминəме, Сəминəме?

Къəлбем — йөрəгем.
Сəминə — таза, көр; симез.

* * *

Кәлеб ирдем сәбәб берлән ивеңгә,
Күзем төшде сәнең күркәм йөзеңгә [1].

Күреп ирдем сәнең гөлдик йөзләреңне,
Ишетдем бал-шикәрдик сүзләреңне.

Дәхи күрдем мөбарәк буйларыңны,
Белалмадым вәләкин уйларыңны!..

* * *

Түгәрәк алмадай башың,
Каләмдәй сызылган кашың,
Сагынып дивана башым,—
Сабыр телим бер алладин.

Сагынамын көндезләрдә,
Дога кыйламын кичләрдә,
Оныта алмыйм һичләр дә,—
Сабыр телим бер алладин.

* * *

Гыйшкъилә вә илля хәйраным мәнем,
Дәрдилә зар-[у]-пәришаным мәнем.

Мән сәне йар әйләмешем та әбәд,—
Сакласын гъәһдилән пәйман ул Әхәд [1].

Иртә-кич [2] вәсъфыңны укырмын һәйбәт,
Укырым чун «къөл-һу-аллаһу әхәд» [3].

Әй никярем, гөлгъизарем, сәрви къәдд,
Вай ләбе гъөнҗә, дәһани лялә хәдд!

Гыйшкың уты уш мәне кыйлды һәляк,
Висалең утындин ирмәзсә гъәдәд.

Хуриларың хөснендин сәңа нәсыйб
Кем вирә? — Алла вирүр, хәйрелмөҗиб [4].

Хаҗәтең висалемдер һәр собхе-шам,
Висалеңне рузи кыйлсын зу-л-кәрам.

Вә илля — бары тик.
Хәйраным — шашкыным.
Дәрдилә зару-у-пәришаным — кайгы-хәсрәттән зарым һәм моңым.
Та әбәд — ахыргача, мәңгегә.
Сакласын гъәһдилән пәйман ул Әхәд — ул Әхәд вәгъдә һәм шарты белән сакласын иде.
Васъфыңны... һәйбәт — сыйфатыңны... олылап
Чун — нәкъ, шикелле, кайчан (шул чак).
Никярем, гөлгъизарем сәрви къәдд — гүзәлем, алсу йөзем, сәрви (кипарис) сынлым.
Ләбе гъөнҗә, дәһани лялә хәдд — иреннәре гъөнҗә, авызы лаләләй.
Висаль — кавышу, ирешү.
Ирмәзсә гъәдәд — бер кадәре булмаса.
Хөснендин (хөснедин) — матурлыгыннан, күркәмлегеннән.
Собхе-шам — иртә-кич.
Рузи кыйлсын зу-л-кәрам — кодрәтле Алла бүләк итсен.

Озын гомер вирә хода бә-тәуфикъ,
Мөәллиф [5] кыйла сәне мәңа тәхкыйкъ.

Теле тутый, өне былбыл никярем,
Һәмбәрем (?) сәрви буем, гөлгъизарем.

Догагүйең илән ачып кәлями,
Җәнабеңә йибәрдем чук сәлями.

Дәхи хөршидә [6] биңзәш йөзләрүңә,
Шәкәрдин датлу сүзлү телләрүңә,

Әйләб ирсаль догалар гәүһәрени,
Дәхи йөз мең сәналәр жәүһәрени [7].

Озын итсен сезнең гомрегезне хакъ,—
Һәмишә шул догамыз сезгә мотлакъ.

Вируб тәуфикъ, һидайәт үзеңезгә,
Явыз күз[ләр] төшмәсен йөзеңезгә.

Бәдигъәт сәнсен — анлар[ның] кулында [8],
Мәнем җаным фида улсын юлында!

Ходайа тәслим итдем сезләри мән,
Чыкарма хәтерендин безләри сән.

Иляһе әйләсүн сәңа гъинайәт,
Идүбән бәр-дәуам хифза химайәт.

Мәхәббәт атәшенә бәгърүм буйнмыш [9],
Ки гыйшык дәрде илә [10] бәгърүм янмыш.

Бә-тәуфикъ — тәүфикъле, игелекле.
Мөәллиф — дус.
Тәхкыйкъ — аңык, төгәл.
Һәмбәрем — юлдашым (?).
Догагүйең — дога укучың (сиңа изге теләк теләүчең).
Кәлями — кәлямне; кәлям: сүз.
Хөршид — кояш.
Биңзәш — охшаш, охшаган.
Ирсаль әйләү — күндерү, җибәрү.
Сәналәр — мактаулар.
Һидайәт — юл күрсәтү, тугъры юлга башлау.
Бәдигъәт сәнсен — тиңе булмаган матурлык (гүзәллек) син үзең
Тәслим иту — тапшыру.
Гъинайәт — ярдәм, изгелек.
Идүбән бәр-дәуам хифза химайәт — саклыкка дәвамлы игълан күрсәтү белән.
Атәшенә — утына.

Сабр идәрсәм, эчеми гыйшкың якар,
Гыйшкың ирүр мәни кыйлан би-карар.

Маһитабан сәндә күрде бер җәмаль,
Сулды йөзем дәрдеңлән [11], улды һилял.

Дәрдилән йөзе, зөлфе пәришан нәүбәһар,
Сарыйгъ идб йөземезне чун ляла-зар [12],

Күрде мәгъшукыны микән гъәндәлиб [13],
Шадлыкындин агълайур диб: «Йа хәбиб!»

Монтазыйр улыб къәдәмеңә къийам,
Нәзър идүбән кәндеми нәчә сыйам.

Бу халем[и] сәңа дидем сәр-а-сәр,
Дәуа улгыл бу халемгә [сән], әй йар.

Дога-и хәйремез бу җане садыйк:
Ходa кыйлсын сәне җәннәткә лаикъ.

Гөле сәрби Бохаратик җәмалең,
Тәрәкъкый ула һәрдәм гъизз-у-җаһең.

Аһ фиракъәт, ваһ фиракъәт, әл-фиракъ,
Бу фиракъәт такъәтемне кыйлды такъ.

Чүн фиракъ кыйлды ходаем [14] бу заман,
Бу [15] фиракълыкдин юк җиһанда яман.

Би-карар — карарсыз, чарасыз, тынычсыз.
Маһитабан — ай нурлары.
Җәмаль — гүзәл чырай; күркәмлек, гүзәллек.
Һилял — ай (яңа туган ай).
Дәрдилән — дәрд белән: чир (кайгы-хәсрәт) белән.
Зөлфе — чәч бөдрәләре (чигә һәм җилкәләрдә).
Пәришан — моңлы, сагышлы.
Нәүбәһар — иртә яз, яз башы.
Чун ляла-зар — лаләле кыр шикелле.
Гъәндәлиб — былбыл, сандугач.
Хәбиб — сөекле.
Монтазыйр — өмет итү, көтү; интизар булу.
Къәдәмеңә къыйам — баскан адымнарыңа.
Нәзър идүбән кәндеми нәчә сыйам — үземә ничә ураза нәзер әйтү белән.
Сәр-а-сәр — баштан ахыргача.
Җане садыйк — тугърылыклы җан.
Гөле сәрби Бохаратик — Бохараның сәрби гөле шикелле.
Гъизз-у-җаһең — хөрмәтең һәм урының: кадер-хөрмәтең.
Фиракъәт (фиракъ) — аерылу, аерым тору.
Такъәтемне такъ кыйлды — сабырымны җуйды, тәкатемне бетерде.

Әһл бәйтең илән укубән шадеман,
Дөньяда вә ахирәтдә җавидән.

Җаиңны җәннәтдә вирүбән мәҗид,
Сакласын наре җәһәннәмдин бәгъид.

Йөзләрең айа биңзәш[дер], и гъөлү,
Чук дога дидек сәңа [без], и олу!

Көн-бә-көн дәүләтең[ез] улсын гъөлү,
Сакласын хакъ, гәр кыйлса дошман гъәдү.

Нә дийәем сәңа — яр улсын мәләк,—
Тәхте паиң, гъәрше көрси нә фәләк!

Илтимасым: гъәйбә кичмә би-мәрам,
Гъәйби гъәйбәт — җөмләсе мотлакъ хәрам!

Иртә-кичә доганызда мән [16] гъәриб,
Булсак иде кыйамәтдә бәр-фәрикъ.

Әгәр гыйшкың хак улырса би-гөман,
Почмагындин ертып алгайсән һаман [17].

Хәзрәтеңдин безләрә мәкъсудымыз:
Безгә бер къәтгъ кәгазьдер мәхмүдемез.

Гыйшкың мәндә улмаз ирсә, и никяр,
Бу хатымны кайтарасың би-зарар [17а].

Шадеман — шатлыклы.
Җавидән — мәңгелек; мәңгегә.
Җаиңны — урыныңны.
Мәҗид — макталган, дан казанган (Алланың исем-эпитеты).
Наре җәһәннәмдин бәгъид — җәһәннәм утыннан ерак.
Айа — айга.
Гъөлү — биек, югары, өстен; зур дәрәҗә иясе, асыл зат.
Көн-бә-көн — көннән көнгә.
Гъәдү — дошман, көндәш; көнчелек, дошманлык.
Мәләк — фәрештә.
Тәхте паиң, гъәрше көрси нә фәләк — торган җирең, утырган урының имин булсын.
Илтимасым — үтенечем.
Би-мәрам — теләксез, теләмичә; ирексездән (кеше сүзенә ияреп).
Гъәйби гъәйбәт — гаепне гайбәтләү.
Бәр-фәрикъ — бергә, бер төркемдә.
Би-гөман — гөмансыз, шиксез, шөбһәсез.
Хәзрәтеңдин — син олы заттан, син хөрмәткә лаекъ шәхестән.
Бер къәтгъ кәгазьдер мәхмүдемез — бер кисәк кәгазьдер мактаячагыбыз.
Би-зарар — зарарсыз (ертылмаган килеш).

Йибәрдем мәктүб итеб бу намәне,
Белүр өчен арада мажараны.

Әгәр намәм сәңа баруб юлыкса,
Қабул кыйла [18] кичергел, күңел якса.

Сәлам яздым, ирүр күңлем хәкъикъәт,
Хода бирсен йәшеңезгә бәракәт.

Сәлам алмак фарызыдыр бәрадәр,
Җәһед берлән җыйнарга (?) бәрабәр [19].

Ишет әмма сүземне үгет иркән,
Шәригъәткә муафикъ сүзләр икән.

Дийеңез бу намәне шәргъи ирмеш,
Шәригъәт бу намәдин хариҗ ирмеш.

Шәригъәткәчә безгә күреп йәрәшмәк...
. . . .

Күңел якса — күңелгә ошаса; күңел ятса.
Фарызыдыр бәрадәр — туганлык фаразыдыр.
Үгет иркән — үгет икән.
Шәргъи ирмеш — шәригатьчә икән.
Хариҗ — тышкы, тышта; катнашусыз.

* * *

Бу сүземә инангыл, и гүзәл йар,
Мәңа юкдыр сәндин үзгә вәфадар.

Мәнем бер сәндин үзгә сәрдәшем юк,
Ходa белүр: сәнеңдик тиңдәшем юк.

Дидем сәңа тәмами сүзләремне,
Тулидүбән йәш илә күзләремне.

Моны яздыкда итдем берничә аh,
Дәйүб: «Мәңа мәдәд бир, раббем, аллаh!»

Вәфадар — ышанычлы, тугърылыклы.
Тулидүбән — тулы идүбән: тулы итеп.
Мәдәд — ярдәм.

* * *

Бер ан руйе зәминә кәлде рахъәт [1]:
«Пәришан, үлде!» — дәйү кәлде афәт.

Фәкыйрең нәүгъ гъәруси дүнде нालә
Гъәмендән әйләндүкчә аһ-у-налә.

Хыялы тарихның нәкъеше улды,
Сүзе — дилдә, хыялы күздә калды.

Әйа дилбәр, мәнем халем әгяһи,
Булып тәшна фәкыйрьнең гяһи-гяһи.

Җәмалеңне әгәр күрсәтсә Рәхман [2],
Күзем йагын кыйлам мәрһәм ушал ан.

Нәчүкдер халең, и назик мәҗазем,
Вә ликән бәндәмен — юкдыр гъиляҗем.

Төшебдер бер ходайга ихтияҗым,
Теләймен: йәнә яндыргай сираҗым.

Бер ан руйе зәминә кәлде рахъәт — бер мәл җир йөзенә хәсрәт килде.

Пәришан — моң, кайгы; аптыраш.

Фәкыйрең нәүгъ гъәруси дүнде налә — фәкыйрьнең туй-бәйрәме елауга әйләнде.

Аһ-у-налә — аһ ору, үкереп егълау.

Тарихның нәкъеше — узган эшнең гәүдәләнеше.

Дилдә — дил: күңел, җан, рух; хәтер.

Дилбәр — гүзәл, чибәр; йөрәкләрне яулаучы.

Халем әгяһи — хәлемне белүче.

Тәшна булу — омтылу, сусау.

Гяһи-гяһи — вакыт-вакыт, кайчакларда.

Күзем йагын — күзем маен (күз нурын).

Мәрһәм — җәрәхәткә, ярага сөртә торган май (бәлзәм).

Назик мәҗазем — нечкә холыклым, назлым.

Вә ликән — вәләкин.

Гъиляҗ — чара; дәва.

Сираҗ — шәм; яктырткыч.

Газизем, и жаным [вә] миһребаным,
Дилем, жаным, тәмурым, остоханым! [3]

Ки мәгъшукым, гөлем, багым, бәһарем,
Ата берлә анандин йадекярем!

Ки әй мәхбүб, әйа ширин зәбаным,
Карангу әйләдең рәушан жиһаным.

Иөрәгем парәсе, куәти жаным,
Фида улсын бу тәндә сәңа жаным!

Ки мәгъшукым, мәне Мәжнүн [4] итебсән,
Әлифдик къәддемне нун [5] әйләйүбсән.

Бу халеми сәна дидем сәр-а-сәр,
Дәуа улгыл бу халемгә сән, и йар!

Морадынны хода кыйлсун кифайәт,
Башындин китмәсүн чәтре гъинайәт.

Теләгең һәр нәчүк булса, һәман бул;
Яман телдин, яман күздин әман бул!

Бу дөньяда, ул дөньяда аби тап [6],
Нә мәкъсудың — ки андин нигү тап.

Янында гъәндәлиб укыйа дәстан,
Кәчсүн гомрең бәр[дәри?] багы-бөстан [7].

Тәмурым — тамырым, тамырларым.
Остохан — сөяк, сөякләр.
Бәһар — яз.
Ширин зәбан — тәмле тел, татлы тел.
Рәушан — якты, нурлы.
Куәти жан — жан куәте, жан көче.
Къәддем — буй-сыным, гәүдәм.
Сәр-а-сәр — баштан аякка, баштан ахыргача.
Кифайәт кыйлу — канәгатьләндерү.
Чәтре гъинайәт — ярдәм чатыры (саклап тора торган зонт).
Һәман булу — шулай ук булу.
Аби — абны (*аб* — су).
Нигү — яхшылык, изгелек.
Гъәндәлиб — сандугач, былбыл.
Дәстан — дастан; монда; мактау, мәдхия.

Ачылсын күңелүң[нең] нәүбәһари,
Вирә хакъ гъиззәте бәхт сад-һәзари.

Сәхаби зыйльлең эчрә һәр нә ки вар.
Мәсуни, мәхфуз ула анлар, и йар!

Нәүбәһари — нәүбәһар: иртә яз, яз башы; биредә: иртә яз кебек.
Сад-һәзар — йөз мең.
Сәхаби зыйльлең — ышык (булырлык) болытларын.
Мәсуни, мәхфуз — сакланган, исән-имин.

* * *

Башындадыр мамык калпак,
Аякында читек-башмак,
Бәнем күңлем сәңа моштакъ,—
Мәхрүм [1] кыйлмасанә, җаный!

Йөзең рәушан, телең сөчек,
Буең зифа, билең нәзек,
Кулыңдадыр көмеш йөзек,—
Гаҗәб һиммәт ирер, җаный!

Колакыңда көмеш алка,
Дәхи артыңдадыр тәңкә;
Морадыңдыр сәнең кемдә? —
Сереңбелдерсәнә, җаный!

Тәмам әгъзаларың төзек,
Кулларыңда һәм беләзек,
Ауазыңдыр дәхи нәзек,—
Чү былбыл ауазы, җаный! [2]

Яратыбдыр сәне алла,
Сүзем юкдыр сәңа әмма,
Безне һәм күңелдин [3] салма,—
Бәйан әйлә әхуалең, җаный!

Беләкләрең сәнең аппак,
Өстендәдер йәшел күлмәк,
Морадымдыр сәне алмак,—
Бәйан әйлә ахуалең, җаный!

Морадымдыр ирешмәккә
Сәнең илә күрешмәккә,
Дәхи әхуаль сорашмакка,—
Ходa нәсыйб әйләсен, җаный!

Моштакъ — омтылучы; атылып, тартылып торучы.
Сөчек — тәмле.

Йөзең рәушан, билең нәзек,
Бәнем гарзым үзең күрмәк,
Күреп нәчеклекең белмәк,—
Бәйан ит [4] әхуалең, жаный!

Ки исмеңдер сәнең фәлян,
Сәңа, жаным, кыйлам сәлам,
Догаларым [5] сәңа салам,—
Мөбарәк жәмалең күрәм...

Гарз (гаэрз) — үтенеч; теләк.

* * *

Буең[1] күрдем, дидем: әлхәмделилла!
Йөзең күрдем — укыдым «къөль-һу-алла»[2].

Зирәк булсаң, белерсең бу сүземне,
Фәһем кыйлып саласән җан-күзеңне.

Гакыйль улсаң, сүзем тот, и нигярем,
Сән ирерсән, җаным, бәнем сәүәрем.

Нәһар улса, һич чыкмыйсың исемдин,
Кичә ятсам, ки чыкмыйсың төшемдин.

Бу хатымны йибәрдем бән пичәтләп,
Укыгайсән, җаный, боны хисаблап.

Бу хатымны кабул идеб ала күр,
Моңа каршы үзең дә хат яза күр.

Җаным, мәхбүбҗәмалем[3], заре әфгяр,
Үләрмен гакъибәт гамендә на-чар.

Йибәрдем мәктүб итеп бу намәмне —
Белер өчен арада маҗәране.

Сәнең вәсъфың һәмишә күңлемездә,
Сарыйлык пәйда булды йөземездә[4].

Әлхәмделилла — аллага мактау булсын.
Фәһем кыйлып — аңлап, төшенеп.
Гакыйль — гакыллы кеше (гакыл иясе).
Нигяр — сын, санәм (табыну объекты).
Нәһар улса — көндез булса (таң атканнан соң — көне буе).
Заре әфгяр — зар белән җәрәхәтләнү, яралы күңел.
Гакъибәт — ахырда, ниһаять.
На-чар — чарасыз.
Намә — язу, хат; текст.
Васъф — очрашу, кавышу (сәнең вәсъфың — синең белән очрашу).

Фиракъең утыйга көйәм [5] сәр-а-сәр,
Кичә берлән бәңа көндез бәрабәр.

Әгәр күрсәм сәне, мәхбүбҗәмалем [6],
Китәдер күңлемдәге барча гамем.

Сәнең һиҗреңдә көйә тәнем-җаным [7],
Караңгыдыр фиракъеңдә җиһаным.

Морадым, мәкъсудым, күрер күзем сән,
Ничә елдин бирле сүләр сүзем сән [8].

Ничә елдин бирле җәһдеңдә әфгяр,
Сән җан өчен гъәриблыкда герифтар.

Сәнең исмең телемдә, күздә — йәшем,
Ки гыйшыкдан дивана булды башым.

Ки чишмәдик йәш агадыр күземдин,
Халем белгел бәнем әйткән сүземдин.

Тоташ янды йөрәгем гыйшкъ утындин,
Качан булыр кысб сәүәр көн ботындин? [9]

Бән улдым бу җиһанда мисл тутый кош,
Йөземә тулды күземдин акып йәш.

Сәнең гыйшкың янадыр бәгъремездә,
Бән булсамчы бу хальдә яныңызда.

Нәчә язсам да бетмидер бу сүзем,
Егъламакдин күрмидер [10] ике күзем.

Сәнең кайгыңдин бән улдым бичарә,
Йөрәгем янадыр, аһ, нә чарә?! [11]

Бу дәрдемгә дәуа итсен ходаем:
Сәнең куеныңда булсам һәрдаим.

Сәне сәүдем [12] бинийһайә хәддин ашып,
Янадыр җөмлә җисмем ут тоташып.

Сәр-а-сәр — баштанаяк.
Сәнең һиҗреңдә — синнән аерылуда.
Җәһдеңдә әфгяр — сиңа омтылып җәфаланучы.
Герифтар — дучар.
Дәрдемгә — хәсрәтемә, чиремә.
Хәддин ашып — чиктән ашып.

Сәне күрмәй халем юкдыр чыдарга,
Йитешде бу җаным тәндин чыгарга.

Торам кайгым белән, җаный [13], каралып,
Сәне күрсәм, китә кайгым таралып.

Әйа җаным, буең сәнең зифа тал,
Йөзең рәушан, телең татлы сечек бал.

Сәнең исмең ирер мәңа мөляим [14],
Сәне бәңа бирер микән ходаем?

Әгәр бирмәсә сәне алла бәңа,
Әҗәл бирсен мәңа вә йаки сәңа! [15]

Сечек — тәмле, татлы, төче.

* * *

Үзең анда тик торасән,
Фәлянә [1], пәри наз илә,
Сурәтең дөшемә керер,
Фәлянә, пәрваз илә.

Сандугач-былбылдай кеше
[Сайрыйдыр] аваз илә,
Укый да көлә, бакубән
Бу хатка пөр наз илә... [2]

Күз дә кашың уйнаша ла,
Биегәнди баз илә.
Күкселәрең сүзләшәдер
Төрле сүзи саз илә.

И Фатыйма ла, җанашым,
Бер тоташ бу сагышым,
Гыйшкың илә җәй вә кышын.
Үтә көз дә, яз илә.

Ник бу күңлем түзмидер лә,
Ник өмиден өздмидер лә?
Әллә тоташ сүзлидер лә
Дәрдкә сабры аз илә!

Сагынып, и Фатыйма ла,
Килсәнә бер катыйма ла!
Кайгылы әукатыйма ла
Талда бул һәм раз илә! [3]

Пәри наз илә — пәри (кызларына) наз белән.
Пәрваз илә — очып йөргән хәлдә, очкан килеш.
Пөр наз илә — бик назланган хәлдә.
Баз илә — уйнап, уйнаган төсле.
Күкселәрең — күкрәкләрең.
Сүзи саз илә — сүзләрне килештереп.
Дәрдкә сабры аз илә — хәсрәткә (чиргә) сабыры азлыктан.
Әукатыйма — вакытларыма.
Талда булу — дәва булу, таяныч булу, ышык булу.
Раз илә — сер (хикмәт) белән.

* * *

Бер тәбәссем садир улса гөлкөшадлардин мәгәр,
Шөгъләсендин зольмәт ула җөмлә ул нәҗме гомер!

Шөгълә идәр зольмәт эчрә сән нигярнең хәндәсе,
Кашлары һилял кебидер һәм яңагы ләләсе [1].

Ирер идем бер заманда къәрйәдә сакин үзем,
Сәрви къәдд вә сурәтенә дөшде шул дәмдә күзем.

Күрде күзем, дөшде күңлем ул бәдер сурәтеңә,
Хәйран улып, гашыйк улдым шул заман сирәтеңә.

Күз күрергә дилбәри күп, назәнин — хәйр-ел-бәнат,
Дешләре дил рәгъдидәндер, агъзыдыр къәнд-у-нәуат [2].

Йөзләре шәмсекъәмәрди, мисле тавис рәфтәсе,
Ауазы хуш гъәндәлибди, тутый кеби гөфтәсе.

Тәбәссем садир улса — елмаю күренсә, елмаю пәйда булса.
Гөлкөшадлар — чәчәк аткан гөлләр; монда: матур кызларның йөзләре.
Шөгъләсендин зольмәт ула — сүзгә сүз: нурыннан караңгылана; мәгънәсе: кызлар елмаюы янында төссезләнеп (нурсызланып) кала.
Нәҗме гомер — яшәү йолдызы, хәят йолдызы.
Нигярнең хәндәсе — гүзәлнең елмаюы.
Шөгълә идәр — яктырып, нурланып торыр.
Һилял — яңа туган ай.
Къәрйә — авыл.
Сакин — торучы, яшәүче.
Сәрви къәдд — сәрви (кипарис) сын.
Шул дәмдә — шул чакта, шул мизгелдә.
Бәдер — тулган ай.
Сирәтеңә — йөреш-торышыңа (күркәм холкыңа).
Дилбәри күп — күңелгә ягымлылары күп.
Назәнин — хәйр-ел-бәнат — иң назлы — кызларның гүзәле.
Дил рәгъдидәндер — күңел бизәгедер.
Къәнд-у-нәуат — шикәр вә нәуат.
Шәмсекъәмәрди — шәмсекамәрдәй: кояш һәм айдай.
Рәфтәсе — йөреше, хәрәкәте.
Гъәндәлиб — сандугач, былбыл.
Гөфтәсе — сөйләшүе, сөйләве.

Һилялә охшар йөзеңә төшде күңлем рәгъбәте;
Күз күрекле йарны сәүмәк әнбийалар сөннәте [3].

Сән икәнсең, белмәс идем, кыйлды мәдех бер фәлян,
Галимә дип, гыйлемле дип кыйлды тәфсил ул бәйан.

Җәмилә дип, кямилә дип, кәлмеш икән һәр тараф,
Къамәте йәш тал кебидер, дешләре мисле сәдәф.

Маһеруйи күрсәм идем, укыр идем күп сәна,
Садрыма гәр гъилләт улса, гъилләтенә сән дәуа!

Гъилләтемнең юк дәуасы күрмәенчә вәжһеңи,
Мәрхәмәт кыйл бу мәризъга, дидерерсән вәжгъеңи.

Гәр җәсәдем монда булса, дил вә күңлем сәндәдер,
Бәхри-дәрдкә гаркъ улыбмын,— мәгънәсе юк бәндәдер.

Күрдекем сагъәт җиһанда китде зольмәт, килде нур,
Йә кояш сән, йаки ай сән, йаки җәннәт эчрә хур! [4]

Күңлем рәгъбәте — күңелем теләге, мәелем.
Әнбийаләр сөннәте — пәйгамбәрләр сөннәте (гадәте, кушкан эше).
Кыйлды мәдех — мактады.
Җәмилә — күркәм, матур, гүзәл.
Кямилә — камил, уңган, һәр яктан да килгән.
Къамәте — сыны, буй-сыны.
Сәдәф — энҗе кабырчыгыннан эшләнгән зиннәт (төймә); энҗе.
Маһеруйи — ай йөзен (айдай йөзен).
Сәна — мактау, мактау догасы.
Садр — садыр: күкрәк, күңел, йөрәк.
Гъилләт — авыру, чир.
Вәжһеңи — йөзеңне, чырайңны.
Мәризъ — авыру, чирле (кеше).
Дидерерсән вәжгъеңи — әгәр тидерсәң (гыйшкың) чирен.
Җәсәд — тән, бәдән.
Бәхри-дәрд — дәрт-хәсрәт диңгезе.
Гаркъ улыбмын — гарык булганмын, батканмын.

* * *

Гыйшыкның пәйаны юкдыр, баскан туфрак улмаса[1],
Интиһан гыйшык улмаз, тән черел хакь улмаса.

Гъэрзыхаль итмәк өчен бер намә яздым сәңа мән[2],
Та беләсән гыйшкъ удына янмышым кап-кара мән!

И гүзәлем, егъламагыл бу гамеңә сән җәзил,
Гамь җөдалин, эш ходадин — фасбир ул съәбран җәмил!



*** («Гыйшыкның пәйаны юкдыр....») шигыре кулъязмасының баш өлеше (КДУ, ФҚ КБ, № 2383 т. кулъязма).

Пәйаны — ахыры, чиге.
Интиһан гыйшык улмаз — гыйшыкның соңы (чиге) булмас.
Хакь — туфрак, җир.
Гъэрзыхаль итмәк өчен — хәлне бәйан итмәк өчен.
Сан җәзил — син бик та; син бик күп.
Гамь җөдадин — кайгы-аерылудан
Фасбир ул съәбран җәмил — күркәм сабырлык белән сабыр ит.

Ятка куйма мәйелеңи — куйсаң, күрерсән вәйлеңи,
Сакла, җаным, гайреләрдин садрең илә зәйлеңи!

Гакыйль улан үзенә һәр [3] кемсәи йар әйләмәс,
Һәр белер-белмәс катында кәшфе әсрар әйләмәс.

Йар илән сохбәт гаҗәбдер, тәгъне әгъйар улмаса,
Багъ ара гөл-сәбез хушдыр, михнәти хар улмаса.

Бөйлә мөстәсна гүзәлсән, кем сәңа юкдыр бәдәл,
Хөснедин, и җан, мөнкъәтыйгъ кыйлмас бәне илла әҗәл.

Къәсд идәрсә әһле тогъйан алгалы җаным бәнем,
Нә гамем вар, ки хода улса мәдәдкярем бәнем?

Күрерсән вәйлеңи — хәсрәтеңне, бәла-казаңны күрерсең.
Садрең илә зәйлеңи — күкрәгең белән итәк-чабуыңны.
Гакыйль улан — гакыллы булган.
Кәшфе әсрар әйләмәс — серләрне ачмас.
Сохбәт — сөйләшү, әңгәмәләшү, серләшү.
Тәгъне әгъйар — читләрнең шелтәсе (ятларның гайбәте).
Багъ ара гөл-сәбез хушдыр, михнәти хар улмаса — бакчаларда гөл һәм яшеллек хуштыр, әгәр хурлыклы михнәте (нәтиҗәсе) тигәнәк (чәнечке) булмаса.
Бөйлә мөстәсна — болай тиңдәшсез (искитәрлек).
Бәдәл — алмаш, тиң.
Хөснедин; и җан, мөнкъәтыйгъ кыйлмас бәне илла әҗәл — аның күркәмлегеннән мине әҗәлдән (үлемнән) башка бер нәрсә дә аера алмас.
Къәсд идәрсә әһле тогъйан — азгынлык әһелләре явыз нիят итәләр.
Хода улса мәдәдкярем бәнем — ходай минем ярдәм итүчем булса.

* * *

Үсеп бара ла бер җаный,
Чыкып бара матур даный,
Мәдехли һәр кеше аный,—
Йар итсә, кемгә дә ярый!

Үзе яңа үсеп бара,
Йөзе мисле маһа пара,
Күзе — нәргис, кашы кара,—
Ниндәй булыр бара-бара?!

Мәкәрҗә калфагы сәнең,
Башыңда сачагы [уйный],
Кулыңдадыр беләзекең,—
Йөрәгем өзелә, җан[ый]!

Колагыңда көмеш алка,
Дәхи артыңдадыр [1] тәңкә;
Морадыңдыр сәнең кемдә? —
Йөрәгем өзелә, җаный!

Беләзекең кулыңдадыр,
Яка-башың буйныңдадыр,
Ике нәрсәң куйныңдадыр,—
Алар ни нәрсәләр, җаный?

Бән әгәр күршәен дисәм,
Шайәд әллә ояласың,
Оялмакың чын булса гәр,
Зәһи инсафлы баласың!

Икеләнгән булып күңлең,
Ары һәм бире чабасың,

Мисле маһа пара — маһ — ай: айга пар, айга тиң шикелле.
Күршәен — күрешәен; күрешик.
Зәһи — яхшы, шәп; бик.

Бәнем кебек сәне сәүгән,
Күп эзләсәң дә, тапмазсың.

Төшемдә күрешеп, җаный,
Сөйләшдек каты сер сүзләр;
Болай ук сүзләшә алмаслар
Нә кадәр үз булып үзләр.

Әйа җаным, күзем нуры,
Карасам гәр сәңа туры,
Китәдер күзләрем нуры —
Ки сәнсең [чын] оҗмах хуры!

Бигүк садә баламысың?
Бәне искә саламысың?
Йә онытып каламысың
Зифалыгың горурында?

Языйм микән, йитәр микән,
Сәнең мәдхең бетәр микән?
Күңелләрдин китәр микән
Сәнең дәрдең белән, җаный?!

Үз булып үзләр — үз булып беткән кешеләр.
Дәрдең — кайгың, хәсрәтең.

* * *

И белмисең, шөйлә[1] булдым
Җиһанда бән сәңа моштакъ,
Йосыф берлә Зөләйхадик[2],—
Ки бәлки зийадә моштакъ.

И җанки, хили моктандым,
Ки бер күрергә уфтандым,
Еладым, дәхи сыктандым,
Сагынып бик, булып моштакъ.

Сәүгән тоткач, киңәш тарка,
Тагын эш алка да салка[3],
Калырсың көлкегә халка,—
Тик утырма юаш, йомшак.

Юаш дигәнгә рәнҗемә,
Кесәл дә булма, кәлҗемә,
Юк әсбаб берлә алҗыма,—
Юк әсбаблар булыр моштакъ[4].

Юк әсбаб нигә аласың? —
Ки кайгы берлә бетәсең!
Тагы да кемне көтәсең?
Кемә күңлең булыр моштакъ?!

И-и, и генә лә, и генә,
Ни булды миңа, ни генә?
Эшемдә юк ла көй генә,
Нидән буды икән эш так?[5]

Шөйлә — шулай.
Зийадә — бик, бик тә.
Моштакъ — омтылу.
Хили моктандым — байтак, шактый интектем.
Халка — халыкка.
Әсбаб — сәбәпләр.
Так — шулай (русча).

Ничек табыйм ла көй генәм?
Сөйләп бир, җанеки генәм,
Матурым, и чибәр генәм,
Әгәр булсаң ки бик хуш так.

•

Бу карышмак белән, тутка,
Җитәлсаң ярый максудка;
Алып куйса бер Асмутка
Вә йаки бер яман Артак [6]...

Тутка — тутыкай, тетка.

* * *

...Кыйнап-кыйнап та тинсенмәс...
Җибәргән чакта ир селтәп,
Ки кайгы берлә гөрселдәп,
Егылып егълама, аппак.

Язылган булса тәкъдирдә,
Тап улсаң шундайын иргә,
Бәнем дә каргышым бергә
Киләчәк, шөбһәсез, аппак.

Карышканлыкда зәррәни (?)
Күңел генәм дә җәлләми,
Күрәсең бардыр әллә ни,
Йөрәгең җилкенеп, аппак.

Ишет, тыңыла, кыз, ишет,
Ки бер үгетемне биш ит,
Киңәшдән чыкмый бер эш ит,
Кур улмайым дисәң, аппак!

Зәррәни — бертектәй.
Кур улмайым — сукыр булмаем (булмыйм).

* * *

Бу сүзләрне ишетүбән,
Нәсыйхәт ал, и туганым:
«Мәңа дә ошбу кызлардик
Бәля салмасын уганым!»

Язып хат өстенә хатлар,
Күтәрдем күп яман атлар;
Күп үк өшәндереп атлар
Ни юлга китде куганым?

Бире торып да биресең,
Кире торып да киресең,
Нидән соң бәңа килмисең? —
Сөйләшсәнә, и туганым!

Изеп карасу балчыкны,
Йөреп атым да талчыкды;
Бәне кечкенә мальчиктый
Күрмәдең һич, и туганым!

Сүземне саймадың чынга,
Ки бер җавап да юк унга;
Калып торган кеби тынга,
Тик утырдым, и туганым!

Дидем бик күп сәне кыстап:
«Сөйләшергә вакыт, кыз, тап!»
Вә ләкин ялгызың йоклап,
Гафил калдың, и туганым!

Уганым — тәңрем, ходаем.
Мальчиктый — мальчиктай, бала шикелле.
Саймадың чынга — санамадың чынга.

Күңелеңне куеп дилгә,
Үзең килсәң иде мингә,
Ки мин улсам иде сингә,
Ни соң булыр, и туганым?!

Бу гафиллек, и душа мой,
Ки һич күңелгә ошамый,
Күңелемдән дә бушамый,
Бу килмәс дип, и туганым!

Инәлдем дә бугай аша,
Инәлмәсәм, йөрәк таша;
Җәелде бик, чыгып фаша,
Бу телләрдә, и туганым!

Дилгә — йөрәккә, күңелгә.
Инәлдем дә бугай аша — артык инәлдем бугай.

* * *

Дөшән сагъәтдә күңлемә
Сәне күрмәк деләр күңлем;
Гаҗәб мөмкинмедер, җаным? —
Сәне күрмәк деләр күңлем! [1]

Нә дәклү карным ач улса,
Туяр [2] бер ләкъмә йимәкдин;
Вә илля күзләрем туймаз,
Туганым, сәне күрмәкдин!

Дөшән сагъәтдә күңлемә — исемә төшкән сәгатьтә.
Деләр күңлем — беренче очракта: күңелем теләр; икенче очракта: күңелемне телер (кисәр).
Вә илля — вә әмма, тик, ләкин.

* * *

Мөнаҗәтне яза-яза
Каләм тоткан кулым тала.
Күземдин канлы йәш ага —
Хәсрәтеңдин, әйа җаным!

Асыл кошны тотар идем,
Тирәк төбенә [лә] кунса;
Сагъәт саен күрәр идем,
Сән җаныйдин әмер булса.

Сәлам яздым сәнең артдин
Сәне күрмәклекем сартын.
Иякләрең кызыл алтын —
Ушал кыйлмыш сәне мәүля!

Күн итекдер аягымда,
Көмеш йөзек бармагымда,
Йәшләр түгел — кан елаймын
Сәне сагынган чагымда.

Гозер сүзем шулдыр, җаный:
Бүтән йарга дашлап китмә;
Бу мөнаҗәт барып йиткәч,
Сүләшүгә мохтаҗ итмә.

Биек мәсҗед манарасы,
Ялтырыйдыр тәрәзәсе,
Бу дөньяда кауышмасак,
Ута янсын заманасы.

Иртә торып тышка чыкдым,
Кошлар очты оядин ла,
И җаныем, бергә сорыйк
Кауышмакны ходадин ла...

Сәне күрмәклекем сартын — сине күрмәклегем өчен.
Ушал кыйлмыш сәне мәүля — сине ходай шулай яраткан.

* * *

Бәнем җаным синең җаның имәсме,
Бәнем җаным саңа кабул имәсме?
Синең җаның бәнем корбаным улсын,
Кулың — ястык, чәчең юрганым улсын!

* * *

Җөмлә гөлнең нуры китә
Сачак вакытлары үткәч;
Матур кызның кадре китә
Егерме йәшенә йиткәч.

Җиһан багълары ки нурлана
Җөмлә гөлләр сачак аткач;
Бәнем күңлем тынычланыр
Синең куйнгынаңа яткач!

* * *

Сурәтең дөшемә керер,
Дөшем эчрә күзем күрер:
Күз алдында биеп йөрер,
Терәп күксен, идеб рәкъкас.

Ки куркам бу сурәт-нәкъши,
Бер йицел улмасын бәхши,
Дивана булмасам яхши,—
Киделп гакълым, булып гъәувас.

Тагъ-таш, сәхралар кичеп,
Йитәр идем сәңа очып,
Ятыр идем сәне кочып,
Ки куйнында булып гъәувас.

Гашыйк-мәгъшук табышубән,
Агызларны кабышубән,
Кочышубән, очышубән
Улышамыз икәү мәгъас.

Иляһи, ошбу матурга
Нәсыйб ит бергә ятырга,
Үбеп агъзыны татырга,
Ки куйнында булып гъәувас!

Терәп күксен — күкрәген киереп.
Идеб рәкъкас — биеп (тәгәлрәк: биюче кебек итеп).
Бер йицел улмасын бәхши — бер җиңел (төш) бүләге генә булмасын.
Гъәувас — суга чумучы (водолаз).
Мәгъвас — гөнаһлы.

* * *

Ки бән яздым сәңа, җанкәм, ничә хат,
Бәйан итдем ничә хатда ничә кат:

Оемагыл эчеп гъәфләт шәраби,
Заигъ үткәрмә әйаме шәбаби.

И бәгъидә, сәнең хәзер бу чакда
Үбеп-кочып сәүәр вактың кочакда.

Сафадин дөньяның зәукъен алырсың,
Гомерне үткәнен тоймай калырсың!

Ки былтырдан бире нишләп торамыз?
Нә файда әйләдек? Нә эш кырамыз?

Ки бән көтдем сәне, сән елны көтдең,
Бәнем чөн саргаеп, шәт, сән дә бетдең?!

Сәне сәүдем, тотышлый уңга иңдем,
Табып хәйлә, сән аны сулга сүтдең.

Бән әйтәмен, җитим диеп бу дуска,
Сән әйтәсең: «Йөри бу — гакълы кыска!»

Фәлянә, әй, сәне бик сәүде күңлем,
Сәнең күңленне белмәзмен, и сеңлем!

Мәхәббәтдин сәңа вар ирде дәрдем,
Сорарга бер тоташ нийәт идәрдем.

Ишеткәчдин, исем дә китде лә, ух:
Дидем, уф алла, калдым алмыйча ук!

Гъәфләт — ваемсызлык.
Әйаме шәбаби — яшьлек көннәрен.
Бәгъидә — бирЕдә: ерактагы кул җитмәс яр.
Сафадин — рәхәт чигүдән.
Зәукъен — тәмен, ләззәтен.

«Ух» ормакда янар икән йөрәкләр,
Дәуасын тапмады бик күп зирәкләр.

Табыла дөньяда бик күп кирәкләр,
Шәкерткә килгән кызлар тик сирәкләр.

Алар ташмы икән, әллә тимерме?
Гомердә бер генә йомшап, килерме?

Язып, ун хат җибәрдем йә егерми,
Укымыйсың микән, күзең йә күрми?

Язамын күп, эчемдин гамь бушар дип,
Бу күп сүз эчрә бер сүзем ошар дип.

Ки бән вардым сәне сөеп, алам дип,
Ки сән бәне кудың тиле малайдик.

Бу куганыңны сән сайма уенга,
Әгәр уйныйк дисәң, кил, кер куенга!

Үзең яхшы, китаб-Коръән укыган,
Ошыймы соң сәңа, җаным, бу куган?

Төсең-буең ишетеп, сәүдем, и рух,
Йөзең күргәч, сагышыңдин дидем: «Ух!»

Мәхәббәтем шу тәкле сән сылуда:
Ух итәмен, сагынып, һәр сулуда.

Гаҗәб калдым, җаныем, бу эшемгә,
Һушым китәр, исем китәр һушымга.

Мәхәббәт белән янганга йөрәкләр,
Дәуасын тапмады бик күп зирәкләр.

Табыла дөньяда һәрбер кирәкләр.
Гыйшыкка дару юк диләр зирәкләр.

Гъәһеднамә итәр ирдем хатыңны,
Хатың эчрә әгәр күрсәм атыңны.

Йөрердем көндезен кулымга алып,
Кичен ятыр идем куйнымга салып.

Сайма — санама, исәпләмә.
Гъәһеднамә — килешү язуы.

Ходa язган микән ошбу җиһанда
Күрешергә, сөйләшергә ниһанда?

Әй фәлянә, үлекмен — тергезә күр,
Бер аулакда үзеңне күргәзә күр!

Болай торганча икәү ары-бире,
Кушылаек икәүләп, китмә кире.

Килер булсаң, и матурым, сеңелкәй,
Сүземне тыңла, калдырма күңелкәй.

Әгәр дә килмәсәң, алдап йөретмә,
Сәүмәгәнеңне бер дә эчдә тотма.

И матурым, әгәрчә тартса җаның,
Бу дәкле катмасын ла бәңа каның!

Килермүсән? — Сүзеңне сүзлә тугъры,
Сүзе ялган кешене дирләр угъры!

Ниһанда — яшерен җирдә, аулакта.

* * *

Уян гъэфлэтдин, и җанкэм.
Сафа сөр вакъты форсатда;
Карыгач, бу төсең калмас,
Көсүф алмыштый көрсэтдә.

Йә бик шаянмы, шукмы сән? —
Килергә һич ашыкмыйсән.
Йә бүтәнгә гашыйкмусән? —
Сүзең һич узмый рөхсэтдә.

Димә: «Ник язасың бик күп?
Эчең дә әллә пошамы?»
Нәчә язсам да, и җанкәм,
Эчем ник бер дә бушамый!?

Вә йә күңлем кышын-җәен
Бу бәгъидә абыстаем
Сагынып «ух» оран саен
Кулым язарга кушами?

Бу халем тамаша кебек:
Тоташ көек, тоташ көек!
Ки һич дә күрмәгәндин үк
Җиһанда вакъты хушами...

Вакъты форсатда — форсатлы вакытта, җайлы вакытта.
Карыгач — картайгач.
Көсүф алмыштый көрсэтдә — каты суыктан кояш тотылган кебек (тоныкланып, нурсызланып) калганда.
Бәгъидә абыстаем — ерактагы абыстаем.
Вакъты хушами — бәхетле вакытымы.

* * *

Сәлам яздым сәңа, сәрвиҗәмалем [1],
Сәламемне алыр булсаң, гүзәлем.

Морадың [вә] мәкъсудың бирсен алла,
Хаталардин сәне сакла[сын] алла [2].

Сәнең йөзең кояшдик нур икәндер,
Ходай сәне бәңа язган микәндер?

Сачең охшый Зөләйханең [3] сачена;
Сәнең керфекләреңдин нур сачелә.

Язаеммы, җаныкаем, йитәрме?
Сәне алмай күңел гыйшкы бетәрме?

Сәне сәрбагъ эчендә гөл яратды,
Бәне сайрамага былбыл яратды [4].

Сәнең сайрамакың дидар өчендер,
Бәнем сайрамакым сән йар өчендер.

Кулың — ястык, сачең юрганым улсын,
Бәнем җаным сәнең корбаның улсын [5].

Надан ирне кияү итсәң үзеңә,
Кыямәт көн кара ягар йөзеңә.

Нә хурлыкдыр сәнең кебек матурга
Надан астында кыймылдап ятырга.

Сәнең вәгъдәң көтә-көтә, гүзәлем,
Өзелеп бетәдер бәнем үзәгем.

Сәрбагъ — бакчалар «башлыгы»: бакчалар бакчасы, иң яхшы бакча.
Дидар — күрешү, очрашу.

* * *

Фиракъеңдин күземдә[1] йәш корымай,
Бән йөримен кичә-көндез оемай.

Иляһи, җөмлә гамгинне шад кыйлгыл,
Ки гамедин бәндәне азад кыйлгыл.

Гозер кыйлып язам хәлемдин хәбәр,
Мәне гыйшык утыйга кыйлма грифтар.

Без гъәрибләр йөзеңне күрсәк иде,
Билең кочып, ләбеңне сурсак иде[2].

Морадым, мәкъсудым бәнем, гүзәл, сән,
Нәчә елдин бирле эчем өзәлсән.

Тәмам гомрем сәнең һиҗреңдә әфкяр,
Гамең берлән гъәриблекдә грифтар.

Йөземгә бак — тәнем, ике күзем сән,
Шикәр агъзыңни ач — ширин сүзем сән.

Фәрагъәт берлә һич гашыйк ятармы?
Кеше рәхәт белә гашыйк итәрме?[3]

Фиракъеңдин — аерылудан, аерым торудан; синнән башка торудан.
Оемай — йокламый.
Гамгин — гамьле, моңлы, кайгылы.
Кыйлма г[е]рифтар — дучар кылма.
Гъәрибләр — монда: кимсетелгәннәр, өлешсезләнгәннәр.
Сәнең һиҗреңдә әфкяр — синнән аерылуны фикерләүдә.
Фәрагъәт берлә — тынычлык, гамьсезлек белән.

* * *

Сәнең күңлең, җаным, кемне көтәдер?
Көтеп юкны, газиз гомрең үтәдер.

Бу кадәр үк инәлеп, и җаный ла,
Сүзем тыңлап, йарым булсаң, ярый ла.

Әгәр дә тыңламасаң, и Фатыйма [1],
Үкенермен бу инәлгән хатыйма.

Гомер буенча хәсрәткә саласың,
Ничек итим, эчем өзеп аласың.

Сагынып егъласы булсам гомергә,
Эчем янып, дүнәр кара күмергә.

Егъларга каламын йөрәк канилә [2],
Җаный ла, и җаный ла, и җаный ла!

Җаныем ла диеп хәсрәт йиәргә,
Нигә ташладың, и җаным, дийәргә.

Үкенечкә генә туган икәнсең,
Бәңа хәсрәт өчен булган икәнсең.

Сәне сәүгән идем җаным-тәнемлә,
Нидән ташладың, и җаным, бәне лә?

Исемә төшәсе булсаң ялан бик,
Халем мөшкил булыр, җаный, яман бик.

Канилә (каны илә) — каны белән.
Йийәргә — ашарга.

* * *

Кулым йитмәс, ки тотсам, йар, үзеңне,
Күзем йитмәс, ки күрсәм, йар, йөзеңне [1].

Бәнем халемдин аңа һич хәбәр юк,
Ки бу дәрдемдин аңа һич әсәр юк.

Әйа җаным, сәне кайдин табармын?
Мамык берлән нәчек утны яварымын?! [2]

Бән бичара сәне кайдин күрәрмен?
Чыкмыйча утыңызда күп йөрәрмен.

Сәнең дидареңә мохтаҗ булыпмын,
Тәкый гыйшкың утыйга янып-көепмен [3].

Мөнәүүәр җәмалеңчөн басты кайгу,
Бәңа сәнсез ошбу җиһан карангу!

Җәмалеңне күреп хәйран булыпмын,
Сәне күрмәк өчен гирйан улыпмын.

Көчем юкдыр хәрәмеңә йитәргә [4],
Илкем йитмәй сән җаныйны тотарга.

Йөзең күрергә теләймен, үзеңне,
Билең кочып сүләшергә сүземне!.. [5]

Дидар — күрешү, очрашу.
Мөнәүүәр — нурлы, якты, балкып торган.
Гирйан — елаучы, күз яше түгүче.
Хәрәм — тыелган әнрсә; гаиләдә ят кешеләр өчен тыелган урын (хатын-кыз өчен билгеләнгән урын, бүлмә).
Илкем — кулым

* * *

Гаҗәб лэтыйфәдер җисмең,
Ки белми ничек[дер] исмең;
Йөрәгем, бәгъреми кисдең,
Ки күргәзеп кэмаляти.

Билең нечкә, буең һәм төз,
Тәнең саф, гүйәки ак буз;
Әгәр дисәң дә сән бер сүз,
Укыр идем йөз айати [1].

Гаҗәбдер ки билең анчә,
Лэбең лэгъел, дешең гъөнчә;
Юк ирде күрдекем бончә,
Күрүбән күп кэмаляти.

Үзең сылу, йөзең күркәм,
Нәчә дисәм дә улыр кәм;
Язарга фәһм йитмидер һәм [2]
Кәгазь, кара, мәкаляти.

Кашың кара сызылмышдыр,
Дешең йинҗү дезелмешдер,
Йөрәк-бәгърем өзелмешдер
Гыйшык дотып сәңа катый.

Сачең кара ирер төндик,
Сачең ара йөзең көндик;
Улыбмын имди Мәҗнүндик [3],
Идеп гыйшык хыйаляти.

Лэтыйфә — гүзәл, күркәм, нәфис.
Кэмаляти — камиллекне.
Айати — айәтләрне (догаларны).
Лэбең — иренең.
Гъөнчә — чәчәк бөресе.
Фәһм (фәһем) — аң, аңлау, төшену.
Мәкалят — мәкаләләр; бу очракта: сөйләр сүзләр.
Хыйаляти — хыялыйларча.



*** («Гаҗәб ләтыйфәдер җисмен...») шигыре кулъязмасының баш өлеше (Ш. Абилов коллекциясеннән).

Сәнең өчен, әйа җаным,
Тәнемдә калмады каным;
Бетебдер дәрде-дәрманым
Күрәчәк ошбу халяти.

Әйа җаным, кызыл алмам,
Ки сәндин күңлеми алмам;
Килүрсән — гайрени алмам,
Идеп сәңа макаляти! [4]

*

...Колак салып ишет, җаным,
Идәем бер хикәяйәти... [5]

Яратыбдыр сәне ул хакъ,
Кызыл йакут кеби һәм ак
Йөзеңә салды күп рәүнәкъ,
Идүбән күп ригайәти [6].

Йөзеңне әйләде гөлтик,
Чәчеңне кыйлды сөнбелтик,

Күрәчәк — күргәч.
Рәүнәкъ — яктылык, нур.
Ригайәти — ригайәтне: олылауны, игътибарны.

Ауазың итде былбылтик,
Идеп фазли гъинайәти [7].

Сылу әйләде үзеңне,
Тулан ай итде йөзеңне,
Идеп нәргистәй күзеңне
Мөдәүвирсез бигайәти [8].

Кашыңны әйләде кара [9],
Ачык кыйлды ике ара,
Һиляля охшашы вара,—
Чигелмеш биниһайати!

Йөзең биңзәр тәмам айа,
Күрәнләр хур кеби [10] сайа;
Сәңа охшашлы, әйт, кайа? —
Яңылдым бер бу айати.

Йөзең охшар кызыл гөлә [11],
Йөзеңдин нурларың агыла,
Күрәчәк күзләр чагыла,
Көнәш кеби шәрайати.

Күзең гәр кешегә бакылыр,
Күзеңдин утларың чакылыр,
Кәлүбән сөрмә якылыр,—
Кидәрер һәм бу сагъәти.

Ки ак йакут кеби балкып
Ике садрең тора калкып,
Ки күлмәк үтәли балкып,—
Нуры улыр галямати! [12]

Идеп фазли гъинайәти — фазыйльлекне (өстенлекне, камиллекне) бүләк итеп.

Мөдәүвирсез бигайәти — бик тә туры карый торган.

Һиляля охшашы вара — айга охшашлыгы бар.

Биңзәр ... айа — айга ... охшаш.

Сайа — саный.

Көнәш кеби шәрайати — шартлары (сыйфатлары) кояш шикелле.

Бакылыр — багылыр: төбәлер, карар.

Кидәрер һәм бу сагъәти — бу сәгатьләрдә һәм җуяр (шунда ук юкка чыгар да).

* * *

Мөбарәк къамәтең хубий,
Үзең мәхбүбләрнең хуби,
Ки тугаймусың куби?—
Бу галәм бәрчидә нәбат!

Кашың карасыдин сәүдем,
Ки күрмәен сәне сәүдем.
Жанка ... суйдым (?),
Вә илля соңрада һәйәат.

Сәнең исмең зикер әйләп,
Сыйфатыңны фикер әйләп,
Ки һушың гакълыми бәйләп,
Вә илля соңрада һәйәат!

Къаматең хубий — буй-сының гүзәл.
Хуби (хубы) — яхшысы, әйбәте, матуры.
Тугаймусың куби — күпләп, куп булып туганмысың.
Бу галәм бәрчидә нәбат — бу галәм яшеллек (гөл-чәчәк?) беләв тулы.
Вә илля соңрада һәйәат — әмма соңында үкенеч.
Зикер әйләү — искә төшерү, кабатлау, гел искә тоту.

* * *

Сөйгәнемгә инанмасаң [1], Бәдига,
Ни әйтерсән йөземдәге сарига?

Инәлә белмәдем сәңа, күрәсең:
Итеп мәхрүм, ишегеңдин сөрәсең.

Бәдига, ник болай мәңа катасың?
Бәнем күз йәшемә ничек батасың?

Әгәр чәнди [2] мәне мәхрүм итәрсән,
Күрәек, нинди егеткә китәрсән!

Мәхәббәт булмасын барган йиреңдә,
Сафалар сөрмә һич барган ирендә [3]:

Болыттик кайгылар башыңа ягъсын,
Тәэссефтин күзеңнән йәшләр аксын!

Йә тап булгыл ки бер залимгә хун-хар,
Йә бер зәнки кеби астында бул хар! [4]

Этен сөргәндәй кусайде катындин,
Җәфа күрсәтсәйде көндәш хатындин!

Йә, сөйәмен дип алдап, бер мут алсын,
Утырыр йиреңне, баргач, ут алсын!

Җәмалең күрсәйде кара төтендик,
Мөбарәк йөзеңи хурлап этендик!

Катасың — катысың.
Чәнди — монда: моның кадәре, моның тикле.
Сафалар — рәхәтләр.
Тәәссефтин — үкенечтән.
Хун-хар — канэчәр.
Зәнки — тупас, кырыс, мәрхәмәтсез.
Хар булу — хур булу.
Кусайде — куса иде.
Күрсәтсәйде — күрсәтсә иде.
Җәмалең — матурлыгың, гүзәллегең.

Мөбарәк куксинә мендергәненңне,
Күңел алып сөеп көлдергәненңне.

Тәваззигълык итәнләрең йөз анча [5],
Берин [6] курмәсә иде ул тузанча!

Йә онтылсаң иде сән кала-кала,
Йә тап булсаң иде бер ак сакала!

Мыекы санысчайде михе әлимтик,
Агыз-йары [7] тоелсайде хәмимтик.

Сулышы килсәйде баде сәмумтик,
Кирәкле эгъзасе булсайде мумтик [8].

Уенны уйнай алмасдин [9] уенча,
Ки моктандырсайде гомре буенча.

Бәдига, рәнжемә: каргадым уйнап,
Хатерең калмасын юк фикри уйлап.

Сәңа килеп бу кайгылар, бу дәмләр,
Мәңа шул хәлдә юктыр яхшы дәмләр.

Йөреткәнгә якын булдым йуләргә,
Юк ирсә ярамас болай сөйләргә.

Нидән үфкәлисәң мәңа, Бәдига?
Нидән бизден, нә эш булды, зәригъә?

Күземнең рәушане, жаным Бәдига,
Төшәр бер көнге сүз күнлең йадига.

Колак салдым сораган ул үләткә,
Йәрәштермә, дидем, надан егеткә!

Кийәү итсәң надан ирне үзеңә,
Кыяматдә кара якар йөзеңә.

Куксинә — кукрәгенә, түшенә.
Тәваззигълык итәнләрең йөз анча — йөзләрчә түбәнчелек итүләрең.
Михе әлимтик — кайгы кадагы шикелле.
Агыз-йары тоелсайде хәмимтик — авыз тарафы тоелса иде тирләгән кебек.
Баде сәмумтик — сәмум җиле шикелле.
Мумтик — мум шикелле, балавыз шикелле.
Моктандырсайде — интектерсә иде.
Дәмләр — вакытлар; сулышлар.
Зәригъә — монда: яшь кыз (асылда: үсенте).
Күңлең йадига — күңелең хатерен.

Матур булсаң да, баргачдин наданга,
Күрәлмәссән гомер буенча санга.

Бу дөньяны беләсән һич, Бәдига,
Вәфасы юк, зәуаледер сәригъә.

Безем тик килде күп гашыйкы-мәгъшук [10],
Тора торгачтан ук һәб булдылар юк.

У Тәймус шаһ кызы ирде Зөләйха [11],
Ничә ел егълайуб, итәрде нәүхә.

Дир ирде, сагынып, һәр дәмдә «уф!» дип,
«Йосыф лә! И Йосыф лә! И Йосыф!» — дип.

Ахир бер көнне ул мәкъсудка йитде:
Тереклек итде бергә, үлде-китде.

Мисъри шаһ угълы Сәйфелмөлек дә [12]
Ничә ел йөрде хәсрәтдә, көекдә.

Дир ирде: «Ник ишетмисән, сәригъәм,
Бәдигам лә, Бәдигам лә, Бәдигам!» [13]

Адашыңны алып, мәкъсудка йитде,
Сафалар сөрде һәм дөньядин үтде.

Дәхи Мәҗнүн, тотып күп гыйшкы-мәйле,
Дәйүр ирде: «И Ләйле лә! И Ләйле!» [14]

Дәхи борын заманда үтде Фәрһад,
Ки Ширин атлы кызчөн итде фәрйад [15].

Барысы да җиһанга килде-кичде,
Бу дөньядин ахир бер көнне күчде.

Ки мән дәхи бу арага тезелдем,
«Бәдигам!» — дип өзелдем лә [16], өзелдем!

Буш үткәрмә, Бәдига, бу бәһари,
Матур чаклари һәм ләйле-нәһари.

Вәфасы юк, зәуаледер сәригъә — ышанычы юк, ә бетүе исә тиз.
Һәб — барысы да, һәммәсе.
У — ул.
Итәрде нәүхә — зар елар иде.
Сәригъәм — ашыгучым, сабырсызым.
Мисъри шаһ — Мисыр шаһы.
Итде фәрйад — елады; агълады.
Бәһари — бәһарне: язны.
Ләйле-нәһари — төн һәм көннәрне.

Ки гыйш-гыйшрәтдә булубән бу чаклар,
Сафалар сөрәдер бик күп кочаклар [17].

Бу дөньяга таянмау, и Бәдига,
Вәфасыздыр, зәуаледер сәригъә.

Баралсаң мәндин артыкка ярый ла:
Сәнеңтик сайлаган — сазга тарый ла!

Җәмалең берлә мактанма, Бәдига,
Ки бәндәсән: ничекдер ул талигъә? [18]

Җәмал дәхи китә торган буяутик,
Китәр тиздән кояш төшкәч кыраутик.

Мәни ташлап, күтәрмә бер дә борның:
Йәшем төшсә, һич уңмас барган урның!.. [19]

Вәфасыздыр, зәуаледер сәригъә — ышанычсыздыр, ахыры (бетүе) исә якын (тиз үтүчән).
Талигъә — бәхет.

* * *

*

Сәламулла күземнең карасыйга,
Җигәргүшәм, йөрәгем парәсыйга.

Ике күзем нуры, җаным Бәдига [1],
Тәнем, рухым, рәуанем мәкъсадыйга.

И фәлян иленең шәмсе вә маһы,
Ничек тими сәңа гыйшкымның аһы?

Исем китәр ки сән абызтутыйга:
Бәне салдың Зөләйханең утыйга [2].

Һауаланган булып, гакълымны йуйдың,
Бәне мәхрүм идеп хәсрәткә куйдың.

Һауаланган сәнең кебек ничәләр,
Егълып, гомре вар хәсрәт чигәләр.

Кеше үз-үзенә гәр салса бәла,
Җиһан халкы җыелса, белмәс ала.

Сәне белгән идем тугъры үземдик,
Сүзеңә дә инандым үз сүземдик... [3]

Сәнең сүзең икән ялган катышлы:
Күңелгә булмады бик үк ятышлы.

Сәламулла — алланың сәламе.
Җигәргүшәм — бавырым кисәге, бәгырем.
Бәдига — күркәм, гүзәл, тиңсез; татлы телле; хатын-кыз исеме.
Рәуанем мәкъсадыйга — юнәлешем максатына.
Шәмсе вә маһы — кояшы һәм ае.
Йуйдың — җуйдың.
Гомре вар — гомере барынча, бар гомеренә.
Җыелса, белмәс ала — җыелса да, ала белмәс (бәладән ала алмас).

Бәне ничек ишегендин сөрәсең?
Үзең дә һәм аны бер-бер күрәсең:

Сәнең кебек күтәргәнләр борынны
Сирәк буладыр уңдырган урынны.

*

Баралсаң бәндин артыкка — ярый ла,
Сәнеңдик сайлаган — тазга тарый ла.

Бәне ташлап, күтәрмә бер дә борның,
Йәшем төшсә, ки һич дә уңмас урның.

Йә алдалап, үзеңне бер мут алсын,
Утырыр йиреңне, баргач, ут алсын!

* * *

Сәламулла [1] йөрәгем парәсыйга,
Тәнем рухы, күземнең карасыйга.

Сәлам, и куәти рухы рәуаным,
Сәлам, и дилбәри җан-у-җиһаным!

Сәлам, и миһербани дилнәуазем,
Сәлам, и бостанә сәрвийе-назем!

Сәлам, и лаләи руй гөлгъөзарем [2],
Сәлам, и куәти җан-у-бәһарем!

Бәңа сәнсез бу эчкәнләр кызыл кан,
Бәңа сәнсез ачыйгъ ирер сөчек җан.

Бәңа сәнсез газаб ирер бу рахәт,
Бәңа сәнсез йөрәкдә мең җәрахәт.

Бәңа сәнсез хәрам [3] ирер бу сохбәт,
Бәңа сәнсез бу сохбәтләр чү михнәт.

Бәңа сәнсез мөсыйбәтдер мәгъишәт,
Бәңа сәнсез мәгъишәтләр мәшәкъкъәт.

И куәти рухы рәуаным — и җанымның ургылып торган куәте.
И дилбәри җан-у-җиһаным — и җан һәм дөньялыгымның иясе (гүзәл хуҗасы).
И миһербани дилнәуазем — и миһербанлы (шәфкатьле) күңел иркәләүчем.
И бостанә сәрвийе-назем — и бакчалардагы назлы сәрвием.
И лаләи руй гөлгъөзарем — и ләлә йөзле алсу йөзем.
И куәти җан-у-бәһарем — и җанымның һәм (тормыш) язымның куәте.
Сохбәт — сөйләшү, әңгәмәләшү, серләшү.
Чү михнәт — михнәт шикелле.
Мөсыйбәтдер — бәхетсезлектер.
Мәгъишәт — тормыш, яшәү, тереклек.

Сәнең гыйшкың белә ахир үләрмен,
Фиракъең утыйда әксәр көйәрмен.

Кыйлыбдыр такъэтем такъ иштийакың,
Ки үртәр хәстә җанымны фиракъең.

Эчәрмен ширбәти һиҗран һәмишә,
Фиракъыйда күзем [4] гирйан һәмишә.

Сәнең йадың белән гөлзар ачылыр,
Сәне күрмәй йөрәкдә кан сачылыр.

Мән, и бидил [5], сәне къәндин күрәрмен? —
Фиракъең утыйда бисйар көйәрмен.

Сәламулла йөрәкем парәсыйга,
Тәнем рухы, күземнең карасыйга! [6]

Фиракъең — аерым булуың, аерым торуың.
Әксәр — бик, күп, көчле.
Кыйлыбдыр такъэтем такъ иштийакың — сиңа көчле мәхәббәтем, теләге тәкатемне (сабырымны) җуйды.
Ширбәти һиҗран — аерылу ширбәте.
Күзем гирйан — күзем йәшле.
Сәнең йадың — сине йад итү белән.
Гөлзар — гөлбакча, чәчәклек.
Бидил — шәфкатьсез, каты бәгырьле.
Къәндин — кайдан, кайда.
Фиракъең утыйда бисйар көйәрмен — синнән аерылу кайгысы утында бик көярмен.

* * *

Қаләм язды бераз монча кәлями,
Қабул идеп ала күргел сәлами.

Боны яздым сәне гайәт сәүгәндин,
Қи гыйшкың утыйла эчем көйгәндин.

Гафил улма, сүзем тот, и нигярем,
Ике гыйшык онытмас бере-берен.

Мәгъшукый җан, күзләрем күрде сези,
Шул замандин хәйран әйләде безн.

Күзләрем күрде — сезә улдым биһуш,
Имди сәнсез күңлем һич улмаз хамуш.

Җәмалең хур кебидер, күзләрең нур,
Қыйла күрмә висалеңдин бәни дур.

И җаным [1], кыйл бәнем сүземи кабул,
Шаде-харәм әйләгел, кыйлма мәлүл.

Әйа мәхбүб, тутый кош сән җиһанда,
Бәнем илә күрешсәнә ниһанда.

Күңелдин чыккусы юкдыр хыялың,
Дәрига, күрмәдем ширин җәмалең.

Сәлам улсын сәңа, фәлян, ки бәндин,
Қи мондин соң көтәрмен мән дә сәндин.

Кәлами — кәлямне: сүзне.
Нигярем — гүзәлем, чибәрем.
Хамуш улмаз — телсез, тыныч булмас.
Висаль — кавышу, күрешү, очрашу.
Дур — ерак.
Шаде-харәм — шатлыклы; күңелле.
Мәлүл — күңелсез, боек; кайгылы.
Мәхбүб — сөекле, сөйгән яр.
Ниһанда — аулакта, яшерен урында.
Дәрига — үкенеч, кызганыч.

Робагыйлар[2] чыкарып яздым хатый,
Язмаз ирдем бу хатымны — гыйшкым катый.

Мәгъшукый жан, сән кабул кыйлсаң бәни,
Җан-дилилә бән кабул кыйлдым сәни [...]

Ирсаль әйләдем сезгә бән бу хатый,
Тауил гомер рузый кыйлсын ул бакый [...]

Фида улсын сәңа һәм җөмлә малым,
Дәригъ итмәм, теләсәң дәхи җаным.

Ошбу хатка исмеңезне язмадык,
Язар ирдек, гайреләрдин базмадык.

Мәгъшукый җан, сәнең исмең фәлянә,
Сәне бәңа рузый кыйлсын бер алла.

Бу сүзләрдин морад нәдер — аны бел,
Сәүәр ирсәң, ишарәтне бәйан кыйл.

Ошбу сүзне халка изһар әйләмә,
Хатыңызны бездән ниһан әйләмә [...]

Кабул күрсәң, хатыма каршы хат яз,
Кабуллыкны эчендә аңлатып яз.

Әгәр япсаң кешенең[3] бер гайбене,
Ходай япкай сәнең һәм гаебеңне.

Гөнаһ, гаеб — бәндә[ләр]нең эшидер,
Кирәк кызлар, кирәк егет эшлидер...

Җан-дилилә — җан-күңел илә.
Ирсаль әйләдем — җибәрдем, күндердем.
Тауил гомер рузый кыйлсын ул бакый — ул (алла) мәңгелек озын гомер бүләк итсен.
Дәригъ итмәм — кызганмам.
Рузый кыйлсын — бүләк итсен, багышласын.
Халка изһар әйләмә — халыкка белдермә.
Ниһан әйләмә — яшереп тотма (ягъни: безгә җиткез).
Япсаң — яшерсәң (капласаң).

* * *

Бу хатымны кабул итеп аласың,
Кабул итсәң, читен өзеп каласың [1].

Сәнең өчен аһе-ваһ органларым,
Бер күрергә тилмереп торганларым!

Қаным, сәүгән йөрәгем парәсе сән,
Тәнем рухы, күземнең карасы сән.

Ходa язсын мөкъәддәр каләмендә:
Кауышдырсын бу дөнья галәмендә [2].

Қыяфәтең, сыйфатың суда кондыз,
Үзең былбыл, күзең мисальдә йолдыз.

Сәнең дәрдең белән даим йөримен,
Сәне күргәч, сары майтик эримен!

Сәнең дәрдең билә булдым герифтар,
Хода кыйлса иде сәне, гүзәл йар!

Сәнең буең Ак Иделнең камышы,
Сүләгән сүзләрең былбыл тауышы.

Сәнең өчен акыздым күздә йәшем,
Бу хәсрәтдин чыкар микән бу башым?! [3]

Мөкъәддәр — тәкъдир, язмыш.
Мисальдә — чагыштыруда.
Герифтар — дучар.

* * *

Гүзәлсән мисле алмадый,
Җәмален күңелем алдадый,
Түзәр хәлем калмадый,—
Нитәен бән бу бәляне?!

* * *

Ишет хотбә гыйшыклык мөнбәрендән:
Бәйан идәм мәхәббәт гъәнбәрендән.

И җаныем, бәне ташлыйсың ахры,
Беленәдер сүзеңнең рәһбәрендән.

Гъәнбәр — хуш исле үлән; *мәхәббәт гъәнбәрендән* — мәхәббәт әроматыннан.
Сүзеңнең рәһбәрендән — сүзеңнең сөрешеннән.

* * *

Бән сезләрә бер сүземне
Йад итәлем, ки аңлагыл,
Колак дотып бу сүземне [1]
Ихлас берлә [ки] дыңлагыл.

Әй нигярем [2], теләгел сән
гыйлем йарны,
Үзенә [3] эзләйүбән
алгыл аны.
Гүйә очкан кош кебидер
гыйлем кеше,
Күп мәшакъкать [4] берлә тотар
аны кеше [5].

Кулыңдан сән аны куйма,
Онытып, гыйльмеңне йуйма,
Гыйлемлек кошыный суйма,—
Сәңа булгай разый алла.

Табар булсаң гыйлем ирне,
Ки муафикъ булыр йарны;
Бу үгетне тотар булсаң,
Сәңа булыр разый алла.

Үзең наданлара катма,
Гыйлемлекне суга атма,
Тутый берлә ки карганы
Килтереп бер ивгә япма.

Надан ир малына кызма,
Алар сари кулың сузма,

Нигярем — гүзәлем, чибәрем.
Йуйма — жуйма.
Ивгә — өйгә.
Кызма — кызыкма.
Сари — таба.

Каралык көенә йөзмә,—
Ки булырсән гъисйан алла.

Надан ирне көтеп алмак,
Ирүр мөшкел кочып ятмак;
Анын малын ута якмак —
Нәданә гъәсъбән алла [6].

Кирәк малын утка якмак...
Анын чөн хәсрәтә калмак...[7]

. . . .
. . . .

Наданга үз буен сонсан,
Үзен аңа мотыйгъ булсан,
Аңа разый булыр исән,
Сәңа разый имәс алла!

Разый булып, ата-ана
Бирәм дисә ки наданга,
Алар ризалыкы өчен
Гомерлек хәсрәтә калма.

Дигел анлара бу сүзне,
Бакып анлара дөз күзне:
«Ятыр катында кискәдәй,
Бирүбән тын ки мичкәдәй!»

Оялмасана, и жаный,
Дигел анлара сән аный;
Оялып хәсрәтә калсан,
Разый ирмәс сәңа алла.

Ике мәгъшук бергә кушла —
Ефәк булып ки ишелә,
Кәлүб куйнына ки керсә,
Нәсыйб итеп, кушып алла.

. . . .
. . . .

Муафикъ кулларын салса,
Гүйә разый аңа алла [8].

Гъисйан алла — аллага каршы баш күтәрүче.
Нәданә гъәсъбән алла — белмәгәнгә алла әжере (жәзасы).
Мотыйгъ булу — буйсыну, баш ию.
Бакып анлара дөз күзне — аларга күзне туры төбәп.

Кушылып [бу] ике жаный,
Ки белеп хөкме уганый,
Ки мондан яхшысы [9] къәный? —
Бу дорур ризаи алла.

Бу икеләре гыйлем булса,
Белүб андай гамәл кыйлса,
Ки галимнең кулун [10] алса,—
Булыр и һәдаи алла!

Сүзем тотып ки ал гыйбрәт,
Ярин сәңа булыр рәхәт,
Бу эшләрдер сәңа гыйбрәт,—
Сәнеңчөндер җәннәти мәүля.

Гыйлемдән ки йөз дүндермә,
Гыйлем чырагын сүндермә,
Аңа чытык йөзең вирмә,—
Разый булыр сәңа алла...

Салур андин түбән башны [11],
Чытар йөзи, күзне-кашны,
Ачылып хатнына дәшми,—
Көлеп бакмак аңа къәный?

Каралык къәлбене баскан,
Агыр балта биленә аскан,
Юан-юан агач кискән,—
Арыгач уйнамак къәный?

Арыгач ачылып тормаз,
Үзе йәш, ултырып тормаз,
Хәлалене күзе күрмәз,—
Торыр килеш карап аный.

Йәнә ул дәмдә кич булгай,
Кәлүб түшәккә ултыргай,
Хәлаленә моны айгай: [12]
«Дийәен бән, ишет моный [13].

Хөкме уганый — ходаның хөкеме.
Къәный — кайда.
Һидаи алла — алланың тугъры юлы.
Ярин — киләчәктә, алда.
Мәүля — хуҗа, ия; монда: алла.
Къәлбене — йөрәген, күкрәген, күңелен.
Ул дәмдә — шул мизгелдә.
Айгай — әйткән, әйтер.

Дийәем бән, сән ишеткел,
Кәлүб аякымны чишкел,
Үгетне бу онытмагыл:
Кибәргә пичкә сал аный».

Китәндәй ак беләкләрен,
Кәлүб ул сызганып анда,
Чишеп алыр аякларын,
Алып пичкә салур аный.

Наданның хале бу улгай,
Чабатасына туфрак тулгай,
Оекы һәм кара булгай,—
Чыкуб хатун кагар аный.

Йәнә сузар аякыны,
Ки тартырга оекыны,
Коеп тузан увакыны,—
Буянурсән йәнә, җаный.

Бу мескин чыкубән какгай,
Ки әле туфракга баткай,
Керүбән катында яткай,—
Торып да ул үбәр аный [14].

Кияр аякына лапта [15],
Аны киеп йөри таптап,
Көйдермәгел берүк утка,
Әгәр салса кибәргә аный.

Киеп лапталары тузгай,
Кадерсез гомре, бел, узгай,
Ишетеңез моны сез, һай,—
Ахирәт эстәмәк къәный?

Аякы, тубыкы бәйләнгәй,
Йите кат киндерә әйләнгәй,
Кәзеб [16] сүзләргә бәйләнгәй,—
Басубән гъәфләти аный.

Надан [дин] хур дәхи барму,
Бу сүзгә сүз дәхи барму?
Галимне хур күргәнләргә
Ходаның рәхмәте къәный? [17]

Китән — мамыктан, киндердән эшләнгән ак тукыма.
Тузан увакыны — тузан вагын (увак — уалу).
Лапта (лапти) — чабата.
Кәзеб — ялган.

Ни мәгъкульдер моный күрмәк,
Гыйлем кызны нәданга [18] вирмәк,
Гыйлем егет наданны алмак,
На мәгъкульдер [19] дидем аный.

Әгәрчә ир галим улса,
Хәлял кәсеб: иген иксә,
Возу кыйлып, намаз кыйлса,
Ушал ирдер ки рәхманый!

Намаз кыйлса, алып таһрәт,
Булубән анда ул шөһрәт;
Бу эшләргә йөзең үгрәт —
Булырсән чөн ки рәхманый.

Зирагъәтдән әгәр кайтса,
Тиз үк хәлялен әйтсә,
Ки комганга суын салса:
«Намазга вараем, җаный!»

Кәләше анда су койса,
Торубән һәм возу кыйлса,
Намазга мәсҗедә варса,
Ки мондин яхшысы къәный?

Ки бәгъзеләр надан булса,
Галимләргә коллык кыйлса,
Тагъәт, коллыкны күп кыйлса,
Галимләрдин сайуң аный! [20]

Берәүләр гәр галим булса,
Кяһиллек тагъәтен кыйлса,
Үзе кешегә «кыйл» дисә,
Монафикъ дип белгел аный.

Әгәр хөкме хода улса,
Галим бер дөхтәри алса,
Үзенең нәсыйбы улса,
Ниләр дийәм — ишет аный!

Возу кыйлу — тәһарәт алу.
Рәхманый — рахманныкы, ягъни алла юлындагы кеше.
Зирагъәт — игенчелек, иген игү.
Тагъәт — буйсыну (аллага); дини йолаларны үтәү.
Сайуң (санаң) — санагыз.
Кяһиллек тагъәте — ялкаулыкка, ушәнлеккә баш ию.
Монафикъ — икейөзле.
Дөхтәри (дөхтәрне) — кызны.

Дәйүр: «Җаный, бирү килгел,
Оекым [21], читекем алгыл,
Килеп янымда ултыргыл,—
Кушылдырды бези алла!»

Укыгай ул торып намаз,
Кыйлып ул мәүляйа нийаз...
. . . .
Дир ул хәмед-сәна кыйлса,
Аңа хушнуд булыр алла [22].

Дәйүр: «Җаный, тиз үк булсаң,
Самавар ярагын кыйлсаң,
Китереп сөфрәйә куйсаң,
. . . . будыр җаный» [23].

Дилваз ярагыны кыйлып,
Бер-беригә күз[ен] салып,
Ки чәйнеккә чәен салып,
Диеп ул: «Әлхәмделилла,

Кушылдырды безн мәүля,
Китер бал, чәй, лимун тагы,
Куең һәм сөфрәгә аный...
. . . .»

Утырыр ике[се] алда,
Самаварны алып алга,
Сузарлар кулларын балга,—
Ки мондин яхшысы къәный?..

Салубән [24] күзләрә күзне,
Тәбәссем берлә дир сүзне,
Көлешеп дийәрләр сүзне:
«Ки кушды безне ул мәүля!»

Галим булса, булыр дәүләт,
Нәдан [булса], булыр зилләт,
Әгәр сән эстәсәң гыйззәт,
Дигел [сән]: «Бир[ер] ул, алла!».

Мәүляйа нийаз кыйлу — ходага ялвару.
Хәмед-сәна кыйлу — мактау, олылау сүзе әйтү.
Хушнуд — риза, канәгать.
Ярагын — әзерләгән.
Дилваз — яхшылап, матур итеп.
Сөфрә — ашъяулык.
Тәбәссем — елмаю.
Зилләт — түбәнлек белемсезлек.

Наданга сән әгәр варсаң,
Берәүне сәүмәен алсаң,
Ки бер гъише нуш кыйлсаң —
Ки үлмәкең ирүр әфзаль.

Гыйлем йарны сәүеб алсаң,
Аның илә самит торсаң,
Ике мәгъшук гомер сөрсәң —
Бусыдыр, бел, җаный, әүля!

Ки наданга берәү бармак —
Үзене зиндана салмак,
Ки хәсрәтдер уйлә кыйлмак,—
Ки кушмасын берүк алла!

Хода кушса ушал йарга,
Мәхәббәт дөкәнсә анда,
Аның илә мосахибдән
Ки әфзаль зиндани, алла.

Мәхәббәт йебе киселсә,
Әгәр салкын йиле иссә,
Ки дә әйтсен ушал дәмдә:
«Сыгынырмын сәңа, алла!»

Үз-үзеңә моны сүзлә,
Ки дәрман дәрдеңә эзлә,
Китәр юлынны сән эзлә,—
Үзеңә тиң бирүр алла.

Өзелеп, егълайу калсын,
Үзедик мәҗнүнне[25] алсын,
Малы-мөлке ута янсын —
Котылдырсын берүк алла!

Гъише нуш кыйлсаң — типтереп калсаң (алдануны татып карасаң).
Әфзаль — өстен.
Самит торсаң — кычкырышсыз, ягъни тыныч торсаң.
Уйлә — шулай.
Дөкәнсә — бетсә.
Мосахибдән — иш һәм әңгәмәдәшлектән.
Ки дә әйтсен ушал дәмдә — әйтсен ки шул чакта.
Дәрдеңә — чиреңә, кайгыңа.

Сәүешмәклә кулын салмак,
Ки ләбендән пусә кыйлмак,
Аның нәхренә кул салмак
Ирүр, бел, ләззати алма.

Ки галимдән хәбәр килсә,
Ата-анаң аңа вирсә,
Мәһәрә керәнләр салса [26],—
Аны кабул әйләгел, җаный!

Әгәр сән наданга варсаң,
Барып таш бота керсәң,
Мәхәббәтсез билә торсаң —
Суган булыр сәңа алма!

Пусә кыйлмак — үпмәк, үбү.
Нәхренә — муенына.
Ләззати алма — алма ләззәтләре.
Мәһәрә — мәһәргә.

* * *

Колак тотып ишет, җаный,
Идәем бер хикяйәти,
Сәңа гашыйк улып тәкый,—
Фида җаным сәңа, җаный!

Яратыбдыр сәне ул хакъ,
Ки ак йакут [1] кеби һәм ак,
Йөзеңә салды күп рәүнәкъ,—
Фида җаным сәңа, җаный!

Йөзеңне әйләде гөлтик,
Чачеңне итде сөнбелтик,
Үзеңне итде былбылтик,—
Фида җаным сәңа, җаный!

Йөзең биңзәр тулар айа,
Күрәнләр хур диеп сайа,
Сәңа биңзәшле кыз кайа? —
Фида җаным сәңа, җаный!

Йөзең биңзәр кызыл ләгълә,
Йөзеңдән нурларың агъла,
Күрәчәк күзләрем чагъла,—
Фида җаным сәңа, җаный!

Гаҗәб ләтыйф дорыр җисмең,
Мәгълүм дор[ыр] [2] сәнең исмең,
Йөрәгем бәгърене кисдең,—
Фида җаным сәңа, җаный!

Билең нечкә, нәзек дорыр,
Буең зифа, төзек дорыр,

Рәүнәкъ — нур, яктылык; монда: гүзәллек.
Биңзәр — охшар.
Күрәнләр хур диеп сайа — күргәннәр хур дип исәпли (саный).
Ләгъла (ләгългә) — асыл ташка (алсу һәм кызыл төстәге ташка).
Ләтыйф дорыр — матурдыр, күркәмдер.

Җиһан эчрә аз ук дорыр,—
Фида җаным сәңа, җаный!

Билең нечкә, буең һәм төз,
Төсең саф, гөл кеби йөз,
Әгәр дисәң иде бер сүз,—
Фида җаным сәңа, җаный!

Матурлык исмене алдың,
Хәлаикъ эчрә дан алдың [3],
Зөләйха [4] урнына калдың,—
Фида җаным сәңа, җаный!

Сүзем язылды күп төрле,
Тагы да әйтәем берне:
Кабул итәрмүсән серне? —
Фида җаным сәңа, җаный!
Килермүсән бәңа үзең?
Дәхи кашың, кара күзең,
Бал-шикәрдин татлы сүзең,—
Фида җаным сәңа, җаный!

[Әгәр кал]сам сәне алмай,
Ки куйныңа керә алмай,
Ботыңны ботыма салмай,—
Фида җаным сәңа, җаный! [5]

[Сә]лам яздым сәнең артын [6],
Сәне сәүмәклекем сартын;
Яңакларың кызыл алтын,—
Фида җаным сәңа, җаный!

Сәлам яздым каләм кашка,
Ки сәүмәкдә эшем башка,
Чыкармагыл серне фашка,—
Фида җаным сәңа, җаный!

[Әйа] җаным, ки бел халем,
Җана гыйшкъ утына җаным,
Тәнемдә калмады каным,—
Фида җаным сәңа, җаный!

Җиһан эчрә — җиһан эчендә: җиһанда, дөньяда.
Хәлаикъ эчрә — халыклар эчендә, кешеләр арасында.
Сартын — өчен, хакына.

Әйа жаным, нәчек итим,
Гыйшыкдин саргаеп бетдем,
Атаң-анаң бирә белмәс [7],—
Фида жаным сәңа, жаный! [8]

Намаз артларындин, жаный,
Телимен алладин сәни,
Кабул итсен ки сүземни [9],—
Фида жаным сәңа, жаный!

Әйа жаным, абыстаем,
Кызыл йөзең — тулан аем!
Сәнең өчен кышын-жәен
Фида жаным сәңа, жаный!

Языйм микән, житәр микән,
Сәнең мәдхең бетәр [10] микән,
Күңелләрдин китәр микән? —
Фида жаным сәңа, жаный!

Хисабың, сагышың кайда?
Болай торуда ни файда,
Кауышыйк без шушы айда! —
Фида жаным сәңа, жаный! [11]

[Күземне күзеңә] салсам [12],
Ходай язып сәне алсам,
Ки куйныңа керә калсам [13],
Фида жаным сәңа, жаный!

Кауышыйк инде бу айда,
Вакыт житкән ки, жаный ла!
Ирадәң әллә байларда? —
Фида жаным сәңа, жаный!

Мәдх (мәдех) — мактау, дан.
Ирадә — теләк, ихтыяр, омтылыш.

* * *

Ќечекдин [1] сәүдем, и күңлем зыйасы,
Йөрәгем-бәгърем, күзем тутыйасы [2].

Үзеңне күрмәен күнелемне алган,
Ќөйдереп тә яндырып утка салган.

Морадым, мәкъсудым, күрер күзем сән,
Нәчә елдин бирле сүләр сүзем сән.

Нәчә елдин бирле җәһдеңдә әфгяр,
Гамең берлә гъэриблыкдэ герифтар.

Сәне нәчә сыйфат кыйлсам төгәнмәс,
Вәли күрмәй кеше һәргиз ышанмас.

Ләбең [3] — йакут, дешең энҗү дезелмеш,
Йөрәк-бәгърем сәнең өчен өзелмеш.

Гыйшыклыкдин берәүгә ут чакылса,
Гаҗәб улмаз җиһан утка якылса!

Гыйшык хәле мәризъдан каты, ачы,
Ќочаклашып үбешмәкдер гыйляҗы [4].

Күңлем зыйасы — күнлем нуры, яктылыгы.
Күрмәен — күрмичә.
Җәһдеңдә әфгяр — янында җәфаланучы.
Герифтар — дучар, тоткын, әсир.
Вәли — вә ләкин.
Мәризъ — чир, авыру.
Гыйляҗы — дәвасы, даруы.

* * *

Сезнең йортыңыза вардым,
Сәнең сылулыгың күрдем,
«Бу нидәй кыз?» — диеп сордым,
Гаҗәб итдем сәңа, валлаһ! [1]

Ки төрдем мәктүбеңезгә [2],
Дәхи вардым өеңезгә,
Юлыкдым сән кызыл йөзгә,
Биһуш улдым күреп, валлаһ!

Нәзар кыйлдым сәңа нәгяһ,
Була күр, туташым, әгяһ:
Гашыйк улдым дәхи сәңа,
Нәсыйб итсен сәне, валлаһ!

Гъәҗиб уенларың күрдем,
Ки хәйранә калып тордым,
Йөрәгемә гыйшык ордың,
Ки сәүдем шул заман, валлаһ!

Читек-башмакларың [3] киеп,
Йөрисең, гүзәлем, биеп;
Эчем-тышым тора көеп
Күрү белән [4] сәне, валлаһ!

Оялмадың үзең бәндин,
Бән алмадым күзем сәндин,
Чыка язып җаным тәндин,
Гашыйк улдым сәңа, валлаһ!

Валлаһ — валлаһи (Алла исеме белән ант итәм).
Биһуш — һушсыз.
Нәгяһ — кинәт, көтелмәгәндә.
Әгяһ булу — уяу булу, сак булу.
Гъәҗиб — гаҗәеп, искитәрлек.

Сызылмыш кашларың җайдай,
Йөзең нурлы тулан айдай,
Күрәнләр сәне хур сайдай,—
Сылу кыйлды сәне, валлаһ!

Беләгең нечкә йәш талдай,
Сүзең датлы ирер балдай,
Гыйшыкың сабрыми алдай[5],
Кауыштырсын бези, валлаһ!

Ки исмең һәм фәлян булды,
Гыйшыкыңдин эчем тулды,
Ки белмимен[6] ничек булды,
Күрүбән бер[7] заман, валлаһ!

Ки сының дөлдөлә[8] биңзәр,
Йөрисең былбыла биңзәр,
Кәлямең[9] тутыйа биңзәр,—
Гомер вирсен сәңа, валлаһ!

Башыңа киясең калпак,
Сыйфаты кар кебек һәм ак[10],
Сәүәрем, валлаһи, бик хак,—
Бәңа вирсен сәне, валлаһ!

Күзеңнең нуры йолдыздай,
Керпекләрең дә кондыздай,
Җәмалең мисле хур кыздай,—
Яратыбдыр сәне, валлаһ!

Юлыкдым бән сәңа үзем,
Ки төшде йөзеңә күзем,
Оялды һәм кызыл йөзең,—
Карап калдым сәне, валлаһ!

Гъәҗәбләй ук[12] ки йөзеңне,
Ки былбыл кеби сүзеңне,
Бәңа бирсәләр үзеңне,
Шөкер идәр идем, валлаһ!

Җайдай — дөресе: йайдай (*йай* — җәя).
Сайдай — санады, исәпләде.
Биңзәр — охшаш, шикелле.
Кәлямең тутыйа биңзәр — сүзең (сөйләвең) тутый кошка охшар.
Мисле — мисалы.

Ки улсайчы бәңа үзең,
Дәхи кара кашың-күзең
Вә һәм гөлтик кызыл йөзен
Йөрәгем яндыра, валлаһ!

Кичә ятсам, күрәм сәне [13],
Исәпләсәм, улам би-һуш,
Гашыйк улып сәңа җәй-кыш,
Йөримен һәр заман, валлаһ!

Йөреп [һәм] күп заман түзеп,
Йөрәгем-бәгъреми өзеп,
Ки гъәм дәръясыйда [14] йөзеп,
Гашыйк улдым сәңа, валлаһ!

Ки бер көн сүзләшеп үзем
Сәнең белән бераз сүзем,
Ки әйтдең сән бәңа үзең:
«Чыка күр [сән», дийә], валлаһ! [15]

Чыкып китдем [ки] сахрага,
Йөрәгем чыдамаганга,
Менеп [бән] бер биек тауга [16],
Ки ятдым кайгырып, валлаһ!

Ки чыккансың үзең балкып,
Ике садрең тора калкып;
Тәмам беткән идем йалкып,
Көтеп сәне, җаным, валлаһ! [17]

Сәүендем сәне күргәчдин,
Киләсең югары очдин,
Дәхи тәңкәләрең сачдин...
Яратыбдыр сәне, валлаһ!

Юлыкды сәңа үз ишең,
Вар икән анда киңәшең...
Күземдин түгелә йәшем!—
Карап тордым сәне, валлаһ!

Улсайчы — булса иде; булсаң иде.
Ике садрең — ике күкрәгең.

Ходадин [гәр] нәсыйб улса,
Гүзәлләр дәхи юлыкса,
Алыр идем хода язса,—
Ниятем күп бәнем, валлаһ!

Сәңа яучыны бән салсам,
Хода язып, сәне алсам,
Ки куйныңа керә калсам,
Нийәт бирер идем, валлаһ! [18]

Сәнең кеби гүзәл мәхбүб,
Хода язса, табылыр күп,
Вәликән үзеңез бик хуб...
Ки вирмәде сәне, валлаһ!

Нийәт бирү — ниятләп куйган нәзерне бирү.
Мәхбүб — сөекле, сөйгән яр.
Вәликән — ләкин.

* * *

Үзеңне зур күреп, күрмә бәни хур,
Барымызны яраткан бер хода зур.

Өмид илән каләм алды бу әлем [1],
Ходауәндә, кабул әйлә теләгем!

Қабул күрмәй кире вирсәң хатымны,
Хода кашында сорармын хакымны!

Әгәр мәхрүм куярсән бу куендин,
Агырдыр хәсрәтем дөнья утындин.

Җаныкаем, чиләнмә сән укырга,
Күңел төшде боны һәм туктатырга [2].

Мөбарәк исмеңез фәлян икәндер,
Тарафыңдин гыйшык йиле искәндер.

Сәнең гыйшкың беләп ахир үләрмен,
Фиракъең утында әксәр күәрмен [3].

Сәне күрдем ике күзем нурытик,
Күренәсең бәңа оҗмах хурытик [4].

Йибәр яулык ике башын нәгышлап,
Дәхи бер көн кауышмакый багышлап.

Қабул күрмәй кире мәхрүм кыйларсән,
Гомри гъоссә белән мәхзүн кыйларсән [5].

Кешегә сүзләмәдем бу сүземне,
Сабыр берлән тыя тордым үземне.

Әлем — кулым.
Ходауәндә — йа ходаем.
Қашында — каршында.
Фиракъең — аерым булуың, аерым торуың, бергә булмавың.
Әксәр күәрмен — бик, көчле көярмен.
Нәгышлап (нәкъешләп) — бизәп, чигеп.
Гомри гъоссә беләп мәхзүн кыйларсән — гомерне сагыш белән кайгылы (хәсрәтле) кылырсың.

* * *

Китабларда [1] бу сүзне күргәнем бар:
«Оялган кемсәнең ризкы булыр тар;

Икеләнеп, оялып корган [2] эшләр
Сүтеләдер, сүреләдер!» — димешләр.

«Бирепез үк!» [3] — дигел, бер дә оялма,
Сүзем будыр сәңа, җаным, багалма.

Сәнепчөн нә дәкле бән әйләдем зар,
Әгәр ялган дисәң, бер ходаем бар!

Бу инәлүләрем таш да белерде,
Урыс кызы динен ташлап кәлерде.

Ишетмәдең, җаным, фөрйади-зарый,
Йитәр инде, инәлмәм мондин арый.

Күп ирде лә язсам хатка [4] тагы да,
Туласы булды ла ике ягы да [5].

Йитәр, сүзне йибәрмә күп озынга,
Дәхи инәлдерәм диеп кузынма [6].

Әйа җаным, вәйа җаным, җәмалем,
Сәнең өчен өзеләдер бу җаным!

Әдәбле диделәр ки әһле инсаф,
Тәнигә [7] кул тимәгән диделәр: саф.

Нә хурлыкдыр сәнең кебек матурга
Надан астында мимылдап ятырга!..

Фөрйади-зарый — зардан кычкырап егълауны.
Кузыну — кызулану, исәрләнү; кәпәренү (*куз* — «утлы күмер» тамырыннан).

* * *

Карарым калмаен. яздым сәламем,
Мөгъәккъиб әйлә[йү]бән дәхи кәлямем [1].

Җиһан зольмәт ирер бәнем күземә,
Көенмәкдән фәлянага җөнанем [2].

Зәһи халь-ү, зәһи халь-ү, зәһи халь! —
Бән егълармын — һәммә галәм сәр-асим.

Мәнем сез бакмаңызлар сурәтемгә,
Йөрәгем кан ирер, мәхзүн җөнанем [3].

Әйа абзый вә абыстай, сүземдән
Нәбиләр хаккычөн бәне исергән.

Мөдилл улың, кабул идеп, сүземдән,
Бәне чәндан җәфаләрә дөшермән! [4]

Нәбинең хаккъ-хөрмәте [5] гыйззәтичөн
Фәрекъ итден дөнеми көндеземдән.

Әгәр тәзвиҗ идәрсәм кардәшеңне,
Хәлегъ [6] идәм хәлялемне соңындан.

Мөгъәккъиб әйлә[йү]бән дәхи кәлямем — тагы сүзләремә аңлатмалар ясау белән.

Җиһан зольмәт ирер — дөнья караңгыдыр.

Җөнанем — йөрәгем; бәгырем; күңелем.

Зәһи халь! — Нинди хәл!

Сәр-асим — гаҗәпләнгән, таңга калган; исе китеп пошынган.

Мәхзүн җөнанем — күңелем хәсрәтле.

Нәбиләр хаккычөн — пәйгамбәрләр хакы өчен.

Исергәү (исеркәү) — истә тоту, игътибар итү; хөрмәт күрсәтү.

Мөдилл улың — дәлилле булыгыз; монда: ышаныгыз.

Чәндан — шул кадәрле, шул тикле.

Тәзвиҗ — никяхлау.

Хәлегъ идәм — аерам; талак кылам.



*** («Карарым калмаен яздым сәламем...») шигыре теркәлгән кулъ
мадан фотокүчермә.

Гаҗәб хәйран ирермен бу эшемдин,
Берәр ләхза китә белмәз исемдин.

Тәфәххөсъ әйләң халем әкъуалемдән [7],
Йөрәгем айпылырдай сагышымдан.

Гаҗәб катыйгъ исергән бу сүземдән:
Хәҗәр йомшар иде йомшак күңелдән.

Физинһар, сөммә зинһар, бәгъдә зинһар,
Мөдилл улың, аермаң мәгъшукъемдән! [8]

Сәбәб улың висалә ба җәнанә,
Колыңызмын сезә җан-у-дилемдән [9].

Ләхза — чак, мизгел (кыска вакыт).
Тәфәххөсъ әйләң халем әкъуалемдән — хәлемне сүзләремнән ти
шереп (күзәтеп) аңлагыз.
Хәҗәр — таш.
Сөммә — янә, тагын.
Бәгъдә — аннан соң, сонра, соңыннан.
Висалә ба җәнанә — җәннәт белән кавышырга.

Әйа абзый вә абыстай, беленләр,
Ки гяһ-гяһ екылып китәм һушымдан.

Нәтәк былбыл гашыйкдыр җөмлә гөлгә,
Чәнаникә гашыйкмын сеңлеңезгә.

Әйа абзый, өмидем хат язмакындыр,
Кире бәңа, кабул идеп...[10]

Гяһ-гяһ — вакыт-вакыт.
Чәнаникә — шуның шикелле, шуның кебек үк.

* * *

Язаем сән җанашыма сәламләр,
Сәламләр бәгъдендә бераз кәлямләр.

Булыр микән күреп күзем туяр көн,
Тулан айтик йөзеңне һәм үбәр көн?

Булыр микән йөрәгем басылыр көн,
Шифа татып висалең бәрһәмендин?

Зифа буең күреп туймас булыпмын,
Күреп дәхи йөзеңнең күрклекендин.

Нәчек итим, бәнем тереклегем тар,
Ходай кыйлсын үзеңне дә герифтар[1].

Гаҗәб хәйран буламын бу эшемдин,
Кичә ятсам ки чыкмыйсың дөшемдин.

Әйа җаным, беләсән дә беләсән,
Кабул идеп, бу тарафка киләсән.

Әйа җаным, сереңне гизләмәсмен,
Сәне ташлап, бүтән йар эзләмәсмен.

Бу дөньяда күрепмен дөхтәри чук,
Сәнең кебек зифаны күргәнем юк!

Кәлямләр — сүзләр.
Висалең бәрһәмендин — синең белән кавышудан.
Герифтар — дучар; тоткын, эсир.
Гизләмәсмен — яшермәсмен.
Дөхтәр — кыз бала.

* * *

Аты фәлян-гүзәл [1], матур икәндер,
Укырга да дәхи матур [2] икәндер.

Фәлян шәкерт фәлян атлы [3] бу йарга
Язып хатлар йибәргән күңле барга.

*

Нәдән тора икән гъэфләт эчендә:
«Нә вар икән — диде, әлбәт,— эчендә?»

*

Шушы айның көнендә, йә кичендә
Бән буламын микән күңлең эчендә?

Вә йә барча җәендә, йә кышында
Булам микән сәнең күңлең тышында? [4]

*

Нәдән үртәнмисең гомрең үтүдин?
Ятырсың[мы], җаный [5], йокың китүдин?

*

Җәмалеңдин йә алданып торамы?
Сылумын дип, матур дип лаф орамы? [6]

Ки бу фикрә булып фәлян-сөрур да [7],
Тора микән бик алданып горурда?

Җәмал дәхи [8] китә торган буяутик,
Китәр тәндин көздә дөшкән кыраутик.

*

Гомер һәм чылтырап сукган сагъәттик;
Бу форсатлар үтәр тиз йөгрек аттик[9].

*

Ышанма һич атаңның байлыкына,
Олугъланма йөзеңнең айлыкына.

Атаң байлыгыны вирмәз сәңа һич,
Яныл, тәүбә кыйлып бу сүздин ваз кич!

*

Әҗәл угын әгәр корса атарга,
Әман вирмәз мишәргә[10] һәм татарга.

* * *

Мәхәббәтне сәңа салды ходаем,
Моны язмай ни халь илә түзәем?

Сәламемне кабул әйләп ала күр,
Бәңа каршы үзең дә [1] хат яза күр!

Иляһи, барча гыйльме мәтълабын бир,
Кәрам берлә мәрарәгә тәскин бир [2].

Кәлямем сәңа барып йитә алмас,
Каләмдин гүргә кермәен котылмас [3].

Ходаем гыйшкыңызны салды безгә,
Анынчөн йибәрдем бу сүзне сезгә.

Бу язмакдин күңелнең туясы юк,
Сәне алмай күңелнең тынасы юк [4].

Ки хакъ язмаса [гәр] бән азмас идем,
Ул сүзенезгә бән хат язмас идем.

«Йитәр!» — дисәм, каләмем [5] тыңламыйдыр,
Гыйшыклык халене һич аңламыйдыр.

Бу мәктүб халигә кыйлсаң итагъәт,
Сәгадәтдер, сәгадәтдер би-сыйфат!

Каләм әһле каләм илә йөретер,
Наданлар тел илә [сүзне] йөретер.

Гыйльме мәтълабын — теләк гыйльмен, теләккә ирешү гыйльмен.

Кәрам берлә мәрарәгә тәскин бир — юмартлык белән ачынуларга тынычлану (сабыр) бир.

Кәлямем — сүзем.

Бу мәктүб халигә кыйлсаң итагъәт — монда: бу хаттагы хәлгә карап гамәл кылсаң.

Би-сыйфат — чагыштыргысыз.

Йөрәгем яндырыр [6] күңел һәуасы,
Качан ула бу дәрдемнең дәуасы?

Абыз туткай [7] ялыкмасын укырга,
Күңел төште моны аңа язырга.

Бу хатка яздым ирсә [бән] атыңны,
Гыйшыклык тотмады һич такъәтемне.

Зөләйха Йосыфә гашыйк улыбдыр,
Кулындин камчысын әлә соныбдыр [8].

Ки ул камчы көйдерде Йосыф әлене,
Бел имди сән бу гыйшыклык халене! [9]

Күңел һәуасы — күңел теләге; күңел ашкынуы.
Дәрдемнең дәуасы — хәсрәтемнең дәвасы.
Әлене — кулын.

* * *

Сәлам яздым сәңа, җаным, гөзидә [1],
Сәнең кебек ки тугъмаз йир йөзидә.

*

Сәлам яздым сәңа, җаным, тиң итеп,
Сәламемне ки кайтарма ким итеп.

*

Сәлам яздым сәңа, җаным, үзеңә,
Күзем дөшде сәнең күркәм йөзеңә [2].

*

Сәлам яздым сәңа, җаным, асылный [3],
Сәне күрмәй бәнем күңлем басылмый.

*

Сәлам яздым сәңа, җаным, гүзәлем,
Сәне күрми, җаным, һич [дә] түзәлмим.

*

Сәлам яздым сәңа, җаным, хәкыйкъәт,
Йосыф — Зөләйхадин алгыл нәсыйхәт [4].

*

Сәлам яздым сәңа, җаным, йитәрму,
Бу хат берлә арада сүз бетәрму?

Гөзидә — сайланган, сайлап алынган (бердәнбер).

*

Сәлам яздым сәңа — кабул аласән[5],
Ике читенә бер билге саласән.

*

Сәлам яздым сәңа, җаным, кичә көн,
Кабул итмәз исәң, ватма пичәтен.

*

Сәлам яздым сәңа, җаным, бу микъдар.
Бәлки булмас микән диеп бәңа җар[6].

*

Сәлам яздым сәңа, җаным, үзеңә,
Яман күз дөшмәсен күркәм йөзеңә.

*

Сәлам яздым сәңа, җаным зыйасы,
Йөрәк бәгърем, күземнең тутыйасы.

*

Сәлам яздым сәңа, җаным-фәлянга,
Бу мәктүбне кабул итеп аланга.

*

Сәлам яздым сәңа, җаным, ике күз,
Сәнең хәсрәтдин саргайды нурлы йөз.

*

Сәлам улсын сәңа, җаным, кара каш,
Бу серемне әйләмә һичкемгә фаш.

Җар — хәбәр, белдерү, игълан; кычкырып дәшү, ачык игълан кылу.
Зыйасы — яктысы, нуры.
Тутыйа — минераль кушылдык (күз даруы).

*

Сәламдин соң кабул булса, җанашым,
Кичә-көдез сәнең берлә сагышым.

*

Сәламдин соң кәлям яздым үзеңә,
Җефетлеккә өмид идәм үземә.

*

Сәламдин соң дәхи сәңа кәлямем:
Кабул иткәй идең бәнем сәламем.

*

Сәлам язмак пәйгамбәр сөннәтедер,
Сәлам алмак матур кыз хөрмәтедер [7].

*

Сәлам язмак галим шәкерт эшедер,
Кабул күргән дәхи изге кешедер [8].

*

Бәнем юкдыр сәңа лаикъ бүләгем,
Ни булса да гаеп итмә, йөрәгем [9].

*

Әйа җаным, ерак булдым үзеңдин,
Тыеп булмый йәшем ике күземдин [10].

*

Әгәр белсәң иде, җаным, халемне,
Үзең бирер идең газиз җаныңны.

Кәлям — сүз.
Сөннәт — пәйгамбәр эшләргә кушкан эш.

*

Сәлам яздым сәңа — кабул аласән [5],
Ике читенә бер билге саласән.

*

Сәлам яздым сәңа, җаным, кичә көн,
Кабул итмәз исәң, ватма пичәтен.

*

Сәлам яздым сәңа, җаным, бу микъдар.
Бәлки булмас микән диеп бәңа җар [6].

*

Сәлам яздым сәңа, җаным, үзеңә,
Яман күз дөшмәсен күркәм йөзеңә.

*

Сәлам яздым сәңа, җаным зыйасы,
Йөрәк бәгърем, күземнең тутыйасы.

*

Сәлам яздым сәңа, җаным-фәлянга,
Бу мәктүбне кабул итеп аланга.

*

Сәлам яздым сәңа, җаным, ике күз,
Сәнең хәсрәтдин саргайды нурлы йөз.

*

Сәлам улсын сәңа, җаным, кара каш,
Бу серемне әйләмә һичкемгә фаш.

Җар — хәбәр, белдерү, игълан; кычкырып дәшү, ачык игълан кылу.
Зыйасы — яктысы, нуры.
Тутыйа — минераль кушылдык (күз даруы).

*

Сәламдин соң кабул булса, җанашым,
Кичә-көдез сәнең берлә сагышым.

*

Сәламдин соң кәлям яздым үзеңә,
Җефетлеккә өмид идәм үземә.

*

Сәламдин соң дәхи сәңа кәлямем:
Кабул иткәй идең бәнем сәламем.

*

Сәлам язмак пәйгамбәр сөннәтедер,
Сәлам алмак матур кыз хөрмәтедер [7].

*

Сәлам язмак галим шәкерт эшедер,
Кабул кургән дәхи изге кешедер [8].

*

Бәнем юкдыр сәңа лаикъ булэгем,
Ни булса да гаеп итмә, йөрәгем [9].

*

Әйа җаным, ерак булдым үзеңдин,
Тыеп булмый йәшем ике күземдин [10].

*

Әгәр белсәң иде, җаным, халемне,
Үзең бирер идең газиз җаныңны.

Кәлям — сүз.
Сөннәт — пәйгамбәр эшләргә кушкан эш.

* * *

Ки бисмилла[1] илән алдым каләмем,
Хуш улсачы бәнем язган сәламем.

Гыйшыклыкдин халем йитде үләргә,
Ки белмәдем халем кемгә сөйләргә.

Гыйшыклыкдин сөйләем бер хикяйәт,
Бәнем гыйшкым сәңа дөште бигайәт.

Гашыйк хале ауыр икән, канатым,
Қауышырга җәһед иткел, канатым.

Сәлам язып ике кулым бушамый,
Бу дөньяда сәңа һичкем ошамый.

Сәлам яздым сәңа, җаный, исәпләп,
Сүзем әйтер идем, җаный, кочаклап.

Йөрәгем янадыр, һай-һай, янадыр,
Сәнең гыйшкың бәне утка саладыр.

Йөрәгем ут доташды яна-яна,
Сәнең гыйшкың бәне кыйлды диуана.

Сәне сәүдем ике күзем нурытик,
Күренәсең бәңа җәннәт хурытик.

Сәне сәүдем хәкыйкъәт бән, җанашым,
Ки дәрдендин диуана булды башым...

Гыйшыклыкдин сары сукды йөземә,
Җаныкаем, булырмусән үземә?

Әгәр булса канатым да очарга,
Очып барыр идем сәне кочарга.

Бигайәт — чиксез, чиктән тыш, бик.
Җәһед иткел — тырышлык күрсәт.

Сүзем расдыр бәнем — ялган имәсдер,
Бәнем кеби сәне һичкем сөймәсдер.

Җаныкаем, укып аңла хатымны,
Чыкармагыл бәнем яманатымны.

Бән хатымны сәңа яздым үземдин,
Өмид идеп сәнең датлы сүзеңдин.

Ки мән яздым, гүзәл, сиңа сәламем,
Кабул күрсәң бәнем сән бу кәлямем.

Сәлам яздым сәңа, җаным, җәмалем,
Ходай кыйлса иде сәне хәлялем.

Җаным сәүгән йөрәгем парәсе сән,
Тәнем рухы, күземнең карасы сән.

Гыйшыклык булмаса [2], мән азмас идем,
Әрсезлек кыйлып [мән] хат язмас идем.

Язаем, җаныкай, бераз сәламләр,
Сәламдин соң язаем мән кәлямләр.

Сәнең гыйшкың күңелдә, күздә — йәшем,
Гъәҗәбдер — һәм диуана булды башым.

Торамын, алга [3] тамды йәш күземдин,
Җаным, аңла бәнем айган сүземдин.

Сәнең күңлеңдә бармы бер гъәҗәб халь,
Булыр булса, бу хатымны алып кал.

Әгәр булмаса, кайтаргыл хатымны,
Чыкармагыл бәнем яманатымны.

Ки күркәм берлә мәрҗан буйныңызда,
Күзем йомсам, буласың куйнымызда [4].

Сәлам алмак фарыздыр [5], и каләм каш,
Бу сүзне гъәйреләргә әйләмә фаш.

Чара юкдыр сәне күрми чыдарга,
Йитешде бу җаным тәндин чыгарга.

Кәлям — сүз, сөйләм.
Җәмалем — матурым, гүзәлем.
Айган — әйткән.
Буйныңызда — муеныгызда.

Сәламемдер сәңа, жаным-жиһаным,
Фида улсын сәнен юлында жаным!

Сәламемне кабул итеп ала кур,
Мәңа бер кош телетик хат[6] сала кур.

И жанкаем, жәмалең күрсәм иде,
Сәнең куйнында жаным бирсәм иде!

Сәнең гыйшкың ходаем салды мәңа,
Аның өчен йибәрдем моный сәңа.

Сәңа кауышдыргучы [ул] ходадыр[7],
Сәнең өчен бәнем жаным фидадыр.

Гъәжәб хәйран уламын бу эшемдин:
Кичә ятсам ки чыкмайсән дөшемдин.

Сәлам яздым сәңа, и бәне белгән,
Мәңа хәсрәт өчен дөньяга килгән!

Ки сән, жаный, бәне нәчөн онытдың,
Ки бәндин нәчек күңлеңне суытдың?

Аның кебек булыр жиһанда сүз күп,
Ки бәнем сәндин үзгә сәүгәнем юк[8].

Ки кем өчен күңелеңне суытдың?
Нә өчен бән фәкыйрьләр[и] онытдың?..

Гыйшыклыкда сәңа язылды күп хат,
Барып кайта ки хатым бушка мотлакъ[9].

Сәлам язмак егет кеше эшедер,
Бүләк салмак матур кызлар эшедер.

Нәчә баксам кү[р]енәсең күземә,
Инансана бәнем ошбу сүземә!

Мотлакъ бушка — гел бушка.

* * *

Сәнең өчен күп егъладым җомгада [1],
Хәйр бирдем Баһаутдин хуҗага [2].

Сәнең өчен күп укыдым хәдисдин [3],
Йөзең дәхи яктыракдыр кенәшдин.

Сәнең өчен күп хәсрәтләргә батдым,
Кичә егълап, йәнә дә ялгыз ятдым.

Сәнең өчен сәхәрләрдә утырдым,
Сәнең өчен аерылдым ойкыдин.

Сәнең өчен къәйед кыйлдым башымны,
Ходай кабул кыйлар микән йәшемне?

Сәнең өчен йәшем канга әйләнә,
Сөйләп булмый — дәхи телем бәйләнә.

Сәнең өчен кан егъладым җомгада,
Сәне сорап зарый кыйлам ходага.

Сәнең өчен зар-интизар булаем,
Гомерләрне сәнең берлә сораем [4].

Кенәшдин — кояштан.
Ойкыдин — йокыдан.
Къәйед кыйлу — багълау, тоткын итү.

* * *

Җаным фида сәңа, җаным-җаный ла,
Гомерлек йар гынам булсаң ярый ла!

Сәнең өчен акыздым күздә[н] йәшем,
Бу хәсрәтдин чыкар микән бу башым?

Ходай язсын мөкъәддәр каләмендә:
Қауышдырсын бу дөнья галәмендә [1].

Шад уламын, әгәр күрсәм йөзеңне,
Тулар дөнья[м], әгәр алсам үзеңне.

Ходай бирәр микән мәңа үзеңне?—
Сүләр идем сәңа хаҗәт сүземне.

Йөзең нурлы сәнең кояш нурытик,
Қыяфәтең сәнең җәннәт хурытик [2].

Йөзең нуры кояш нурыйга биңзәш,
Қыяфәтең җомах хурыйга тиңдәш [3].

Үзең былбыл, йөзең мисле тулан ай,
Ашар ашың сәнең [4] шикәр, сары май.

Йөзе[ң]дин нурларың йиргә тамадыр,
Сәнең дәрдең бу көн бәңа бәлядер.

Әлиф-лямтик [5] сәнең кашың карадыр,
Сүләгән сүзләрең бәңа дәуадыр.

Ходай биргән сәңа күркәм җәмальне,
Қачан кыйлыр икән безгә висальне?

Мөкъәддәр каләме — тәкъдир, язмыш каләме.
Биңзәш — охшаш; шикелле.
Җомах — оҗмах.
Мисле тулан ай — тулган ай кебек.
Дәрдең — монда: хәсрәтең, кайгың.
Җәмаль — чырай, кыяфәт.
Висаль — кавышу, очрашу, табышу.

Сәнең йөзең охшаш шәмсекъәмәргә,
Суләр сүзең охшар багы сәмәргә.

Йөзең күркәм, суләр сүзең гарәбчә [6],
Гакыл-фигълең сәнең бар да гадәтчә.

Үзең былбыл, күзең нәркис карасый,
Сүзең ширин, үзең йөрәк парәсый.

Әйа җаным, җаныкаем, каләм каш,
Сәнең өчен кичә-көндез күзем йәш.

Қашың — кондыз, күзең йолдыз икәндер,
Хода сәне бәңа бирер микәндер? [7]

Телең татлы сәнең хөрмә йимешдин,
Йөзең күркәм сәнең нурлы кояшдин.

Ходай кыйлган сәнең йөзеңне күркәм,
Ходай кыйлган зифа буеңны өлкән.

Қичә-көндез телләремдә сән сүзем,
Сәндин гъәйре кемсәне күрми күзем.

Шәмсекъәмәргә охшар нурлы йөзең,
Бал-шикәрдин татлыдыр сәнең сүзең.

Сәңа биргән ходаем күркәм җамаль,—
Хакъ тәгалә әйләсен мәңа хәлял.

Хакъ тәгаләдин сорыйм даим сәни,
Фәзъле берлә мәңа бирсен ул гъәни.

И гүзәлем, әйлә сүземне кабул,
Ике күзем! Қил, гомерлек йарым ул!

Гөл йөзеңә төшсә күзем — шад улам,
Нәсыйб әйләсә ходай сәни — алам.

Сүзем дыңла, зинһар, сөммә зинһар,
Бәне ташлап бүтәнгә китмә, зинһар! [8]

Шәмсекъәмәр — шәмс һәм камәр: кояш һәм ай.
Багы сәмәр — бакча җимеше.
Ширин — татлы, тәмле.
Фәзъле берлә — рәхмәте белән, олы күңеллелеге белән.
Гъәни — бай (алланың эпитеты).
Сөммә — тагын, янә.

* * *

Бәдре-лямигъ [1] дилбәрә гыйшык тотыпмын [2], бинәуа,
Нәзъмилән уламыдыр [3] бер дәрде-дил үзрә дәуа?

Нам чү былбыл, сүзе ширин, шәмсе талигъдер йөзи,
Назир улмас шул кояша: талдырыр ике күзи [4].

Бөйлә [5] кәлмәс, күңлә кәчмәс хөсненең мең дә бере,
Галәм эчрә хуш сыйфатлар анда мәүҗүд һәрбере!

Бу җиһан мәхбүбләрендә юкдыр аның тиңдәше,
Илля улыр оҗмах эчрә хурлар [6] аның биңзәше.

Йөрер ирдем бер вакыт хуш, күземи алды та уш,
Күрдекемдин гашыйк улып, шул заман улдым биһуш.

Кәндемә дидем гаҗәблән: бу ходаның сәнгате!
Нә кыйлаен? — нәфсә мәйл итмәк нәбиләр сөннәте... [7]

Бу гашыйклык силсиләндә йөрер идем бән гъәриб,
Кәндеми белмәй, диуана, әҗнәбиме йә къәриб?

Бәдре-лямигъ дилбәрә — тулган айдай нурлы, әсир итүче гүзәлгә.
Бинәуа — мескен, бичара; монда: чарасыз.
Нәзъмилән уламыдыр — нәзым (шигырь) белән булыр микән.
Дәрде-дил үзрә — күңел чиренә, күңел хәстәлегенә.
Нам чу былбыл — исеме (атагы) сандугач шикелле.
Шәмсе талигъ — туып килә торган кояш.
Назир улмас — караучы булмас.
Бөйлә кәлмәс — болай килмәс.
Хөсненең — куркәмлегенең, чибәрлегенең.
Мәүҗүд — бар; табыла.
Мәхбүбләр — сөйгән ярлар.
Биңзәше — охшашы.
Күземи алды та уш — күземне нәкъ шул алды (үзенә каратты).
Кәндемә — үземә.
Мәйл итмәк — теләү; омтылу; ярату.
Нәбиләр — пәйгамбәрләр.
Гашыйклык силсиләндә — гашыйклык чылбырында (гашыйклар төркемендә).
Гъәриб — мескен; аптыраган кеше.
Әҗнәбиме йә къәриб — чит кешеме яки якынмы.

Һәр талибә угърадымса, дәрдемә кыйлды тимар,
Ибтидадин мең зийадә ул бәни кыйлды бимар [8].

Бу җиһан зольмәтә дунде: нә шәмес вар, нә — сираҗ,
Йөрер ирдем зольмәт эчрә дәрдемә эстәп гыйляҗ.

Йөрер ирдем зольмәт эчрә бәхре-әфкярә батып,
Бәгъремә санчеп уятды керфек угыйлә атып.

Күземи ачдыкда күрдем, дидем: «И Сахибҗәмал!
Шәфкъәт ит, үлтермә бәни, уш сагъәт куйнына ал!»

Үзе — шивә, күзе — нәргис, йөзедер сахиб җәмал,
Исменә җисмен муафикъ кыйлмыш аны зөлҗәлял!..

* * *

Бер тамаша: бу гашыйклык берлә күңел азмасын,
Агыр икән, хәсрәте чук — дошманыңа язмасын.

Бу гашыйклык тоткан икән, нинди түзем исә дә,
Бән түзәрмен дисә дә [кем], үлчәшергә базмасын.

Ул Зөләйха түзмәде лә, бер өмиден өзмәде [1],
Бер тоташ им эзләде лә, бетереп мал-казнасын...[2]

Һәр талибә угърадымса — һәр гашыйкка (монда: талиб — гашыйк) очрадым исә.

Дәрдемә кыйлды тимар — чиремә (хәсрәтемә) кайгыртучанлык күрсәтте.

Ибтидадин — баштагыдан.
Зийадә — артык.
Бимар — авыру, сырхау, чир.
Зольмәтә дунде — караңгылыкка батты.
Нә шәмес вар, нә — сираҗ — ни кояшы, ни шәме юк.
Гыйляҗ — чара, дәва, дару.
Бәхре-әфкяра батып — уй-фикер диңгезенә батып.
Уш — шушы.
Шивә — назлылык, күркәмлек, көязлек.
Сахибҗәмал — гүзәллек (матурлык) иясе.
Зөлҗәлял — алла.

ВАРИАНТЛАР

* * *

Хисабың, сагышың кайда?
Болай торуда юк файда:
Йә күп елга, йә күп айга
Хисабың бармы сайларга?

Әйа жаным, абыстаем,
Ҡызыл йөзем, тулан аем,
Сәнең өчен кышын-җәен
Эреп сарка йөрәк маем.

* * *

Сәба йиле, исәр булсаң,
«Фәлян» йиргә йитәр булсаң,
Рәбигане күрер булсаң,
Сәлам дигел аңа бәндин!

Сәба йиле, нә хуш йилсән,
Гъәҗаибдән исеп килгән!
Хәбәр китермәде микән
Рәбига[ләр] тарафындин? [1]

Сәба йиле белән шаулый
Агыйделнең камышлары,
Йөзләремә сары сукты
Рәбиганең сагышлары [2].

Нәчә сахраләргә чыксам,
Нәчә төрле йыгач күрсәм,
Йәнә катларыйна барсам,
Хәбәр сорыйм бән анлардин:

«Әйа йыгач, йәшең күпме?
Түгелгән яфракларың күкме? [3]
Бәнемдик [4] михнәтең күпме?» —
Диеп сарыйм йыгачлардин.

Яфраклар йәш гомер икән,
Ботаклары бала икән,
Айрылу зур бәла икән
Гомер иткән Рәбигадин [5].

* * *

Ходадин һәм теләп сине,
Кичә-көндез кыйлып зари,
Кауыштырсын сәңа мине,—
Әйа җаным, фида җаным.

Ходаның кәляме[1] безгә,
Күңелем төшде һәм сезгә,
Гомер бирсен икемезгә,—
Әйа җаным, фида җаным.

Ки ай кебек синең йөзең,
Ки нечкәдер синең билең,
Кауыштырсын мәңа үзең,—
Әйа җаным, фида җаным.

Шәкәр кебек синең телең,
Ки чулпандыр ике күзең,
Ки әйт миңа асыл сүзең,—
Әйа җаным, фида җаным.

Бу дөньяда гүзәл мәхбүб
Синең кебек булыр микән?
Сине миңа бирер микән?—
Әйа җаным, фида җаным.

Кашың кара сызылмышдыр,
Тешең йенже тезелмешдер,
Йөрәк-бауры[2] өзелмешдер,—
Әйа җаным, фида җаным.

Ки хакъ йакут[3] ике ирнең,
Төшемдә аузыма тирдем,
Гяһи сурып үбәр идем,—
Гяһи мин тотубән әшуак.

Кәлям — сүз, сөйләм.
Мәхбүб — сөйгән яр, сөекле.
Гяһи — әле; кайчак.

Әйа жаным, кызыл алмам,
Ки синдән гайрене алмам,
Нәсыйб булсаң, сине алам,—
Мине фәһем итсәнә, жаным.

*

Әйа жаным, ябыстаем,
Кызыл йөзле тулан аем,
Синең өчен кышын-йайен
Эридер лә йөрәк маем.

Жаныкаем, фиракъ булдын,
Ки күземдән ерак булдың.
Сагынмаклык хале белән
Бауырларым кәбаб булды [4].

Әгәр сәүәм дисәң мине,
Дийәем мин сина, жаный,
Кабул күрсәң үзең мине
Булыр идем сине, жаный [5].

Фиракъ — аерылу, аерым яшәү.
Кәбаб булу — яну, көю; куырылу.

* * *

Әйа гариф, гаҗәб мәгъна диеленде,
Бер аз монча гаҗәб сүз әйделенде[1].

Әйа гариф, ишет бәндин гаҗәб сүз,
Тәхәммелдә булып сән һәм аңа түз[2].

Әйа гариф, нәчек түздем бу сүзгә,
Ки калмады җаным чыкмакдин үзгә.

Әйа гариф, бу эшләр үтде бездин,
Бәйан кыйлдым гаҗәб улмаса сездин[3].

Әйа гариф, күңелне тотма үзгә,
Гаҗәб мәгъна булыр, белгел, бу сүздә[4].

Әйа гариф, ходадин нөсърәт эстә,
Догаңыздин имин булсакчы без дә[5].

Әйа гариф, бән имам булганымдин
Сәңа яздым үзем хур булганымдин[6].

Әйа гариф, гаҗәбләнмә бу сүзгә,
Хатасыз булмагай бер хакъдин үзгә.

Әйа гариф, укып кара сүземдин,
Бу эшләри үткән өчен үземдин ([3a]).

Әйа гариф, үзем бер имам идем,
Бу гыйшык булмаса, бән әман идем ([6a]).

Әйа гариф, хараб булдым үзем дә,
Хата булмаса кирәкдер сүземдә.

Әйа гариф, гашыйк булдым бер кызга,
Гаҗәб калдым инанубән риййа сүзгә.

Гариф — белүче, аңлаучы; акыл иясе, укымышлы.
Тәхәммел — түзем, чыдам.
Нөсърәт эстә — ярдәм эстә (эзлә).

Әйа гариф, качан барсаң сәфәргә,
Төшәрсез кем мәгъшукъәдин хәтәргә.

Әйа гариф, ышанма сүзләренә,
Инаныб сән карама йөзләренә.

Әйа гариф, карасаң йөзләренә,
Инанмагыл — рийадыр — сүзләренә.

Әйа гариф, мәни йад итсә сезгә,
Дога кыйлүң, гъәфур рәхмитсә, безгә.

Әйа гариф, хата дәйүб төзәтмә,
Газиз гомрең юк эш берлән озатма[7].

Әйа гариф, бу көн күрең үземне,—
Рийазәтне чикүб яздым сүземне.

Әйа гариф, нәчек яздым бу сүзне,
Егетмен дип, гыйшык тотма бу кызны.

Әйа гариф, хараб итәр бу сезне,
Йад итәрсез тәмаме ахир безне.

Әйа гариф, күңелдә тот бу сүзне,
Гыйшык дәйүб йад итмә һич дә кызны.

Әйа гариф, сәңа яздым хатасыз,
Гыйшыкның ахыры булмас җәфасыз.

Әйа гариф, бу кызга сүз катасыз,
Бу көн газиз җаныңа ут якасыз.

Әйа гариф, әгәр дә ул сүзи катса,
Газиз гомрең ярым акчага сатса?

Әйа гариф, әгәр белсәң халемне,
Бирүр идең үзең газиз җаныңны[8].

Әйа гариф, хараб итәр малыңны,
Хараблыкдан ки саклагыл җаныңны.

Әйа гариф, бу мәгъшуклар күп улыр,
Гыйшык дәйүб, ахырында хур улыр.

Гъәфур — кичеручe, гафу итүче.
Рийазәтне чикүб — кыенлыкларны чигеп, җәбер күреп.

Әйа гариф, жиһанда кыз күп улыр,
Гыйшык дәйүб, ахырында юк улыр.

Әйа гариф, дәрәжәдин төшәрсән,
Рийазәтдә булып дөнья куарсән.

Әйа гариф, бу эш үткән адәмдин,
Гъәйб булган аңа яхшы-йамандин.

Әйа гариф, рийа сүзләр күп улыр,
Инанмасаң, ахырында хуб булыр.

Әйа гариф, бу эш улырмы мәгъкуль,
Күрермусән бәнем сүземне мәкъбуль?

Әйа гариф, гыйшык йөрер адәмдин,
Аермагыл күңелеңне иманидин.

Әйа гариф, йад итдем күп гөнаһым,
Гъәфуре рәхим рәхмане иляһым [9].

Әйа гариф, ишет сән хәфа къәндин,
Ки саклангыл бу гыйшыклык афәтендин.

Әйа гариф, хисаб кыйлгыл бу эшкә,
Бу мәгъшуклык ки кермәсәйе дөшкә.

Әйа гариф, дөшемдә күргәнемдин,
Гашыйк булдым аның хуш сүзләрендин.

Әйа гариф, гашыйк булдым сүзендән,
Битакъәт мән китеп бардым үземдән.

Әйа гариф, күзем дөшде йөзенә,
Гашыйк булып, киләлмады үземә [10].

Әйа гариф, ишетдем бән үзендин,
«Җанашым» дип, аның сөчек сүзендин.

Әйа гариф, битакъәтмен бу сүзгә,
Нәчек идүб күңелне тотмак үзгә?

Мәкъбуль — кабул ителгән.
Гъәфуре рәхим — рәхимле гафу итүче.
Рәхман — рәхим иясе.
Хәфа къәндин — хафа кайдан.
Битакъәт — тәкатьсез.
Сөчек — тәмле, татлы.

Әйа гариф, сүзе булды «җанашым»,
Көне-төне ки ул булды сагышым.

Әйа гариф, хараб булдым бу сүзгә,
Чара юкдыр бу көн үлмәкдин үзгә.

Әйа гариф, дога кыйл нөсърәт өчен,
Укыганларга булсын гыйбрәт өчен.

Әйа гариф, нәләр үтде башымдин,
Моны яздым үземнең күз йәшемдин.

Әйа гариф, күңелгә сал бу эшне:
Агыз белән тоталмазсән бу кошны.

Әйа гариф, хасыйәтләр бу безгә,
Укып кара: васыйәтләр бу сезгә.

Әйа гариф, күңел салма бу кызга,
Нәхәрәм дип, ки зинһар, бакма йөзгә.

Әйа гариф, йөрәккә җара улды,
Нәфес берлән бу көн йөз кара булды.

Әйа гариф, бу эшләр чыкды юкка,
Сикереп төшкәнем белмәдем утка.

Әйа гариф, бу дөхтәр җара салды,
Бу газиз гомреми вәйранлык алды.

Инанубмын: бу кызларда хәйадыр,
Аларның күбесе булыр рийадыр [11].

Әйа гариф, бу көн ул китде къәнда?—
Китүб баргач җаным калмады тәндә.

Әйа гариф, мөселман булса алың,
Кабул итмә бу гыйшыкның вәбалын.

Әйа гариф, йөземне сары кыйлды,
Бу мәгъшуклык үземне къарый кыйлды.

Нөсърәт өчен — ярдәм өчен.
Нәхәрәм — тыелган түгел, тыелмаган.
Дөхтәр — кыз.
Хәйа — оят; ышаныч, тугърылык.
Вәбал — гөнаһ, язык; авырлык.
Къарый — карт.

Әйа гариф, нәчә еллар, нәчә ай,
Үземне сорсаңыз, белгел, Төгәлбай [12].

Әйа гариф, ишедеб вармаясыз,
Үзең дөшмәс чокырны казмаясыз.

Әйа гариф, [бу] мәгъшуклар җаныңтик,
Бу дөньяда сарыф булган малыңтик [13].

Әйа гариф, сакыйн мәгъшук халедин,—
Аерылып малыдин һәм җаныдин [14].

Хәмед берлән башладым бу китабны,
Укып кара күрерсән күп хисабны [15].

Әйа гариф, йәшем акды битакъәт,
Әҗәлемне көтәм сагъәт-бә-сагъәт.

Әйа гариф, моны яздым битакъәт,
Сабырым калмады сагъәт-бә-сагъәт.

Әйа гариф, бу кыз китмәй — күңелдә,
Нә сүзләсәм, ки ул булды сүземдә.

Әйа гариф, герифтармын бу хальгә,
Нә кадәр эстәйүб булмады әле дә.

Әйа гариф, гаеп итмә бу сүзгә,
Гаеп итеп ки, зинһар, орма йөзгә [16].

Әйа гариф, бу эш бәнем үземдин,
Гакылың булса, аңлагыл сүземдин [17].

Әйа гариф, бу мәгъшуклар булыр тик,
Йөрерсез ки ит эстәгән мышыктик [18].

Әйа гариф, егет дип ормагыл лаф,
Тәмам булмас бу эшең, кәлтүр инсаф [19].

Әйа гариф, гыйшыклык халене бел,
Әман булсайе дип сән бер дога кыйл [20].

Сорсаңыз — сорасагыз.
Сакыйн — саклан.
Хәмед — мактау, алкыш.
Битакъәт — тәкатьсез, сабырсыз.
Сагъәт-бә-сагъәт — сәгатьтән сәгатькә.
Герифтар — дучар (тоткын).
Мышык — мәче, песи.

Әйа гариф, нурым бетде күземдә,
Бу гыйшыкдин сары улды йөземдә [21].

Әйа гариф, зыйафәт булды хәйран,
Ахырында булыл[мын] үземә хөсран [22].

Әйа гариф, гыйшыкдин кит алып баш,
Күтәреп йөрмәгел тагъдин агыр таш! [23]

Әйа гариф, бу кыз чыкмай йадымдин,
Көне-төне теләгем иляһымдин.

Әйа гариф, бәнем күбдер гөнаһым,
Бу күз йәшемдин кичергел, иляһым.

Әйа гариф, тәүбә кыйлгыл бу эшкә,
Нәсыйхәт ит үзең белгән дус-ишкә.

Зыйафәт — сыйлану, хөрмәтләнү.
Хөсран — зарар, үкенеч, кайгы.

* * *

Бу бәетне[1] сәңа яздым үземдин,
Өмид идеп сәнең датлы сүзеңдин.

Икенче һәм сәламемдер, гүзәлем,
Сәне күрмәй нәчек итеп түзәрем?

Сәлам язмак егет кеше эшедер,
Бүләк салмак матур кызлар эшедер.

Сәлам улсын сәңа, мәгъшук, ки бездин,
Хәбәрләр юк без мәхутичка (?)[2] сездин.

Сәлам алмак фарыз[3] торыр, каләм каш,
Бу серне[4] гайреләргә әйләмә фаш.

Чара юкдыр сәне күрми чыдарга,
Йитешде бу җаным тәндин чыгарга.

Җаныкаем, ишегең[5] ач — керәем,
Гөл-мөбарәк йөзеңне һәм күрәем.

Мөбарәк йөзләреңне күргәндин соң
Ауызыңдин бер суырып үбәем.

Нәчә баксам, күренмисең күземә,
Инансана бәнем ошбу сүземә!

Сәлам улсын сәңа, җаным-хәбибәм,
Сәнең илә ула күңлем, табибәм.

Сәламемдер сәңа, җаным-җиһаным,
Фида улсын сәнең юлыңда җаным.

Нә кыйлаем: ерак улдың үземдин,
Тыеп булмый йәшем ике күземдин.

Хәбибәм — яратканым, сөеклем.
Табибәм — дәвалаучым, савыктыручым.

Сәламемне кабул итеп ала күр,
Бәңа да берничә хәбәр сала күр.

И җанкаем, җәмалең күрсәм иде,
Сәнең куйнында җаным бирсәм иде!

Сәнең гыйшкың ходаем салды бәңа,
Ходай үзе каушдырсын бәне сәңа.

Сәңа каушдыргучы, җаным, ходадыр [6],
Сәнең өчен бәнем җаным фидадыр.

Гаҗәб хәйран уламын бу эшемдин,
Кичә ятсам, ки чыкмайсән дөшемдин.

Сәлам яздым хәбәр сорып ки сездән,
Маңа хәсрәт өчен дөньяга килгән!

Сәламләр әйләдем, җаным-гүзәлем,
Сәне күрмәй нә халь итеп түзәрем[7]!

Җәмалең күрсәм иде — йөзеңне (чыраеңны) күрсәм иде.

* * *

Сәлам улсын сәңа, бәгърем парәсый,
Кабул әйләсәнә, күзем карасый.

Кабул итсәң сәламемне, җанашым,
Ки әйтәем сүземне, кара кашым.

Сүзем шулдыр: кабул әйлә сәламем,
И җанашым, укып кара кәлямем!

Камыш бармак, көмеш тырнак, каләм каш,
Сәнең өчен ике күздин ага йәш.

И җанашым, ишетәмен сүзеңне,
Ки сәндин һич алалмыймын күземне.

Әгәр күрсәм буеңны йә йөзеңне,
Кочаклаган кебек улам үзеңне.

Ишетәмен тауышың йә сүзеңне,
Диуана уламын, белмим үземне.

Ки һич бер хәбәрең юк, җаный, бәңа,
Ни хальләр булды ләкин, җаный, сәңа?

Мәгълүм, җанкәем, ходага эшемез,
Бу хәсрәтдин котылырмы башымыз?

Кулым бәнем сәлам сәңа язадыр,
Сәнең өчен йөрәк маем сызадыр.

Ки ятларга күзеңне сала курмә,
Мәне сәумәс дәйүб алдана күрмә.

Кабул итсәң әгәр бу сүземезне,
Ки аулакда күрерсән үземезне.

Кәлям — сүз, сөйләм.



*** («Сәлам улсын сәңа, бәгърем парәсый...») шигыре кулъязмасының ике бите (В. В. Радлов коллекциясеннән — КӨИ ЛБ, № В, 4580, XII).

Сүзем растдыр, җанашым, алдамыйм һич,
Сәнең өчен ике күзем егълады кич.

Сәнең өчен эчем-тышым янадыр,
Итем бетеп, коры сөйәк каладыр!

*

Сәлам улсын йөрәгем парәсыйга,
Кара кашым, күземнең карасыйга.

Сәлам улсын күземнең карасыйга,
Җигәргүшем — йөрәгем парәсыйга.

Каләмгә биңзәр сәнең [и] кашларың,
Йинжүйә биңзәр дезелмеш тешләрең.

Мән сәни бу сурәтлү [дип] беләрдүм,
Такъәтем юк, нәчүк сабыр кыйлырдум?

Робагый [1] чыкарып яздым бу хатны,
Язмас идем бу хатны — гыйшкың каты.

Җигәргүшем — бәгырем ите.
Биңзәр — охшар.

Күзем йомсам, күрнәсең янымызда,
Кулың — муйнымда, үзең — куйнымызда.

Карап калдым мөбарәк буйларыңны,
Вәләкин белалмадым [2] уйларыңны.

Әгәр белсәм иде сәнең уеңны,
Фида әйләр идем газиз җанымны.

Сәламәтмен бу халәт тигрү, җаным,
Һәмишә гыйшкым илә көйә каным.

Сәлам яздым сәңа, Сахибҗәмалым [3],
Сәнең зифа буең кайда күрәем?

Сәлам яздым сәңа, и бәни белгән,
Бәңа кайгу өчен дөньяга килгән.

Сәлам яздым сәңа, җаный, сагынгач,
Ки йәш йөрәгемә утлар кабынгач.

Сәлам яздым сәңа, җаный, кара каш,
Бу серләрне кешигә әйләмә фаш.

Сәлам улсын сәңа, җаный, ки бездин,
Ки мондыйн соң кәтәрмен үзеңездин.

Шул ук сагъәт йокымдин күз [4] ачылды,
Агъзымыздин гыйшык уты сачылды.

Күз-керфекләремябла бер-беренә,
Сәнең вәсъфың күренәдер күземә.

Сәни күрсәм, бәнем күңлем җуана,
Ки күрмәсәм, буламын [бер] диуана.

Бәнем кебек сәне сәүгән булырмы,
Ки сәүмәсәм, болай сүзләр булырмы?

Сәни күрәм ки үземә мөляим,
Бәни күргел сән үзеңә мөляим.

Сәни күрәм җаным кеби тәнемдә,
Бәни күргел җаның кеби тәнеңдә.

Тигрү — тикле; чаклы.
Сәнең вәсъфың — синең сыйфатың, кыяфәтең.

Сәнең кебек ки кыз юкдыр җиһанда,
Мәгәр булса булыр багы Ирәмдә [5].

Сәлам яздым сәңа, җаный, сагынып,
Ки йәш йөрәгемә утлар кабынып.

Сәламемне кабул итеп ала күр,
Үбә-коча куеныңа сала күр!

Ки бисми[лла] илә улсын сәламем,
Бәнем [сәндин] шулдыр ахир морадым.

Мәхәббәтем сәңа салды ходаем,
Моны язмый ни халь берлә чыдаем?

Нә улыр йибәрсәң мәңа [сән] бер хат?
Укыр идем алубән көндә йөз кат.

Сагынмаклык илән яздым сәлам хат,
Кабул итеп, алубән бер укып бак.

Түзәргә хальләрем бәнем китәдер,
Бу җаным чыкмага, җанкәй, йитәдер.

Кара кашың, зифа буең камышдыр,
Сәүмәк өчен эчем тулы сагышдыр.

Гаеб итсәң дә [сән], язмый халем юк,
Сәни күрми түзәргә дәрманым юк.

Ни хальләр итәем: эчем янадыр,
Сәнең өчен күземдин йәш тамадыр.

Бәни тилмертүбән хәсрәткә салма,
Юкса уйлар уйлап сагышка калма!

Сәлам бәгъдендә сорсаңыз, җанашым,
Кичә-көндез сәнең илә сагышым.

Ходаем гыйшкый сезгә, салды безгә,
Шуның өчен язамын моный сезгә.

Сәни сәүдем ике күзем нурытик,
Күренәсең мәңа оҗмах хурытик.

Сәлам бәгъдендә — сәлам соңында.

Әгәр белсәң иде мәнем халемне,
Фида әйләр идең газиз җаныңны.

Җәмалең илә кәмалең дигәндә,
Очар кошдик буламын бән һауада [6].

Йөрешләрең гаҗәб хәйран икәндер,
Хода сәни мәңа язган микәндер?

Сәнең исмең — дилемдә, күздә — йәшем,
Ки дәрдеңдин диуана улды башым.

Сәламдин [соң] халь сорсаңыз, гүзәлем,
Сәнең өчен көнен-төнеп көйәмен [7].

Укыр идем көндез әлемә алып,
Ятыр ирдем кичен күкрәккә салып.

Инан, җанкәй, сүзем ялган имәсдер,
Мәнем кеби сәни һич кем сөймәсдер.

Кабул итсәң [мәнем] ошбу хатымны,
Чыкара күрмәгел яманатымны.

Мони яздым сәни бик сәүгәнемдин,
Йөрәгем утыйга бик күйгәнемдин.

Сәлам улсын сәңа, бәгърем, җанашым,
Кызыл йөзем, тулан аем, кояшым!

Сәлам яздым, кабул итеп ала күр,
Бәңа бер кош теледик хат яза күр!

Җәмалең, кәмалең — гүзәллегең, камиллегең.

* * *

Әссәламе, вәссәламе, вәссәлам!
И җаным, бәгъдәссәлам булыр кәлям.

Гүзәл мәхбүбсән, нәкъеш[сән], и җаным [1],
Улмайа сәндик гүзәл һич күргәнем.

Къәнда барсам, җаным, бән сәне күрәм,
Дөньяда сәндик җаный юк дип беләм.

Гыйшкълык илә җанды, эчем кайнады,
Йөрәгем көйде, буыным каушады [2].

Сәнең кебек газиз кемгә төшәдер,
Сүзләрең[нең] ләззәте бал-шикәрдер.

Хәйран улып бакдым [сәнең] үзеңә,
Сәнең вәсъфың күренәдер күземә.

Телләрең[дер] багы Ирәм [3] былбылы,
Нурлы йөзең һәр урында билгеле!

Аһ җаным, сәне янымда дип беләм [4],
Эзләйү, «къәни?» дәйү хәйран улам.

Кайда барсам, күз илә вәсъфың күрәм,
Дөньяда сәндик гүзәл юк дип беләм!

Ятса [гәр] куйнында [бер] кичкә газиз,
Үлсә [ул] һич улмайа әһле тәмиз [5].

Бәгъдәссәлам — сәламнән соң, сәлам артыннан.
Нәкъеш — гүзәл рәсем.
Кәлям — сүз, сөйләм.
Мәхбүбсән, нәкъешсән — сөеклесең, күркәмсең.
Къәнда — кайда.
Газиз — монда: кадерле, затлы.
Вәсъфың — сыйфатың, билге-галәмәтләрең.
Газиз — монда: изге, пакь кеше.
Әһле тәмиз — пакьлек, сафлык иясе.

Сүзеңне ишедән[ләр] җанны асрый,
Дийә, дийә корый[дыр]агыз суый [6].

Үләрем тәхкыйкъ сәнең гыйшкың илә,
Йимәк-эчмәк кайгысы китде бөйлә.

Бәндә күңлең бармы? — тугъры әйтсәнә!
Хәлял җефетлекне кабул итсәнә!

Сүзләр исәм, телем сәне сүзләйә,
Кичә-көндез күңлем сәне эзләйә.

Гүзәл мәхбүб, и җаным-җаныкаем,
«Асылың нә?» — дәйү бер сүз сүзләем [7].

Бәгъдә сән, [җаныем], аңлагыл моный,
Ни [киңәш] вирсәм, дәхи тоткыл аный.

Сәне күрдем — йөрәгем [ут то] ташды,
Сәне күрдем — [күңелдә дәрдем] ташды [8].

Башлаем бу сүзи [бән] алла илә,
Йөрәгем [илля] җанды бу дәрд илә.

Һәр кайу җирдә күрәм[ен] бән сәни,
Гыйшыклык [9] уды чолгап алды бәни.

Җанды эчем, кайнады дәрдең илә,
Бөйлә валлаһ гыйшыкың [сәнең] илә.

Көн-көне гыйшыкың кайгысы илә,
«Аһ!» дисәм [ки] агызымдин ут чыга!

Өзеләдер нәкъеш нәзек биленә [10],
Яңа туган айтик нурлы йөзенә.

Җөмлә кызның фазыле сән гъәфифә,
Гыйшкъ уды кыйлмыш бәңа [күп җәфа].

Көн-бә-көн дөшемдә күрәм бән сәни,
Сары ауруга салдың, [җаным], бәни.

Тәхкыйкъ — анык, ачык билгеле.
Бөйлә — шулай, шул рәвешчә.
Бәгъдә — соң, соңра, аннары.
Нәкъеш (*нәкыш*) — бизәк, рәсем (монда: сурәт кебек нәфис).
Фазыле — өстенлеге; асылы.
Гъәфифә — саф, намуслы; гыйффәтле.
Көн-бә-көн — көннән көнгә; көн саен.

Ожмах эчрә хур кебек йөзең нури [11],
Сән уласән ике күземнең бери!

Ишедәнләр васъфыңлә [12] хәйран ула,
Һәм күрәнләр жаныны фида кыйла.

Сандугачтик сайрагучы телләрең [13],
Бал-шикәртик датлы ирер сүзләрең.

И жаным, имди сәңа бу[дыр] сүзем:
Кичә ятсам, һич йокы күрмәс күзем [14].

Үләмен имди, жаныем [15], үләмен,
«Хәлялем» дисәнә — үлмәй каламын.

Бу серемне һич кемсәйә сөйләмә,
Сөйләп [бәнем серем] мәшһүр әйләмә.

Бән дидекем сүзләри кыйлгыл кабул:
Аның хатыны әлеңә алмагыл [16].

Сән бу хатны йәшерәсән шул кадәр,
Һич дә кеше белмәсен моны мәгәр [17].

Ишедәнләр васъфыңлә хәйран ула — ишеткәннәр сыйфатыңа хәйран була.

Әлеңә алмагыл — кулыңа алма.

* * *

...Сәнең халеңне белмимен, и җаным,
Сәнең кайгыңдин бөрйан булды җаным.

Сәнең кайгың белә ахры үләрмен,
Фиракъең утыйда даим күәрмен...

*

Бихәмдилля, йәнә күрдем шәраиф:
Мөбарәк йөзеңә булдым мөшариф.

Сәнең фикреңдәдер бән заре әфгяр,
Кичә-көндез гъәмең берлән бән грифтар.

[Әйа җаным,] күземнең нурыдыр сән,
Дөньяга ингән җәннәт хурыдыр сән!

Әгәр шәмсе къәмәрдик дөхтәр улса,
Кирәкмәс гъәйре, җәннәт хуры улса.

Бәңа сәндин бүтән ярлар кирәкмәс,
Бәңа сәнсез бу тәндә җан кирәкмәс!..

Бөрйан булу — янып-көю.
Күәрмен — көярмен.
Бихәмдилля — аллага мактау.
Шәраиф — олылык, мәртәбә.
Мөшариф булу — (күрү) бәхетенә ирешү.
Заре әфгяр — зар белән җәрәхәтләнгән; зарланучы.
Грифтар (герифтар) — дучар, тоткын.
Шәмсе къәмәрдик дөхтәр — ай һәм кояш шикелле кыз.

* * *

[Сабрым юк]дур сәне күрми чыдарга,—
Ки гөл бирүр сәнеңтик тиңдәшем юк [1].

[Сабрым юк]дур сәне күрми чыдарга,—
Йитешде бу җаным тәндин чыкарга.

[Ки яңак]ларың мисле багы алма,
Салур [ул] алма бәни шадыманга [2].

[Гыйшык уты], җанашым, хәддин ашып,
Янадыр җөмлә тәнем ут тоташып.

Әйа җаным, вәйа җаным, җанашым,
Сәнең өчен өзеләдер үзәгем [3].

Фәлян илнең фәлян кеше бу йарга
Язып хатлар йибәрмешдер [аңарга] [4].

Гыйшык [дәрде] каты мәризъдыр, ачы [5],
Кочаклашып үбешмәкдер гыйляҗы.

Сәлам улсын, җаныем, пешкән алма,
Бәнем күп сәламемдин таңга [калма].

Сәлами җавидани миһербаный,
Йөрәгемдә ут янадыр — белгел аның.

Нәгяһан егълайуб алдым каләмем,
Язаем дип сәңа би-хәдд сәламем.

Бу хатка исемемезне язмадым,
Язар ирдем — гайреләрдин базмадым.

Шадыманга салу — шат иту, шатландыру.
Гыйляҗы — чарасы, дәвасы.
Сәлами җавидани миһербаный — иксез-чиксез, миһербанлы сәлам.
Нәгяһан — кинәт, көтмәгәндә.
Би-хәдд — чиксез.

Сәлам улсын ки сән абызтутыйга,
Гүйә салдың бәни дөнья утыйга.

Морадым сән иде[6], бәнем морадым,
Ходадин дәмбәдәм сәни сорадым.

Бетәр кайгу илән күңлүм таралып,
Күрер ирсәм — китә кайгум таралып[7].

Хатымызны карагачдин[8] тәмам ит,
Кире тапшыр үземезгә — әманәт[9].

Ничә итсәм күренмәйсән күземә,
Инан, жаный, [бәнем] ошбу сүземә.

Дәмбәдәм — туктаусыз (сулыш саен).

* * *

Бәңа дөшкән гыйшыкны кемсә белмәс,
Бу сүзем раст ирүр, [һич] ялган ирмәс.

Мәхәббәтем бар иде сәндә, җанин,
Бу әйләде мөкъәддәм...[1]

Мәхәббәтем сәүекле сән сылуда,
Әйа җаный, аһ итәм һәр сулуда.

Бән улсамчы бу хальдә садрыңызда,
Күзем йомсам, күрәмен ойкымызда.

Кулың муйнымда, үзең — куйнымда,
. . . .[2]

Нәчә язсам да бетмидер бу сүзем,
Ки егълап күрмәс улды ике күзем.

Бәет язып ике кулым бушамый,
Бүтән кемсә, җаным, сәңа охшамый...[3]

Диделәр кем сәнең кебек кыз улмас,
Ки улса да, сәнеңдик назин[4] улмас.

Ходаем гыйшыклыкны салды безгә,
Аның өчен йибәрдем моны сезгә.

Буең зифа икән сәнең, йөзең — ай,
Кабул итсәң, йәшерен сүзләрем бар[5].

Күрешеп бер сүзләшә күр, гүзәлем,
Эчемдәге серем[6] сәңа чишәлем.

Бу хәсрәтне ходадин дип беләмен,
Әйа җаный, сәнең өчен үләмен!

Мөкъәддәм — элек, әүвәл.
Садр — күкрәк.
Ойкы — йокы.
Назин — назлы.

Нәсыйб булса, сәнең куйныңа керсәм,
Үкенмәсмен, җанашым, шунда үлсәм.

Кайчан килер икән икәү күрешмәк,
Кочаклашып, тел очындан үбешмәк.

Әйа җаный, үләмен — тергезә күр,
Җаным, үзең халеңне белдерә күр.

Сагынмакдин сары булды чыраем,
Аермасын, кауштырсын ходаем.

Нәчә баксам, күренәсең күземә,
Инанәсән бәнем язган сүземә.

Сәлам улсын сәңа ләйли бәһарым,
Сәне сагынамын ләйли нәһарым.

Күз өстендә кара кашың сызылмыш,
Сәнең өчен йөрәк-бәгърем өзелмеш.

Сәнеңтик барму [икән] бу җиһанда,
Ки белмим[ен], булса булыр ниһанда.

Әйа җаным, ки белсәнә халемни,
Бу хәсрәтдән чыкармагыл җанымный.

«Барам, җаный»,— дибүк алдап җуатма,
Ки вәгъдәңне озак куеп җылатма.

Тоташды ут — эчемне сүндерә күр,
Җаныем, үз халеңне белдерә күр.

Бәңа дөшкән гыйшыкны кемсә белмәс,
Ки уйласа һич тә гакълына килмәс.

Укып белгәч, кире йибәр хатымны,
Фаш итмәгел бәнем яманатымны.

Сәне сәүдем, җаныем, хәддин ашып,
Җанадыр җөмлә җисмем ут тоташып.

Бәңа салгыл мәхәббәтле күзеңне,
Сөеп дүнгел (?) [7] бәнем әйткән сүземне.

Инанәсән — инанасың.
Ләйли бәһарым — язгы кичем.
Ләйли нәһарым — кич һәм көндезем.
Ниһанда — серле, яшерен урында.

* * *

Сәнең дәрдең миңа дөшде кечекдин,
Газиз башым гъәриб булды гыйшыкдин.

Сәнең дәрдең бәнем күңлемдә даим,
Сәне бирсә иде бәңа ходаем!

Сәнең дәрдең белә даим йөримен,
Сәне күргәч сары майтик эримен.

Сәнең дәрдең белә мән иртә вә кич,
Сәнең дәрдең күңелдин китмидер һич.

Сәнең дәрдең белә булдым герифтар,
Хода кыйлса иде сәни гүзәл йар.

Сәнең дәрдең бәндә[дер] кичә-көндез [1],
Җиһанда юк сәңа охшашлы бер кыз!

Кыяфәтдә сыйфатың — суда кондыз,
Үзең былбыл, күзең маңәндә йолдыз.

Буең зифа Иделдәге камышдин,
Йөрәгем янадыр сәнең сагышдин.

Сәнең буең — Ак Иделнең камышы,
Сүләгән сүзләрең былбыл тауышы.

[Җаным сәү]гән йөрәгем парәсый сән,
Тәнем рухы, күземнең карасый сән.

[Сәлам яздым] сәңа, җаным, җәмалем [2],
Ходай кыйлса иде сәне хәлялем!

Дәрд — хәсрәт, кайгы.
Гъәриб булу — монда: чит күрелү, кимсетелү; хәсрәтле булу.
Герифтар булдым — грифтар (дучар) булдым (хәсрәтенә).
Маңәндә — охшаш; шикелле.

* * *

Гашыйк булдым сәңа, җаным, күзалмам,
Сәне күрми ки бер сагъәт түзалмам.

Әйа җаным, ике күзем, багалмам,
Ки билләһи, сәне алмыйча калмам.

Сәне күрми ни халь берлә чыдаем,
Сәне бәңа бирер микән ходаем?

Әйа җаным, ки сән Бәдигъҗәмалем [1],
Сәне күрми корыйдыр йөрәк [2] каным.

* * *

Йир үбеп, дидек догалар гәүһәри,
Һәм дәхи улсын сәналәр җәүһәри.

* * *

Ки йокларга күзем йомсам, уянам:
Сәнең гыйшкың бәни кыйлды диванаң.

Ходай язган микән ошбу җиһанда
Күрешергә, сүләшергә ниһанда?..

Дәхи — тагын, йәнә.
Сәна — мактау, алкыш.
Ниһан — яшерен, аулак урын.

* * *

Үләм, җаныем, үләмен, тергезә күр,
Бер аулакта үзеңне күргезә күр!

* * *

Надан кеше керсә сәнең куйныңа,
Кыямәт көн богау салыр муйныңа.
Әгәр ул китмәсә, сән кит, алып баш,
Күтәреп йөрмәгел тагъдин агыр таш.

* * *

Ки каргадин туар карга,
Атасына булыр парга;
Ки козгындин туар козгын,
Атасыннан булыр азгын.

* * *

Галим ага, бире кара,
Шушы сабый сорауилә
Биреп җибәр пырауилә.
Бирмәсәң пырауиләңне,
Кочармын Рауиләңне.

* * *

Сәне сәүдем ике күзем нурытик,
Күренәсән бәңа оҗма[х] хурытик.

Сәне күрми чарам юкдыр чыдарга [1],
Йитешде бу җаным тәндин чыгарга.

Әй җанашым, ерак булдың үземдин,
Тыелмыйдыр йәшем ике күземдин.

Нә булгай бу заман күрсәм йөзеңне,
Алып ятсам чыбылдыкда үзеңне

Салауат ул Мөхәммәд Мостафага,
Каушдырсын алла бәне [сән] тутайга [2].

Салауат — дога, теләк, мактау.

* * *

Язаем сән жаныема сәламләр,
Сәламләр бәгъдендә бераз кәлямләр.

Нәчә язсам да, бетмидер бу сүзем,
Егъламакдин күралмый ике күзем.

Бу дәрдемгә дәуа итсен ходаем,
Сәнең илән булсам иде һәрдаим!

Моны яздым сезгә, жаный, кисәкләп[1],
Укыгайсән, жаный, моны исәпләп.

Шушы айның көнендә йә кичендә
Булам микән сәнең күңлең эчендә?

Сәне күрсәм, күңелләрем буладыр,
Жылыйсым ла килә — күңлем туладыр.

Язаем, жаный, сезгә житәрме,
Монда язып бәнем сүзем бетәрме?..

Бәгъдендә — соңында, артында.
Кәлям — суз, сөйләм.

* * *

Сәлам яздым сәңа, кабул кыйла күр,
Мөбарәк әлеңә алып тота [1] күр.

Ялыкганда язаем бер-ике юл,
Янып барган йөрәккә ял була ул.

Сәлам язган [өчен] [2] бәне орышма,
Мәхәббәтле күнелеңне суытма.

Сылукаем, абызтутыкай, каләм каш,
Нәчек булса да серем [3] итмәгел фаш!

* * *

Хода сәне бәңа язган микәндер?
Бу хәсрәтләр китәр көн бар микәндер?

Әгәр белсәм иде сәнең халеңне,
Фида кыйлыр идем барча малымны.

Йөрәккә уты төшде яна-яна,
Бу хәсрәтең бәни кыйлды диуана.

Кеше хален кеше белмәс икәндер,
Бу хәсрәтләр китәр көн бар микәндер?

Әлеңә — кулыңа.

ПОЭМАЛАР

РИСАЛӘИ-Л-ИРШАД

[Мөкаддимә]

. . . .
. . . .[1]

Ходa рәсүле Мөхәммәд,
Һидайәт шәмсе ул Әхмәд[2],
Дөруд ула хисабе юк,
Аңа би-хәд, аңа би-гъәдд.

Ифазә хәйр идә йәздан
Рәсүлемез үзә чәндан,
Салауате-сафйате күп —
Тәгъәддед улмайә имкян.

Дәхи сахибе гъарыйна[3]
Вә гъәйре жар-у-йарыйна,
Вә гъәйре сахбе һәм алә
Уладыр җөмлә — барыйна.

Вә бәгъде бәндәи әфкъәр,
Ходa рәхмәтенә әксәр

Һидайәт шәмсе — туры юлга күндерүче кояш; юл күрсәтүче кояш.
Дөрүд ула — мактау була.
Би-хәд, би-гъәдд — чиксез, сансыз.
Ифазә — игелек.
Йәздан — ходa, тәңре.
Чәндан — өллә нихәтле, бик күп.
Салауате-сафйат — саф игелек; ихлас дога.
Тәгъәддед улмайә имкян — санап чыгуы мөмкин булмас.
Сахибе гъар — мәгарә иясе (мәгарәдәш).
Жар-у-йар — якыннар һәм дуслар.
Сахбе һәм алә — иярчен һәм нәселләренә (варисларына).
Вә бәгъде — һәм моннан соң.
Бәндәи әфкъәр — иң фәкыйрь бәндә.
Әксәр — бик күп, күпләгән; монда: бигрәк тә (бәйле).

Догалар әйләде сезгә
Гъәбде мозаф иля-л-Җәббар[4].

Бәтебдер Гъәбде-л-Җәббар[5],
Нәсыйхәт һәрбере на-чар,
Тәмам ошбу рисаләдә
Вәгъәзләр бабедин ачар.

Нәсыйхәт әйләдем вәгъзый,
Дота күр җан белән хифзый,
Әйа җан дилистаным сән,
Идә күрмә аңа гъәйзый.

Тәрек кыйлган нәсыйхәтләр
Күрисәр күп фәзыйхәтләр.
Ки, зинһар, тәрек кыйлмагыл,
Сәңа — ошбу вәсыйәтләр!

Нәсыйхәт дыңлаган угълан
Зәляләтдин үзен йолган,
Сәгадәтне ала куйган[6] —
Һидайәт эчидә улган.

Ки вәгъәз вә нәсыйхәт ал,
Күңел берлән колагың сал,
Сәгадәт эчрәдә булгыл,
Һидайәтдә сөрүбән халь.

Кичә-көндез улып нажи,
Башыңызга һода тажи
Куна дип, уламыз раҗи,
Сәгадәт вирелеп чәндан.

Бәтебдер — язылтыр; язгандыр.
На-чар — чарасыз.
Бабедин — баба: ишек; бүлек.
Вәгъзый — вәгазьне.
Хифзый — саклык; монда: хәтердә саклау.
Дилистан — җаным, бәгърем.
Гъәйзый — ачу (ачуны).
Тәрек кыйлу — ташлау; монда: тыңламау.
Күрисәр — күрер.
Фәзыйхәт — хурлык; кадерсезлек.
Зәляләт — адашу, хак юлдан язу.
Сәгадәтне ала куйган — бәхетне алга куйган, алда тоткан.
Һидайәт эчидә улган — тугърылык юлында булыр.
Сөрүбән халь — хәл сөрү белән; ягъни: яшәп, гомер итеп.
Нажи — котылган, ирекле.
Һода — хак юл, дөреслек юлы.
Раҗи — өметләнүче, үтенүче.

Кичермә юк белән әзман,
Тәмами гъөмр идеп вәйран.
Пошиманлык уласән соң,
Улып үз-үзеңә хәйран.

Еракка күзеңи салма,
Шәкъәуәт йилкәңә[7] салма,
Сәгадәтдин хөшек калма
Фәсадәт эчрә, гөлистан[8].

Ләгъү-ләһү эченә чыкма,
Шәйатин сүзенә бакма.
Бу сүзләрне уда якма,
Нәсыйхәт сәңа, и угълан!

Ки әшрар куймагыл яңа,
Ахыр тәэсир идә сәңа,
Ки соңра каласән таңа,
Улып үз-үзеңә хәйран.

Алар-лә сохбәт итмә һич,
Алар килсә дә, сән бар, күч,
Ки ахыр күстәрерләр көч,
Фәсадәт-лә идеп тогъйан.

Ки шухлыкда улып гъәййар,
Шаярып йөрмәгел сәййар,

Эзман — заманнар.
Пошиман — үкенүче, тәүбә итүче («пәшиман» әйтелеше дә бар).
Шәкъәуәт — бәхетсезлек, бәла-каза.
Йилкәңә — җилкәңә.
Хөшек калу — кибеп калу: уңышсыз калу, коры калу.
Фәсадәт — бозыклык, азгынлык.
Ләгъү-ләһү — буш сүз, мәгънәсез уен-көлке.
Шәйатин — шайтаннар.
Уда якма — утка якма.
Әшрар — явыз, усал кеше.
Яңа — янга, янына.
Таңа калу — таңга калу, гаҗәпкә калу.
Сохбәт — сөйләшү, әңгәмә.
Күстәрерләр — күрсәтерләр.
Фәсадәт-лә идеп тогъйан — бозыклык белән баш күтәреп, бәрей чыгып.
Шухлык — шуклык.
Сәййар — йөрүче; монда: хәрәкәт итүче.

Сакыйн: алдамасын гъэддар
Җиһанда, аңлагыл, и жан!

Гыйлемлек хәсълидә улгыл,
Җәһаләтдин үзең йолгыл,
Нәчек улса, җәһед кыйлгыл,
Ки, зинһар, калмагыл надан.

Ки, зинһар, калмагыл надан,
Дога алгыл ата-анадан,
Дота күр хәүфе рижадан,
Сакыйн[гыл] әз-фискъ-у-гъисйан.

Укый күргел кичә-көндез,
Гыйлемлек хәсълидә тиз-тиз,
Бәнемдик калмагыл гаҗиз,
Җәһаләтдә улып гъишйан.

Гыйлемлекдә ике дөнйа
Чырагын идәсән әхйа.
Бу сүздә зәррә юк әхфа,—
Бәйан идәр рәсүли жан.

Җәһаләтлек — яманлыкдыр,
Бере аның наданлыкдыр,
Болардин һич яман юкдыр,
Гизәрсәң гәр зәмин-асман.

Иген икмәк — вирер икмәк,
Мәшәкъкать-лә михән чикмәк;
Гыйлемлек — мәкъсудә йитмәк,
Һәр ике дөнйада әйкан.

Сакыйн — саклан.
Гъэддар — хыянәтче, икейөзле, хаин.
Хәсълидә — теләгендә; монда: эстәү юлында.
Җәһаләт — наданлык.
Җәһед (җәһд) — тырышлык.
Дота күр хәүфе рижадан — ышанып кына ятудан хәвеф ит.
Әз-фискъ-у-гъисйан — бозыклык һәм гөнаһ эшләрдән.
Гъишйан — аңсыз; алданган (тормышка алданган).
Әхйа итү — тергезү, җанландырып җибәрү.
Әхфа — яшерен уй, сер.
Рәсүли җан — пәйгамбәр юлындагы кеше.
Зәмин-асман — җир-күк.
Михән — михнәтләр, бәла-газаплар.
Мәкъсудә — максатка.
Әйкан — ап-ачык.

Җәһелдин эстәсәң файда,
Һидайәтлек сәңа кайда?
Зәлялэтлек улып пәйда,
Тәхәйердә китеп дәрман

Җәһаләтдин ерак качкыл,
Голүмең бабедин ачкыл,
Сәнендик дөнйада кач кол
Җәһаләтдә ирер гъищйан.

Җаһилләр лөкъмәсен капмак,
Тәмам михнәт белән тапмак:
Урак урмак, печән чапмак —
Михәнләр эчрә сәргәрдан.

[I] Нәсыйхәт фи-вакъты-с-сабый вә вәгъзәһү[9]

Сабыйлык төш кеби улыр,
Егетлек кош кеби улыр,
Къарилык буш-тәһи улыр,—
Кайа мәгърифәтә, йәздан!

Сабыйлыкда уйын кыйлсаң,
Шәйатингә муйын сонсаң,
Күнелмәссең бөйлә улсаң,
Егетлекдә улып сөкран.

Тәфахердә нәсәб кыйлма,
Никъаб дот, би-әдәб улма,
Уйын-көлке таләб кыйлма.
Уламын дип мин-эс-сабйан.

Җәһел — наданлык.
Һидайәтлек — тугъры юлда булу.
Тәхәйер — гаҗәпләнү, хәйран калу.
Голүмең бабедин — гыйлемнәр [illegible]шегеннәк.
Кач кол — күпме кол, нихәтле кол.
Лөкъмә — бер кабым ризык.
Сәргәрдан — иза чигү, михнәттә йөрү.
Къарилык — картлык.
Буш-тәһи — буш-мәгънәсез.
Бөйлә — шулай.
Сөкран — исерек.
Тәфахер — мактанчыклык; горурлык.
Никъаб — пәрдә, йөз пәрдәсе.
Би-әдәб — эд[illegible].
Уламын дип мин-әс-сабйан — сабыйлардан булам дип.

Көчекдин Хакъга тагъэт кыйл,
Һәр әмренә итагъәт кыйл,
Хәсадәтдин фәрагъәт кыйл,
Һәр әмренә соныл гәрдан.

Нәсыйхәт дыңлаган угълан
Күземнең рәушаны, бел, ан,
Ерак кыйл нәфсең әшрардан,
Күңел һәм әйләмә мәйл ан.

Гъәбәсдә къил-у-къаль итмә [10],
Кеше берлән җәдаль итмә.
Гъәбәскә дили мал итмә,
Ләгъүләр әйләйүб әйтан.

Хәтәргяһ әйләмә җайи,
Якыйна салма һәм пайи,
Якыйны улсаң, сәңа вайи
Йитешер күп зарар, и җан!

Нәсыйхәт дыңлаган хуш йар,
Әгәр сәндә исә һушйар,
Гел итмә фигъле бәд-бисйар,
Вә илля уласән гъөсран.

Ләгъин Иблис сәне көн-төн
Китереп күстәрә алтын,
Дәхи һәм үзенең артын,—
Сакыйн: сән бакма бәр-шәйтан.

Хәсадәтдин фәрагъәт кыйл — көнчелектән азат бул.
Гәрдан — муен.
Рәушаны — яктысы, нуры.
Ан — мизгел, вакыт.
Әшрар — явызлык, усаллык.
Мәйл әйләмә — күңел бирмә, күңел салма.
Гъәбәс — нәтиҗәсез, файдасыз эш.
Җәдаль — талаш, кычкырыш.
Дили мал — күңел максаты.
Ләгъү — буш, мәгънәсез сүзләр.
Хәтәргяһ — куркынычлы.
Җайи — җайны (урынны).
Пайи — аякны.
Һушйар — тулы акыл, зирәк исәп.
Бәд-бисйар — бик алама, бик начар.
Гъөсран — кыенлык, кысынкылык.
Бәр-шәйтан — шайтанга, шайтанга таба.

Хәлаикъ алдыйда торсаң,
Утырсаң да вә йа йөрсәң,
Түңелмәслек беләң улсаң,
Укырлар афәрин әлуан.

Ула күргел үкенмәслек,
Кеше күргәч түңелмәслек;
Ула күрмә кунелмәслек,
Сезн азгырубән шәйтан.

Уйын-көлке үзә мәргъүб,
Шаярып йөрмә, әй, мәхбүб!
Сәнендик дөнйада күп-күп
Соңында уладыр хөсран.

Кичермә юк беләң әзман,
Ләһү-ләгъү идеп чәндан.
Боның соң үкенү әлуан
Беләң дә кермәйә дәрман.

Дәхи баз әйләмә бази,
Шаярып кышый һәм язый,
Ки шухлыкда күби-азый
Кичермә йил үзә дәүран.

Ки бән шухлык беләң улдым,
Шаярмаклык беләң улдым,
Вәлий гъәфләт беләң улдым,
Җиһанә улубән алдад.

Малайәгъни беләң, зинһар,
Кичермә шаярып рузгяр.

Хәлаикъ — халык; кешеләр.
Түңелмәслек — ваемсызлыкка бирелмәслек.
Әлуан — төрле; күптөрле.
Азгырубән — аздыру белән.
Мәргъүб — теләүче; омтылучы.
Мәхбүб — сөекле.
Хөсран — адашу, юлдан язу.
Әзман — заманнар.
Ләһү-ләгъү — буш, юк-бар сүз.
Чәндан — әллә нихәтле, күп.
Баз — уен; баз әйләү — уйнау.
Йил үзә — җилгә.
Алдад — алданылган.
Малайәгъни — мәгънәсез.
Рузгяр — көннәр; вакыт, чор, дәвер.

Ки шухлык әйләмә бисйар —
Улырсың сүземә мөнкад.

Җәмигъ гомрем йилә вирдем,
Шаяру-шухилә йөрдем.
Вәли гъөзр, и нури бәдрем,
Бәнемдик улмагыл фәссад.

Кечекдин кыйл гыйбадати,
Тәрек кыйлгыл фәсадати.
Сәгадәт әйлә гадати —
Соны һәм уләсән могътад.

[II] Егетлек вакытындагы нәсыйхәтләр вә вәгъәзләр

Егетлек йил кеби үткәй.
Къарилык фи-з-зәман йиткәй,
Бакып күр халеңи: ниткәй,
Фәсадәтдә үтеп рузгяр.

Егетлек китәдер фәүри,
Йилә вирмә газиз дәүри,
Ки шәйтан салмасын җәүри,
Идеп әфгалеңә әзрар.

Җиһанга салмагыл мәйли,
Ки булгыл пакь, лөтъф зәйли,
Ки булма соңра дәр-вәйли,
Пошиманлар идеп бисйар.

Бисйар — күп.
Мөнкад — буйсынучан, тыңлаучан.
И нури бәдрем! — И тулган аем!
Фәссад — азгын, бозык.
Гыйбадати — гыйбадәтләрне.
Фәсадати — бозыклыкларны.
Гадати — гадәтләрне.
Могътад — күнегелгән, гадәтләнгән.
Фи-з-зәман — тиз арада, шунда ук.
Фәүри — тиз, ашыгыч.
Дәүри — дәверне.
Җәүри — җәберне.
Әфгалеңә әзрар — уй-гамәлләреңә зарарлар.
Мәйли — мәелеңне, күңелеңне.
Лөтъф зәйли — итәк-чабуың матур, ару (монда: әхлаклы, әдәпле).
Дәр-вәйли — кайгыда, хәсрәттә.
Пошиманлар (пәшиман) — үкенүчеләр, пошынучылар.

Сакыйнгыл, нәфсеңи пакь ит,
Вә һәуа нәфсеңи тәрк ит.
Дәхи һәм даминең пакь ит,
Ки зәррә әйләмә әшрар.

Фасикълардин фиракъ улың,
Алардин сал ерак юлың,
Йәтимләр башына — кулың
Идүбән шәфкъәтең һәм зар.

Мәкер, хәйлә идеп мәккяр,
Йөрер әтрафыңа сәййар,
Ки гъарәт итмәсен гъәддар
Ки ушал хәмкъәи гъинад.

Шәйатин, бел, гъәдур улгай,
Хакында гөфтегү кыйлгай.
Мәкерләр җөстеҗү кыйлгай
Заляләтдә бә-иҗтиһад.

Фигъали кыйлма на-мәгъкуль,
Ләгъү-ләһү белән мәшгуль.
Ки танда уласән мәсьүл,—
Ки рузие вакът гъәдл-ү-дад.

Шәрәфкярең шәр әфкярә [11]
Вирә күрмә бу рузгярә.
Би-кәфкярә тәләфкярә [12]
Кичермә гомреңи бәр-бад.

Димәгел йөзеңи күркәм,
Үзеңи даимән күр кәм,

һәуа нәфсеңи тәрк ит — һавалы нәфесеңне ташла.
Даминең — итәк-чабуың; монда: йөреш-торышың, гамәлеңне.
Фасикълардин фиракъ — бозыклардан аеры (ерак).
Мәккяр — мәкерлек эшләүче.
Гъарәт иту — талап алу.
Гъәддар — хыянәтче, икейөзле.
Хәмкъәи гъинад — киребеткән, үҗәт, ахмаклар.
Гъәдур — мәкерле; оятсыз.
Гөфтегү — сүз сөйләү, әңгәмә.
Җөстеҗү — эзләнү, казыну.
Заляләтдә бә-иҗтиһад — бозыклыкта тырышлык белән.
Рузие вакът гъәдл-ү-дад — вакыт бүләге ул гдаел хөкем.
Шәрәфкярең шәр әфкярә вирә күрмә бу рузгярә — шәрәфле (данлыклы) эшләреңне явыз фикерләргә бу заманда бирә күрмә (буйсындырма).
Би-кәфкярә тәләфкярә кичермә гомреңи бәр-бад — кулыңдагы эшне әрәм итеп, гомереңне җилгә очырма.

Сәнендик дөнйада күркәм [13],
Җәмале гъәни итеп фөссад.

Сакыйн мәккяр мәкерендин [14]
Вә шәр әфкяр фикерендин,
Җөда кыйлмайа зикреңдин,—
Мәкер-хәйлә идеп әз-дад.

Ки шәйтан бер шәкъи гази,
Дотар чөн чәнгяле пази [15];
Уласыз фәүзедин фази [16],
Сакыйнсаң, табасән иршад.

Йөремә шухи нийәтдә,
Бәнемдик әшрар сохбәтдә,
Уласән таңда хәсрәтдә,
Эчең-тышың улып хөсран.

Чыкубән йөрмәгел илгә,
Вирүбән гомреңи йилгә,
Заляләти виреп дилгә,
Уласән таңда сән хөсран.

Һидайәт әһледин улгыл,
Сәгъиди әһледин [17] улгыл.
Латыйф, пакь зәйледин улгыл,
Тәмами күстәреп борһан.

Шәрафәтең шәр афәтә,
Кәмаләтең кәм аләтә,
Вирүбән ушбу халәтә,
Соңыйда калма дәр-тогъйан.

Җәмале гъәни итеп фөссад — йөз байлыгын бозыклык (чарасы) итеп.
Шәр әфкяр — явыз фикерче.
Зикреңдин — хәтереңнән.
Әз-дад — хөкемнән, җәзадан.
Шәкъи гази — рәхимсез клоун.
Чәнгяле пази — карчыга тырнаклары шикелле.
Уласыз фәүзедин фази — җиңүсннән котылучы булырсыз.
Иршад — юнәлеш; тугъры юл.
Шухи нийәтдә — шуклык нияттә.
Хөсран — үкенеч-сагыш.
Заляләти виреп дилгә — күңелне әшәкелеккә биреп.
Һидайәт — туры юл.
Сәгъиди — бәхетле, бәхетлеләр ише.
Зәйл — итәк-чабу.
Борһан — дәлил, үрнәк.
Шәр афәтә — явыз, хәтәр эшләргә.
Алэт — чара, эмәл.
Калма дәр-тогъйан — чамадан тыш азгын хәлдә калма.

Шәйатиндыр хәседрани,
Йар, андин дотма йарани [18],
Катыңдан ку ба-зур [19] ани,
Мәкам идеп аңа зиндан.

Көдурәтең ерак атгыл,
Мәляхәт мелхедин татгыл,
Диленнең җанына катгыл,
Ки һәмчү дамәги сөбхан.

Күңелне югары дотма,
Шәйатин хален онытма [20],
Соңгы гъәм-гъөссалар йотма,
Улубән бәгъреңә бөрйан.

Чү хәшмиш (?) төхмедик аша,
Юкары чикмәгел баша;
Хаша хөшек калган хаша,
Ки бәд тәрке белән, и җан!

Явыз эшне күрүбән хуб
Дилең аздырма, и мәхбүб,
Яманлык төхмен икмә күп,
Аның төхме ирер гъисйан.

Яман сагыш алырса гъиш [21],
Орыр ниш үз-үзенә хиш,
Йөзи саргайта бәд-эндиш,
Әмәлләр асле мин-ниран.

Хөседрани — көнчелек иясе.
Йар, андин дотма йарани — дус, аны (шайтанны) үзеңә юлдаш итмә.
Көдурәт — кәефсезлек, кайгы.
Мәляхәт мелхедин — матурлык, нәфислек тозыннан (тәменнән).
Һәмчү дамәги сөбхан — шушы ходай дөньясы шикелле.
Бөрйан — яну, кыздырылу.
Төхмедик — орлыгы шикелле.
Хаша хөшек калган хаша — коры калган ботак чүп-чар ул.
Бәд тәрке белән — ташланганлыгы белән начар.
Дил — күңел.
Гъисйан — бозыклык, гөнаһ.
Гъиш — тормыш, яшәү.
Ниш — сөңге.
Хиш — туган, кардәш.
Бәд-эндиш — начар уй.
Әмәл — өмет, ышаныч.
Ниран — ут, җәһәннәм.

Сакыйн туль эмэллэрдин[22],
Зирэ суэи гамэллэрдин,
Харам эшдер дэгъэллэрдин
Сакыйн сэн, эйлэмэ, и җан!

Ки шэйтан тезэйүб кямен,
Салып дамeнгэ дамен,
Сакыйнгыл, тапмасын рамен,
Мэкер-хэйлэ идүбэн ан.

Җэһеддэ акызып эз-кан,
Атар аркаң үзэ аркан,
Сакыйнгыл, дошмэсен дэр-ан,
Ул аркан буйныңа гэрдан.

Бакып йэмин-шималеңэ[23],
Бакыйбэн үз җэмалеңэ,
Ки гъөҗб эйлэмэ халеңэ,—
Тэкэбберлек идеп бэр-дар.

Йитешсэң блүгъийэтдэн
Китүбэн тофулийэтдэн,
Хазз алсаң шэбабийэтдэн,
Йөремэ мэст[24] улып, и йар!

Блүгълар, на-блүгълар да,
Ки сэндин һэм олугълар да
Кичеп китте рөҗугъ дарга,
Ки мэдһуш ятмагыл, һушдар.

Туль — дэвамлы, чамасыз.
Суэи — явыз ниятле.
Дэгъэл — алдакчылык, хэйлэк.
Кям — телэк, омтылыш.
Даменгэ дамен — ау естенэ ау.
Рам — буйсынучылар; монда: җаен, ибен.
Эз-кан — каннан.
Гэрдан — уралу, эйлэнү.
Бакып йэмин-шималеңэ — карап көньяк һэм төньягыңа.
Бэр-дар идеп — күтэрелеп; монда: масаеп.
Блүгъийэт — үсеп җитү, балигъ булу.
Тофулийэт — балалык, үсмерлек чоры.
Хазз — өлеш.
Шэбабийэт — егетлек.
Мэст — исерек.
Блүгълар, на-блүгълар — балигълар, балигъ булмаганнар.
Рөҗугъ дар — кайту йорты («теге дөнья»).
Мэдһуш — истэн язу хэле, аңсыз.
Һушдар — акыл иясе.

Нигәчә ятасән, йарукым,
Шәйатин төхме — бәд йир, ком,
Күзең ач, дөнйа күр: пөр ком,
Гъәкъим йилдә ула сәййар.

Һауага бакып, и рухи,
Йөремә бонда ба-шухи.
Сәнеңдик бонда күп бу хи [25],
Хөсирүн ула күп гъәййар.

Нәсыйхәт дыңлаган хуш йар,
Әгәр сәндә исә һушйар,
Кил, итмә фигъл бәд бисйар,
Вә иллә уласән дәр-хар.

Һәм әшрар нарыдин качкын,
Бер очкын килсә дә ычкын,
Киләчәк, бозлы су сачкын,
Сәне көйдермәсен ул нар.

Әгәрчә уты суз улсын,
Бозылсын, ки та боз улсын,
Къәһәрә шәб вә руз улсын
Җәһәннәмдән мәгъә-л-әшрар.

Шәйатин җәһд итеп сезгә,
Итәр тәргъиб яман чизгә.
Яманлык күстәреп күзгә
Дәхи һәм күстәреп әдбар.

Шәкъәуәт әйләмә һәргиз
Улубән фетнәләр әнгиз;

Йарукым (*йарук*) — нур, нурлым.
Пөр ком — тулы ком.
Гъәкъим — кысыр, мәгънәсез.
Ба-шухи — шуклык белән.
Хөсирүн — югалтучы, зыян күрүче.
Һушйар — сәламәт акыл.
Бисйар — күп.
Дәр-хар — хур (булу).
Әшрар нарыдин — бозык эшләр утыннан.
Суз — көйдерерлек, көчле.
Шәб вә руз — төнен һәм көндез.
Тәргъиб — теләк уяту, котырту.
Чиз — әйбер.
Әдбар (*идбар*) — уңышсызлык.
Шәкъәуәт — бәла, начар эш.
Әнгиз — кузгату, ярсыту.

Болардин идәсән пәрһиз,
Әгәр гакыл улырса йар.

Мәхәббәт әһленең пише,
Уласән бер сәгъид кеше,—
Тәрек әйлә гөнаһ эши,
Қитүбән эзенчә әбрар.

Олыга гыйззәт ит, хөрмәт,
Қечекләргә идеп шәфкъәт,
Ходадин уласән рәхмәт,
Қичерсәң бөйләдә әгъсар.

Нәсыйхәт тыңлаган шабем,
Сәнең чөн вәгъзидин бабем,
Итагъәтдә ул, әсхабем,
Ки ташлап җөмлә-ил-әшрар.

Йөремә мәст улып сөкран,
Егетлекдә гъәлят-т-тогъйан,
Соңыда уласән хөсран,
Килеп эш ахыры дишвар.

Мәшәкъкать дөнйада улмыш,
Эчидә фетнәләр дулмыш,
Фәуаиддин улыбдыр тыш,
Вәләкин көн-бә-көн әзрар.

(III) Қызларга улган нәсыйхәтләр, вәгъәзләр бәйане

Блүгъә йитешәчәк җан,
Фәуахиш итмә һәм тогъйан,
Сакыйн, һич әйләмә гъисйан,
Сакыйн һәм кыйлмагыл әшрар.

Пәрһиз — тыелу.
Пише — алдынгысы.
Әбрар — изгеләр.
Сәгъид — уңыш, бәхет иясе.
Әгъсар — гасырлар (күп вакыт).
Шаб — егет.
Әсхаб — дуслар.
Җөмлә-ил-әшрар — барлык начар эшләрне.
Гъәлят-т-тогъйан — фетнәдә, башбаштаклыкта.
Хөсран — хәсрәтле.
Дишвар — авыр, кыен.
Фәуаид — файдалар.
Әзрар — зарарлар.
Блүгъ — балигълык.
Фәуахиш — фәхеш, бозык эшләр.
Тогъйан — фетнә, бунт.

Гизүбән йөрмәгел, и рух,
Җиһанда улубән сән шух,
Ямандыр ки шәкъәуәт, бух,—
Фәсадәтләр хале изһар.

Йөремә чыкубән илә,
Фәсадәт эстәйүб бөйлә,
Һәммә гомрең виреп йилә,
Зи-хөсран үлмә соң, и йар!

Фасикълар катына килмә,
Фәуахиш эстәйүб йилмә,
Ки сөкран улубән йөрмә,
Шаярып улма һәм сәййар.

Сакыйн, дуст әйләмә әшрар
Һәм итмә юлына әдбар,
Ки анлар тәбгыдин күп-күп
Күрәсән соңындин әзрар.

Фәсадәтдән атың шаигъ,
Һодадин карныңыз җаигъ (?).
Кил, итмә гомреңи заигъ
Һәлякәтдә тәмам дәр-хар.

Кичә-көндез гизеп юлдин,
Сәгадәт вирмәгел кулдин,
Ки улма соң фасикъ колдин,
Ерак китеп мин-әл-әбрар.

Бу сүзгә саласән, җан, гүш,
Газиз гомреңне вирмә буш;
Соңы — гъәмләргәдер сән туш,—
Сәне гъәбн идәчәк гъәддар.

Рух — җан; җан иясе.
Фәсадәт — бозыклык.
Изһар — ачык, анык.
Зи-хөсран — хәсрәттән.
Фасикъ — бозык, азгын.
Тәбгъ — билгеле бер төркем иярчене.
Шаигъ — даның чыккан.
Һода — хак юл, дөреслек юлы.
Мин-әл-әбрар — изгеләрдән.
Гүш — колак.
Гъәмләргәдер сән туш — хәсрәт-бәлаләргә очрарсың.
Гъәбн иту — алдау.
Гъәддар — хыянәтче.

Колак сал та ниһайәти,
Ки бер сабый хикяйәти,
Ничек идәр шәкяйати,
Ки бер мөштәридин, и йар!

Тофулийәт заманымда,
Сабыйлык үзә данымда,
Ки атам ошбу анымда
Алып вирде ләүхе дәфтәр.

Дәхи алтын йөзек, һиммәт,
Бәһасе дәхи зи-кыйммәт,
Алубән вирде һәм, әлбәт,
Мәхәббәт улынып дәркяр.

Зәмани мин-әл-әзмани
Вирел бер хөрмә вә алмани,
Алып бер мөштәри ани,
Сатуда гъәбн итеп бәрдар.

Бонын дикен сәне мәлгунь,
Сакыйн, әйләмәсен мәгъбүн,
Мәкер вә хәйләсе әфзүн,
Сакыйн, лилхафиз саттар.

Шәйатин үзрә кем бака,
Ходаүәндә аңа кака:
Баканларны уда яка,—
Белерсең кәндүзең, и йар!

Халыкдин улубән мәстүр,
Үзең кемлек белән пәс тор,

Мөштәри — сатып алучы, сәүдәгәр.
Тофулийәт — сабыйлык, үсмерлек.
Ан — кыска вакыт, мизгел.
Ләүхе дәфтәр — язу дәфтәре.
Һиммәт — бүләк.
Дәркяр — кирәкле, яраклы.
Зәмани мин-әл-әзмани — заманнардан бер заманны.
Бәрдар итү — йөкле итү.
Мәгъбүн әйләү — алдау.
Әфзүн — чиксез.
Лилхафиз саттар — саклаучы, гафу итүче (алла).
Кака — кага.
Уда яка — утка яга.
Кәндүзең — син үзең.
Мәстүр — яшерен.
Пәс тор — башкалардан артта, түбәндә тор.

Имәстер гъәксенә дәстүр,
Ки мәхрүм әйләйүб изһар.

Ки шамдин ятма та собхи
Ойып гафләтдә, басып хи,
Тора бакып хи ба-кобхи,—
Хәйа берлән шәрм бисйар!

Гөлстани җинан садрең,
Бөйләдер, беләсең, кадрең,
У мәнзилдә ике бәдрең,—
Алардин йуймагыл әкърар!

Кадерсез кыйлма, ки белсәң,
Ике күксенне, чөн күк сән,
Соңы тугъры бәһа күрсәң,
Әлемдин күп әләмләр вар.

Якыныңа килеп шәйтан,
Идә сәңа комар бахтән,
Сакыйн, әйләмәсен тахтән,
Килеп галиб мәгъә-л-әгъйар.

Үтеп сөк-ран, итеп сөкран,
Кабарга уладер фикран,
Мәгәр саклайа зи-л-гофран,
Идеп үз фазлене иншар.

Идеп шәбхун, түгеп шәб хун,
Йөрер әтрафыңа мәлгунь,

Гъәкс — бер нәрсәнең киресе.
Дәстүр — рөхсәт.
Шамдин ятма та собхи — кичтән иртәгәчә ятма.
Хи — арт сан.
Ба-кобхи — кабахәтлек белән; оятсызлык белән.
Хәйа берлән шәрм — оят белән намус.
Гөлстани җинан садрең — җәннәт гөлстаны күкрәгең.
У мәнзилдә — шул урында.
Бәдрең — тулган аең (имиең).
Әкърар йуйу — ныклыкны җую, йомшару.
Ике күксенне — ике имиенне.
Әлемдин күп әләмләр вар — кулымнан күп бәлаләр бар.
Комар бахтән — комар уйнау.
Тахтән — һөҗүм итү, өскә ташлану.
Килеп галиб мәгъә-л-әгъйар — башкалар белән бергә җиңеп.
Үтеп сөк-ран, итеп сөкран — рәхәтләр үтеп, исереп.
Зи-л-гофран — гафу итүче алла.
Идеп үз фазлене иншар — өстенлеген мәгълүм итеп.
Шәбхун — төнге һөҗүм.
Шәб хун — төнлә кан.

Таба та аздырып фәрхун,—
Сакыйн, мәкр итмәсен мәккяр!

Бәшир бөшри бәшәр булгыл,
Мөшире Хакъ, би-шәрр улгыл,
Шәкъәуәтне нәшер кыйлгыл,
Сәгадәткә куйып әкъдам.

Сәгадәт багыны багый
Улубән булмагыл багый,
Шәкъәуәтне улып рагый,
Ки гомрең әйләмә инзам [26].

Кыйлыр инша нә кем иншаэ [27].
Лик әфша кыйлмайә хәйф шаһ [28];
Вәли изгеләргә охша,
Дели җаның белән бул тамм.

(IV) Тәләттыйфлык белән сөйләмәк бәйане

Тәләттыйф берлә сүз әйлә,
Ишедән дили суз әйлә [29],
Шөйлә ки йинҗү риз әйлә,—
Тәмам рәнҗү бетә эттам.

Дилең миһри — делең лөтъфи
Белән сүз әйләп би-зәгъфи,
Миһербанлык идеп зөлфи,
Дигел йомшак ләгъилә рам.

Фәрхун — шатлыгын.
Бәшир бөшри бәшәр — кешелекле, сөендерүче кеше.
Мөшир — киңәшче.
Би-шәрр — зарарсыз, усал түгел.
Шәкъәуәтне нәшер кыйлгыл — бәла-казаларны туздырып ташла.
Әкъдам — адымнар.
Багый — баш тартучы, гыйсъянчы.
Рагый — көтүче, җыеп торучы.
Инзам әйләү — кысып тоту.
Лик әфша кыйлмайә хәйф шаһ — ләкин алла гына үкенечне фаш итми.
Дели җаның белән бул тамм — телне жаның белән бер ит.
Тәләттыйф — матур, күркәм.
Ишедән дили суз әйлә — ишеткән күңелне көйдер.
Йинҗү риз әйлә — энҗе итеп сип.
Эттам — бөтенләй.
Дилең миһри — *делең лөтъфи* — күңелең мәхәббәте — ул телең (сүзең) нәфислеге.
Би-зәгъфи — көчсезлек.
Ләгъилә рам — сүз белән күндерү.

Сүәксез дел яратды Хакъ,
Сүзи та кыйладыр йомшак,
Җәрахәт дел беләи кыйлмак
Яман әз-нәйзаи Бәһрам [30].

Җәрахәт гәр кыйлыр нәйза,
Уңалыр тиз сагъәт үзә,
Уңалмас, китмәйү мадәм
Вәли дел җәрхе чөн нәйза.

Яман тел һич кемә вирмә,
Дәхи гайбәт кыйлып йөрмә,
Бу форсатны йилә вирмә,
Шәйатин салмайа та дам [31].

Сүзи сөйлә сарих-ачык,
Йибәрмә тел къәбихә чук,
Сүзендә ул тәуазигълык
Фәуаиддин идеп тәмам.

Нәмимә гайбәти сүзләп,
Йөремә һич [дә] шабезләп [32],
Ки улмагыл хәйасез һәп,
Бу эшләр улмайа ихсан.

Делең бу сүзгә фәкк итмә,
Булып нәммам, бөтек итмә,
Кеше гайбен һәтек итмә [33],
Харам эш уласән, и җан!

Шаярып йөрмәгел сәййах,
Ки шухлыкда улып шәййах [34],
Нә ятырсән: хоруслар сах,—
Әгәр наим исәң, уйган!

Әз-нәйзаи Бәһрам — Бәһрам сөнгесеннән.
Уңалыр — төзәлер.
Чөн — кебек.
Дам — тозак, капкын.
Тәуазигълык — түбәнчелек.
Фәуаиддин — файдалардан.
Нәмимә — ике кеше арасын бозар өчен сүз әйтү.
һәп — бөтенләй, баштанаяк.
Ихсан — яхшылык.
Делең ... фәкк итү — телеңне чишү.
Нәммам — әләкче.
Бөтек — язу.
һәтек иту — тарату, хурлау.
Хоруслар сах — әтәчләр сак.
Наим — йоклаучы.

Улыр иршад белән ир шад [35],
Шәкъидин кача бад чөн бад [36],
Идәр хәйфе сәмамда әфсад [37]
Ки тәгъвиз әйлә бәр йәздан.

Белерсең кәндүзең ир дип,
Ахыр урыны, белең, зир [38] дип,
Фирашыңи — кара йир дип,
Торабеңи дәхи — юрган.

Гъәбәс вирмә дәваздәһи [39],
Кичермә улубән ляһи,
Нәгяһан йитешеп раһи,—
Сәфәрдер даре дөнйадан.

Гамәлдә ижтиһад әйлә,
Варасы юлый йад әйлә.
Сәфәргә заде зад [40] әйлә,
Ахыр тапмайасән ибкаэ.

Һидайәт әйләгел дәр-пиш [41],
Рийадин буш улубән хиш,
Ки шәйтан салмасын тәшвиш
Рийа гъәжбә идеп әгъраэ [42].

Рийа улса гамәлдә чук,
Зыйасы һич мәхәлдә юк,
Кә-әннә фи-л-мәсәлдә юк:
Кәмәгъдүм ләйсә мин әшйаэ [43].

Иршад — юнәлеш.
Шәкъидин кача бад чөн бад — бәхетсездән җилдәй кача.
Тәгъвиз әйлә — әжер бир.
Йәздан — ходa, тәңре.
Зир — аст (җир асты).
Фираш — ятар урын, түшәк.
Тораб — кабер туфрагы.
Гъәбәс — юкка; мәгънәсезгә.
Дәваздәһи — унике (ай).
Ляһи — кәеф-сафа сөрүче.
Раһи — юлы.
Заде зад әйлә — юл азыгын артыгы белән әзерлә.
Ибкаэ — калдырып китәр нәрсә; җылаучы.
Һидайәт әйләгел дәр-пиш — киләчәккә тугъры юнәлеш ал.
Хиш — үзен.
Рийа гъәжбә идеп әгъраэ — рияга, тәкәбберлеккә кызыктырып.
Зыйасы — нуры.
Мәхәлл — урын; җир.
Кә-әннә фи-л-мәсәлдә юк — гүяки һәкъ мәкальдә юк.

Танып белгел урынларны,
Ки безләрдин борынларны,
Виреп йилгә корунларны,
Къәмусы кичәсәр зи-инжа [44].

Кемә бу йәнә горур тукый? [45]
Әҗәл укы килеп укый,
Белерсән форсатың юкый,—
Нимә алданасың, әй-ва?!

(VI) Хәмийәтсез ирләрнең вә чапәк хатынларның нәсыйхәте

Гаҗәб гъәсри хәлаикълар
Тәмам мөрдәгә лаикълар:
Эче тулы гъәляикълар [46],—
Фәсадатдан дәхи тогъйан.

Би-гайрәт кеше кем дәййүс [47],
Тәмугъга уладыр мәэнүс,
Җинан андин ула мәгъбус [48],—
Ки зәррә күрмәйә руйан.

Гаҗәб бу хиндәге гъәүрат
Үзене сала ба-гъәүрат
Һәммә гомре мәгънә-с-сурат [49]
Идүбән фискъ-у-гъисйан.

Гаҗәб бу хиндәге ирләр
Бу дөнйаны «Безем!» — дирләр.
Хосусән Болгари йирләр
Җиһанә хирсъ улып дәр-зән [50].

Корунлар — гасырлар; монда: чордашлар, гасырдашлар.
Къәмусы — һәммәсе.
Зи-инжа — моннан, бу урыннан.
Хәмийәтсез — булдыксыз, рухсыз, намуссыз.
Чапәк — өлгер, житез.
Гъәсри хәлаикълар — гасырдаш халыклар.
Мөрдә — үлек, мәет.
Гъәляикъ — болганчык.
Дәййүс — үз хатыны белән сату итүче.
Мәэнүс — күнеккән.
Жинан — җәннәт.
Мәгъбус улу — лаек булмау.
Руйан — йөзләр (кеше йөзе).
Хин — вакыт, заман.
Гъәүрат — хатыннар (*гъәүрәт* — хатын һәм: женси әгъза).

Улубән әһлә би-гайрәт,
Кичәләр вакъты ба-хәйрәт[51],
Ивидә ивлеге гъәүрәт
Заляләтдә вирер дөр-ан.

Кичүбән ошбу халәтдә
У гъәүрәти фәсадәтдә.
Һаман рузи кыйамәтдә
Ки рисвай ула ул инсан.

Әгәр әһлең фәсидә буд,
Күрәчәк дөнбалә дәр-зуд.
Төшермәйә сәни бәр-худ,
Һәлякәткә идеп хәйран.

Дигел: «Зән, йөрмә ба-шухи,
Фәсадәтлек идеп бу хи;
Нәчек зәне Лутъи, Нухи[52]
Иденерләр иде көфран.

Ки булма күчләри рәү-зән[53],
Аңа һәм бакма зи-рәүзән[54];
Карышып бакъдисә ру-зән[55]
Нәсыйхәтләр белән бер ан.

Аның чөн бәндәи дәййүс,
Биһештең исидән мәәйүс,
Җинан андин ула мәхнүс[56],
Имәс бакъдырмака имкян.

Хәмийәт риштәсен пиш-дар,
Йөретмә әһлени мишвар[57],
Юк ирсә эш ула дишвар,
Идисәр сәне дәр-хәжлян[58].

Ба-хәйрәт — гаҗәпләнү белән.
У — ул.
Фәсидә буд (фәсидә булса) — бозык булса; усал, явыз булса.
Күрәчәк дөнбалә дәр-зуд — күргәч артын тиз генә.
Зән — хатын.
Ба-шухи — шаярып.
Күчләри рәү-зән — урамнарда йөрүче хатын («рәфтән зән» гыйбарәсеннән).
Зи-рәүзән — форточкадан, тәрәзәдән.
Ру-зән — йөзенә бәр («ру задән» гыйбарәсеннән).
Биһештең — җәннәтнең.
Мәхнүс — йөз чөерү.
Хәмийәт риштәсен пиш-дар — намуслылык җебен алда тотучы.
Мишвар — базар (сату урыны).
Дишвар — кыен, авыр.

Улырсың аңа би-гайрәт,
Зәнең ирдер ки, сән — гъәүрәт,
Мәляик иде сәр-ләгънәт[59],
Сәңа дип йад дәхи бер ан.

Догадин улмагыл хали,
Йад әйлә әһли һәм ани,
Сөаль ит боны әз-гали[60]
Иляһи вир нәдер бә-ан.

Иляһи ошбу сөалем:
Аләм әшраредин алыйм.
Диле салим[61] үзә салим
Улалар та гъәля-л-ихсан.

Голяма юлларын азмыш,
Тәрикъы мөстәкъим язмыш,
Шәкъәүәткә халык басмыш,
Дөшебдер фетнәгә заман.

Голямага халык бакмыш,
Дәйүрләр: «Ошбу сүз хакмыш»,—
Әгәр хакъдин улачак тыш,
Ки тәрк әйләр иде кем ан.

Гөнаһдин мөддәти мөддәт[62]
Тәмам азгылуга мәддәт[63],
Кил, и җан, әйлә сән рәүүәт[64],
Фәсадәтдин дулып бу ан.

(VII) Хатынларга улган нәсыйхәтләр бәйане

Гаҗәб бу хиндәге гъәүрәт,
Ачып гъәүрәт, салып гулат[65],
Гизәрләр салубән шурәт[66]
Никъабсыз хәр кеби бәд-нам.

Мәляик — мәләкләр; фәрештәләр.
Сәр-ләгънәт — ләгънәт башы, баш ләгънәт.
Хали — буш, өлешсез.
Аләм әшраре — явызлык кайгысы.
Диле салим — сәламәт күңел.
Гъәля-л-ихсан — ихсан (яхшылык) өстенә.
Голяма — галимнәр.
Тәрикъы мөстәкъим — туры юл.
Мөддәти мөддәт — вакыт артыннан вакыт (узды).
Мәддәт — артты.
Никъабсыз хәр — ябынчыгы юк, иярсез ишәк.

Җиһан тәркенә кыйл гайрәт,
Сакыйн, һич әйләмә рәгъбәт.
Нә улса адәмә гыйбрәт:
Кирәк ник шәй, кирәк бәд-кям.

Ки улма чапкучы чапәк[67],
Фигъали идубән нә-пакь,
Ки ахыр күрәсән бер бакъ —
Үкенечләр белән әкъсам.

На-мәшругъ фигълә — на-мәшругъ
Улубән, булыңыз мәмнугъ,
Вә иллә уласән мәсругъ[68],
Тәмам зәхмәт белән мадәм.

Уйын-көлке мәкяненә
Вара күрмә дәр-ан инә,
Шәтем вир[69] анда ханына,
Нәсыйхәт-лә идеп әгъзам.

Кайадур рәнди мәҗлеси,
Ки тәргъиб идә иблиси:
«Вара күр, табак кәҗ лиси»[70],—
Дәйүбән, хасиди залям.

Дәйүр: «Зән, юла экъдәм зән[71],
Имәс күр сән — варып күр сән.

Җиһан тәрке — дөнья ташлау.
Рәгъбәт — омтылыш.
Ник шәй — яхшы нәрсә.
Бәд-кям — начар уй, начар омтылыш.
Бакъ — курку.
Әкъсам — ант бирү, ант эчү.
Мәшругъ — закон кушкан, шәригатьчә дөрес.
На-мәшругъ — шәригатьчә түгел.
Мәмнугъ — тыелган.
Вә иллә — югыйсә.
Мәсругъ — ауган, аударылган.
Зәхмәт — хезмәт, азап.
Мадәм — мәңгегә.
Мәкян — урын.
Ин — шул, шушы, бу.
Шәтем — орышу, сүгү, шелтәләү.
Хан — табын өстәле.
Әгъзам — бик нык итеп.
Рәнди — азгынлык, типтерү, кәеф-сафа.
Тәргъиб — куркыту.
Табак кәҗ лиси — кыйшык табак яла.
Хасиди залям — кара көнчелек.
Экъдәм зән — юлга бас, атла.
Имәс күр сән — сукыр түгел син.

Урам кем кичә күрәсән,
Тәмам зиннәт белән инзам».

Дотып зиннәт, идеп нәкъши,
Вара бер мәҗлеси фәхши,
Ауази дузе вә кәфши [72]
Вирисәр салачак әкъдәм.

Бу саутә әйләмә рәгъбәт
Ауази фигъл иде ләгънәт;
«Сәңа ләгънәт ки, ә гъәүрәт!» —
Дәйүбән вирәдер дөшнам.

Кеше дәф орса һәм — танбур,
Кидәсән сохбәтендин дур;
Вә иллә күрисәр сән зур [73],
Орыр зәнбур [74] кеби алям [75].

Фасикъдин дотмагыл дустан,
Заляләт далидер у сетан,
Хәзәр күп әйлә: бу дастан
Сәңа һәм бу ирер игъләм.

Ерак бакма, якындин күр,
Фасикъларның хален сән сур,
Фәсакъәтдә вирүбән дур,
Заляләтдә куйыблар нам.

Һода дәүрани дур ани [76],
Йибәрмә, дота күр ани,
Бу күрәни зи-кү рани [77],
Идүбән хурлыкка алям.

Инзам — монда: бизәлгән, тезелгән.
Саут — аваз, тавыш.
Рәгъбәт — теләк, омтылыш.
Дөшнам — тиргәү, сүгү.
Дәф — шөлдерле барабан.
Танбур — кыллы уен коралы.
Дур — ерак.
Күрисәр сән зур — көч күрәчәксең.
Орыр зәнбур кеби алям — мәгънәсе: рәнҗүләр (чирләр) туптан аткан кебек сугар.
Заляләт далидер у сетан — мәгънәсе: адашу бәркетедер ул аздыргыч.
Хәзәр ... әйлә — саклан, сак бул.
Ирер игъләм — мәгълүм булыр.
Сур — сора.
Фәсакъәтдә вирүбән дур — мәгънәсе: бозыклыкта ерак китү белән.
Һода — хак юл, дөреслек юлы.

Делецне[78] әйләмә ачигъ,
Дилец һәм ацадыр ражигъ;
Әгәр вәгъзым исә нажигъ[79],
Сакыйн, дил әйләмә бәд-кям.

Сакыйнгыл, зиште зән улма,
Къәһер-лән моште зән улма[80],
Кешигә суэи-зъән кыйлма,—
Ки бәгъзе-л-зъәнн фискъ гъисйан[81]!

(VIII) Яман хатыннарның бәйане вә ирен рәнҗеткүчеләр

Кил, и талиб, кил, и гакыйль,
Яман зәндин хәзәр күп кыйл,
Яман хатыни зиндан бел,
Әгәрчә маһи, и инсан!

Яман хатын, яман гъәүрәт
Сиҗендә кичерә дәүрәт,
Кичә-көндез идеп җәүрәт,
Идәр әгъмарецн зиндан.

Әгәрчә ай ула күрке,
Аны бел дөнйаның кәрке,—
Кирәкдер әйләмәк тәрке,
Иллә алмаганың бәһ ан!

Яман зән агъзи вә ирне
Азар әйләдисә ирне,
Итисәр агъзилә тирне,—
Зәбани зәхм һәм дәндан.

Дилец һәм ацадыр ражигъ — куңелең һәм аңар (телеңә) бәйледер
Дил әйләмә бәд-кям — күңелгә начар теләк алма.
Зиште зән — начар хатын, әшәке хатын.
Къәһер-лән моште зән улма — каһәр (ачу) белән йодрык сугучы булма.
Суэи-зъән (зъәни) — яман уй, начар ният.
Бәгъзе-л-зъәнн фискъ гъисйан — кайбер ниятләр бозылык һәм башбаштаклыктан гыйбарәт.
Әгәрчә маһи — ай кебек (булса да).
Сиҗендә кичерә дәүрәт — мәгънәсе: төрмәдә эшләгәнен кабатлый.
Җәүрәт (җәүр) — җәбер, гаделсезлек.
Әгъмар — гомерләр.
Кәрк (гәрк) — ана бүре.
Бәһ ан — яхшырак.
Азар әйләү — рәнҗетү; көендерү.
Тир — ату, ук.
Зәбани зәхм һәм дәндан — сүз ярасы һәм тешләү.

Сөчеклек ләфзы берлән чүн
Ирен шад әйләсә хатын,
Бәкъадарны алып сатын,
Фәнадин әйләмеш һиҗран *.

Йөзендә күрки вә рәнги,
Әгәрчә бәччәи зән ки,—
Көнәш һәм ай дикен зән ки,
Бу нардан кем эрер, и җан!

Яман хатын ки ул мәзкүр,
На-мәхрәм [82] у на-мәстүр,
Иредин улса би-дәстүр,
Ирер дәхи зи-тогъйан.

Никү хатын, ки кыйлдык йад,
Иренә әйләдисә шад,
Һәзар[ан] афәриннәр бад,—
Ки ул хатын үзә һәр ан.

Заһир идән бә-на-мәхрәм
Исә күркәм дә сән күр кәм,
Делинең очы зәһәр-сәм
Исә улдыр сөке ниран.

(IX) Бу җиһанның тиз үткәне вә аңа мәгърур улмаслык

Вәфаны дотмайур фани,
Йилә чирмә тәләф ани [83],
Йөрәк каны белән къәни
Бөкя кыйлмак? къәни хөсран?!

---

* Мәгънәсе: мәңгелек йортны сатып алып, бетә торганыннан аерылу.

Сөчеклек ләфзы — тәмле тел (сүз).
Рәнг — төс, нур.
Бәччәи зән ки — баладай хатын.
Көнәш һәм ай дикен зән ки — кояш һәм ай диярлек хатын ки.
На-мәхрәм у на-мәстүр — намәхрәм ул, намуслы түгел.
Би-дәстүр — рөхсәтсез.
Никү — яхшы.
Һәзар [ан] — меңнәрчә.
Бад — булсын.
Сәм — агу.
Сөке ниран — углы кайгы (таяк).
Вәфа — тугърылык, ныклык.
Тәләф — әрәм-шәрәм.
Къәни — кайда.
Бөкя кыйлу — кайгыру, үксеп елау.
Хөсран — югалту, һәлак булу.

Къэни гөнаһенә ташып,
Къэни ник-эндишә талып,
Къэни ник-къэлебә калып,
Сәгадәтдә үтеп әзман?

Къэни Әхмәд, хәбибе Хакъ[84]?
Къэни чарйари, кани ракъ (?)[85]?
Әйдиләр катыйле фөссакъ,
Къэни һәм газый, ник-мәрдан?

Бу дөнйа дәхи бу дәри,
Һалякәт йарида бари[86],
Ки шәйтан җар улып җари,
Йөрер этрафыңа һәр ан.

Гизүбән ошбу дөнйани
Мәшәкъкатьләр беләп ани,
Ки хөсыль идәсән нани
Тәмам михнәт үзә, и җан!

Хәйердин ул дисә гәр буш,
Фикер кыйл гәр сәнең вар хуш,
Нә вар алмакда дәр-агуш
Фәуаид эстәйүб әз-фан?

Җиһанда килдеңез ирсә,
Базар дигән мәҗалисә,
Тушә чүн алубән кисә,—
Җәһед кыйл мәкъсадә, и җан!

Килеп алга гъәдү әхнас,
Идеп тәлбис, салыр вәсвас,

Ник-эндишә талып — яхшы уй, изге теләккә чумып.
Ник-къэлеб — яхшы күңел, изге рух.
Катыйле фөссакъ — гөнаһлы, намуссыз үтерүчеләр.
Газый — дин өчен сугышучы.
Ник-мәрдан — яхшы ирләр, игелекле затлар.
Дар — торган йорт-җир; ил, дәүләт.
Җар — күрше, иш.
Хөсыль иду — эзләү, теләү.
Дәр-агуш алмакда — кочакка алуда.
Фәуаид — файдалар.
Әз-фан — эз-фани· фани (дөнья) дан.
Мәҗалис — мәҗлесләр; җыелу урыны.
Кисә — капчык, букча.
Гъәду әхнас — ант бозган дошманнар.
Тәлбис идеп — алдап, хәйләләп.
Вәсвас — аздыручы, вәсвәсәләүче.

Тәмам дилләр уладыр къас,
Горурында улып һәр ан.

Агяһе улачак гяһи
Ләгъин Иблис ора раһи,
Дәйүр: «Йа сәүдаме хаһи?
Ашыкма»,— дир ләгъин шәйтан.

«Кичерер кич ирер әкнүн,—
Дәйүбән сезне көн-дәр-көн,—
Ки сәүда танда кыйлгайсән,
Ашыкма!» — дир ләгъин шәйтан.

Адәм гъәфләт үзә ятып,
Үлем киләдер уятып.
Әҗәл йайдин укый атып,
Һәмандәм къәсд итеп бәр-җан.

Үлем килеп, уладыр туш,
Фигъани адәм идә гуш.
Фигъан судсыз уладыр буш,
Кичәдер би-түшә гъөрйан.

Бөйлә халеңдер, и адәм,
Җиһан базарыйдыр гъәләм;
Ки ахыр күрәсән мадәм,—
Гъәрәт улдың ки сән дәр-ан.

Качан гъәфләтдә гъәф ләттә [87]
Табылгай эстәсә, әлбәттә,
Вәләкин ләттәи бәттә (?)
Никабын өртенеп һәр бан [88].

Къас — каси: рәхимсез, каты күңелле.
Агяһе улачак гяһи — кайчак хәбәр булачак.
Раһ ору — юл салу.
Сәүдаме хаһи — сәүдәме телисең.
Әкнүн — бүген.
Йайдин укый атып — җәядән укны атып.
Къәсд итеп бәр-җан — жанга явыз ният белән.
Туш улу — очрашу.
Фигъан — ыңгырашу, кычкыру, үкереп елау.
Гуш итү — ишетү, тыңлау.
Судсыз — файдасыз.
Кичәдер би-түшә гъөрйан — гәүдәгә ялан ачлык килә.
Мадәм — монда: чик, ахыр.
Гъәрәт улдың — таландың, бөлдең (беттең).
Дәр-ан — шул вакытта.
Гъәф ләттә — буш сүздә.
Ләттәи бәттә — мәгънәсез сүзләр.
Һәр бан — һәр күзәтүче, һәр сакчы.

Җиһанә йөрмә, мәргъүб йар,
Йөз әвер аңа — мәргъуб вар,
Сәнендик мәгъбуни күп вар,
Соңыйда улисәр пошман.

Йилә вирмә газиз әгъмар,
Ки шәйтан — мар кебидер мар,
Сәңа зәһәр салып, и йар,
Соңыйда уладыр хөсран.

Фәсадәтдә виреп рузгяр,
Гөнаһдин кыйлма шәб рузкяр,
Сәнендик бонда явызкяр,
Соңыйда улисәр гөрйан.

Бу дөнйа хәйредин гарый,
Эчидә тулы абзарый,
Һәзар егълата ба-зарый[89],—
Юк ирер качмакка имкян.

Имәс бу дөнйа на-дамәт,
Нийәт идүбән икамәт,
Дота күрмә рижа-дамәт,
Горурын әйләйүб һәр ан.

Әҗәлдә өнсе җан, җани,
Ки пәймани бәһ пәймани,
Ба-мани кежа мани,—
Мәкаме идүбән, и җан?

Җиһан ташдин хәзәф, белсәң,
Дилең бәрсәң, өзә бирсәң,

Мәргъүб — теләүче, үтенүче.
Мәгъбун — алданган.
Мар — елан; азгын.
Уладыр хөсран — һәлак булыр.
Рузгяр — чор, вакыт, язмыш.
Кыйлма шәб рузкяр — көндезне төн итмә.
Гөрйан — елаучы.
Гарый — буш; ялангач.
Абзарый — тәмле нәрсәләр.
Һәзар егълата — мең кат елата.
На-дамәт имәс — үкенерлек, кызганырлык түгел.
Икамәт — тору, яшәү; торган җир.
Рижа-дамәт — өмет-үтенеч.
Әҗәлдә өнсе җан — әҗәлдә җанның кыскалыгы.
Ки пәймани бәһ пәймани — кайсы гамәл башка гамәлдән яхшырак.
Ба-мани кежа мани — арып кайда туктарсың.
Хәзәф — чүлмәк; монда: катырак.

Җиһанны дотмака йөрсәң,
Имәс күркәм бу рай, и җан!

Җиһан бәд, җифәсендин туй,
Яңача гиз, сәйер сән куй;
Бакып күр: үре, сәрләр, күй
Кичеп — кидә йөрер кәрван.

Беләм дирсәң бу дөнйани,
Хәкъикәтдә ирер фани,
Фани сә, эстәмә ани,
Үзеңнең ахирың һәм фан.

Шәйатиндер хәсәд рани,
Йар, андин тотма йар, ани.
Дәхи һәм кыйлма җар ани,—
Мәкам әйлә аңа зиндан.

(X) Шәйтан адәмине үзенә мәгърур әйләгәне

Килеп алга гъәдү хасид,
Сиңа әфсад белән касыйд,
Сакыйн, алдамасын фасид,
Сәгадәтдин идеп гъәрйан.

Ки иблис мари, чөн мари
Аны, дуст, әйләсәң йари,
Ахир зәһәр салыр бари,—
Белерсәң, сахибе гъәрфан.

Гъәзазил [90] салмага тигъы
Йөрер, ба-хәрбе катыйгы,

Рай — фикер, уй-исәп.
Бәд — әшәке, начар.
Җифә — үләксә, мәет.
Сайер — йөрү, хәрәкәт.
Сәр — тау башы.
Күй — юллар.
Фан — чикле, бетә торган.
Хәсәд рани — көнчелекнең аягы.
Җар — күрше.
Гъәдү хасид — көнче дошман.
Әфсад белән касыйд — бозыклык белән үчлек итүче.
Гъәрйан — ялангач, шәрә.
Мар — елан.
Гъәрфан — акыл иясе.
Тигъ — кылыч, хәнҗәр.
Ба-хәрбе катыйгы — каты сугыш белән.

Өмидең әйлә катыйгы
Ки тәгъвиз иду бәр-йәздан.

Кичә-көндез ләгъин иблис,
Идеп вәсвас, салып тәлбис,
Горурда төземә мәҗлис,
Мәкам итмәк өчен дәр-ан.

Сагъәтең кичсә сагъәти,
Теләсәң фигъл тагъәти,
Кыйла та ул итагъәти,
Хакъ әмренә сонып гәрдан.

Шәйатин җәһд итеп кидә,
Идеп хәйлә, салып хәйлә,
Буйыныңа идеп сайдә,
Нийәтең итәдер ибталь.

Никүсә нийәте инсан,
Идә ибталь аны шәйтан,
Дәйүр: «Ашыкмагыл бу ан,
Һәнүз вакыт ула фи-л-халь».

Бу сүзләри идеп тәзкир,
Горурә әйләйә тәсхир,
Тагъәтдин идүбән тәзхир,
Идисәр гъәфләтә икъбаль.

Яман әфгале ул садә
Дөшергәй дәм-бә-дәм йадә,
Дәйүр: «И адәми-задә,
Зәһи ник дидекем әгъмаль!

Тәгъвиз — бөти, сихер кайтару чарасы.
Бәр-йәздан — аллада.
Тәлбис — алдау, хәйлә.
Дәр-ан — шул заман ук.
Гәрдан — муен.
Сайд — ау (элмәк).
Ибталь итү — юк итү, бетерү.
Никүсә (никү исә) — яхшы исә, игелекле исә.
Фи-л-халь — шул ук хәлдә.
Тәзкир итү — искәртү, кисәтү.
Тәсхир — сихерләү.
Тәзхир — кичегү.
Идисәр гъәфләтә икъбаль — ваемсызлыкка таба юнәлер.
Дәм-бә-дәм — әледән-әле.
Зәһи ник дидекем әгъмаль — кылырга мин әйткән гамәлләр бик шәп.

Кыйлачак ачыла деллəр,
Бөтə дилләр үзə гөлләр,
Нәчек гөл бөтерә чүлләр!»
Дәйүбән идисәр дуртал.

Йамак фикри күрүбән хуб,
Дилең аздырма, и мәхбүб!
Шәкъәуәт фикри салма күб,—
Әмәлларгә гамәлләр гъаль.

Гыйбадәт әйлә ба-ихлас,
Дога ит улубән кол-хасс,
Укыгыл фатихә ихлас,
Тагъәтдә идүбән икъбаль.

Шәйатинга күңел якма,
Аның хәйләсенә бакма.
Дамендин үзеңи сакла,
Делеңгә әйләмә иҗмаль.

Һуш илә хәмли забтъ итмәк —
Үзеңгә иртибат итмәк,
Нәчек ирер сыйрат үтмәк,—
Аның хәмлен идеп әхмаль?

Ләгъү-л-ләһү салып къәлбә,
Ләгъбдин дөшәсән ләгъбә.
Дөшәсән бер ахыр тәгъбә,
Улырсың дөнйада дәр-заль.

Бөтә дилләр үзә гөлләр — күңелләргә гөлләр үсә.
Бөтерә — үстерә.
Чүл — дала.
[illegible] — баш әйләндерү.
Әмәлларгә гамәлләр гъаль — гамәлләр өмет-теләкләргә чокыр ул.
Кол-хасс — чын күңелдән ходай колы.
Идүбән икъбаль — бәхет итеп.
[illegible] — [illegible].
Делеңгә әйләмә иҗмаль — телеңне кыскартма (?).
Һуш илә хәмли забтъ итмәк — йөкне акыл белән саклау.
Иртибат — якын итү.
Аның хәмлен идеп әхмаль — аның йөген үзеңә йөкләп.
Ләгъү-л-ләһү — мәгънәсез сүзләр, уен-көлке.
Къәлб — күңел, йөрәк.
Ләгъбдин ләгъбә төшү — уеннан уймак чыгу.
Тәгъб — михнәт.
Дәр-заль — адашучы, юлдан язучы.

Шәкъәуәт бадә сатасән,
Беләсән: зәхем дадәсән,
Мәбадә, калма бадә сән,
Итеп салып гъәля-л-эзлаль.

Ки шәйтан адәмә хөссад,
Сәне аздырмасын фөссад.
Ки гомрең вирмәгел бәр-бад,
Сәне алдамайа та ан.

Шәкъи афәтигә өфтад
Улубән, улмагыл мөгътад,
Ходага йадны кыйлгыл йад,
Аны үз белмәгел йаддан.

Улырсың къәдрең дана,
Һәлякәт салма сән жана,
Газиз дот жанынңи жанә,
Ничек къәумә газиз солтан

Диленңи салмагыл баля,
Ки шәйтан килеп ул халя,
Һәлякәткә сәне сала,
Ки шәйтан диленезгә хан.

Гъәдүгә сери баз итмә,
Шәйатин үзә раз итмә,
Гъәдүгә сер дираз итмә,—
Сәни жәзб идә бәр тогъйан.

Шәкъәуәт бадә(се) — бәхетсезлек шәрабы.
Зәхем дадәсән — авыру, чир бирәсең.
Мәбадә, калма бадә сән — мәгънәсе: зинһар, калма җилдә (бушлыкта) син.
Гъәля-л-эзлаль — үзе өчен тирән ялгышу.
Бәр-бад — җилгә.
Та ан — шул чакта.
Өфтад улу — хәтәр хәлгә эләгү.
Мөгътад улу — күнү, ияләшү.
Йад кыйлу — искә алу, зикер итү.
Йаддан үз белмәү — хәтердән аерым дип уйламау.
Дана — белүче.
Баля — югарыга, өскә.
Гъәду — дошман.
Баз итмә — ачып бирмә.
Раз итмә — серенне ярештермә.
Жәзб иту — җәлеп итү, тарту.
Тогъйан — фетнә, башбаштаклык.

Бу җиһан нәҗес мордардыр,
Эчидә фетнә пәрдардыр,
Әгәр ул фетнәле дардыр,
Сакыйн сән, дөшмәгел бәр-ан.

И җан, егъла Хакъка зар-зар,
Ки та күздин ака, йар, җар;
Фәнане куй, бәкадер дар,—
Кыйласән ахыры һиҗран.

Нә ятырсән бу гъәфләтдә,
Бәнем дик әшрари сохбәтдә?
Кидәрсән ахры рихләтдә
Бу җиһан даредин, и җан!

(XI) Хода юлында дуст дотмак эхәббә фи-ллаһи вә әл-бәгъзу фи-ллаһи [91]

Мәхәббәт әһленә тәргъиб
Идәсән нәфсеңи тәртиб,
Ки анлар сохбәте тәркиб,
Улыбдыр ник беләи иршад.

Никүләр сохбәте рухә,
Гъәзадыр җөмлә мәҗрухә;
Җәрахәтләр китә тухә [92],
Идәрсән сохбәтен мөгътад.

Мәхәббәт әһленә сохбәт
Идә күр анларга рәгъбәт;
Дин әһле бонда күп, әлбәт,—
Дотисәр яхшыдин дустан.

Пәрдар — күп, тулы.
Дардыр — тулы йорттыр.
Бәкадер — мәңгелек йорты, теге дөнья.
Әшрари сохбәтдә — бозыклар белән утырдашлыкта.
Рихләт — күчү, үлү.
Тәргъиб итү — омтылу, әсәрләндерү.
Тәркиб итү — төзү, билгеле максатка яраклы итеп төзү.
Иршад — туры юл.
Ник — яхшылык, изгелек.
Рухә — рухка, җанга.
Гъәза — азык.
Мәҗрухә — яралыларга.
Китә тухә — бетә, төзәлә.
Мөгътад — ияләшү, күнегү.
Рәгъбәт — теләү, ашкыну.
Дотисәр — тотар.

Рәндәи һәмнәшинне куй[93],
Ҡил,ултыр, кил, әйләә хуб руй;
Сәңа тәэсир идә хуб буй,—
Ҡирәк әгъйан, кирәк әлуан.

Фасикъә әйләмә рәгъбәт,
Заляләткә идә дәгъвәт.
Ҡи, зинһар, салмасын зәхмәт,
Шәйатиндик ирер дошман.

Гизәрди берәгү чүлләр
Юлыкды буйи хуш гөлләр.
Диде соң ул гөлә ул әр:
«Мөшек сән, йаки гөл-рәйхан?

Сәнең буйиң күреп дәр-ан,
Димагымга кереп бер ан,
Аның хушбуй нәсимендән
Улып китдем тәмам сөкран».

Диде: «Гөл ирмәзем — туфрак,
Вәли вар хушбуем дәр-хакъ,
Гөл иләнултырып анчак,
Бәңа тәэсир идеп дәр-ан».

Никүләри улың хастә
Идәрләр юлыңи растә.
Әгәр дилең исә хәстә,
Шифадыр сохбәте бер ан.

Ҡубачакдан къийамәтдә
Җәмигъе ошбу халәтдә,

Рәндәи һәмнәшин — бозык әңгәмәдәш, азгын юлдаш.
Хуб руй — яхшы чырайлы.
Хуб буй — яхшы ис, хушбуй.
Әгъйан — аксөякләр, затлылар.
Әлуан — төрле төсләр.
Дәгъвәт — чакыру, өндәү.
Буйи хуш — хуш исле.
Әр — ир, ир кеше.
Мөшек — миск (мускус).
Дәр-ан — шунда, шул вакытта.
Димагъ — борын, сулыш юлы.
Нәсим — йомшак җил.
Сөкран улу — исерү.
Дәр-хакъ — хәкыйкатьтә.
Никүләри улың хастә — яхшыларны теләүче булыгыз.
Растә — дөрес.

Кубар мәгъә-л-муалятдә
Кирәк иршад, кирәк тогъйан.

Нәчек зәне Лутъи, Нухи [94],
Бәдандин йар дотып шухи,
Тигеп димагына кухи,
Иденер улдылар көфран.

Зәне Нух һәм зәне Лутъи
Шәйатиннең иде сәутый,
Җәһәннәмнең дотып утый,
Тәмугъ эчрә мәгъә-ш-шәйтан.

(XII) Явызлар берлә сохбәт итмәслек эл-бәгъзы фи-ллаһ тәрикынча [95]

Кил, и мәхбүб, кил, и садикъ,
Бәди күрмә йара лаикъ,
Мозыйлль ула сәни баикъ
Идәрсәң анлари әсхаб.

Җиһанда күп шәкъи әҗсад,
Әйде сәрникләри әфсад,
Дәхи күп вәҗәдалар шад,
Ки мослихләр улып әсбаб.

Сәгъидләрә рәфикъ улгыл,
Йәтимләрә шәфикъ улгыл,
Аларның хатирен соргыл,
Идүбән шәфкъәт, и әфтаб!

Мәгъә-л-муалятдә — дуслыкта, бергә-бергә.
Зән — ир хатыны.
Бәдан — яманнар.
Кухи — сасы ис.
Сәут — камчы.
Мәгъә-ш-шәйтан — шайтан белән.
Садикъ — тугъры кеше; турылыклы (аллага).
Бәди — явызны.
Мозыйлль — юдан яздыручы.
Баикъ — ачык, анык.
Әсхаб — шәкерт, дус.
Шәкъи әҗсад — азгын кешеләр.
Әйде сәрникләри әфсад — яхшы башларын бозык итте.
Вәҗәда — вөждан.
Послих — үзгәртү, яхшырту.
Сәгъидләрә рәфикъ — бәхетлеләргә иптәш, иш, дус.
Шәфикъ — шәфкатьле.
Хатир — хәтер.
Әфтаб — кояш, кояш нуры.

Рәндәи һәмнәшинин куй,
Кил, утлыр, гөл илән хуб буй,
Сиңа тәэсир идә хуб буй,
Ничек тәэсир идә гөляб.

Иөремә рәндәләргә күп,
Алардин дури киткән хуб,
Килүрсә, башыйа ор чүп,
Вәли худ чикмәсен бәр-наб (?).

И җаным, дыңла әз-әүбаш
Кача күр, качмакыңда — баш,
Башыңа ормасын та таш,
Сакыйнгыл, гәр уласың шаб.

Ул әүбаш хәйлә дәр-пиш,
Улып дәрвиш, салып сәр-пиш,
Күрәлмаз лик сөляси хиш,
Вәли салмак деләйүр наб.

Ишедеп кач боны, и йар,
Алардин бары китеп вар.
Барыдин качасән, зинһар,—
Барының юлына әз-баб.

Мөнаҗат кыйлмакка ба-дир,
Дигел: «Йа, һәрнийә кадыйр,
Ерак кыйл әһле әфсад ир,
Дигел, һәм кыйлма, дип, әхбаб.

Явызлардин улың фаригъ,
Ишикен улма һәм къаригъ,
Никүләр юлына шаригъ
Уласән, тарехе әтраб».

Гөляб — гөл суы.
Дури киткән — ерак киткән.
Вәли худ — яки үзе.
Әз-әүбаш — сукбайдан, хулиганнан.
Шаб уласың — егет булырсың.
Дәр-пиш — алдында, алда.
Сәр-пиш салып — башны түбән салып.
Лик сөляси хиш — мәгънәсе: ләкин үзе өч (кешегә) тора.
Наб салмак — теш салу, тешләү.
Әз-баб — ишектән, капкадан.
Кадыйр — көчле, кодрәтле.
Әхбаб — дуслар, сөйгәннәр.
Фаригъ — азат.
Къаригъ — сугучы, шакучы.
Шаригъ улу — башлаучы булу.
Тарехе әтраб — мәгънәсе: шатлык бирүче (башкаларга шатлык еләшүче).

(XIII) Нәфес артындин йөрмәк вә тәмгъ дотмак бәйане вә жиһани диләмәк

Тәмгъ кыйлма кешедин, дуст,
Бергәгү тәмгъ кыйлса уст,
Кыйамәтдә кубар би-пуст,
Улубән халкъ ара рисвай.

Тәмгънең хәрфе вардыр сәһ [96],
Фәуаиддин өчи дә тәһ,
Бәс аны тәрек кыйлмак бәһ,
Дәхи табигъенә күб вай.

Һәуага улубән табигъ
Ки зәррә дотмагыл тамигъ,
Хакъың вирдекенә канигъ
Улыр ирсәң, уласән бай.

Гидадер кемки хирсъ итсә,
Күңел зәһб-у-физза итсә,
Әгәрчә фәлси хирсъ итсә,
Хирсълыкда салыпдыр пай.

Тәмгъдин улынан нани,
Әгәрчә әз-у йимәни;
Вәли күп ула ямани
Соңыдин кем пәдид улгай.

Нәфес берлән рәуан улма
Һәм артындин дәуан кыйлма,

Тәмгъ — ачкузлелек, комсызлык.
Уст (у әст) — улдыр.
Би-пуст — тиресез, шәрә.
Сәһ — өч.
Фәуаиддин өчи дә тәһ — файдалан өчесе дә түбән.
Табигъенә күб вай — буйсынучыларына (тәмгъ колларына) күп вай-вай (булыр).
Һәуага табигъ — тәкәбберлеккә буйсынучы.
Тамигъ — ачкуз, комсыз кеше.
Гидадер — гидайдыр; ярлыдыр.
Зәһб-у-физза — алтын һәм байлык.
Фәлс — тәнкә, вак металл акча бирәмлеге.
Хирсълыкда салыпдыр пай — хирыслыкта мәңге калыр.
Нани — ипинне, ипине.
Әз-у — аннан, аңардан.
Пәдид — ачык, күренеп тору.
Рәуан улма — юл башлама.
Дәуан кыйлма — йөгереп барма.

Вәкадә дип гөман кыйлма,—
Әгәр сәндә исә хуб рай.

Нәфес этдер, белең аны,
Йоларсың ничә ел аны.
Нәфес — дошман, ки бел аны,
Гъәдуләрдин нәфес — шәйтан.

Нәфс нәфсе артыдин йөрсә,
Йимәк-эчмәк-лә симерсә,
«Ари!» — дир һәрнәи күрсә,
Ки һәргиз улмайа шәбган.

Симертсәң аны, димешләр.
Котырып, күп фөссад эшләр.
Яман тешләр белән тешләр,
Килеп сөкран, килеп сәг ран.

Кеше гәр ихтийар салгай,
Зәмамин үзе эт алгай.
Котырып котылып варгай,
Фәсадәтдә улып фәрхан.

Нәфесең халенә гүш сал,
Симертерсәң дәйүр: Хушхаль;
Әгәр син вирәсән күш мал,
Халем тин, дир, бә-дәр-зиндан.

Ойып бу нәфсенең чәнгә,
Дәйүр тәңкә, төшеп тиңгә.
Дәригъ! Гомре газизеңгә,
Ки заигъ уладыр әзман.

Вәкадә — монда: дәртлелек (якты йолдыз).
Рай — уй, фикер.
Ари — әйе.
Шәбган улмау — туймау, артыгы белән ашау.
Сөкран — исерек; котырган.
Сәг ран — эт боттан (тешләү).
Зәмам — тезген.
Фәрхан улу — сөену, шатлану.
Гуш салу — колак салу.
Күш — күч (*куча* — русча).
Халем тиң, дир, бә-дәр-зиндан — хәлем зиндандагы белән тиң, дияр.
Чәңг — тәпи, бармакларын тырпайткан кул; монда: тырпаклар.
Төшеп тиңгә — тарлыкка төшеп.
Дәригъ — аяныч, үкенеч.

Гъәҗүзи зән ки бу дари,
Бизәнеп зиннәти дари,
У къари һәркеми карый,—
Һәлякәтдә виресәр җан.

Къарилыкда бизәнүбән,
Җәуан кеби дөзәнүбән,
Йөрер сәни күзәдүбән,
Һәляк итмәк өчен бер ан.

Деләр бер көндә бер ирне,
Деләйүр танда — дигәрне,
Юк идә, сачу зәһәрне,—
Кичәрдер даре дөнйадан.

(XIV) Ходаның рәхмәтендин өмид итмәк вә газабындин курыкмак, фи-бәйани риҗаә вә гафу мин-аллаһи [97]

Хода рәхмәтедин, йаран,
Уласызлар риҗадаран,
Ходаның хәуфилә күздин
Дүгәсез аби чү баран.

Ширеклек кыйлма дәр-синнә,
Күнел сабак дәресенә,
Йөкерлек (?) дотма һич кинә,
Хөседлек кыйлма һәм, и җан!

Уян гъәфләтидин шәбе хиз,
Сәхәрләрдә дога кыйл низ,
Фәсадәт куй, улып тәбриз,—
Ничек баран идәр сәйлян.

Гъәҗүзи зән — карт хатын, кортка, убырлы карчык.
Дар — дөнья.
У къари — ул карт.
Җәуан — яшь кеше, егет.
Дигәр — бүтән, икенче.
Даре дөнйа — бу дөньялыктан.
Йаран — дуслар.
Риҗадаран — үтенүче, сораучы.
Дүгәсез аби чү баран — суны (күз яшен) яңгыр кебек түгәсез.
Ширеклек — күп аллалык, күп аллага ышану.
Дәр-синнә — яшьлектә.
Шәбе хиз — сикереп тор; йокыдан тор.
Низ — шулай ук.
Фәсадәт куй, улып тәбриз — бозыклыкны ташла, юып чыгар.
Ничек баран идәр сәйлян — яңгыр ташкындай юган кебек.

Хода хәуфилә дук йәшләр,
Ничек ташлар сулар ташлар,
Ки ахир бу гъәриб башлар
Рөҗүгъ идә Хакъка, и җан!

Ходаның хөкеменә маша,
Риза ул, әмри дот баша;
Ахир кол уласән хаша,
Имәссән фагъиле әкүан (?).

Кичә-көндез хәтәрләрдә,
Дога әйлә сәхәрләрдә,
Хәтәр күпдер бәшәрләрдә,
Мәгәр хифз идә ул йәздан.

Догада егълагыл Хакъа,
Күзеңдин та сулар ака,
Шайәд Хакъ рәхимлә бака,
Ки у зә-л-гъизз вә-л-гъифран,

Мөнаҗәт даимән сән ар,—
Ходага егълагыл зар-зар,
Күзеңдин йәш идеп иншар,
Нитә кем дукелә баран.

Идеп тәүбә мин-әл-батыйль,
Ки егълап аб ула та сил,
Ничек ягъмур ула һатил,
Әбр дәр-фасле бәһаран.

Рөҗүгъ идә — мөрәҗәгать итә.
Маша — шөкер; яхшы.
Хаша — алла саклап.
Бәшәр — адәм балалары.
Хифз идә — саклый, яклый.
Йәздан — алла, тәңре.
Ки у зә-л-гъизз вә-л-гъифран — ки ул кодрәт иясе һәм кичерүчән (гафу итүчән).
Ар (аүәр) — башкару.
Иншар иту — сиптерү.
Баран — яңгыр.
Мин-әл-батыйль — ихлассызлыктан, ялганнан.
Аб — су.
Сил — ташкын.
һатил — көчле яңгыр, коеп яуган яңгыр.
Әбр — болыт.
Бәһаран — яз көне.

Идәсән тәүбә бәр-йәздан,
Рөҗүгъ ит, җөмлә яуыздан,
Ки гыйбрәт ал бу гаҗиздән,—
Кичә-көндез улып тогъйан.

(XV) Әнуагъ йимешендән ихтираз әйләмәкнең бәйане

Нәмимә кыйлма, и әфтаб,
Йөремә улубән мөгътад,
Димәгел һич кемә әлкъаб,—
Хәрам дир айәте Коръән.

Ишедерсәң әгәр дастан,
Дөругъмы ан вәй йә раст ан?
Дәйүбән идүбән [98] тәфтиш,
Йөремә багъ илән бостан.

Фәсадәткә дилең вирмә,
Шәкъәуәтлек беләи йөрмә,
Сәнендик бонда күп әбләһ,
Соңы әз-ан [99] улалар хөсран.

Җәмигъен гъәбн идеп мәлгунь,
Улыплар көллесе мәгъбүн.
Соңида улдылар мәймүн,
Шәйатингә улубән дан.

Телең бер сүзгә фәкк итмә,
Булып нәммам тәбек [100] итмә;
Кеше гайбен һәтек итмә,—
Хәрам эш, беләсән, и җан!

Әнуагъ — төрле, һәртөрле.
Ихтираз — сак эш итү, тыелу.
Нәмимә — яла.
Әфтаб — кояш нуры.
Мөгътад — күнеккән, гадәтләнгән.
Әлкъаб — кушамат, ләкаб, мәсхәрәле исем.
Дөругъ — ялган.
Тәфтиш — тикшерү.
Әбләһ — ахмак.
Әз-ан — моннан.
Гъәбн идеп — алдап.
Көллесе — һәммәсе.
Мәгъбүн — алданган.
Дан — жим, алдавыч жим.
Фәкк иту — чишү; ачылу.
Нәммам тәбек итмә — гайбәтче булып йөрмә.
Һәтек иту — тарату, мәсхәрә итү.

Ки булма дилдә бер гизләп,
Хәрамә йөрмәңез сез һәб,
Нәмимә-гайбәт сүзләп,
Йөремә соң улып хөсран.

Кешене әйләмә тәхкъир,
Дотар ул гәрчә бең тәкъсыйр,
Нә кыйлсын бөйләдер тәкъдир,
Хода салмыш бөйлә әгъйан.

Шөкер кыйлварына һәрдәм,
Сабыр кыйл юк үзә сән һәм,
Сәнендик дөнйада кем кәм? —
Хирыслыкда вирисәр җан.

Хода нигъмәтенә шакир
Уласән, даимән закир,
Идисәр нигъмәти пакь ир,
Дәхи артык идә йәздан.

Берәгү тәрк идеп шөкран,
Идәрсә нигъмәтә көфран,
Ходаем къәһр итеп аңа,
Идисәр нигъмәтне нокъсан.

(XVI) Кешегә вәгъәз әйләмәк — әмре мәгъруф кыйлмаклык

Кешегә вәгъәз кыйл, мәүгъиз,
Нәсыйхәтләр идеп тилмиз.
Т..ляттыйфлык белән тәлфиз
Идәсән һәр кемә, и җан!

Бөйлә дә улмаса тәэсир,
Такъәтенчә идеп тәзкир,

Гизләү — яшерү.
Тәхкъир әйләү — хурлау.
Тәкъсыйр — кимчелек, гаеп.
Бөйлә әгъйан — шулай билгеләнгән.
Шакир — шөкер итүче.
Закир — исендә тотучы.
Нигъмәтә көфран — нигъмәткә көфер итү, күргән яхшылыкның кадерен белмәү.
Нокъсан идисәр — киметер.
Әмре мәгъруф — белем тарату.
Мәүгъиз — вәгазьче.
Тилмиз — шәкерт, укучы.
Тәляттыйф — хуш һәм яхшы мөгамәлә, яхшы сүз.
Тәзкир итү — үгетләү, туры юлга дәшү.

Соң әйтмә: «Ник сүзе тәбзир[101],
Эремәз боз, диген, ташдан?»

Мих орубән катигъ сәнггә,
Вара дип дөшмәгел тәнггә,
Бөйлә вәгъзи би-нам нәнггә[102]
Ки зәррә вармайа, и җан!

Зәмине шүрәгә[103] сөнбел
Бөтәр дип аймагыл сән гел,
Төхем салма аңа сән, бел:
Ки заигъ уладыр төхм ан.

Ачигъ йирдә бәтә бум-хас[104],
Вә шәүкәдик, хашәк дик бәс[105],
Шунын дикен сәхтедил кәс,
Көдүрәтләр бөтәдер ан.

Ачигъга салу гөл төхмен,
Гөл алмак әйләмә тәхмин,
Зирагъәтнең чигеп зәхмен,
Кичермә бөйләдә дәүран.

(XVII) Пирлек вә къарилык вакытындагы хәлләр вә нәсыйхәтләр

Кил, и къари, вакыт бик тар,
Даимән зәгыйфлек артар,
Фәналеккә сәне тартар,
Кичә-көндез китеп дәрман.

Ник сүзе — яхшы сүзе.
Тәбзир — күп, артык, исраф.
Мих — кадак.
Сәнг — таш.
Тәнггә дөшмәгел — тарлыкка төшмә.
Би-нам нәнггә — хурланган затсыз җаннарга.
Зәмине шүрә — тозлы туфрак.
Төхем — орлык.
Ачигъ — ачы.
Бәтә бум-хас — усә чүп-чар.
Шәүкә — чәнечкеле үлән.
Хашәк — чыбык-чабык, чүп.
Сәхтедил кәс — каты бәгырьле кеше.
Көдүрәт — кайгы-хәсрәт, уңайсызлык.
Тәхмин әйләү — чамалау.
Зирагъәт — игенчелек.
Зәхмен — хезмәтен, азабын.
Пирлек вә къарилык — картлык, олыгайганлык.
Фәналеккә — бетүгә, юк булуга.

Акарды сакалың, башың,
Саны йөзгә йитеп йәшең,
Ки вармы дүгелән йәшең,
Идеп тәүбә мин-әт-тогъйан?

Вәләкин ки бу хиндә,
Чыкыбдыр халкың эчендә,
Тәфахер йәш белән сини дә
Улып гами ара, и җан!

Гаҗәбдер бәгъзы ул гами,
Йәшенең куплегегәми,
Дәйүр: «Гомрем-фәлян гали
Улубән, къари ник мәрдан».

Дәйүр: «Бонча гомер сөрдем,
Бу кадәр йәш гомер күрдем,
Бихәмдиллаһ, бәнем гомрем
Тәмам йөзгә йитәр бу ан».

Ки вармы кыйлдыкы тагъәт
Бу йәш эчрә нисъфе сагъәт?
Вәли үтмеш улып тагъйәт,
Кыйлубән фосыкъ вә гъисйан?

Тагъәте юк, гөнаһы чук,
Йәш артыгы имәс артык.
Алыр аз гомредә артык
Сәгадәтдә исә дәүран[106].

Бәһаимдик йимәк-эчмәк,
Гъәми йәшдин йәшә кичмәк,
Гъәми нәфсе морад гизмәк
Имәслек тагъәти йәздан.

Мин-эт-тогъйан — бозыклыклардан.
Хиндә — вакытта.
Тәфахер — дан, горурлык.
Сини — монда: олы яшьле.
Гами — гади халык, кара халык.
Ник мәрдан — яхшы егет.
Бихәмдиллаһ — аллага шөкер.
Тагъәт — гыйбадәт кылу.
Нисъф — ярты.
Улып тагъйәт — һәлак булып.
Исә дәүран — яшәсә.
Бәһаимдик — хайван кебек.
Гъәми — сукыр (монда: мәгънәсез, максатсыз).

Мәгасыйдин әгәр пакь сән,
Әгәр йәк санда сән йәк сән,
Никү мәрдан илән йәксан,
Идәрсәң даимән ихсан.

Зә-ник мәрдан улыр мәрд ан,—
Бизәр ул җөмлә әшрардан.
Егерме йәш илән артык
Ула йөз еллык әгъмардан.

Ки белмәз микъдарын, урнын,
Борынгыйәм дәйүб, борнын
Күтәреп йөрийүр къәрнин,
Имәсдер фигъле әбрардан.

Үзеңи даим әндәк гир,
Тәкәббер әйләмә, фәккир,
Шәйатин халене зәккир.
Ничек мәлгун улыбдыр ан.

Нәфесендә исә фаслең
Үз-үзең белмәгә къәсдең;
Карасаң, кырасың аслең,
Адәм гаит идәр бер ан.

Икенче аслең — нөтфә,
Дөшисәр әз-сәр къәлфә [107].
Мәкянең бәүл үзә тәлфә [108]
Хөруҗең һәм ирер әз-ан.

Мәгасый — гөнаһлар.
Әгәр йәк санда сән йәк сән — әгәр бер санда син бер генәсең.
Никү мәрдан илән йәксан — яхшы егетләр белән бер тиң син.
Зә-ник (әз-ник) — яхшыдан.
Мәрд ан — нәкъ шул ир ки.
Бизәр — качар.
Әшрар — начар, усал кешеләр.
Әгърардан — гомерләрдән.
Борынгыйәм дәйүб — борынгыдаймын диеп.
Күтәреп йөрийүр къәрнин — күтәреп йөрер гомер буе.
Әбрардан — изгеләрдән.
Әндәк гир — кечек тот.
Фәккир — фикерлә.
Зәккир — исеңә төшер.
Къәсдең — теләгең, омтылышың.
Гаит идәр — эчендәге бушатыр.
Нөтфә — тереклек орлыгы, нәсел орлыгы (мәни).
Дөшисәр әз-сәр къәлфә — әгъза башыннан йозакка төшәр.
Бәүл — бәвел, сидек.
Хөруҗең һәм ирер әз-ан — чыгуың да шуннан була.

Дорып бәүл мәкянендә,
Һаман нөтфә зәманында,
Ничекдер ошбу анендә,
Тәкәббер ула чөн шәйтан?!

(XVIII) Бу җиһандан гъәфләт эчендә иркән әҗәл килгәне

Хәмакъәт арканын чолгап,
Йөгердең дөнйаны болгап,
Кил, имди ахир, эшең тап,
Дөшәр сәфәр сәнең дәр-раһ!

Гөнаһең күп — имәс сани:
Юарга тәүбәләр къәни?!
Деләрләр алмага җани,—
Ки бу хиндә дәхи бу гяһ.

Китәсән бер ерак юла,
Азыкың вармыдыр кула?
Төшәсез, халь ничек ула?
Белерсең ани, и дөрлаһ!

Кеме боны горур тукый,
Әҗәл укы килер укый.
Белерсән форсатың юкый,—
Нимә алданасән, и маһ?!

Иман ауәр кичәләрдә,
Сәнең дикен ничәләр дә
Кичәләрдә кичәләр дә,
Ки һиҗрәт берлә чук инсан.

Җиһани кичәсән күфрек,
Бөтек андин улып йөгрек,
Сәнендик дәхи дә йөгрек,
Кичисәр ахры, и җан!

Хәмакъәт — ахмаклык.
Дәр-раһ — юлга.
Къәни — кайда.
Хин ... гяһ — вакыт ... чак.
Дөрлаһ — шаяручы, юк белән вакыт уздыручы.
Нимә — нәрсәгә, нигә.
Маһ — ай.
Иман ауәр — иман китер, ягъни: иман белән бергә бул.
Һиҗрәт — күчеп киту.
Күфрек — күпер.
Бөтек — язу (бөти), язмыш язуы.

Сәба йиле килеп һәббәт,
Нә вар наим күреп һәйбәт,
Бу гәз сәңа килеп нәүбәт,
Ки тәнһа калма сән дәр-фан.

Идеп гъәфләт шәрабен нуш,
Нигәчә ятасән мәдһуш? —
Күзең ач, бакыйбән күр уш:
Кичеп кәрван варадыр ан.

Ки булма мала бу малә,
Сәне салган зәгъиф халә,
Соңы хәсрәт белән налә,
Ки әсыйгъ кыйлмайа, и җан!

Сәнеңдик бонда күп йөгрек,
Дәхи сәндин дә һимматрәк.
Идеп һиҗрәт, улып әтрәк,
Җиһани идүбән һиҗран.

Җиһанда зән дә һәм ир дә —
Фәнасез калмайа бер дә,
Соңы — әҗсад кара йирдә —
Ятисәр кийубән әкфан.

Къәни ул дөнйадар анлар:
Къәни әүүәлге йаранлар?
Җиһандин китде, йар, анлар,—
Идәрсең бу сүзә әйкан.

һәббәт — исү, акрын исү.
Наим — йокыдагы кеше, йоклаучы.
Гәз — кат (бу юлы).
Тәнһа — бер ялгыз.
Дәр-фан — фани дөньяда.
Нуш иту — авыз итү, эчү.
Мәдһуш — һушсыз.
Мала — малай (?); йөк ташучы хайван дип аңларга да була.
Малә — малга.
Налә — елау, ыңгырашу.
Әсыйгъ — файда, ярдәм.
һимматрәк — тырышрак.
Улып әтрәк — ташлап китүче булып.
Зән — хатын-кыз.
Фәнасез калмайа — юкка чыкмый калмаячак.
Әҗсад — тәннәр, гәүдәләр (ягъни мәетләр).
Әкфан — кәфеннәр.
Дөнйадар анлар — дөньяны тотучы заманнар.
Әйкан иту — ышану, дөреслеккә алу.

Нә кем вар дөнйада дәри —
Кирәк адәм, кирәк пәри,—
Әбәд калмайа һичбери,
Үлем күрмәй вә улмай фан.

Къәни шаһлар, къәни ханлар? —
Җиһанда ирделәр анлар,
Къәмусы вирделәр җанлар,
Чизи алмадылар әз-ан!

Къәни ул сәййеде гъәлям [109]?
Къәни ул атамыз Адәм [110]?
Къәни Шиш, Нух һәм мадәм? —
Къәмулары виребдер җан!

Къәни Дауд, къәни Идрис,
Къәни Хәууа, къәни Чәрҗис,—
Киеп әкфан — киеп мәлбис
Җиһандин китделәр, и җан!

Къәни Исхак, къәни Йагъкуб?
Къәни Йосыф, къәни Әййүб?
Къәни Йәхйа? — һәммә мәгъйүб;
Җиһандин китде һәм Лөкъман.

Къәни Муса, къәни Һарун?
Къәни Фиргъәуен вә Къарун [111]?!
Ходa күчәр кыйлып барын,
Мәканә һәрберен һиҗран!..

(XIX) Җан алынган вакыт вә әҗәл килгәне

Ятыркән бонда ба-гъәфләт,
Оралар чүн күсе рихләт [112],

Дәри — тау эраларында, дала-уйсуларда терсклек итүчеләр.
Әбәд — мәңге.
Чизи алмадылар әз-ан — бернәрсә дә алмадылар шуннан (милекләреннән).
Мадәм — хәзергә; монда: кайсылар.
Къәмулары — һәммәләре, барчасы.
Мәлбис (мәлбәс) — кием-салым.
Мәгъйүб — юкка чыккан, гаиб булган.
Ятыркән — ятыр икән.
Мәкян — урын.
Ба-гъәфләт — гъәфләт белән; ваемсыз.
Күсе рихләт — күченү быргысы.

Качан анда вирә миһләт,
Ки нәфәс алмага ул ан.

Ула шадлык гъәмә тәбдил,
Үкенечләр белән тәзлил,—
Бәс, укы шәһадә, тәһлил [113],
Чыкарга җан идә җәүлан.

Чү, Гъәзраил кәлисәр зуд,
Фөган иделә бә-фәрсуд,
Фөган һич кылмайдыр суд,—
Гъәҗәб гъәмдер, гъәҗәб хөсран!

Һәммә кыйлмыш килә йадә,
Фөган идә адәм-задә,
Җәһед әйләмәдем задә,—
Китәрне белмәдем бу ан.

Бу сәкяратда китеп дәрман,
Килә хәйлә белән шәйтан,
Имана уладыр касыйд,
Тәмам хәйлә идеп җәрйан.

Зәһи ник, гәр иман таза,
Сәлямәт килдисә җәза,
Нәгъүзе биллаһ, гәр фаза,
Имандин идисәр гъәрйан.

Җиназә иденеп мәркәб,
Ләхедкә уласыз мәҗзәб [114],

Миһләт бирү — срогын кичектерү.
Нәфәс — сулыш.
Гъәмә тәбдил — гамьгә, кайгыга алмашыну.
Тәзлил — хурлану, кимсенү.
Җәүлан итү — бөтерелү, газаплану.
Зуд — тиз.
Фөган — кычкыру.
Бә-фәрсуд — газапланып, әлсерәп.
Суд — файда, чара, әмәл.
Задә — монда: туганнан бирле, һич тә.
Сәкярат — үлем газабы, җан бирү газабы.
Касыйд — үч тотучы, канызучы.
Җәрйан — эш барышы.
Зәһи ник — нинди яхшы.
Нәгъүзе биллаһ — алла сакласын.
Гәр фаза — курыкса.
Гъәрйан — ялангач, буш.
Мәркәб итену — монда: күтәреп илтеп кую
Мәҗзәб — тартылу.

Керем ханәи тәнһа һәб,
Калып әгъмаль илән дәр-ан.

Ятыркән бәйте вәхшәтдә,
Кәлле җан ула хәсрәтдә.
Нәгяһан, килә һәйбәтдә
Ике мөнкир [115] мәгъә-л-гъәйран.

Бәркъ дикен килә йөгрер,
Ауазы чү рәгъд күкрер.
Сәрасимә улисәр дәр-гүр,
Күрәчәк каладыр хәйран.

Бу һәйбәтлек белән ду йар
Ауази идә зәр дубар.
Сөаль үзрә җәуаби ар,
Күр ауаз ул, къәйу дастан!

Бу һәйбәтлек белән баша
Гакыл йар улмайа, шаша,
Тәмам хәйран ула, хаша [116],
Ходадин хашә [117] һәр инсан.

Сөалидә җәуаб эстәр,
Җәуаби ба-сауаб күстәр,
Вирерсәң, уласән рәстәр
Боларның хәүфедин асан.

Җәуаб вирсәң, мәкам ул ан
Улисәр раузаи ризван;

Ханәи тәнһа һәб — ялгызлык йорты.
Әгъмаль — гамәлләр, кылган эшләр.
Бәйте вәхшәт — вәхшәт йортында.
Һәйбәтдә — куркыныч кыяфәттә.
Мәгъә-л-гъәйран — аерылып тора торган билгеләр белән.
Бәркъ дикен — яшен шикелле.
Чу рәгъд — күк күкрәве кебек.
Сәрасимә — гаҗәпләнгән, исе киткән.
Дәр-гүр — гүр эче.
Һәйбәтлек — куркыныч.
Ду йар — ике дус (ягъни Нәкир һәм Мөнкир).
Дубар — икенче кат; тагын.
Җәуаби ар (ауәр) — җавап бар.
Хашә — курка.
Ба-сауаб күстәр — дөрес, тугъры күрсәт.
Рәстәр — котылган, азат ителгән.
Мәкам ул ан — ул чакта урынлы.
Раузаи ризван — оҗмах куанычлары.

Шашасың гәр җәуабында,
Улисәр атәши ниран.

Улырсың салихе мәсгъүд
Җәуабың вирисәр сән зуд,
Җинанда жайыңи нәмүд,
Бу ике йар, китеп андан.

Ике Мөнкир хәнүс әйләр [118],
Мәками Хакъ шәмүс [119] әйләр,
Һаман нәүми гъәрус әйләр,
Къыйәмәткәчә ул инсан [120].

Сөаль гәр улса бәдбәхтә,
Җәуаб идәлмийа пөхтә,
Вара кяри катигъ — сәхтә,—
Вәсъфда къәсыр ирер әзһан.

Болар утлыгъ гъәмүд илән,
Орып тәгъзиб нәмүд илән,
Һаман атәше руд илән
Дулар къәбр эчидә ул ан.

Тәмам къәбер аңа закъәт
Ауазы идә би-такъәт,
Ишедә җөмлә мәхлукат,
Мәгәр ки җен белән инсан.

Боны парә-парә орып,
Бу ике йар китә дорып —
Тәмугъдин жайыны күреп,
Ула таңгача дәр-хөсран.

Атәши ниран — тәмугъ уты.
Салихе мәсгъүд — бәхетле изге җан.
Зуд — тиз.
Жайыңи нәмуд — урыныңны күрсәтер.
Хәнүс әйләр — кире китәр.
Мәками Хакъ шәмус әйләр — ул урынны ходай якты итәр.
Нәүми гъәрус әйләр — йокыны кәләш итәр.
Кяри — эше.
Сәхтә — кыен, авыр.
Вәсъфда къәсыр ирер әзһан — тасвирларга зиһеннәр кыска булыр.
Утлыгъ гъәмуд илән — утлы кисәү белән.
Тәгъзиб нәмуд илән — газап күрсәтү белән.
Атәше руд — ут ташкыны.
Закъәт — тар, кысынкы.
Би-такъәт — чарасыз, сабырсыз.
Дәр-хөсран — һалакәттә.

Бу нә шиддәт, бу нә хурлык?
Ула көн-көн хәүеф артык,
Къәбер һәм уладыр заййикъ —
Кабыргасы идә хилт ан.

(XX) Фәнаи дөнйа фи-ахире-з-заман вә бяла [121]

Фани бу дар йәкъин улды:
Фәналеккә якын улды,
Качан ахыры ин улды —
Ула дөрле зоһурийат.

Диләсә Хакъ бу дөнйани,
Ки фани кыйлмага ани —
Ула тизлек үзә фани,—
Ничек әмр идә ул сәрват.

Чү! Исрафил [122] чаладыр сур,
Уладыр йир вә күкләр һур [123],
Хәлаикъ уладыр һәм бур [124],
Уладыр көллесе әфуат.

Һаман күкләр дәхи йирләр,
Бозыла баля һәм зирләр,
Бозылып, чү рәгъдгирләр
Вирә һәйбәт үзә асуат.

Җәмигъ мәхлүкъ ишедеп бух,
Һәммә әнфас ула мәҗрух,

Шиддәт — көч, басым.
Заййикъ — *тар,* тыгыз.
Хилт итү — ботарлану.
Йәкъин — анык, ачык, һичшиксез.
Ин — бу.
Зоһурийат — булмаганнан килеп чыккан нәрсәләр.
Сәрват — тезеклек.
Чаладыр сур — быргы кычкырта.
Уладыр ... һур — җимерелә.
Уладыр ... бур — һәлак була.
Әфуат — вафат булу, үлү.
Баля һәм зирләр — өст һәм астлар (җир-күкләр).
Чү рәгъдгирләр — әйтерсең күк күкрәтүчеләр.
Һәйбәт үзә асуат — куркынычлы тавышлар.
Бух — тавыш (?)
Мәҗрух — яралы, җәрәхәтлеләр.
Әнфас — нәфесләр, ягъни җан ияләре.

Һәмандәм вирисәрләр рух,
Һәлякәтдә улып әлмәүт.

Чү! Исрафил чала сури,
Къәбердин дорасән үри;
Гарасатга вара — йөри,
Хисабә җөмлә мәхлүкат.

Хәкаикъ гъәҗз ула ул ан,
Тәхайер-лә китә дәрман.
Сәнендик гасый күбдер ан,
Ула гирйан, улып сәкрат.

Кяферләр әйләйүрләр закъ,
Вә уйлата әгәр купсак,
Ки кяшки без төраб улсак
Иде, күрмәз идек хәсрат.

Җәмигъ кыйлмышлар ула йад,
Пошиманлар ула әфрад.
Килеп хосман, деләйүб дад,
Хөкемдә улалар сәрват.

Кешегә гәр кеше көчи
Онытмай сәндин ул сөчи.
Ки ахир бер алыр үчи,
Хөкемләр берлә дәр-гъәрәсат.

Көн эсигъ уладыр — һәб дан,
Көнәш сезгә ула — һәб дан,

Вәрисәрләр рух — җан бирерләр.
Әлмәүт — үле.
Дорасән үри — үрә торасың.
Гъәҗз — гаҗиз.
Гасый — гөнаһлы.
Гирйан — елау.
Сәкрат улу — үлем газабында булу.
Закъ (заикъ) әйләү — кычкыру-бакыру.
Төраб — туфрак, кабер.
Әфрад — кешеләр.
Хосман (хосаман) — дошманнар.
Дад — дөрес хөкем.
Хөкемдә ... сәрват — төзек (дөрес) хөкемдә.
Сөч — гөнаһ, гаеп.
Эсигъ — эссе, кызу.
Көнәш — кояш.
Һәб дан — яхшы бел.

Тамам ул көйдерә әбдан,
Улып хәйран, китә әкъват.

Кызара йир димердәк бәс,
Һава кызарубән чүн мәс [125],
Көйә кем улды мәгъзуб кәс,
Хәрарәтдин идеп чәулан.

Кенәшдин бу кадәр әшракъ [126],
Улачак йир, һауа, ихракъ.
Бу ихракъда бер уч туфрак [127]
Нәчек такъәт идәр бер ан?

Зиба буй һәм ула качи,
Һауа тәлх ула — ачи,
Сабыйлар гъәзб илән сачи
Агарып китәдер ул ан.

Күрәчәк гъәзбилә хәшман,
Идеп әфгаленә пошман,
Хода чөн дустидан башка
Улисәр дуст дигән дошман.

Ауаз идә, ауазы — дад,
Къәни Фиргъәуен вә Шәддад [128]?
Җиһани — безем ул дәйүб,
Заляләт кыйлды зи-л-әутад.

Къәни ул Нәмруди фәссад [129],
Къәни Дәкъйанус гъинад [130],
Къәни зали мөзыйль сәмүд,
Кәни һәм дәхи зали гъад [131].

Әбдан — бәдәннәр, тәннәр.
Әкъват — куәтләр.
Чүн мәс — бакыр шикелле.
Мәгъзуб кәс — каһәрләнгән, каргалган кеше.
Хәрарәт — эсселек.
Чәулан — әйләнеп, бөтерелеп.
Ихракъ — янгын, ут.
Качи — вак-вак.
Тәлх — әчкелт, тәмсез.
Гъәзб — газап.
Хәшман — ярсу.
Идеп әфгаленә пошман — эшләгән эшләренә үкенеп.
Заляләт кыйлды зи-л-әутад — мәгънәсе: үзләрен дин үзәге дип ялгыштылар.
Фәссад — бозык, азгын.
Гъинад — үҗәтлек.
Зали мөзыйль — юлдан язган.

Къэни «Мин!», «Мин!» дигэн ханлар?
Къэни дөнйауи солтанлар? —
Фэсадат кыйлдылар анлар,
Гүйэки улдылар кэссад.

Къэни кяфирани рузгяр,
Бу көнгэ кыйлдылар инкяр? —
Күрең ин руз, курең ин кяр!
Кемэдер кем аңа солтан?!

Китерең ул пэлидлэри,
У мөнкэри гъэнидлэри,
Килеп йэүме вэгъидлэри,
Къэни Иблис, къэни шэйтан?

Мэгэр Хакъ юлына баши
Виреб, кем дүкэр күз йэши,
Җинанэ уладыр маши,
Аңа рэхмэт идеп рэхман.

Зөбанилар ушал анда,
Тамугъ этлэре һэм анда
Гизэ та кайсылар [132] къэнда,
Улубэн сала бер ниран.

Идисэр гасыйлар фөрйад
Тэмам ауаз белэн эфрад,
Ходадин юкса гэр эмдад,
Тэмугъга идисэр дэр-ан.

Нидэлэр, килсэ ул хальдэ,
Күренез, йитде бу вэгъдэ.
Һэзар рэхмэт ула сэгъдэ,
Һэзар къэһр ли-зи-тогъйан.

Кэссад улу — тукталу, сүнү, бетү.
Кяфирани рузгяр — кяферлек чоры.
Күрең ин руз, күрең ин кяр — күрегез бу көнне, курегез бу эшне.
Пэлидлэр — түбэн җаннар.
Мөнкэри гъэнидлэр — кире кагылган тискэрелэр (үҗэтлэр).
Йэүме вэгъид — кисэтү, янау көне.
Җинанэ... маши — җэннэткэ керүче.
Ушал — шунда ук.
Ниран — ут.
Эмдад — ярдэм, куэт бирү.
Һэзар — мең.
Сэгъдэ — бэхетлегэ.
Ли-зи-тогъйан — фетнэчелэр өчен, фетнэ иялэре өчен.

Гъәрасатда идеп мәйдан,
Күреп хәсрат, гөнаһ шәйдан,
Бәс ул халь дизелә сыйрат [133],
Бәс анда корыла мизан.

(XXI) Намәләр [134] килмәке вә хисаб улмаклыкыны бәйан идәр

Намәләр вирелә кула,
Кемә уңа, кемә сула,
Кемә аркасыдин ула,—
Кеми хәндә, кеми гирйан.

Кемисенә хисаб ула,
Кемә газаб, гъитаб ула.
Күрепдер халеңи нәүлә,
Әгәр хәйр исә ихсан.

Әгәр намәң килеп уңдин —
Хисаб асан ула соңдин.
Вәләкин килсә сул яңдин,
Газаби уласән вәждан.

Әгәр Хакъ гафу кыйлса уш,
Гъитаб улса да улмаз хуш.
Нәгъүз билләһи, гәр бәр-дүш
Вирелерсә, газаб андан.

Кеми көлә ушал халә,
Кемисе әйләйүр налә,
Кемисени алып шалә,
Хәйадии гаркъ ула сәйлян.

Шәйдан — эштән, әйбердән.
Дизелә — төзелә.
Мизан — үлчәү.
Намә — язу, хат.
Уңа, ... сула — уңга, сулга; уңнан, сулдан.
Хәндә — көлү; көлә.
Гирйан — елау.
Гъитаб — гаебен күрү, шелтә.
Нәүлә — сөенеч, бүләк.
Ихсан — игелек.
Вәждан — һуштан язу.
Нәгъүз билләһи — алла сакласын.
Бәр-дүш — җилкәгә.
Налә — елау.
Шалә (шала) — кисәү, таяк.
Хәйа — оят.
Сәйлян — ташкын.

(XXII) Фи бәйани шәфагъәти-н-нәби салли аллаһе гъәләйһессәлам [135]

Нәби сәййеде гъәләм,
Салатуллаһ аңа мөдам,
У гәүһәр зөбдәи адәм,
Шәфагъәт идәсәр ул ан.

Поракъ-лә [136] биңзәйүр бәркъә,
Оча гяһ гъәрбә, гяһ шәркъә,
Хода әзне белән халкъә,
Шәфагъәт чөн идә хиҗлян [137].

Гъосат-ел-мөэминин анда,
Мөхәммәд өммәте къәнда,
Зөбанилар килеп рандә,
Дузахә әйдәрләр ул ан.

Мөхәммәд, кем рәсүлуллаһ,
Болара угърайа ул гяһ.
Ала ошбу шәфагъәт хаһ
Хода әзне белән дәр-ан.

Поракъ илән очар ула,
Ќерүбән гяһән бер юла,
Ќерә гяһ уңа, гяһ сула,
Бәркъ диген идә сәйран.

Гъосат өммәтендин ула,
Дотан нар этедин ула.
Ул этнеҗ агъзыдин кула
Идүбән шәфкъәте чәндан.

Сәййеде гъәләм — галәм башлыгы.
Мөдам — һәрвакыт.
Зөбдәи — иң яхшы.
Поракъ — күк аты, мифик ат.
Бәркъ — яшен.
Гяһ гъәрбә, гяһ шәркъә — бер көнбатышка, бер көнчыгышка.
Әзн — рөхсәт.
Хиҗлян иту — оялу, уңайсызлану; монда: ялвару, үтенү.
Гъосат-ел-мөэминин — гөнаһлы (юлдан язган) мөэминнәр.
Рандә — куып.
Угърау — очрау.
Ул гяһ — шул вакыт.
Шәфагъәт хаһ — яклауны сораучы.
Бәркъ диген — яшен кебек.
Ќула — куыла (?).
Чәндан — шул хәтле, шул кадәр, күп.

Мөхәммәд китәчәк гъәрбә,
Идәләр шәркъ үзә зарбә [138],
Гъосати доту чөн гәрбә,—
Нәчек ул күтәрәдер муш.

Боера чарийарыйна [139],
Поракълар вирә барыйна,
Зөбанилар гөзарыйна
Варубән уласыз дип туш.

Поракъ-лән кидәләр сәйрә
Күрәчәк оралар нәгърә,
Йөрәк һәм чяк ула зәһрә,
Тәмам дилләр уладыр җуш.

Бу халь эчрә Гъәли хәзрәт
Зөбаниларга ба-гайрәт.
Идеп нәгърә, дота һәйбәт,
Зөбанилар кала мәдһуш.

Килер иркән бу һәйәәтдә,
Тәмам гайрәтдә — һәйбәтдә,
Зөбанилар бу рөәзийәтдә
Кала хәйран Гъәли-л-бәтшан.

Вәләкин анда күп фөссакъ,
Зөбанилар улубән лакъ (?),
Салып гъоллар гъәля-л-әгънакъ
Тәмугъга идәләр хәшан [140].

Бу хали күрәчәк, ул шаһ
Ора вә: «Өммәта!», дип аһ,
Йөз орып сәҗдәгә дәргяһ,
Гъәрешкә башыни гъәршан [141].

Гәрбә — мәче.
Муш — тычкан.
Гөзар — монда: торган җир.
Туш улу — очрашу.
Чяк ула зәһрә — ачудан ярыла.
Җуш — кайнау, тетрәү.
Ба-гайрәт — гайрәт белән.
Һәйәәт — тес, кыяфәт.
Рөәзийәт — хәлдә, күренештә.
Гъәли-л-бәтшан — Галинең көченнән, куәтеннән.
Лакъ — кыйнау (?).
Гъоллар гъәля-л-әгънакъ — муеннарына богаулар.
Өммәта — өммәтләрем (*өммәт* — бер дингә иярүче халык).
Дәргяһ — алла каршында.

Дийә гъәрш изисе аңа:
«Йа хәбиб, килеп бәна
Нә сорсаң, виререм сәна,
Идубән өммәтең бәхшан!»

Бу хальдикән рәсүл-сәүчи [142],
Зөбанилар улып фәүҗи,
Чыкубән йөри чүн мәүҗи,
Гъоссани идибән къәмшан [143].

(XXIII) Сыйрат кичмәклекнең бәйане будыр

Ула күфрек дүзах аша,
Тәмам нечкәлеге фаша,
Күрәчәкдән гакыл шаша,
Ки андин кичмәгә, и йар!

Кичисәр бәндәгяни ник,
Бәркътик, бәгъзысе йилтик,
Очисар бәгъзысе җондик,
Ничек йилдә идәр сәййар.

Вә бәгъзы ник кичәр күфрек,
Идеп тәрк, ат кеби йөгрек,
Вә бәгъзы кяфери мөшрик
Улып, тәкдән кичәдер нар.

Кичәр бәгъзы хаша-хаша,
Ахыр салим кичәр аша,
Чү тоу бәгъзы зәгъифләшә,
Чыгалмайун дөшәр дәр-гъар.

Гъәрш изисе — күк хуҗасы (алла).
Хәбиб — сөекле.
Бәхшан — бүләкләп.
Бу хальдикән — шул хәлдә килеш.
Фәүҗи — төркем, җыйнаулашып.
Мәүҗи — ташкын булып.
Күфрек — күпер.
Дүзах — тәмугъ, җәһәннәм.
Фаша — ачык, мәгълүм.
Бәндәгяни ник — яхшы, изге бәндәләр.
Бәркътик — яшентик, яшен шикелле.
Тәрк идеп — узып чыгып.
Мөшрик — күп аллага ышанучы, мәҗүси.
Хаша-хаша — киреләнә-киреләнә.
Салим кичәр — зыян-зарарсыз кичәр.
Чү тоу — синең кебек.
Дәр-гъар — чокырга.

Шулар, кем кичделәр андан,
Хәтәрләр кичереп җандан,
Зәһи мәгъфур, ник мәрдан,
Җинан эчрә идәрләр дар.

Биһеште гъәдн җайини,
Гизеп җәннәт сарайини,
Татып нәфсе һәуаини,
Сафада улалар сәййар.

Дөшисәр нара күп бәндә
Сыйраты кичмәк эчендә,
Булышып атәшә анда,
Газаби улалар дәр-хар.

(XXIV) Оҗмах сыйфаты вә һәм аның әһленең әхуале

Шулар кем керәләр җәннәт,
Тәмам һәйбәт улып һиммәт,
Ки зәррә калмайа гъилләт,
Бәдәндә зәррәчә микъдар.

Къас улмас дил вә дулмаз [144],
Ки һич бәүл-гаит улмас,
Зәһи дәүләтледер бу нас,
Зәһи әгъзаз, зәһи әкъдар.

Әбәд-бакый үлә улмас,
Әләм, гъәм-гъоссалар күрмәс,
Йөзидә нур улып, сулмас,
Тәмам рәүшан ула, и йар!

Зәһи мәгъфур, ник мәрдан — ярлыканган, изге, яхшы ирләр.
Җинан — җәннәт.
Дар итү — йорт итү.
Биһеште гъәдн — оҗмах, җәннәт.
Нәфсе һәуаи — ашкынулы хисләр.
Нар — ут, җәһәннәм.
Атәш — ут, ялкын.
Дәр-хар — хурлыкта.
Зәррә — туван кадәр дә.
Гъилләт — кимчелек, чир, авыру.
Къас — сизү, тою.
Бәүл-гаит — кече һәм олы табигый тәрәт.
Нас — кешеләр.
Зәһи әгъзаз... әкъдар — яхшы, газиз, кадерле (кешеләр).
Әбәд — мәңге.
Әләм, гъәм-гъосса — кайгы-хәсрәт, чир.

Тәхетләр ләгъл илән фирүз,
Килеп хурлар ула мәншүз,
Җәмале чү әфтаб әфрүз
Идүбән нур идә иншар.

(XXV) Сыйфаты-л-җинан вә әнһарһа вә әшһарһа [145]

Һәзар хөррәм ула дилләр,
Һәзар бөстан вә чүлләр,
Бөтә багълар, үсә гөлләр,
Зәһи энгам, зәһи ихсан.

Дивары — сим, зәр бамдин,
Мөзәййән нөкърәи хамдин [146],
Зәһи макъсуд, зәһи кямдин
Идисәр яхшылар сәйран.

Гъәсәлдин елгалар ака,
Ки сөткә биңзәйүр — ака,
Җинан әһле варып бака —
Ничек ул идәдер сәйлян.

Дәрәхтан бә-һәр фәрддән
Бодаклари зөбәрҗәддән,
Йимеше татлыдыр къәнддән [147], —
Васъфда къәсыр ула әзһан.

Һәзар шәһәр, һәзар мисъри [148],
Һәзар күшәк, һәзар къәсъри,

Мәншүз — меңү.
Әфтаб — кояш.
Әфрүз — якты, балкып торган.
Идә иншар — сибә, тарата.
Хөррәм — шат.
Бөтә — үсә.
Әнгам — муллык, байлык.
Сим — көмеш.
Зәр бам — алтын түбә (түшәм).
Мөзәййән нөкърәи хамдин — ак көмеш беләк зиннәтләнгән.
Зәһи кямдин — яхшы канәгатьләнүдән.
Гъәсәл — бал.
Сәйлян — ташу.
Дәрәхтан бә-һәр фәрддән — агачларның һәрберсеннән.
Къәнддән — шикәрдән.
Васъфда къәсыр ула әзһан — тасвирларга зиһен кыска була.
Күшәк — матур җиңел корылма (павильон).

Тəмам васъфə кагыл къəсъри,—
Имəс васъф итмəгə имкян.

Бу — былбыл, гъəндəлибстан [149],
Вə гайре мəргый дəр-бөстан
Укыйурлар һəзар дəстан,
Мəкяне иду̇ фи-л-əгъсан.

Идеп сəйер, кереп багъа,
Күрəрсəн: елгалар ага,
Əбрдин йинжүлəр яга,
Нəһер улып идə сəйлян.

Зəһи ширин ки бу əнһар,
Хосусəн — хəүзəи Кəүсəр!—
Йəкъин бел, эчсə аны гəр,
Сусамас һəргиз ул инсан.

Иляһи, безгə бер жөргъəт
Нəсыйб кыйлгыл əз-ан ширбəт!
Мөхəммəдə идеп өммəт,
Алып хəмсəн илəн гъəтшан.

Хосусəн ул шəҗре Туби
Зəһи никя, зəһи хуби,
Зəһи мөждə, зəһи туби,—
Җиһанда кем кыйла ихсан.

Мөрəссəгъ кясəи зəррин,
Тəмами йинжу-дөррин,
Мөлəззəз нигъмəте ширин,
Китерə гъилмане вилдан,

Къəсъри (къəсыр) — сарай, крепость.
Мəргый — чирəмлек, көтүлек.
Əгъсан — ботак.
Əбр — болыт.
Нəһер улып — елга булып.
Зəһи ширин — бик татлы.
Əнһар — елгалар.
Хəүзəи Кəүсəр — Кəүсəр чишмəсе.
Жөргъəт — йотым.
Əз-ан ширбəт — бу ширбəттəн.
Хəмсəн илəн гъəтшан — бишлəтə сусау белəн.
Шəҗре Туби — бəхет (җəннəт) агачы.
Зəһи никя — бигрəк тə матур.
Мөждə — яхшы хəбəр, күңелле яңалык.
Мөрəссəгъ кясəи зəррин — асыл ташлар белəн бизəлгəн алтын кясə.
Мөлəззəз — ләззəтле.
Ширин — тəмле; татлы.
Гъилмане вилдан — җəннəт хезмəткəрлəре.

Идеп тәкйә, сонып дәстар,
Тәгъамдин нә дилең эстәр:
Хәрир, атлас, бенеп, ситәр [150],
Хәрирдин ула һәм юрган.

Дивары баля вә йуча,
Гяһи кошлар килеп оча,
Гяһи хурлар килеп коча,
Зәһи хуш йар, зәһи хуш жан!

(XXVI) Ожмахда хурларның сыйфаты вә бәйане

Киләдер алдыңа хурлар,
Йөз әлуан йөзидә нурлар,
Курәчәк алә сөрерләр,
Җәмагъи идүбән шәбкъән [151].

Һәзар ак нур, һәзар рөхсар,
Тәмами шәмескә охшар,
Зәһи яхшы гөлстанлар,
Зәһи гөл-багъ ула мөлкъән.

Чү, хурлар киләчәк — дан, туш,
Мөганикъ улалар бәр-душ,
Зәманлар уласән мәдһуш,
Кәнарендә улып согъкъән [152].

Идеп бусә аны һәп ир,
Гъәкыйкъ дикен ора ләбләр,
Өзеп шәфталу гъәбгъәбләр
Бөйлә ва шәукъән, ва шәукъән!

Тәкйә иту — сөялү; монда: тез чүгү.
Дәстар — сөлге, тастымал.
Дилең эстәр — күңелең теләр.
Хәрир — ефәк.
Ситәр (ситр) — пәрдә, вуаль; тән япкыч.
Баля вә йуча — биек һәм югары.
Йөз әлуан — йөз төрле, йөз төсле.
Җәмагъи иту — кавышу, җенси якынлашу.
Рөхсар — йөзләр, кыяфәтләр.
Мөлкъән — ташландык җир.
Дан, туш — бел, каршыла.
Мөганикъ — кочаклау, кочу.
Бәр-душ — иң өстенә, иңнәргә.
Кәнарендә улып согъкъән — янында (кочагында) һуш китеп.
Бусә иту — үбү.
Гъәкыйкъ дикен — ахак шикелле.
Гъәбгъәб — ияк асты.
Шәукъән — көчле теләкне канәгатьләндерү.

Қәнарендә зәһи бәхтә,
Бенеп тәхтә, салып тәхтә,
Җәмагъе идәсән пөхтә,
Улубән балядә фәүкъән.

Җәмагъидә улып баля,
Ула бакирә һәр халә,
Мөтәххәйр-лә китеп валя,
Улачак галибе шәукъән.

Бенеп атлас хәрирендә,
Ләгъле, җәүһәр сәрирендә,
Салып хурлари зирендә,
Ула худ нөтфәи дәфкъән[153].

Күреп бонлар җәмалене,
Коча-коча кәмалене,
Һаман ширин золялене,
Идеп нуш уладер зәукъән.

Ула йөзе көнәш табан,
Кирәк инсан, кирәксә җан,
Әлем һич вирмәмеш бер ан,
Ки сәндин әүүәлә хәлкъән.

Кәнаригә салубән уш,
Җәмагъи идәләр дәр-хуш,
Кочубән күксене бәр-душ,
Бөйлә вә гъишкъән, вә гъишкъән.

Йөзидә нур ала шәгълә,
Ки охшар дешләри ләгълә,
Шулар берлә дөшеп шөгълә,
Табар ул җайида ибкъән.

Салып тәхтә — аска салып.
Балядә фәүкъән — югарыда, өстә.
Ула бакирә — гыйффәтле кала, кызлыгы исән.
Мөтәххәйр-лә — гаҗәпләнү белән, шаккатып.
Валя — рәшә (мираж); монда: исереп.
Сәрирендә — ятагында.
Зирендә — астына.
Нөтфә — аталык орлыгы.
Золял — салкын, саф су.
Зәукъән — зәвекъ белән.
Көнәш табан — кояш ялтыравы.
Хәлкъән — тыштан, читтән.
Кочубән күксене бәр-душ — мәгънәсе: күкрәген күкрәккә кочып (кысып).
Табар ибкъән — монда: артыгын табар.

(XXVII) Ходай тәбарәкә вә тәгъаләнең дидарын мөэминләр күрмәке

Улыркән гъизз илән наздан
Дидари күстәрә йәздан;
Җәмалинә улып нәзран,
Калалар һәрбери хәйран.

Бу назыйрлар дидар күрде,
Һәммәсе мөэминүн ирде,
Җинан эченә кем керде[154] —
Күрисәр дидари йәздан.

Дилем тәсдикъ, дилем икърар
Идеп белде сәни бер, бар[155],
Рәхимеңдин өмидем вар,
Газабыңдин улып тәрсан.

(XXVIII) Фи бәйани әһле-н-нар вә гъәзабәһү[156]

Шулар кем керделәр нарә,
Тулашып зар үзә зарә,
Булышып гъәкърәбә, марә
Газаби улу бәр-ниран.

Җәһәннәмдә яна әшрар,
Катигъ эш-кяр, ула эш тар,
Уладыр көн-бә-көн дишвар
Җәһәннәмдә газаби ан.

Тәмам ут эчидә көффар,
Дөшеп вадилар[57] дәр-хар,
Бөйлә къәһр әйләйә къәһһар
Шуңа, кем кыйлдылар тогъйан.

Дидар — йөз-чырай.
Улыркән — булыр икән.
Гъизз — кадер, мәртәбә.
Нәзран (назыйран) — карап.
Улып тәрсан — куркып.
Нарә — утка.
Гъәкърәб — чаян.
Мар — елан.
Әшрар — явызлар, бозыклар.
Дишвар — кыен, авыр.
Көффар — кяферләр.
Дөшеп вадилар дәр-хар — төшеп хурлык даласына.
Къәһһар — каһәрләүче.
Тогъйан — азгынлык.

Тышы мәхрукъ, эче мәхзүн,
Газабы уладыр әфзүн,
Хосусән Иблиси мәлгунь
Тәмугъдин ула дәр-зиндан.

Шәраби һимһәмим мәгълүм,
Сәмәрләре ула зәкъкум.
Тәгъаме уладыр мәсмүм,
Сийабе уладыр къәтран.

Һәм утдин вадилар анда
Күп ула, улмайа санда,
Дөшәрсәң — чыкмага къәнда,
Шәйатин-лә улып җиран!

Ула аждаһалар әзърәб,
Бә-туни тулы мар-гъәкърәб,
Зәһәр сачып, ула әкърәб,—
Газабда кем ирер дәр-ан.

Болытлар килеп ул халә,
Ула хәмраи дәр-баля,
«Ләгъәл-уллаһ рәхим сала,—
Дийәләр,— та виреп баран».

Қиләчәк, ягадыр нарлар,
Гъәкариб, аждаһа, марлар.
Ушал мар дәхи әкътарлар
Қилеп чолгана бәр-гәрдан.

Мәхрукъ — кабынган, ялкын алган.
Мәхзүн — боек, кайгылы.
Әфзүн — арта бару.
Һимһәмим — котырып ачыган.
Сәмәр — җимеш.
Зәкъкум — ачы; җәһәннәм агачы.
Мәсмүм — агуланган.
Сийаб — кием-салым.
Къәтран — дегет, сумала.
Вади — уйсулык, дала.
Җиран — күршеләр.
Әзърәб (зъәрәбә) улу — сугышу.
Мар-гъәкърәб — елан-чаян.
Ула әкърәб — янында була.
Ула хәмраи дәр-баля — өстә (болытлар) кып-кызыл булалар.
Ләгъәл-уллаһ — бәлки алла, ихтимал алла гына:
Баран — яңгыр.
Әкътар (къытар) — тезелгән төркем, кәрван.
Бәр-гәрдан — муенга.

Мөәббәд улалар анда
Кяферләр җөмлә хәйранда,—
Вәләкиннә әбәд калмас
Мөселманлар нар эчендә!

Мөселмане гасйан әз-нар
Чыкасәр янубән дәр-хар,
Гөнаһы нә къәдәр микъдар
Вә йаки фазыль идә рәхман.

(XXIX) Мөнаҗат [158]

Иляһена, ходаүәндә,
Деләисәр ушал бәндә:
Өмидем шул ирер сәндә,
Тәмугъдин саклагыл, мәннан.

Иляһи, гаҗизәм, зарәм,
Зәгъифәм бән, гөнаһкярәм,
Нә кыйлсаң да имәс чарам:
Кирәк гадел, кирәк ихсан.

Халем дишвар, улып закъәт,
Тәнемдә зәррә йук такъәт,
Ки юктыр кыйлдыкым тагъәт,
Вә ләкин әйләдем тогъйан.

Уен-көлке таләб кыйлдым,
Фәсадәтләри һәп кыйлдым,
Ки белмәзем, гаҗәб, нулдым,
Мәгәр рәхмидә ул хәннан.

Тәрикъе мөстәкъим яздым,
Шәйатин мәкрилән аздым,
Рәхим кыйл бәңа, юкса бән
Гакылдин бу заман яздым.

Мөәббәд (әбәд) — мәңгелек.
Мөселмане гасйан әз-нар — гөнаһлы мөселманнар уттан.
Фазыль итү — кичерү.
Мәннан — юмартлык иясе.
Гаҗизәм ... зәгъифәм — гаҗизмен .... зәгыйфмен.
Дишвар — авыр.
Улып закъәт — тарлык булып.
Һәп — күп.
Нулдым (нә улдым) — ни булдым.
Рәхмидә — рәхим итә.
Хәннан — алла.
Тәрикъе мөстәкъим — туры юл.

Никүләр-лә кубар булсам,
Зәһи никдер. зәһи әнгам!
Вә иллә әһле тогъйан-лә
Тәмугъә уласәр илзам.

Зөнүбем би-хисаб, җәмед,
Фирагъәт форсатым тәммәт.
Китәрсәм бөйлә бән, әлбәт,
Бу йөкләр берлә дәр-хәсрәт.

Гөнаһы әйләдем ифрад,
Имәс имкян гъәля-т-тәгъдад.
Ки сәндин юкса гәр иршад
Нә кыйла бәндәи фөссад?

Йа Гъәбделҗәббар [159], [сән] аңла:
Нә әйтүрмән — аны дыңла,
Билә һиммәт фута багъла.
Һидайәтдин ула та ан.

Нәсыйхәт әйләдем, угълан,
Дилә алгыл аны, и җан!
Ерак кыйл нәфсеңи бәддән
Дәхи нә шәй уладыр ран.

Һәуага бакыйбан күзи,
Ки дотмассаң ушал сүзи,
Улисәр сән кара йөзи,
Доташып ataше ниран.

Кяри бер тәркитер тәркин,
Ки дот бәрк һида, бәркин,
Китәр сәрдин шәка, сәркин
Пошиманлар идеп этъйан.

Никүләр-лә — яхшылар белән.
Зәһи никдер — нинди яхшыдыр.
Әнгам — муллык, байлык.
Илзам — мәҗбүрән.
Зөнүбем би-хисаб, җәмед — гөнаһым бихисап, җыелган.
Фирагъәт форсатым тәммәт — ирекле мөмкинлекләрем бетте.
Тәгъдад — хисаплап бетерү.
Билә һиммәт фута багъла — билгә һиммәт путасын ура.
Һидайәт — чын юлга басу.
Ран улу — кушылу, серелү, фаш булу.
Улисәр сән — булачаксың син.
Кяри бер тәркитер тәркин — эшлекле бер ташлар ташлаячакны.
Дот бәрк һида — чынлыкны нык тот.
Китәр сәрдин шәка — баштан бозыклык китәр.
Әтъйан — киләчәк, булачак.

Ишет ошбу нәсаихи,
Дилә ал, та ки ляихи:
Кыйлып гәр бу къәбаихи,
Уласән соңы дәр-тогъйан.

Яуыз күзне, яманларны,
Сәңа дошман уланларны,
Бәгъид идә Хакъ анларны,
Сачубән сәңа гөл-рәйхан.

Һидайәт нурыны баша
Вирә Хакъ хәддедин аша,
Күр, анлар, гакъледин шаша,
Къәмусы улубән хәйран.

Нури тап, аны табани
Табам дирсәң, шитаб ани,
Табарсәң, дот никъаб ани,
Сакыйнгыл, әйләмә гъөрйан.

Сакыйн, чяк әйләмә дамен,
Вәдигъә куй Хакъкә кямен.
Ходай саклар, бәнем замен,
Хакъкә тәслим исә, и җан!

Китәр инсаф, имәс ин саф,
Һәммә гомрең идеп әтляф.
Газиз нәкъдең кыйлып исраф,
Соңида улма дәр-гъөсран.

Нәсаихи — нәсыйхәтләрне.
Ляих — ачык, аңлаешлы.
Бәгъид идә — ераклаштыра.
Нури — нурны (иляһи нурны — күңел нурын).
Аны табани — аны тапканны.
Шитаб — тиз эшләү, тырышу.
Никъаб — яшерү, яшерен.
Гъөрйан — ялангач, шәрә.
Чяк әйләмә дамен — ертык, тишек итмә авын (җәтмәсен, пәрдәсен).
Вәдигъә — сакларга бирелгән, әманәт әйбер.
Кям — теләк, омтылыш.
Замен — ышаныч, гарантия.
Тәслим исә — тапшырылса.
Китәр инсаф, имәс ин саф — китәр инсаф, бу саф(лык) түгел.
Әтляф итү — әрәм-шәрәм итү.
Нәкъд — кулда булган акча.
Дәр-гъөсран — мохтаҗлыкта, кысынкылыкта.

Гажәб бу хиндәге ирләр
Мөратиб, гъиззе дин дирләр,
Гъәналыкдин дип ул ирләр
Җиһани кичәләр бер ан.

Димә һәр әтрафым йафигъ
Улып кадрем бәнем рафигъ,
Җиһан аслында юк нафигъ
Дәйүсәрләр дәхи ихсан.

Гажәб хәйрат, гажәб вәйа
Нәзар кыйлсаң бу дөнйайа:
Фәкъирә игътибар һич юк,
Идәрләр гъиззәти байа [160].

Фәкъирнең зәррә юк къәдри,
Дәйү(р)ләр ля-әдәб йәд-ри,
Әгәрчә вирәсән садри,
Утыргай мөгътәриф җайа.

Диде боны рәсүлулла
Гъәләйһ күп салауатуллаһ [161]:
Фәкъирнең гъиззедин ула,
Дәйүб, әлфәкъре-фәхрәна [162].

Нәсаих әйләдем, и йар,
Сәнең өчен язып әшгъар,
Кабул итеп, дотып юл вар,
Еракка китмәгел, найа [163].

Нәсыйхәтләр сәңа хуб бад,
Боның исмен идәрсәң йад,
Атап «Рисаләи-л-иршад»,
Язылган ошбу дүрт пайа.

Мөратиб, гъиззе дин — мәртәбәле, дин күрке.
Гъәналык — байлык.
Йафигъ — ябык (рифма өчен).
Рафигъ — күтәрелүче, үсүче.
Нафигъ — файдалы, отышлы.
Ля-әдәб йәд-ри — әдәпсез, кулы озын (сорамыйча алучы).
Вирәсән садри — мәгънәсе: ирек бирсәң, юл куйсаң.
Мөгътәриф җай — күрекле урын.
Әшгъар — шигырьләр.
Юл вар — юл (белән) бар.
Худ бад — хуп булсын, яхшы булсын.
Дүрт пайа — дүрт «аякта» (ягъни дүрт юллы шигъри строфада).

КЫЙССАИ ИБРАҺИМ ӘДҺӘМ [1]

[Мөкаддимә]

. . . . :
. . . .[2]

Хәмед-лә тәсълийәдин фаригъ улам,
Максадым сөйләмәгә шаригъ улам.
Бәгъзы йаран фәкъире, бәгъзы нас
Әйләделәр бу гъәрибдин илтимас:
«Бер кәтабәт кыйссаләрдин әйләгел,
Һәр нә гъәҗаибдин улса, сөйләгел;
Төрки улсын ул кәтабәте шәриф,
Самигъең дили улса ирде ләтыйф».
Бу фәкъире Гъәбделҗәббари зәгъиф
Бине Гъәбделмәҗид Болгари [3], нәхиф,
Күрде кыйссадин бу фәкъир күп кәтеб,
Деләйүр язмага аны җәмгъ итеб.
Нә ишетдем һәм нә күрдем бән фәкиръ,
Язайым яхшы-яманыдин кәсир.
Ләкин идә ул ходауәндә мәдәд —
Ибтидадин интиһайә ул сәмәд.

Хәмед-лә тәсълийәдин фаригъ улу — алланы мактау белән аны олылаудан азат булу.
Шаригъ — урам, олы юл; монда: башлаучы.
Нас — кешеләр.
Илтимас әйләү — үтенү, сорау.
Кәтабәт — язу, язма әсәр.
Самигъең дили — тынлаучының күңеле.
Ләтыйф — күркәле, хуш.
Нәхиф — хәлсез, дәрмансыз.
Кәтеб — язмалар, әсәрләр, китаплар.
Җәмгъ итеб — җыеп, берләштереп.
Кәсир — күп; монда: шактый.
Мәдәд — ярдәм.
Ибтидадин интиһайә ул самәд — баштан ахырга кадәр ул (алла) мәңгелек.

I

Шөругъе-л-бисатъ... Ибраһим Әдһәм[4]

Шаһи Бәлх[5] ирде солтан Ибраһим,
Ул хода вирмеш иде мәлик гъәзим.
Та ки Ибраһим Әдеһәм бер көне
Ҡыйлды җөмлә мәмләкәтин тәркине.
Көһнә җамә киде[6] ушал бәхтийар,
Сахраларда гъәрбәт итде ихтийар.
Йөрер ирде гъөбрәт эчрә руз-у-шәб,
Идәр ирде Хакъ ризасыни таләб.
Юлга къәдәм орды бер көн ул сәгъид,
Тугъры килде шәһри Һарун әр-Рәшид[7].
Йитешеп шәһрә, ләкин улмышды кич,
Тапмады имкяне ул кермәгә һич,
Ул кичә шәһәр тышында кунды ул,
Булмады шәһәр эченә кермәгә юл.
Кәлде дузур[8], дотды кич берлән бони:
«Нә кеши сән? Нә идәрсән бу дөни?»
Ул кичәне, собх улачак, ул дузур
Шаһ къашига илтү куйды дәр-хозур.
Миргъәсәс[9] диде ки: «И шаһе зәман!
Бу кичә бер дуздини дотдым һәман».
Диде: «Күстәрең бәңа аны гъәйан,
Нә кешидер, әйләсен хален бәйан».
Шаһ бойырды, та ки керде ул гъәриб,
Диде Һарун аңа: «Кил бире къәриб!»
Диде: «Сән дузди ирерсән, әй кеши,
Юк исә, дөн эчрә кыйлдың нә эши?»

Мәлик гъәзим — зур хөкемдар.
Та ки — шулай итеп.
Тәрк кыйлу — ташлау, нәрсәдәндер баш тарту.
Көһнә җамә — иске, сәләмә кием.
Гъәрбәт итде ихтийар — гариблекне (иленнән аерылып йөрүне) ихтыяр итте.
Руз-у-шәб — көн һәм төн.
Къәдәм ору — атлап киту, юлга чыгу.
Сәгъид — бәхетле.
Собх улачак — иртә булгач, таң аткач.
Къашига — янына.
Дәр-хозур — каршысына.
Миргъәсәс — төнге сакчылар башлыгы.
Дузди (дузд) — карак.
Күстәрең... гъәйан — күрсәтегез... шиксез.
Къәриб — якын.

Диде: «Дузди ирмәзем, и падишаһ,
Лик йөрердем эстәйүб вәжһе илаһ.
Хакъ ризасын эстәйүб кыйлдым мөрүр,
Ул зәманда килде лотды бу дузур».
Миргъәсәс боны ишетде, дәр-рәуан
Сәлли дөнбалинә орды би-әман:
«Шаһ сөаль үзрә китермәкдә сези,—
Бу сүзендән эстәйүр гъәйри сүзи!»
Диде Һарун миргъәсәскә: «Йа дузур,
Нә өчен гөстахилек итден бә-зур?
Нә сөаль кыйлдым бән андин — нә җәуаб,
Ул җәуаб бирде ки хәзер ба-сәуаб.
Шаһ катында кем әмер кыйлды сәңа,
Къәһр идеп, сәлли орыйрсән сән аңа?»
Кыйлды әмер анда Һарун әр-Рәшид:
«Сәлли гъәүәзигә дәһ сәлли зәнид!»
Шаһең әмре берлән миргъәсәсигә
Ордылар ун сәлли бер сәллисигә.
Һарун ул дәм палудә йийәр иде,
Диде: «Боны йийең, и хубе лика,
Ибраһим алдига хазыйр әйләде.
Имди күрдек, сүзеңез варды хака».
Ибраһим, күр, соңрасынча нәйләде,
Аны күрәчәк, тәбәссем әйләде.
Күрде Һарун, сорды: «Бу нә мөстатрәб,
Бу тәбәссем итмәкендә нә сәбәб?»
Диде: «Бәндин, бел аны, шаһи зәмин,
Ул тәбәссем миргъәсәснең халедин.
Ул фәкъир кыйлды ризалыкың таләб,
Сәлли ордырырсән аңа, ул — гаҗәб!

Лик — ләкин.
Эстәйүб вәҗһе илаһ — эзләп алла йөзен (алла белән очрашуны, ягъни тугърылык юлын эзләп).
Мөрүр — юл үтү.
Дәр-рәуан — монда: барып, йөгереп барып.
Сәлли дөнбалинә орды би-әман — рәхимсез рәвештә арт санына сукты.
Гөстахилек итдең бә-зур — көч белән тупаслык эшләдең.
Ба-сәуаб — дөрслек белән, гаделлек белән (*сәуаб* — дөреслек).
Сәлли гъәүәзигә дәһ сәлли зәнид — бер сугу урынына каты итеп (үзенә) унны суктырырга.
Палудә йийәр иде — кесәл ашар иде.
Хазыйр әйләү — хәзер китерү.
Хубе лика — ягымлы йөз, сөйкемле.
Хака варды — хакка, дөреслеккә барды.
Нәйләде (нә әйләде) — ни эшләде.
Тәбәссем әйләде — елмайды.
Бу нә мөстатрәб — моның нәрсәсе көлкс.

Бу сүзи чөнкә ишетде хасс-у-гъамм,
Фәүҗе-фәүҗе күрмәгә чыкды тәмам.
Кафилә белән килерде ул гъәриб,
Калачәк Йәмәнгә бер мәнзил къәриб,
Кафиләдән айрылып ошбу газиз,
Китде тәнһачә ушал әһле тәмиз.
Бер кеше юл үзрә, әз-халкы Йәмән,
Кем мөлякъәт улды Ибраһим белән.
Диде ки: «Җөмлә Йәмән халкы бу көн
Чыкдылар Ибраһими күрмәк өчен.
Ошбу сүз чөнки ишетелде аңа,
Үз-үзенең халенә варды таңа.
Фикр идеп диде ки анда Ибраһим:
«Нигә халең йитде, и къәдәр гъәзыйм!
Сәне күрмәгә җәмигъ халкы шәһәр
Мөштакъ улмышлар килеп зир-ү-зәбәр.
Гъамм-у-хасс җөмләи халкы җиһан
Сәне күрмәклеккә мөштакъ би-әман.
Къәйу мәнзилгә йитеп сән дәр-мәкъам,
Ул ходаның гъиззәтидә йа тәмам».
Һәм пошиманлык улубән күп хитаб,
Фикр идеп үз-үзенә кыйлды гъитаб:
«Нә гөман фасид идарсән үзеңә,
Хали тәгъәҗҗеб идеп кәндүзеңә?»
Бу хитаб белән иде шаһи Бәлех
Фәүҗи килер, күрде ба-нәүхи-рәүех.

Хасс-у-гъамм — затлы кешеләр һәм гади халык.

Фәүҗе-фәүҗе — төркеме-төркеме белән.

Кафилә — кәрван.

Калачәк... бер мәнзил къәриб — бер күч җир (тукталыш) чамасы калгач.

Тәнһачә — берүзе, ялгыз гына.

Әһле тәмиз — пакьлек, сафлык иясе.

Әз-халкы Йәмән — Йәмән халкыннан.

Мөлякъәт — очрашу, күрешү.

Варды таңа — таңга калды.

Къәдәр гъәзыйм — олы язмыш; авыр язмыш.

Мөштакъ улмышлар — бик теләгәннәр.

Зир-ү-зәбәр — асты өскә (килү).

Мәнзил — тукталыш, станция.

Дәр-мәкъам — бу урында: урнашу, тукталу.

Хитаб — эндәшү, әйтү.

Гъитаб кылу — шелтәләү, әрләү.

Фасид — бозык.

Хали тәгъәҗҗеб идеп кәндүзеңә — үз-үзенә гаҗәпләнеп.

Фәүҗ — халык төркеме.

Ба-нәүхи-рәүех — елау-сыктау һәм шатлык белән.

Кем Йәмәндин чыкмыш ирде хасс-у-гъамм,
Юлда юлыкышдылар — җөмлә тәмам.
Ирешүбән, сордилар андин хәбәр,—
Солтан Ибраһим Әдеһәмдин мәгәр.
Диделәр һәм: «Сән дәгелме гъәләми
Ханы-солтаны Бәлех Ибраһими?»
Диде: «Нәчөн идәсез андин сөаль?» —
Үз-үзенә хәйран улыбдыр бу халь.
Үз-үзенең халидә хәйран ирер,
Үз эшидә башы сәргәрдан ирер.
Ул җәмагъәт гъәзб илән диде аңа,
Диде: «Нәчөн бөйлә дәйүрсән аңа?»
Сәлли ордылар аның дөнбаледин,—
Биһуш улып арды кәнде халедин.
«Әһле бәлягъәтне тәхкъир әйләмә!
Солтан Ибраһимне бөйлә сөйләмә!» —
Бөйлә куйып китерделәр Ибраһими,
Юла ордылар [вә] һәм әкъдамени.
Һуша килде, купды йирдин паке зат,
Күрде ул халкый китебдер бә-иштат.
Фикер илән дорып һәм-ан бу әфтаб,
Кыйлды вә тәфсир хитаб иду гъитаб.
Диде: «Күргел кәнде халең, и зәбун,
Һәм олугълык фикрен итмешдең дәрун.
Бөйлә ирдең сән бозорги рузегяр,
Бу көн улдың халкың арасында хар.
Бу нә гъәзамәт ирер, бу нә олугъ:
Бу нә фәзыйхәт ирер, гъаре фөругъ.
Та ки белдең кәнде халең би-гөман,
Кыйлма гъәйре һич фикер — халең чәнан!»

Сәргәрдан — башы каткан, аптыраган.
Гъәзб илән — ачу белән.
Әһле бәлягъәтне тәхкъир әйләмә — камиллек ияләрен хурлама.
Әкъдамени — адымнарын.
Бә-иштат — таралып, таралышып.
Әфтаб — кояш; бу очракта: нурлы йөз, нурлы зат.
Кыйлды вә тәфсир хитаб иду гъитаб — үзен шелтәләп, аңлатып сөйләде.
Зәбун — түбән жан.
Дәрун — күңелдә, уйда.
Бозорги рузгяр — замана олысы.
Гъәзамәт — бөеклек, олугълык.
Фәзыйхәт — хурлык, түбәнсенү.
Гъаре фөругъ — шәп хурлык.
Би-гөман — шиксез.
Чәнан — шундый, шулай.

Бөйлә дәйүб, китде ул фәхри мәзид.
Ул дийарда аны һичкемсә нәдид.
Китде андин эстәйүбән ул көрүһ,
Булмадылар эстәйүб һамуни күһ.
Солтан Ибраһимне белмәзләр иде,
Белсәләр гәр, бөйлә итмәзләр иде.

III

Көнләр эчрә бер көни дәр-рузегяр
Ибраһим бер шәһрә керде дәр-базар,
Мәмләкәт тәрк итмешигә күп зәман
Кичмеш ирде та утыз ел, би-гөман.
Ул зәманда та диле ин падишаһ
Инҗир-хөрмә улырды гяһе-гяһ.
Керде базара, идәйүм диде нуш,
Күрде-бакты инҗиру-хөрмә фөрүш.
Варды катына аның бу паке зат,
Диде: «Бәңа инҗир вә хөрмәни сат».
Диде: «Ләкин дотмазәм һичбер дирәм [14],—
Көһнә нәгълләйенемне һәм вирәрәм».
Диде: «Иске нәгълә вирмәзәм ани,
Сату кыйлмазәм — нәгъле көһнә фани».
Бөйлә дийәчәк, ишетде маһеру,
Орды әкъдамени ул юлга керү.
Ул мәкяндә бер кәмаләт әһледин
Йахшы кемсә вар иде — бер әһле дин.
Инҗиру-хөрмә фөрүшкә диде ул:
«Белмәдеңме, бу килән кем иде ул?
Шаһи Бәлехдер сәңа килән гъәриб
Һәм кәрамәт әһледер Хакъка къәриб».

Фәхри мәзид — артык мәртәбәле кеше.
Дийарда — илдә, төбәктә.
Нәдид — күрмәде.
Көрүһ — оя, урын.
Булмадылар — мәгънәсе: тапмадылар.
Һамуни күһ — сахра таулары.
Рузегяр — вакыт, чор.
Тәрк итмешигә — ташлап китүенә.
Та диле ин падишаһ — бу падишаның күңелендә.
Нуш иту — авыз итү.
Фөрүш — сатучы.
Дирәм — акча, тәңкә.
Көһнә нәгълләйен — иске агач башмаклар.
Орды әкъдамени ул юлга керу — ул юлга керү адымнарын атлады.
Мәкян — урын.
Къәриб — якын.

Диде: «Алгыл инҗиру-хөрмәңи тиз,
Чагырып, йөгер, зи-ибне гъәзиз!
Вирибән дигел аңа, и маһеру,
Инҗиру-хөрмә вирәм, дүнгел киру!
Һәр нә ки инҗиру-хөрмә, ул йийәр,
Һәрбери хакына вирәм бең динар! [15]»
Гъәкъәбдин йөгерде, диде: «И нику!
Инҗиру-хөрмә вирәм, дүнгел, бә-ту».
Диде: «Кире дүнмәзәм һәм кайтмазәм,
Тийен-тимергә динеми сатмазәм!»
Боны диде, китде базардин һәм-ан,
Инҗиру-хөрмә фөрүш дүнде, гъәйан.
Суи сахра китде Ибраһим рәуан,
Уңына-сулына бакды ул зәман:
Күрмәде сахра эчидә һичкеми,
Белмәйәләр та хали Ибраһими.

IV

Һәм мөнаҗат кыйлмага кыйлды агаз,
Диде: «И гъәни зи-гъәләм, би-нийаз,
Мәуляи мән, мәуляи мән, и хода,—
Зикрең тәмри вә хәлвани гида.
Кем сәнең зикрең, хода, раббе-л-кәрим,
Инҗир-ү-хөрмәм ирер улдыр бәнем.
Мәуляи зикрең гөлстаным дорыр,
Зикрең, и Хакъ, багый-бөстаным дорыр.
Зикрең, и Хакъ, әһле әүлядым дорыр,
Дөнйа-ахирәт вә гъәдел-дадем дорыр».

Чагыру — кычкыру.
Зи-ибне гъәзиз — газиз кешенең улыннан (син), ягъни: яхшы атаның баласы.
Кире дүну — кире кайту.
Нә ки — нихәтле.
Гъәкъәбдин — арттан, артыннан.
И нику! — И яхшы (кеше)!
Бә-ту — сиңа.
Һәм-ан — шунда ук.
Гъәйан — ачык; бу очракта: билгеле инде.
Суи сахра — сахрага таба.
Агаз кыйлу — башлау.
Гъәни зи-гъәләм, би-нийаз — дөньяның хуҗасы, ихтыяҗы юк зат.
Мәуляи мән — хуҗам минем.
Зикрең тәмри вә хәлвани гида — сине искә төшерү гидай (ярлы) өчен хөрмә вә хәлвә.
Әһле әүлядем — бала-чагаларым, нәселләрем.
Гъәдел-дадем — гаделлек бирүчем.

Диде: «Зикрең берлә без ике гъәриб,—
Ике гъәриб бере берсенә къәриб».
Боны диде, җан Хакъка асмарләде,
Даре-дөнйадин гөзари әйләде [17].

V

Бер олугъ мәҗлес улыбдыр рузегяр.
Саф кыйлубән әз-сыйгар (вә) әз-кибар.
Бер кәмалят әһледин, сахибе дил,
Көһнә җамә пушидә гъәйре җәмил.
Казый әйванына бенде зате пакь.
Казый бо (ни) күрде, улды хишемнакь [18].
Гъәзәб дотды һәм казый диде рәуан,
Боңа бакыйбән: «Ки сән, йа фәлян,—
Диде,— сән, и көһнәи җамә кийән,
Би-әдәб сән, микъдареңи белмәйән.
Микъдарең белмәй торырсән, ултырып,
Бу мәкъамдин чык, вә йа киткел торып.
Бони күрмәймүсән: балаи тәгъам
Җаиң ирмәз, ошбудыр җаи кәрам.
Кем бозорги къәдр иләндер, и кеши,
Мәхзән ирмәсдер къарилыкың эши.
Ошбу мәнзилдин улың тиз дур(и)-дур!» —
Дотды мөгъәрриф, чыгардылар бә-зур.
Диде мөгъәрриф аңа: «Й би-әдәб,
Бәңа нәчөн мәнзил итмәлен таләб?»
Диде казый: «Ул әдәбсезлек итәр,

Къәриб — якын; иш.
Асмарләү — тапшыру, бирү.
Гөзари әйләү — узып китү.
Әз-сыйгар (вә) әз-кибар — яшьләрдән һәм олылардан.
Сахибе дил — саф күңелле.
Көһнә җамә пушидә гъәйре җәмил — матур булмаган иске кием кигән.
Әйван — өй алдындагы сәке; веранда.
Хишемнакъ булу — ачулану.
Диде рәуан — ачыктан-ачык әйтте.
Микъдарени белмәйән — дәрәҗәңне, үз бәяңне белмәгән.
Балаи тәгъам — табынның түре.
Җаи кәрам — олыларның (хөрмәтлеләрнең) урыны.
Бозорги къәдр — кадерле зур кеше.
Мәхзән ирмәсдер къарилыкың эши — картлыгың кагыйдәдән тыш түгел.
Мәнзил — өй, торак; урын.
Дур — ерак.
Мөгъәрриф — кунакларны каршылап, озатып торучы хадим.
Бә-зур — көчләп.

Бу хәйа шәрм гъокубәткә йитәр».
Диде: «Сонра беләсән микъдареңи,
Гомреңә йад[19] идәсән бу гъареңи.
Сонра кыйлмайәсән ки бу кяре бар,—
Кем гъокубәт ула сәңа ошбу хар!»
Бу сахиб дил китде, утырды түбән,
Баш әлә алды тәхәййерлек белән.
Сәре хиҗаләт салып ултырды пиш,
Диле көйде атәш илән, көйде риш.
Ул түбән сафда улан дәрвише рәнг
Күрде, купды юкары бәхси бә-җәнг.
Күрде бер саф эчрә купмышдыр җидаль,
Җәнг хорусларыкеби, һәмчү къиталь.
Ошбу дәрвиш китдеке саф ирделәр,
«Ля нәсәллиму!» — дәйүб кәф ордылар.
Һәрбере истидляле әйләделәр,
Һәр нә делгә килдисә сөйләделәр.
Күп мөназарә чук улды ул зәман,
Һичбере хилл кәшф идәлмәде гъәйан.
Көһнә җамә дәр-сафе ахыртәрин,
Диде ауазилә чу шире гъәрин,
Диде: «И данә фикъһ, тәфсире осуль,
Фарикъе әбуаб, фасыйле фосуль[20].

Бу хәйа шәрм гъокубәткә йитәр — бу оят, хурлык җәза өчен җитәр.

Гъареңи — гарыңны, оят-хурлыгыңны.

Кыйлмайәсән ки... кяре бар — эшне күтәреп йөрмәссең (кабатламассың).

Гъокубәт ула... ошбу хар — җәза була... шушы хурлык.

Баш әлә алды тәхәййерлык белән — аптырау белән башын кулларына алды.

Сәре хиҗаләт салып ултырды пиш — оятка калган башын түбән салып утырды.

Диле көйде атәш илән, көйде риш — күңеле утта янды, сакал да янды (*сакал* — абруй, авторитет).

Дәрвише рәнг — дәрвиш төслесе.

Купды... бәхси бә-җәнг — мәгънәсе: сугышка әверелә барган бәхәс чыкты.

Җидаль — шау-шу, талаш, җәнҗал.

Җәнг хорусларыы — сугыш әтәчләре.

Һәмчү къиталь — нәкъ канлы сугыш.

«Ля нәсәллиму!» — дәйүб кәф ордылар — «Без кечсез!» — дип баш тарттылар.

Истидлял — дәлилләр.

Мөназарә — бәхәс; диспут.

Һичбере хилл кәшф идәлмәде гъәйан — мәгънәсе: һичбере ачыктан кичерүгә (гафу ителүгә) юл ача алмадылар.

Дәр-сафе ахыртәрин — иң ахыргы сафтагы.

Чү шире гъәрин — усал, ерткыч арслан шикелле.

Юлда бер къәрйәгә һаман йитешеп,
Йөретделәр безне миһман итешеп.
Бу фәкъир көһнә җамаә вә дәлекъ
Кимеш ирде ул заман бәйне-л-хәлекъ.
Көбара[24], данишмәндан билә мәкам,
Сохбәт идешеп алар берлә тәмам,
Һәр нә җәдаль улды ирсә ля-йөтакъ,
На-чар анлар илә кыйлдым иттифакъ.
Һәр нә диделәр, үзем тәслим идеп,
Йари улдым анлара тәгъзим идеп.
Бөйлә хальдә ошбу җамән көһән
Самигъ улды та ки бонлардин сөхән.
Ике данишмәнд һәм ике имам
Бер-берилә кыйлдылар ул хин кәлям.
Лөгъәте гарәб белән тәкърир идеп,
Сөйләйүрләр һәр нәне тәхкъир идеп.
Икесе анда идәр бонча хәдис[25]:
Күрмәмешдек бондакъин вәҗһе хәбис.
Күрмешемез юл бөйлә руи төреш,
Һич җиһанда бондакъин зәнги рәүеш.
Һәм хәкъарәт берлә илкъаи бизакъ
Садир улды бәгъдә, чүн минә-т-тәлякъ[26].
Ахире-л-эмер бөйлә на-чар улып,
Дидемез ошбу серне ачар улып.
Дидемез: «Сез идәсез фигъле хәрам,
Ул хәкъарәт вәҗһеңездә нә мәрам?

Миһман — кунак.
Дәлекъ — дәрвишләр киеме; иске кием.
Бәйне-л-хәлекъ — халык арасында.
Көбара, данишмәндан — олугълар һәм галим кешеләр.
Җәдаль улды ирсә ля-йөтакъ — чиктән ашкан талаш булса.
На-чар — чарасыз.
Иттифакъ — килешү, бер булу.
Тәгъзим идеп — олылап.
Самигъ — ишетүче, тыңлаучы.
Сөхән — сүз, гәп.
Кыйлдылар ул хин кәлям — ул чакны сүз сөйләделәр.
Лөгъәте гарәб белән тәкърир — гарәпчә сүзләр белән сөйләү.
Тәхкъир итү — хурлау, сүгү.
Вәҗһе хәбис — пычркалык йөзе; бу очракта: пычраклыкны, шапшаклыкны.
Руи төреш — сытык чырай.
Зәнги рәүеш — усал-караңгы кәяфәт.
Илкъаи бизакъ садир улды бәгъдә — соңра чәчрәгән төкерекләр барлыкка килде.
Чүн минә-т-тәлякъ — кайчан очрашкач.
Хәкъарәт вәҗһеңездә нә мәрам — хәкарәтле кыяфәт һәм торышыгызда нинди теләк (омтылыш).

Шәргъилә хәрәм беләсез, и гөруһ,
Эстәсәң айәти[27] нәссъ мин көлли вөжүһ.
Айәт илә бакасын һәм бакъ осуль,
Һәм бөйлә дидеме сәңа Хакъ рәсүл?»
Диделәр: «Кәнган үтде — вакъты хәзәр»[28],
На-җарән нәзарга кыйлдылар нәзар.
Бер-ике сүз диделәр анда гъәйан,
Һичбери гайри мәназилдер бәйан.
Ахырында кем сөкүт әйләделәр.
«Һәза әүля, һәза әшбаһ»[29], — диделәр.
Лик бу хальдә дәр-сафе данишмәндан
Вар имеш бер пире би-даниш, надан.
Безә мөлямәт белән кыйлды кәлям:
«Белмәйенчә сүзи кыйлман, и гъөлям,
Лаикъ ирмәз сәңа, и нарасидә,
Сөйләмәк бу гъөляма арасида».
Ишедүбән боны пири садәдил[30]
Хәрр кеби улды, гажиз өфтадә гөл.

VII

Сәйяр идәркән бонда фәкъире мәгәр,
Бер көне чыкдым виляйәти дигәр.
Кем тәгъәллем къәсдилән йөрмәк идем.
Күп гъәраибләр йөреп күрмәк идем.
Юлда йөреркән гизүбән бер зәман
Рәндәләр къәрйәсенә йитдек һаман.
Бер мәхәлләдә бер ивә кердемез,
Зираки кич къәрйә кергән ирдемез.

Шәргъилә — шәригать белән, шәригатьчә.
Айәти нәссъ мин көлли вөжүһ — аять мәгънәсен төрле яктан.
На-җарән — жар (боерык) ителмичә (үз-үзеннән) генә.
Гайри мәназилдер бәйан — чит җирләрнеке.
Сөкүт әйләү — сүзсез калу.
Пире би-даниш — белексез карт.
Мөлямәт белән — шелтә белән.
Гъөлям — бала, яшь егет.
Нарасидә — нарасый (үсеп җитмәгән).
Гъөляма — галимнәр.
Садәдил — саф күңелле.
Хәрр кеби улды — ут шикелле булды (кызарды).
Өфтадә гөл — өзелгән гөлдәй.
Виляйәти дигәр — башка өлкәгә.
Тәгъәллем къәсдилән — белем алу нияте белән.
Гъәраибләр — мажаралар, төрле хәлләр.
Рәндәләр къәрйәсе — хәйләкәрләр, бозыклар, исерекләр авылы; бу очракта: сөрелгәннәр авылы.
Зираки — чөнки.

Ул кичә ул къәрйәдә кунмыш идек,
Йад зәминлекдә һаман нә-хиш дидек.
Рәндәләр ул кичә безне сәмгъ улып,
Собх улачак: килде бонлар җәмгъ улып.
Диделәр: «Сезләр къәйу йирлек кеши?
Ошбу йирдә нә идәрсез, нә эши?»
Дидемез: «Болгари йирлекмез, фәлян,
Къәндил иллек [31] — сүземездә юк ялан».
Диде: «Бән Къәндили белмәзәм ки һич,
Игътимадым юк, кирәк антлари эч!
Бер гъәләмнамә [32] вирәсән безләрә,
Соңра мөгътәмид уламын сезләрә.
Юк улырсә — пайи агыр кешән
Орубән пасбанә итәрәм пиш ан!»
Ул зәман гъәләмнамә мәгъдүм иде,
Ошбу худ рәндәләрә мәгълүм иде.
Ул зәман килде гүшә банек җиррәс,
Килә пасбан, хәмел итмеш ду фәрәс.
Варакән, мәхәлләдин ауазилән
Истадә әйләделәр игъзаз илән.
Керде катыма болар, гъәрз идәчәк,
Сорды гъәләмнамә,— шаһ фарз идәчәк.
Ахире-л-әмер ки гъәләмнамәмез
Юк улачак сәхте шидкяр кямәмез.
Чөнки бу пасбан килә гъәйран улып,
Күрәчәк, китдем биһуш, хәйран улып.

Нә-хиш — жылы киемсез.
Сәмгъ улып — ишетеп.
Собх улачак — иртә булгач.
Игътимад — ышаныч.
Гъәләмнамә — билге язуы, таныклык кәгазе.
Мөгътәмид — ышанучы.
Пайи агыр кешән орубән пасбанә итәрәм пиш ан — аягыңа авыр кешән (богау) салып, шушында каравыллармын.
Мәгъдүм иде — юк иде.
Ошбу худ — моның үзе.
Килде гүшә банек җиррәс — колакка шыгырдаган тавыш килде.
Пасбан — каравылчы.
Хәмел итмеш ду фәрәс — ике атка йөк төягән.
Варакән — бара икән.
Истадә әйләделәр игъзаз илән — дәшеп алдылар хөрмәт белән.
Гъәрз идәчәк — гарыз иткәч, белдергәч.
Гъәләмнамә шаһ фарз идәчәк — шаһ фарыз итәчәк таныклыкны.
Сәхте шидкяр кямәмез — мәгънәсе: омтылышларыбызның нәтиҗәләре авыр.
Гъәйран улып — гайрәтләнеп.
Биһуш — һушсыз.

Нәгяһән, ул дәмдә пасебан татар
Бу тәхәййердә керибән тотар.
«Кем китертде анда ул агыр кешән?»
Диде халкъә: «Пайина аны көш ан!»
Бөйлә мәшгульде болар бәнем белән,
Хәүф эчендә бән җане-тәнем белән.
Ул зәман мәхәлләдин, рәуәндекән,
Ауази килде гүшемә ул зәман;
Кичәр ирмеш бер тәүангири гъәни,
Юлда бу халь белән күрде ул бәни.
Гъәрбәтемне күрде, бөйлә халеми,
Миһре килде рәхм илән әшкялеми.
Аны белдем бер тәүангирмеш гъәйан,
Һәм кәмалят әһледин улды бәйан.
Күп җиһандидә, аны азмудадер
Һәм җиһангиз, һәм раһе нөмүдәдер,
Килде бонлара һәзар гъәйрәт белән,
Боны күреп калдылар хәйрәт белән.
Катына варып [33] сәлями әйләдем
Һәм мөсафәхә тәмами әйләдем.
Соңра сүз күп әкрамилә сөйләдем,
Халеми гъәрз игъламилә сөйләдем.
Соңрасынча, шәфкъәти күп зад итеп,
Алды бонлардин бәни азад итеп.
Һәр нә кем къәсд әйләде ул безләрә,
Орды анлара тапанчә йөзләрә.
Пасебани татари анчә торып,

Бу тәхәййердә — бу аптырап торган чакта.
Пайина... көш ан! — аякларына сал аны!
Мәшгульде — мәшгуль иде.
Рәуәндекән (рәуәндә икән) — узып бара икән; монда: узып барган чакта.
Тәүангири гъәни — бай сәүдәгәр.
Гъәрбәтемне — монда: әсирлегемне.
Миһре килде рәхм илән әшкялеми — чыраена рәхим-шәфкате чыкты.
Күп җиһандидә, аны азмудадер — күп җиһан (дөнья) күргән, аны сынаган.
Раһе нөмүдә — юллар күргән (юллар узган).
Һәзар — мең.
Хәйрәт белән — гаҗәпләнү белән.
Мөсафәхә — кул кысышу.
Әкрамилә — хөрмәт белән.
Гъәрз игъламилә — аңлатып, төшендереп.
Зад итеп — юллык азык биреп.
Тапанчә ору — яңакка сугу.

Әйләде әбсәм, ду тапанчә орып,
Диде: «Бән боны беләрем һәм йирен»,—
Шәрх идеп сөйләде хами һәрберен.
Бөйлә анлардин бәни итде фиракъ,—
Ошбу рәндә къәрйәсендән күп ерак.
Зәһи ник мәрди, миһербанлигъ кеши! —
Пакизати мәрдан, ихсанлигъ пиши!
Ул ходауәндә кәрим һәрдәм бони
Рәхм илән нәзар идә көни-төни.
Һәр ике дөнйада чикмәсен әләм,
Һәм аның гъиззәтидә фәкъир ирә[34].
Һәм жиһанда дәүләтен артык идә,
Аңа игъдаэ кем ула — бар юк идә.
Һәр ике дөнйада чикмәсен әләм,
Дәүләте заид уладыр дәм-бә-дәм.
Күрмәсен зәррә жиһандин гъилләти,
Көн-бә-көн Хакъ артык идеп гъиззәти.
Бәңа һәм аңа ходауәнде рәкъиб[35]
Сәгадәте-д-дарәйн кыйлсын нәсыйб.

VIII

Бер көни[36] гъәиде зоха укыр идек,
Йад шәһәрдә кәндемез улыр идек.
Көһнә жамә берлән ирде халемез,—
Дәстаремез, жамәмез һәм шәәнемез.
Әүүәлән вәгъәз-нәсыйхәтлән имам
Ултырырды халкъә сөйләрде һөмам.
Бер кеше дорды ауазилән бу халь,

Әбсәм әйләү — авыз йомып тору: дәшмәү.
Ду — ике.
Хами — хикәяче, яклаучы.
Фиракъ итү — коткару.
Зәһи ник мәрди — нинди чын ирләрчә яхшы.
Пакизати мәрдан, ихсанлигъ пиши — табигатьтән пакь, кешелекле ир.
Игъдаэ — дошман, каршы.
Бар юк идә — барысын юк итә.
Әләм — кайгы, бәла-каза.
Заид уладыр дәм-бә-дәм — өзлексез артып торсын.
Гъилләт — чир, авыру.
Сәгадәте-л-дарәйн — ике дөньяның бәхетен.
Гъәиде зоха — иртәнге гает намазы.
Кәндемез — үзебез.
Дәстаремез — чалмабыз.
Шәәнемез — дәрәжәбез; бу урында: барлыгыбыз-булганыбыз.
Сөйләрде һөмам — шәп итеп сөйли иде.

Мәгърузән ли-нәфсәи кыйлды сөаль.
Белмәде фарз ирдекен аның имам
Диде: «Бу сөальдә хасыйль юк мәрам,
Кем, сорарсән шәргъ эчендә юк сүзи,
Юк сүз илән кыйлма мәшгуль сән безн!»
Бони бакып ирде би-дана фәкъир,
Көһнә җамәләр белән зар хәкъир.
Гәр тәкәллем әйләсә, лаикъ имәс,
Сөйләмәсә уладыр, хакы димәс.
Эш ахыры иттифакъ боңа дөшеп,
Агаз әйләдек, тәкәллем идешеп.
Дидемез аңа: «Сән аңла би-жидаль,
Юк сүз ирмәз ул кеши сорган сөаль.
Фарз ирер, бакъ, айәт илән белмәгә,
Гъәрзымез юк зәррә җәдаль итмәгә».
Кем гаҗәб ирер гъөләмаи зәман,—
Мале дөнйа гъәрзи бозорги әз-ан.
Гәр аны белмәз исә, мәнгъ алмасын,
Сөйләсен, ләк әмре фәзъигъ атмасын [37]...

IX

...Күп фәсадәтләр җиһанда кыйлдылар,
Заль мөзыйль сир-ү-ниһанда кыйлдылар.
Җаһилә әйләделәр күп иҗтиһад,
Та ки кәндене идә ул игътикад.
Хакъны белде, һәм къәйусы белмәде,
«Худ беләмез» дип Хакъа һич килмәде.
Галим үз къәдрене бөйлә тәрк идеп,

Мәгърузән ли-нәфсәи — нәфес кушканча әйтеп (белдереп).
Сөальдә хасыйль юк мәрам — сораудан максат хасил булмый, ягъни: буш, мәгънәсез сорау.
Би-дана — белемсез.
Тәкәллем әйләү — сөйләү.
Иттифакъ — килешү, берләшү.
Агаз әйләү — башлау.
Би-җидаль — талаш-бәхәссез.
Гъөләмаи зәман — замана галимнәре.
Мале дөнйа гъәрзи бозорги әз-ан — теләгәне дөнья малы һәм кешенең аша зур дәрәҗә.
Мәнгъ алу — тыю алу.
Әмре фәзъигъ — начар әмер, ямьсез боерык.
Фәсадәтләр — бозыклык, азгынлыклар.
Җаһилә — наданлыкка.
Заль мөзыйль сир-ү-ниһанда — яшерен, сер итеп юлдан язу эшләре.
Худ беләмез — үзебез беләбез.
Тәрк идеп — ташлап, бетереп.

Симе-зәр чөн нәфсен тәхәррек идеп,
Галим улмады кем, улды ул бә-зир,
Лик галим улды шаһә хассе вәзир.
Бәгъзи гъәдауәт беләи ул бә-гъәзаб,
Нәфсани ләззәти идүбән таләб.
Къәндадыр ки ул гъәзизане зәман,
Бу дәре-л-хәребдә китде әз-мийан.
Һәрни газиз улдисә хар улдылар,
Багълара гөл калмады — хар улдылар.
Садир улды бәгъзы әз-мәргъиан,
Кәндеңә ихлас кыйла та дагъиан.
Нәфсе гакыл нәфсенә шәйда улып,
Чук харыклары килеп, пәйда улып,
Бу халә мөгътәкъид улдылар гъәуам,
Баш ийәр улдылар аңа бәр-дәуам.
Һәм гаҗәбе галиман даре-л-хәреб
Мәкъсаде-л-къәрбе солтане-л-къәреб.
И бәрадәр, тәрке гъизз-у-җаһ ит,
Һәм сакыйнгыл, тәрке къәрбе шаһ ит:
Къәрбе солтан уладыр җанга бәля,
Улмагыл боның белән сән мөбтәля!
Галәми Хакъ әйләде хассе җиһан,
Хакъ белән әмер итмәк кәшфе ниһан.
Гәр хәуас керсә зәляләтдин юла,
Табигъ улан би-тәрикъ әүля ула.

Нәфсен тәхәррек иту — нәфесне хәрәкәтләндерү, аздыру.
Бә-зир улу — түбәнгә китү.
Шаһа хассе вәзир — шаһка лаек вәзир.
Гъәдауәт беләи ул бә-гъәзаб — дошманлык белән газапланып.
Гъәзизане зәман — замана газизләре.
Бу даре-л-хәребдә китде әз-мийан — бу сугыш мәйданында уртадан китте.
Гөл калмады — хар улдылар — гөл калмады, тигәнәккә әйләнде.
Садир улды бәгъзы әз-мәргъиан — кайберләре чүп-чардан барлыкка килде.
Дагъиан — догачылар, сораучылар.
Нәфсе гакыл нәфсенә шәйда улып — үз нәфесе белән шашып.
Чук харыклар — күп башбаштаклыклар.
Мөгътәкъид — ышанучы.
Бәр-дәуам — өзлексез.
Галиман даре-л-хәреб — сугыш йорты галимнәре.
Мәгъсаде-л-къәрбе солтане-л-къәреб — якынлыктан максат — солтанга якын булу.
Тәрке гъизз-у-җаһ ит — олугълык һәм дәрәҗәне ташла.
Тәрке къәрбе шаһ ит — шаһка якынлыкны ташла.
Улмагыл ... мөбтәля — дучар булма.
Хассе җиһан — дөньяның сайлаганнары, яхшылары.
Кәшфе ниһан — серләр ачу.
Хәуас — аксөякләр.
Зәляләт — адашу, хак юлдан язу.
Табигать улан би-тәрикъ әүля ула — буйсынган юлсыз (надан кешеләрдән) өстенрәк була.

X

Мөнаҗат (А) [38]

Йа иляһи, агыр улды баремез,
Би-гъәдәд улды кыйлан әүзаремез.
Китде күзем күр вә әгъма улып,
Юлыми китдем язып игъва улып.
Йа иляһи, гъувиртә әбсаруна
Куссыйртә вә күвиртә әбсаруна [39].
Юл языпмын, и ходаүәнди кәрим,
Белмәзәм, къәндә варисәрмән һәрим.
Нәфсе шәйтан алды бәнем юлыми,
Көлле әшрарә кичерде кулыми.
Ошбу ләгъин җаныма орды рәкъәм,
Къәлбемне салды бәр-әүҗагы сәкъәм (...)
Нәфсе шәйтан орды бәнем җаными,
Җөмлә алями алып дәрмаными.
Фазыль гъинайәтең илән, и Әхәд [40],
Сакла андин, әйләгел бәңа мәдәд.
Гәрчә бәндәмен гъәрыкъ бәхре гөнаһ,
Ләк сәнең күп фазле ләтфың, и иляһ!
Күп зәманлар фисъкы гъисйанда идем,
Фигъле фәсадәт вә тогъйанда идем.
Нәфсе шәйтан дөнбалем кыйлды рөкүб,
Кыйлды дөнбалемдә ул әшрари күб.
Һич бәнемдик улмайа әһле-з-зәнүб
Имтиляәт бәйне-ш-шималь вә-л-җәнүб.

Баремез — йөгебез.
Әүзар («визер»дән) — гөнаһ.
Күр вә әгъма — күзсез һәм сукыр.
Игъва — адашу, туры юлдан чыгу.
Һәрим (һәрәм) — таушалган, тузган; картайган.
Рәкъәм — тамга, билге.
Бәр-әүҗагы сәкъәм — авыру-чиргә.
Җөмлә алями — барлык кайгыларны.
Фазыль гъинайәтең — өстенлегең, мәрхәмәтең.
Мәдәд — ярдәм.
Гъәрыкъ бәхре гөнаһ — гөнаһ диңгезенә баткан.
Фазле ләтфың — күркәм олылыгың.
Фисъкы гъисйанда — бозыклык һәм фетнәдә.
Фигъле фәсадәт вә тогъйанда — бозык уйда һәм азгынлыкта,
Дөнбалем кыйлды рөкүб — биләмә (аркама) атланып алды.
Кыйлды дөнбалемдә... әшрари күб — аркамда күп начарлыкларын кыйлды (өйде).
Әһле-з-зәнүб — гөнаһ әһеле, гөнаһлы кеше.
Имтиляәт бәйне-ш-шималь вә-л-җәнүб — төньяк һәм көньяк араларындагы барлык җирдә.

Гәрчә мин бәхре мөгасыйда гъәрыкъ,
Ләк сәнеңдер бәхре әлтафың гъәмикъ.
Бары гъәрзем улдыр сәңа, и шәфикъ,
Фазыль гъинайәтең әйлә, и рәфикъ (...)
Гәрчә гасый вә гөнаһкяр бәндәмен,
Ләк хозурыңда өмиддар бәндәмен (...)

Мөнаҗат (Б)

(...) Мөстәкъимдер юлы вә шәргъе рәсүл,
Бәни һәм ошбу юла әйлә кабул.
Мөстәкъим юлдин, ходайа, әз-тәрикъ,
Кыйлмагыл бу бәндәне андин сәхикъ.
Бу Мөхәммәд раһедин сән күземи
Алма, гъәйре юла салма үземи (...)

Мөнаҗат (В)

Йа иляһи, гаҗизәм, зарәм зәлил,
Бән гөнаһлык бәндә, сән — гафир җәлил,
Бән гөнаһлык бәндәдермен, сән — гъәфур,
Дагъи хакдыр сән, ки бән — әһле нәфур.
Гаҗизәм, дәрмандәйәм, дәстәм ба-дар,
Юк исә юкдыр бәңа гъәйри мәдар (...)
Къәлбем агърый алям алды дилеми.
Бу ләгъин кәндеңә салды мәйлеми (...)
Йа иляһ, ярлыка Гъәбделҗәббари,
Күп өмидем вар зи-исме-л-гъәффари!

Бәхре мөгасыйда гъәрыкъ — гөнаһлар диңгезендә гарык.
Бәхре әлтафың гъәмикъ — изгелек диңгезең тирән.
Шәфикъ — шәфкатьле.
Рәфикъ — дус, иптәш.
Мөстәкъим — туры.
Шәргъе рәсүл — пәйгамбәр шәригате.
Әз-тәрикъ — юлдан (чыгарма).
Сәхикъ кыйлу — ерак кылу.
Раһедин — юлыннан.
Зәлил — түбән, хурлыклы.
Гафир җәлил — бөек кичерүче, ярлыкаучы.
Гъәфур — гафу итүче.
Дагъи хакдыр сән, ки бән — әһле нәфур — син хаклыкка өндәүче, ә мин — качучы.
Дәрмандәйәм — моңлымын, көчсез, зәгыйфьмен.
Дәстәм ба-дар — кулларымнан тот.
Гъәйри мәдар — башка житәкләүче.
Алям алды дилеми — кайгы-хәсрәт басты күңелемне.
Зи-исме-л-гъәффари — исеме гъәффарлыкка ия заттан.

XI. Мөәллифе пәнд ба-худ гөфтәнәш [41]

И фәкъир Гъәбделҗәббар, аңла сән ани,
Къәни сәндә Хакъ, гъөбүдийәт къәни?
«Гъәбде» атын [42] алдың [43] исемдә, и йар,
Къәни әфгалеңә һәм улмакый йар?!
Заһирән «Гъәбед» батыйның дәр-нәфүр,—
Гел уласән ошбу нәфрәтдин йәхүр.
«Гъәбд» улып, къәндә гъибадәт кыйлмышың? —
Көн-бә-көн артды фәсадәт кыйлмышың.
Хакъ дисә таңда: «Къәни ник кыйлганың?
Бер җәһәтдин бәңа сән кол улганың?
Тәнең эчендә гъәзиз җан әйләдем,
Һәм аңа куәте дәрман әйләдем;
Бәһаим итмәдем, инсан әйләдем,
Ризкъилә ингъаме ихсан әйләдем.
Һич сагъәтдә зәррә нисйан итмәдем,
Золем-лән һич сәндә гъисйан итмәдем.
Адәм әйләдем, шәйатин итмәдем,
Инсан әйләдем, кара тыйн итмәдем.
Кол итеп, дөнйага салдым бән сәни,
Гакыл вирдем таныгайсән дип бәни.
Ихтиари җөзәи вирдем бән саңа.
Къәни, айгыл: нә китердең сән бәңа?
Бәңа айгыл: къәни тагъәтең сәнең?
Къәни, айгыл сән: гъөбүдәтең, мәннең?
Къәнидыр сән бәңа тагъәт кыйлмышың?
Къәни һәм әмремә итагъәт кыйлмышың?!
Бу сөальләр улса, и мескин гида,
Нә җәуабың вар бе-дяргяһи хода?
Күп хиҗаләткә уласән ул зәман,—

Гъөбүдәйәт къәни? — буйсынучанлык, аллага коллык кайда?
Әфгалеңә — ният-эшләреңә.
Заһирән ... батыйның дәр-нәфүр — ачык ки... эчтән нәфрәтле син.
Уласән ... йәхүр — буталасың, йотыласың.
Көн-бә-көн — көннән көнгә.
Ник кыйлганың — яхшылык, игелек кылганың.
Бәһаим — хәйван, терлек-мал.
Ингъаме ихсан әйләдем — байлык бүләк иттем.
Нисйан итмәдем — онытмадым, хәтердән чыгармадым.
Золем-лән (золем илән) — золым белән.
Кара тыйн — кара, пычрак балчык (ләпек).
Җөзәи — тән әгъзалары.
Къәни, айгыл — кайда, әйтче.
Мәннең (мәнн — миннәт) — яхшылыкны искә алуың.
Бе-дяргяһи хода — ходай каршысында.
Хиҗаләт — оялу, уңайсызлану.

Ул ходаның къәһридә сән кол һаман!
Къәни Хакъа нә идисәр сән гъәрыз,
Тагъәти гъибадәт әз-нәфел, фарыз [44]?
Һәм дәхи ул хиндә сәңа дисә Хакъ:
«Гакыл вирдем, дәсте-пайи, күз-колак,
Та гөнаһдин кыйла дәйү ижтинаб,
Гәр кыйлурса да, уладыр иститаб».
Бу гөнаһлар билә пише зә-л-гъәля
Къәйу ир хөссад берлә варар сән һәля.
Йир йөзе дулмыш гөнаһең-лән бу халь,
Фәрдән фәрд [45] һәр бересе кәл-җәбаль.
Гәр бакып күзең аңар, кыйлсаң мәсыйр,
Йәнкъәлибү хасиән вә һу хәсир [46].
. . . .
. . . . [47].

Нә идисәр сән гъәрыз — син гарызыңны (үтенечеңне) ничек әйтерсең.
Тагъәти гъибадәт әз-нәфел, фарыз — нәфелдән, фарыздан гыйбадәт намазларың.
Ул хиндә — ул чакта; ул арада.
Дәсте-пай — кул-аяк.
Ижтинаб — читләшү, баш тарту, качу.
Уладыр иститаб — тәүбә итүче буладыр.
Пише зә-л-гъәля — бөеклек иясе (алла) алдында.
Хөссад берлә варар сән һәля — көнчелек, күңел тарлыгы белән синең рәвештә барыр.
Фәрдән фәрд — аерым-аерым; берәмләп.
Кәл-җәбаль — тау шикелле.
Кыйлсаң мәсыйр — нәтиҗә чыгарсаң.

ШӘФГЫЙ

I

Сәламләр әйләдем, Шәфгый [1],
Сәламәт итсен ул әгъля,
Тулун айдик йөзең кыйлсын —
Һәмишә көн-бә-көн әҗля.

Бәет яздым сәлам артын,
Сәнең күркәмлекнең сартын,
Йаңакларың кызыл алтын
Кеби итмеш ушал мәүля.

Әйа җаным, абызтаем,
Кызыл йөзлек тулун аем,
Сәнең өчен кышым-җәем [2]
Үтәр кайгыда һәр хәуля.

Җәмал базарларын [3] гиздем,
Нәчә йирдә җәмал сиздем,
Нәзар дәрйаларын гиздем —
Ки сәндин тапмадым әүля.

Әгъля — өстен, бөек (алла күздә тотыла).
Көн-бә-көн әҗля — көннән көн яктырак, нурлырак.
Сартын — өчен.
Мәүля — алла.
Хәуля — аулаклык; монда: ялгызлык.
Җәмал базарларын — матурлык базарларын.
Нәзар дәрйаларын гиздем — монда: бик күп күзәтүләр кичердем.
Тапмадым әүля — яхшыракны тапмадым.



«Шәфгый» әсәре кульъязмасыннан фотокүчермә (КДУ, ФК КБ № 238 т. кульъязма).

II

Колак салып ишет, Шәфгый,
Идәем бер хикяйәти:
Сәңа гашыйк улып, Шәфгый,
Идәем бер шикяйәти.

Йаратыбдыр сәне ул Хакъ
Кызыл йакут кеби һәм ак,
Йөзеңә салды чук [4] рәүнәкъ —
Идүбән күп ригайәти.

Буйыңны [5] әйләде гөлдик,
Сачеңне кыйлды сөнбелдик,
Ауазың итде былбылдик —
Идеп фәзъле гъинайәти.

Сылу әйләде үзеңне,
Тулун ай итде йөзеңне,
Идеп нәргистәй, күзеңне
Матур итде бигайәти.

Кашыңны әйләде кара,
Ачык итде ике ара,
Һилялә охшатды вара —
Чигелмеш [6] биниһайәти!

Ходаем әйләмеш яхши,
Сәңа салмыш бөйлә нәкъши,
Йөзең нурлы идеп яхши,—
Үзеңдиндер бер айәти [7].

Йөзең биңзәр тәмам айа,
Күрәнләр хур дәйүб сайа,
Сәңа охшашлы, әйт, кайа? —
Йә кәлдең бер бидайәти?

Йөзең охшар кызыл ләгълә,
Йөзеңдин нур берүк агъла [9],

Шикяйәт — зар.
Рәүнәкъ — нур, яктылык.
Ригайәт — тәртип, игътибар.
Идеп фәзъле гъинайәти — олы күңеллек белән бүләкләде.
Бигайәти — чиксез.
Һилялә охшатды вара — айга охшатты барысын.
Нәкъши — нәкышне: сурәтне, бизәкне (матурлыкны).
Сайа — саный.
Биңзәр ... айа — айга охшар.
Бидайәти — өр-яңа күренеш (башлангыч) сыйфатында.

Күрəчəк күзлəрем чагъла,
Көнəш кеби сөрайəти [10].

Күзең кешегə бакылыр,
Күзеңдин удлар [11] сачылыр,
Көлүбəн садрем йакылыр,—
Көйдерер һəм бу сагъəти!

Ки ак йакут кеби балкып,
Ике садрең дорыр калкып,
Ки күлмəк үтəдин балкып,
Нуры улыр гъəлямəти.

Гъəҗəб лəтыйфəдер җисмең,
Ки белмəдем нəчек исмең,
Йөрəгем-бəгъреми кисдең,
Ки күргəзеп җəмалəти.

Билең нечкə, буең һəм төз,
Тəнең саф, гүйə ки акбүз,
Əгəр дирсəң дə сəн бер сүз,
Укыр идем йөз айəти! [12]

Гъəҗəбдер, белеңез анчə:
Лəбең лəгъел, дешең гъөнчə,
Юк ирде күрдекем бончə —
Күрүбəн күп кəмалəти.

Үзең сылу, йөзең күркəм,
Нəчə дисəм дə улыр кəм:
Язарга йитмəйүр дə һəм
Кəгазь, кара, мəкъалəти.

Кашың кара сызылмышдыр,
Дешең инҗү дезелмешдер,
Йөрəк-бəгърем өзелмешдер
Гыйшык дотып сəңа къати.

Көнəш кеби сөрайəти — монда: күклəрдəге кул җитмəслек кояш кебек.

Көлүбəн садрем йакылыр — көлүгə күкрəгемə ут кабыныр.

Сагъəти — сəгатьлəрдə.

Лəтыйфə — матур, күркəм.

Җəмалəти — матурлыкны, күркəмлекне.

Айəт — Коръəн шигыре; монда: дога.

Лəбең лəгъел, дешең гъөнчə — иренең рубин, тешең чəчəк бөресе.

Кəмалəти — камиллекне.

Мəкъалəт — сүз, образлы сүз, үткен сүз.

Сачең кара ирер төндик,
Сачең ара йөзең көндик,
Улып мән имди Мәҗнүндик [13]
Идеп гыйшык хийаләти [14].

Сәнең өчен, әйа җаным,
Тәнемдә калмады каным,
Бетебдер дәрде-дәрманым
Күрәчәк улып халәти.

Әйа җаным, кызыл алмам,
Ки сәндин һич күңел алмам,
Барырса, гъәйрене алмам,
Идеп сәңа мөлакъәти.

III

Йөзеңне күрәчәк, Шәфгый,
Күземдин йәш улып йагъмур,
Дидем: «Дөньяда вар микән
Бу Шәфгыйдик сылу мәгъмур?» [15]

Дигел, Шәфгый, ничек итдем,
Гыйшыкдин саргаеп бетдем,
Кибеп, корып бетеп әйтдем —
Тәнемдин улды ул мәһҗүр.

Сүзем язылды күп төрле,
Тагын да әйтәем берне:
Яратмасаң да, бу серне
Халыкга итмәгел мәшһүр.

Делең ирер тутый гөфтә,—
Гъәкыйкы дотасән шәфтә,
Күрәчәк улдым ашөфтә,—
Гыйшыкыңда улып мәкъһур.

Көндик — көн кебек, кояштай.
Хийаләти — шашу.
Мөлакъәт — кавышу, ирешү.
Мәгъмур — яратылган, төзелгән.
Мәһҗүр булу — аерылу, чыгу.
Тутый гөфтә — тутый кебек сөйләүче.
Гъәкыйкы дотасән шәфтә — ахакны арзан бәялисең (тешләреңне күп ялтыратып сөйлисең).
Ашөфтә — борчулы, борчылган.
Мәкъһур — каһәрләнгән.

Әгәр улсамиде мокътад,
Сурәтләр кыйлмага остад,
Сурәтеңне ясатып һәфтад,
Итәрдем халкъара мәншүр.

Хисабларммын вәли сезне,
Дәйүр күңел ки сүзене:
«Ки санга сукмый бу безне»,—
Язарга уладыр мәгърур.

Нә өчен язмаем сезни? —
Сагышыңдин күңел түзми,
Һәмишә өмиден өзми,
Әгәрчә гыйшкыйлә мәхсүр.

Йөзең [16] охшар ки фируза [17],
Нурың биңзәр сәнең руза,
Җәмалең кем күреп уза,
Уладыр шул заман мәсрүр.

Серемдер сән канатымга,
Кабулың юкса хатымга,
Йибәргел кире катымга,—
Дота күрмә идеп мәэсүр [18].

Йөзеңезгә күзем бакды,
Күземдин канлы йәш акды,
Ки гыйшкың удына йакды
Йөзеңездәге якты нур!

IV

Колак салып ишет, Шәфгый,
Ки сөйләем сәңа бер дөш.
Ирәм багында [19] имеш сән,
Ки сайрарсән улып бер кош [20].

Сүземне сөйләем башдин,
Хәбәр виреп каләм кашдин,

Мокътад — җитәкче, әмер бирүче.
Остад — остаз, оста.
Һәфтад — җитмеш (мәртәбә).
Мәншүр итү — нәшер итү, тарату.
Мәхсүр — хәсрәтле.
Руз — көн, көндез.
Мәсрүр — шат, сөенечле.
Хатымга — хатыма.
Мәэсүр — әсир, тоткын.

Гашыйк улып кече йәшдин,
Йөрер идем улып сәрхуш [21].

Кырыңыздин китәр чакда,
Илеңездин үтәр чакда,
Ивеңезгә йитәр чакда
Үтә ирдем улып мәдһуш [22].

Сагышында нәчә елым
Үтәр ирде, и былбылым,
Илеңездин иде юлым,
Сәне булсам иде дип туш.

Сагышым көндә тәшвишдә,
Кулым вармаз иде эшкә;
Кичә ятсам иде төшкә
Керәр ирдең бизәнеп хуш [23].

Гыйшыкыңны дотып эчдә,
Йокым кәлмәс иде кичдә,
Дәхи көндезләрен һич дә
Сагышдин улмадым мин буш.

Ки бер кичен оер ирдем,
Йокымда бөйлә [24] дөш күрдем:
..ауадин кош булып йөрдем —
Сезгә варам имеш мән уш.

Варам иркән очып ялгыз,
Сәне эстәп, әйа мәхбүб,
Юлымны язган имешмән
Буран чыгып, улып мәхҗүб [25].

Юлыкып бер нәчә ирләр:
«Ки къәнда варасән?» — дирләр.
Дидем: «Соң бу кайу йирләр? —
Юлым яздым, улып һәмйуб [26]».

Берсе: «Соң,— диде бәңа,—
Кайу юллар кәрәк сәңа?»

Илеңездин — авылыгыздан.
Мәдһуш булу — аптырау, куркуга төшү, югалып калу.
Туш булу — туры килү, очрау.
Сезгә варам имеш мән уш — сезгә барам имеш мин шулай.
Мәхбүб — сөекле.
Мәхҗүб булу — томанлану, караңгылану.
Къәнда варасән — кайда барасың.

Ишедәчәк идем: «Къәни
Ирәм багынадыр мәнсуб.

Бу Шаһбан падишаһ тагы,
Моның алда Ирәм багы.
Бакарсам сул белә сагый,
Ирәм багы ирер мәкъруб.

Күрәм ки, багы Ирәмдер,
Эчидә яхшы хәрәмдер.
Бизәнеш бу кадәр имеш,
Күнел яраткудик мәргъуб...
. . . .»[27]

V

. . . .
. . . .

Хисаб итдем — улдым хәйран[28],
Әйа җаный, ки бу эшдин,
Кичә ятсам, чыка белмәз
Буең-төсең сәнең дөшдин.

Йә сурәт кыйлгучыларга
Сәнең өчен варыйм микән? —
Сөеп йөргәннәрең, җаный,
Китә белмәс күз алдымдин.

*

Ә(йа).......... иленең[29]
Сылу йөзлек нәзек биле,
Нәтә тигермидер сәңа
Сәламемне сәба йиле?

Әйа .... иленең
Тутыйсы, тайре былбылы,
Нә ул шәгъәфең[30] бере —
Йакарсың бер генә юлы.

Мәнсуб — караган, кергән; мөнәсәбәтле.
Сул белә сагый — сул белән уңга.
Мәкъруб — якын.
Хәрәм — хатын-кыз өе; хәрәмсарай.
Мәргъуб — әйбәт, яхшы.
Нәтә — ничектер; нигәдер.
Тайре былбыл — былбыл кошы.
Шәгъәф — көчле ярату, мавыгу.

Йараткан бер дандәй барың,
Идүбән талигъә йарың;
Сәнең улсын нигяһ даның,
Газиз гомрең идеп тулы.

VI

Нәчә мәдх илә язсам да
Төсең, буеңны, и Шәфгый [31],
Гыйшыкның утына һәргиз
Табалмадым дәуа(и) рәфгый.

Нәчә мәдх әйләсәм бетмәс,
Гакыл дәхи фәһем итмәс,
Кәгазьдә һәм кара йитмәс
Язарга сурәтең, Шәфгый [32].

Йефәк сачле башыңныму,
Яңы айдик кашыңныму
Һәм унбишдә йәшеңнему,—
Нә мәдх илә идәм рәфгый?!

Ак инжү кеби дешеңне,
Сәйиз әжнай (?) [33] йөрешеңне,
Ак алмадай ки түшеңне [34] —
Кайу берин язам, Шәфгый? [35]

Билең нәзек, буең талдый [36],
Үзең гөлдәй, йөзең айдый,
Күрәчәк сабърыми алдый,—
Дәуалар итмәйүр нәфгый.

Шикәр-балдик делеңнемү,
Дәхи нәзек билеңнемү,
Йә түшдәге геңәңнемү —
Кайу берин дийәм, Шәфгый?! [37]

Бер дандәй — монда: бер төсле, охшаш.
Талигъә — бәхетле.
Нигяһ улсын — саклансын, исән булсын.
Мәдх — мәдех; мактау, данлау (сүз бер ижекле итеп укыла).
Дәуа(и) рәфгый — бетерүче дәва, хәлиткеч дәва.
Нә мәдх илә идәм рәфгый — нинди мактау белән (тасвирлап) бетерәм.
Күрәчәк сабърыми — күргәч сабырымны.
Итмәйүр нәфгый — файда итми.

Йөзең [икән] тулун айдый,
Ике кашың ике йайдый,
Сачең тарар исәң, жаный,
Булыр гүйә кара рәфгый [38].

VII

Төсең-буеңны, и жаный,
Қайу берин язам, жаный,
Табынмасын саныңа саный (?)
Сурәтеңә бакып, жаный [39].

Қызыл алтын йаңакларың,
Ләгъле-мәрҗан дудакларың.
Дил алырдай кочакларың,—
Қайу берсен язам, жаный! [40]

Йә ожмах хуры идеңмү,
Булып [хур] йиргә индеңмү?
Вә йаки монда килдеңмү
Ирәм багындин, и жаный?

*

Делең фәсыйх, сүзең датлу,
Бәдигъә [41] кеби сурәтлү,
Жиһанда сәнди сыйфатлу
Ки зиррә тапмадым сәмгый.

Үзеңезә варан көндә
Урамда идең ул хиндә,
Қүренден капка эчендә —
Нурың балка ки чү шәмгый.

Догалы урынга калдың,
Сылулык берлә дан салдың,
Қүрәннең такъэтен алдың
Йөзең нурилә кил (?), мөзый.

Ике йайди (ике йайдай) — ике җәядәй.
Булыр гүйә кара рәфгый — гүя кара (төс) юкка чыгар.
Дудакларың — иреннәрең.
Дил алырдай — җанны алырдай.
Делең фәсыйх — сүзең матур, ягымлы.
Тапмадым сәмгый — ишетеп тә белмәдем.
Ул хиндә — ул чакта, ул мизгелдә.
Чү шәмгый (чун шәмгый) — шәм шикелле.
Мөзый — яктырып, нурланып торучы.

Ишеткел сүземне, йарә,
Гыйшкың — бәгъреми парә,
Дәуа ит, яки — бер чарә,
Күреп күземдәки дәмгый [42].

VIII

Сурәтеңне күреп анда,
Дидем: «Боның кеби къәнда?»
Уяндым — дәре мандә,
Тәмам күңлем идүбән җуш.

Сагышында бәңа бу дәм
Караңгы яктыран галәм.
Бәнемдик вармы бер адәм
Тәмам гомри үтән намуш?

IX

Бу мәхрүмлекдә куйганча
Гашыйклар тыйгыны куйгыл,
Сәнең кулыңдин үтәем,—
Кәлеп, газиз башым йуйгыл.

*

Исем китәр сәңа, җаный,
Дилең каты икән ташдый.
Тәрәххем берлә бакмазсән,—
[Ки] гыйшкым хәддин ашдый.

*

Ки ачыйгъланмагыл җаный,
Нәчән хат яза дип бәңа,
Әгәр белсәң иде гыйшкым,—
Калдырдың шул зәман хальгә [43].

Күземдәки дәмгый — күзләремдәге яшьне.
Дәре мандә — авыр хәлдә калу.
Күңлем идүбән җуш — күңелемне дулкынландырып, борчып.
Намуш — елап, сыктап.
Тыйгыны куйгыл — кылычын сал (мәхәббәткә кылыч сал).
Йуйгыл — җуйгыл, җуй, бетер.
Тәрәххем — мәрхәмәт, рәхим-шәфкать.
Зәман хальгә — бетмәс чир хәленә.

ФӘРХИ

I

Фагыйлятен, фагыйлятен, фагыйлят [1],
Сәңа, Фәрхи, күп сәламләр кямилят [2].

И Багъидә [3], сәне бик сәүде күңлем,
Сәнең күңлеңне белмәзмен, и сеңлем!

Бу еллардин мөкъәддәм — элгәредә,
Мәхәббәт нар иде сән дилбәридә.

Тулан айдик йөзең матур икәндер,
Ике битен кояшдик нур икәндер.

Кашың кара сызылган күз өстендә,
Яңа айдик һавада — күк йөзендә.

Ике күзем нуры, фәлянә-сөрур [4],
Дыңла, сәба йиле хале бу торур:

Сәба йиле йөрер галәмне сүтеп,
Ки илдин илгә йөгрер үтеп-үтеп.

Сәба йиле кәлде бәңа бер заман:
Фәлян илне исеп үтдем,— дир һәм ан.

Хушланып тордым, бу йилгә сүз катып,
Сән җаныйны бән сорадым, туктатып.

Бәгыйдә — озакта; ерактагы; монда: кул җитмәс.

Мәхәббәт нар иде сән дилбәридә — мәхәббәт син йөрәкне җәлеп итүчедә (бәгырьне өзүчедә) ут кебек иде.

Фәлянә-сөрур — сөендерүче фәлян.

һәм ан — шул ук заман; шунда ук; хәзер генә.

К. Насыйриның «Фәвакиһ-ел-җәләсә...» китабында «Фәрхи» әсәренең бер өлеше (горизонталь сызыклар ярдәмендә строфалар циклларга бүленгән).

Һәм дидем: «Фәлянә — ул таң йолдызы,
Нигә йоклый, ята япа-ялгызы,

Кардай беләгене буйнына салып,
Куш та күгерәкләрен куйнына алып?

Ята ялгыз, нәчек эче пошмыйдыр?
Ник мәне бергә ятырга кушмыйдыр?!

Мән аны йоклатыр идем, уйнатып,
Һәм сәбахда убә-коча уйгатып;

Йәш баладай йоклатырдем иркәләп,
«Тор, жаный!» — дип уйгатырдем иркәләп.

Куз-кашыны мәсжедә михраб идәм [5],
Сурәтене көзгедик мәхабб идәм!

Куз карашын жан эчендә жан идәм,
Шәгъләсене тән эчендә кан идәм.

Китсә дә куз алдыдин, дилзар идәм,
Тиз килерме, ди-ди, интизар идәм.

Ике кашыны ике һилял идәм,
Агызларыны абе зөлял идәм!»

Ишедеп бу сүзләри, сәба йиле
Диде: «Сән диуанәмүсән, и тиле?!»

Һәм диде: «Фәлян матурны сормагыл,
Бәнем өчен бик поша, дип тормагыл.

Пошмыйдыр, исенә төшерми сәне,
Вардыр аның, ахры, үзгә сәүгәне.

Сәүмәгәнен шундин аның беләсең:
Катларына нәчә барып киләсең.

Шул өзелеп варганында, и гъәриб,
Катына һәп киләме бер-бер къәриб?..»

Сәбахда — таңда; таң-иртән.
Мәхабб — эшерен саклана торган жир, сер урыны.
Шәгъләә — ялкын; якты шәүлә (нур).
Дилзар — зарланучы йөрәк; сыкранучы күңел.
Һилял — яңа туган ай; ай урагы.
Абе зөлял — татлы су; саф чишмә суы.
Сормагыл (сорамагыл) — сорама.
Һәп — кайчандыр бер; бер вакыт.
Къәриб — якын.

Чөнки ишетдем бу йилдин бу сүзи,
Бинуш улдым нәчә кичә-көндези!

Китде гакълым ул заман, хәйран улып,
Гүйә китде бу җиһан вәйран улып.

Йөрәкемдә ут кабынгандай булып,
Көстәнеп, күп еглъадым, күңлем тулып.

Инде нидәм, и газиз кардәшләрем?
Сән җаный өчен агызган йәшләрем.

Къәнда китде аһ вә аһ органларым,
Бер күрергә тилмереп торганларым?

Къәнда китде, җаный, егълаганларым,
Бик матур дип чабыңи йайганларым?

Хәсрәти әйамда үткән көнләрем,
Хәсрәти әүһамда үткән төнләрем?

Дәрдең уды каплаган әзманларым,
Гыйшкың удында үлә язганларым?![6]

II

Фагыйлятен, фагыйлятен, фагыйлят[7],
Сәңа, Фәрхи, күп сәламләр кямилят.

Къәнда[8] китде дәрддә үткән елларым,
Сагышыңдин тапмый[9] йөргән юлларым?

Соңра: «Сәндин, дидем, и баде сәба,
Тагын барсаң кире, ул Борнай таба[10],

Илтимасым ошбу сәба йиленә:
Бер хатым бар, илт сә Борнай иленә.

Нидәм (ни итәм) — ни эшлим.
Къәнда — кайда, кая.
Чабыңи йайганларым — данымны җәйгәннәрем.
Хәсрәти әйам — кайгы көннәре, матәм көннәре.
Хәйрәти әуһам — тынгысыз хыяллар.
Әзманлар — заманалар; вакытлар.
Кямилят — тулысынча, тәп-төгәл.
Дәрддә үткән — хәсрәттә (мәхәббәт чирендә) үткән.
Баде сәба — иртәнге җил (көнчыгыш тарафыннан исә торган).
Илтимас — үтенеч.
Илт сә — илтсәнә.

Кандалыйдан Фәрхигә илт бу гәзид,
Ул гәзидә күп сәлам булсын мәзид.

Һәм дигел: «Кандалда бер мелла, фәлян [11],
Гыйшкың илә зар булып, хәйран калан.

Искә төшеп, сагыныбдыр һәм сәни,
Гыйшкың илә корды-бетде һәм тәни [12].

Кичә-көндез сагышыңдан ул торур [13]:
Күзидә йәш, дилидә Фәрхи-сәрур.

Фәрхием дип анда егълап киселер,
Ташлама дип егълый-егълый исерер».

Жанкәем лә, аппагым ла, жанашым!
Ташлама са, алтыным ла, көмешем.

Сандугачым, карлыгачым, былбылым,
Ташламагыл, тот са [14], Фәрхи, кил, кулым!

Ай гынам ла, көн генәм лә, гөл генәм,
Жан гынам ла, тән генәм лә, көн генәм!

Жәүһәрем лә, гәүһәрем лә, нур гынам,
Сәрвием лә, жәннәтем лә, хур гынам!

Ташламачы, ай йөзем лә, гөл йөзем,
Тыңласана, кич ходайчөн, бер сүзем! [15]

Матурым ла, сәрвием лә, бер генәм,
Ташламачы, беләсең лә, сер генәм! [16]

Гүзәлем лә, кояшым ла, күз генәм,
Ташлама са, беләсең лә, сер генәм!

Назигем лә, үзәгем лә, гүзәлем,—
Фәрхи, айгыл, ничек итеп түзәлем?!

Гәзид — бүләк.
Булсын мәзид — өстәмә булсын.
Ташлама са — ташлама сана.
Тот са — тот сана.
Көн — биредә «кояш» мәгънәсендә.
Сәрви — төз, зифа буйлы; кипарис агачы.
Айгыл — әйтче.

III

Фагыйлятен,[17] фагыйлятен, фагыйлят,
Сәңа, Фәрхи, күп сәламләр кямилят.

Ничек итим, җаныем ла, Фәрхи лә,
Сәне бик мактадылар ла мәдхилә.

Қар кеби үк тәне, бик ак диделәр;
Шуклыгы юк, үзе бик саф диделәр.

Шуклыгы юк, ди-ди, къәтгъән кистеләр,
Ничә-ничә равиләр чын диделәр.

Тәрәзәдин караганда бер көне,
Көн төшеп, күрдем йөзеңнең[18] күркене.

Күз каравың фетнәи гошшакъ икән,
Ике кашың гүя ике такъ икән.

Симез икән, җанки, къәдде-къаматең,
Бер гъәҗиб-ел-мәнзар икән халәтең.

Симез икән түшләрең, бик зур икән,
Күкрәкләрең ак икән, пор-нур икән[19].

Буең зифа, бик сөйкемле буласы,
Симезеңдин бер кочакка туласы[20].

Сурәтең күрән кеше вәхйә китәр,
Гашыйк улып, алдыңда сәҗдә итәр!

Һәм менә инәлдерәсең ничә ел,
Гакълым алып, баша йитдең ничә юл[21].

Бу сүзем чын, сөйләшәмен алдамый:
Тәмам оныттыра яздың алламый![22]

Көн дә сагыш, төн дә сагышың тотып,
Бинамазым, бинийазым ут йотып,

Мәдхилә (мәдех илә) — мактау белән.
Къәтгъән — катгый рәвештә.
Равиләр — хикәячеләр; монда: хәбәрчеләр.
Фетнәи гошшакъ — гашыйклар фетнәсе.
Такъ — ярым түгәрәк; арка; җәя дугасы.
Къәдде-къаматең — сының-буең.
Гъәҗиб-ел-мәнзар — искиткеч күренеш, мәнзара.
Пор-нур — нур тулы.
Вәхйә киту — үз-үзен оныту.
Бинамаз — намазсыз.
Бинийаз — догасыз.

Аллаһ әкбәр дип әгәр каксам колак,
Сурәтең күңлемә уладыр[23] кунак!

Та сәлам биргәнче, и Фәрхи-сәрур,
Кан кеби буыннарымда тик йөрер.

Аллама баш орсам иде бу кадәр,
Сәне мәңа ул бирер иде мәгәр!

Сормыйсән лә, Фәрхи, үткән кичәми:
Йоклыймынмы йә сагышлап кичәме?

Каплап алды сагышың әукатеми,
Ник ышанмыйсән белеп бер катыми?

Бер нәзардә күңлеми дар әйләдең[24],
Бер нәзардә гыйшкыйлә зар әйләдең!

Бер нәзардә күңлеми бар әйләдең,
Бер нәзардә башым зәбун әйләдең[25]

Чөнки бармам дип хәбәрең карадыр,
Йөрәгемне ярадыр ла, ярадыр!

IV

Кә бән[26] яздым саңа, җаным, ничә хат,
Бәйан идем нәчә хатда нәчә кат!

Оемагыл эчеп гъәфләт шәраби,
Заигъ үткәрмә әййаме шәбаби.

И нитәем сәне хәзер бу чакда,—
Сән качан ятарсың бәнем кочакда?

Сафадин дөньяның зәукъен алырсән,
Гомерең үткән[ен] тоймай калырсән!

Тулан айдик йөзең матур икәндер,
Ике битең кояш кебек икәндер.

Әукатеми — вакытымны.
Бер нәзардә — бер карауда.
Дар әйләү — торып торган урын итү (биләп алу).
Зәбун әйләү — зәгыйфьләндерү, көчсезләндерү.
Гъәфләт шәраби — ваемсызлык шәрабен.
Заигъ үткәрмә әййаме шәбаби — яшьлек көннәрен әрәм үткәрмә.

Кашың кара сызылган күз өстендә,
Яңы айдик һавада — күк өстендә.

Сәба йиле йөрер галәмне гизеп,
Җаныкаем, торам хәбәрең көтеп (...)

V

Нәчә[27] хатлар бән җибәрдем афтаби,
Әгәр жыйсам, улырды бер китаби.

Гыйшыклык яшерә[28] торган ниһанда,
Мәхәббәтем чабы тулды җиһанда.

Сәңа язган идем, җаный, ничә хат,
Катыңа һәм дәхи бардым ничә кат.

Йөредем туктамый яз да вә көз дә,
Күңел чөн димәдең бер яхшы сүз дә.

Бик үфкәм зур ки сән абызтутыйга,
Бәне салдың гүйә дөнья утыйга.

Дисән, имеш: «Сөйәр булса, сорасын!»
Сорасам, белмәгәндәй тик торасың.

Бәңа хәсрәт өчен улмыш икәнсән,
Бәңа фетнә өчен тугъмыш икәнсән.

Качан җиңмәс иде кеше атасын?—
Тәкәббер, кешедин көлеп ятасың!

Качан вирмәз иде, кыз үзе килгәч,
Вирер иде, яратканыңны белгәч.

Инәлдем күп, сәңа моштакъ улам дип,
Аякың астында туфрак улам дип.

Күрәсең, ташлыйсың күңел тышына,—
Чыдам юкдыр ходаның язмышына.

Үзеңне, җаныем, бик зур күрәсең,
Шунынчөн бәне катындин[29] сөрәсең.

Афтаби — төсле кәгазь (саргылт һәм кызгылт төсләрдә).
Улырды — улыр иде: булыр иде.
Ниһан — аулак урын, яшерен җир.
Үфкәм — үпкәм.
Моштакъ улу — омтылып тору; кавышуны теләү.

Бу инәлгәнләрем таш да белерде,
Урыс кызы динен ташлап килерде [30].

Ишетмәдең, җаным, фөрйади-зари,—
Йитәр инде, инәлмәм мондан ари.

Хода өчен, «Фәлянә», итмә мәэйүс,
Кушылаек икәүлән, ахирәт дус!

VI

Килер [31] кызлар өемезгә илемдә,
Сынарга сүзне сүзләтеп телемдә.

Килүбән, төшенүбән тиз сүземгә,
Диярләр: «Остабикә ал үзеңгә.

Укыган кызны ал! Һәм без дә надан;
Вәгъәз дә сөйләр иде хәүф-риҗадан [32].

Кил, ал бер остабикә, укыган кыз,
Ки яхшы җирдә үскән һәм туган кыз.

Сәңа булсын сөйәрди чын җанекә,
Безә улсын кадерле остабикә!..»

Диделәр: «Без ишетдек: бер матур кыз,
Үзе галим, укырга бик батыр кыз.

Бик инсафлы, үзе «фәлян» баласы,
Гакылың җитсә,— шул кызны аласы!

Әдәбле, гакылы бар, фәһме-уе,
Сүзе татлыйгъ, йөзе хур, зифа буе.

Үсеп җиткән яңа гына бөлүгъга,
Йәш улса да, гакыл вирер олугъга.

Сөйәрсән бик, җаның фида кыйлырсың,
Тоташ «җаным!» диеп нида кыйлырсың».

Фөрйади-зари — зардан кычкырып егълауны.
Итмә мәэйүс — өметсез итмә.
Хәүф-риҗадан — хәтәрләр һәм өметле нәрсәләрдән (кирәкмәгән һәм кирәклләрдән).
Бөлүгъга җиткән — балигълыкка җиткән; үсеп җиткән.
Нида кыйлу — кычкыру.

Дидем: «Къэндин табармын? Къэнда ул йар?
Сэнендик тигрәле килгән матур йар?»

Исем китәр, тамаша бу сенәлләр,
Эчемдәгең тәмам белеп диделәр:

«Безә сөйләр иде вәгазь-нәсыйхәт,
Булыр идек аңа мөхлис, хәкыйкъәт!

Сүзен тыңлап, төшәр идек хозурга,
Йәш булса да, тотар идек лә зурга!»

Сәнең гыйшкың бәне аздырды юлдин,
Угырлардем сәне, гәр килсә кулдин.

Болай айрым торып файда беленми,
Зарардин гайре һич нәрсә күренми.

Сезең нәфсең үлекме, йә терекме? —
Кияүсез торудан аслан ирекми!

Сүзем күп ирде, гәр язсам тагын да,
Туласы булды ла ике ягы да.

Сәлам улсын сәңа, җаным, галәмдин,
Сөеп, сурып үбә торган каләмдин [33].

VII

Сәламләр әйләдем бик күп [34]
Ки сән Фәрхи абыстайга;
Догалар һәм дәхи яздым
Ике бите тулан айга.

Дога илә сәлам яздым,
Сәлам соң һәм кәлям яздым,
Гыйшык тотып үлә яздым —
Ки сән Фәрхи җаныкайга [35].

Гыйшык тотып үлә яздым...
Дәхи бер көн җәвап бирдең:
«Килер көз көне дә, диден,
Гәр сабрың булса бу йайга» [36].

Къэндин — кайдан.
Сэнеңдик тигрәле килгән — синеңдәй түгәл уңган.
Мөхлис — ихласлы.
Кәлям — сүз, сөйләм.

Гажәб сән: ниндәй сол алган,—
Ничә вәгъдәйләдең ялган,
Ышанычсызлыкка калган,
«Бу айга»,— ди-ди, ул айга.

*

Нигәчә торасың, Фәрхи,
Тотып хәсъләт һәуасындан?
Мәңа кил, гыйше нуш [37] итим,
Татып [38] вәсъләт дәуасындан.

Һәуаң зур тотма, сындыргыл,
Ки бер җанымны тындыргыл,
Кочып куйнында кундыргыл,—
Биреп вәсъләт дәуасындан.

Егетлек китәдер фәүри,
Йилә бирмә гъәзиз дәүри,
Ки итмә үзеңә җәүри,
Тотып фәсъләт [39] һәуасындан [40].

Бу юкны көтмәк илә сән,
И Фәрхи, нури дидәсән,
Гомереӊ заигъ итәсән,
Тотып гъәфләт дәуасындан!

*

Бу сүзләрне белим дисәң,
Табарсың — эзлә биш катдан!
Әгәр бер катлә тапмасаң,
Табарсың — эзлә биш катдан!

Сол — ысул; юл, чара.
Вәгъдәйләдең (вәгъдә әйләдең) — вәгъдә бирдең.
Тотып хәсъләт һәуасы — өстенлек тәкәбберлеге тотып.
Гыйше нуш иту — мәхәббәт ләззәтен алу.
Вәсъләт дәуасы — кавышу дәвасы.
Китәдер фәүри — тиз китәр, тиз узар.
Итмә үзеңә җәүри — үзеңә җәбер итмә.
Фәсъләт — аерымланганлык, бүленеп тору.
Нури дидә — күз нуры.
Гъәфләт дәуасы — ваемсызлык исереклеге.
Мишкят — монда: калын китап (гомумән: дини, әхлакый эчтәлекле китап).

Тутанны карасы ирде,
Кем ул да ярасы ирде,
«Кияүгә барасы иде!» —
Дәйүб үткәрде әукъатдән.

Сылу йәш чаклары үтде,
Йөзенең рәүнәкъе китде,
Къарыйды — ничәгә йитде,—
Кияүсез янды хиркъәтдән.

Сәне дә, Фәрхи, бер йиргә,
Шул ук безем кеби иргә
Йәрәшерләр, мәгәр бергә
Табылмаслар ла фиркъәтдән.

*

Имиләрең зур икәндер,
Тотарга кыздым, и җана!
Дәуа булмасмы дип янган,
Көеп беткән зәгыйф җана [41].

Бу сүзне димәгел, сакыйн,
Бу шигырь булса да — ялкын [42]:
Эчең, шәт, әллә бик салкын,
Суык боз кебидер,— сана [43].

Эчем-тышым түгел салкын,
Эчемдә янадыр ялкын,
Әгәр күрсәң иде хәркъын,
Күкертдик тоташып яна!

*

Әйа җаным, ике күзем,
Ул утдин мәни йолсана!
Торып көзгетик алдымда,
Гомерлек йар булсана!

Әукъатдән — вакыттан (дөресрәге: вакытлардан).
Рәүнәкъе — нуры (алсулыгы).
Къарыйды — картайды.
Хиркъәт — ялкын, ут; монда: ачы хәсрәт.
Фиркъәт — аерылу, аерым яшәү.
Җана — җанаш; җанга.
Сакыйн — саклан.
Хәркъын — утын, ялкынын (дөрләп януын).

Гомер буенда бер генә:
«Исәнме, җанкәем!» — дәйүб,
Күрешербез микән бергә,
Кочып алып, кысып, сөеп?!

VIII

Агач [44] башындагы кошны
Минеке дип әйтеп булмас,
Очып китсә япан җирдән —
Тотыйм дисәң, тотып булмас.

Алырмын дәйүбән күзгә,
Бән алдансам да бу сүзгә,
Алып та куйса бер үзгә,
Гомергә онытып булмас.

Хурелгъәйн сыйфатлы дип,
Матур да яхшы затлы дип,—
Шикәр дә, бал да татлы дип,
Ки бармакны йотып булмас.

Дисәң: «Бармамын, инәлмә,
Йөремә, басма, юнәлмә,
Үзең дә гомре кинәнмә!»—
Күп инәлеп тә хуб булмас.

*

Җәмал ләүхендә нәкъешең
Язылды охшатып айа,
Төсең-буеңны мәдехләп,
Язылды ошбу дүрт пайа [45].

Ки сән «фәлян» абыстайа
Кеше ни гашыйк улмайа?
И яндырдың да көйдердең,
Сөйдердең гъайәтин-гъайа!

Йә оҗмах хуры ирдеңме,
Бу көн индеңме дөнйайа?

Хурелгъәйн — хурның (хур кызының) үзе.
Җәмал ләүхендә нәкъшең — матурлык тактасында сурәтең.
Дүрт пайа — дүрт аяк-баганага (дүрт юллы строфага).
Гъайәтин-гъайа — чиктән тыш.

Иә Ирәм багыдин [46] тугып,
Үсеп килдеңме бу җайа?

Қанат җәеп сыйпандыңмы,
Бу гөлләрне сачып йирә?
Йөзеңнең нуры дип ачып
Төшердеңме матур җайа?

*

Һәуаны югары дотып,
Мөкъәддәрдин узып булмас,
Егылып бәддога кыйлсам,
Бигүк барган җирең уңмас.

Әгәр бәңа язылган сән,
Аны һәрдәм бозып булмас,
Әгәр бәңа кәлер булсаң,
Бәнем бу күңелем тулмас.

Әгәр бәңа кәлер булсаң,
Үзең бетеп, йөзең сулмас,
Йөрегел дөньяны гизеп,—
Бәнем кеби бере булмас!

*

Сәнең йөзеңне күрүбән,
Қи саргаймыш нәчә йөзләр!
Сәне күреп, тоташ егълап,
Харап булды нәчә күзләр!

Аларның силсиләсенә
Тоташып, дезелеп безләр,
Шулар кеби хараб улып,
Қи мәкъһүр әйләдең безләр.

*

Болай каһәр итеп безә
Ничек житәр доган күгә?
Бу кадәр түгелгән йәшләр,
Күрермез, башыңа житә.

Жайа (җайга) — урынга.
Мөкъәддәр — язмыш.
Силсилә — чылбыр, рәт.
Мәкъһүр — каһәрләнгән.
Күгә — күккә.

Болай къәһр әйләгән мәнләр
Гидай егеткә күп китә,—
Фәкъир-фокъра, талиб-толабә
Догасы анлара җитә.

Болай къәһр итмәгә, җаным,
Кызынма, һич сүзең әймә.
Ходаның ләгънәтен алып,
Тәкәббер сүзләрең димә!

*

Тәкәббер улубән шәйтан,
Аны рәдд әйләде сөбхан,
Үкенде, бәс, аңа Иблис,
Ки файда улмады һәр ан.

Үкенгән чакда әйтерсең
Гомер үткәнгә бушындан:
«Сафалар сөрәсем икән
Җиһанның гъише-нушындан!» [47]

Көенгән чакда әйтерсең,
Күңел кайнаса җушындан:
«Сафа ник сөрмәдем икән
Егетлек вакты хушындан?»

Ки әйтерсең бу «фәлянгә»,
Белерсең булса һушындан,
«Бу бәнем файдама икән,
Дәйүбән, санса кушындан» [48].

Буш үткәрмә ки йәш гомрең!
Киредән бер гырушындан
Мең алтынга да бирмәсләр,
Алыр идең фөрушындан!

Мәнләр — шәхесләр, затлар.
Талиб-толабә — шәкертләр, укучылар.
Рәдд әйләде сөбхан — алла кире какты.
Һәр ан — һәрвакыт; монда: һич тә.
Гъише-нушындан — хозуры-рәхәтеннән.
Җушын (җушкын) — дулкын.
Егетлек — монда: яшьлек.
Санса кушындан — пары (ише) итеп санаса.
Гыруш (грош) — вак тәңкә (ярты-тиен).
Фөруш — сатучы, сәүдәгәр.

*

Ике ел торды бу күңлем
Чыгармый гыйшык разындан.
Өченче елны чыкардым,
Чыкардым сабрым азындан.

Сәңа хат идәче колны
Ки җасус багълады юлны,
Ки күрдем күп кыенлыкны
Башымда һушым азындан.

*

Җанымнын эченә генә
Куяр идем, сыярмусән?
Шулай тилмертебүк әллә
Бәнем җаным кыярмусән?!

Дисәнә: ни ката калдың?
Йә таш күңелле йармусән?
И билләһи, и валлаһи,
Нидән үк бәңа вармыйсән?!

Гыйшык разындан — мәхәббәт сереннән.
Хат идәче — хат илтүче.
Җасус — шымчы, ящерен күзәтүче.
Ни ката калдың — нигә катып калдың.

МӘГЪШУКНАМӘ

[Мөкаддимә]

Хәмед [1] берлән бән агъладым ходага,
Салауатым Мөхәммәд Мостафага [2].

Әйа гариф, ишет бәндин гаҗәб сүз,
Тәхәммелдә булып сән һәм аңа түз.

Үз исмемне йад итсәм гайбәт улыр,
Укыгыл сән — саңа да гыйбрәт улыр.

Йа гариф, бән саңа үз исмемне йад итсәм, сән бәнем гайбәтемә дөшеп гөнаһкяр [3] булырсән дәйүб, үз исмемне йад итмәдем. Бу мәгъшук [4] әүвәл зыйафәтдер, ахыры рийазәтдер: тынычсыз гомер кичермәккә сәбәб булгучыдыр. Нә кадәр иҗтиһад [5] итдем — булмады, бу эш булмаска сәбәбдер. Тәмм [6].

I

Бу эшләр булды һәм бәнем үземдин [7],
Гакылың булса, аңлагыл сүземдин.
Фәлян къәрйәдә бер имам идем,
Бу гыйшык булмаса, бән әман идем [8].

Хәмед — мактау; шөкер (итү).
Салауат — мактау, олылау догалары.
Гариф — белүче, аңлаучы; акыл иясе, укымышлы.
Тәхәммел — түзем, чыдам.
Гөнаһкяр — гөнаһ иясе (гөнаһ эшләүче).
Зыйафәт — сыйлашу, күңел ачу.
Рийазәт — тмелып тору, чикләнү, күңел кырылу.
Къәрйә — авыл.
Әман — имин.



«Мәгъшукнамә» поэмасы кулъязмасыннан (төп редакция) бер бит (КДУ, ФК КБ № 2366 т.)

Әлиф-би[9] берлән бән яздым мисален,
Укыгыл сән, белерсең һәм хисабын.

Әйа гариф, ходадин нөсърәт эстә,
Догаң берлә[10] имин булсакчы без дә.

Бу бабда бер гаҗәб мәгънә дәйүлде,
Бераз мөнча гаҗәб сүз әйделенде.

Бу мәгъшукның башы хәер икәндер,
Карап торсаң, соңы сәер икәндер.

Бу сүзләрне күреп сән азмайасән,
Үзең төшмәс чокырны[11] казмайасән.

Бу гыйшыклар[12] күренәдер җаныңтик,
Бу дөнйада сарыф булган[13] малыңтик.

Бу мәгъшуклар һәм үзеңә булыртик,
Йөрерсән һәм ит эстәгән мышыктик[14].

Талиб куркъмайдыр мәгъшук халедин,
Аерылса да ул газиз җаныдин.

Таҗ улса башына, белмәз үзене —
Гыйшыклыкдин диуана әйләр үзене[15].

Сәна берлән башладым бу китабны,
Гыйшык тагъ булыр — белгел хисабны.

Чыдап булмас бу гыйшыклык эшенә,
Теле һәм кулы вармаздыр эшенә.

Бу кызларның мәхәббәте хәйадыр,
Аның бәгъзеләре булыр рыйадыр.

Аның эстәгәне бер кыз баладыр,
Карап торсаң, аның күңле даладыр[16].

Нөсърәт эстә — ярдәм эстә (эзлә).
Баб — бүлек.
Әйделенде — әйтелде.
Азмайасән (*азмагайсың*) — азмасаң иде.
Казмайасән — казымасаң иде.
Җаныңтик — җаның тикле, җаның шикелле.
Мышык — мөшек: песи, мәче.
Талиб — укучы, шәкерт.
Тагъ булыр — бер булыр.
Хәйа — тыйнаклык, оятлылык.

Әйа гариф, бу мәгъшукка күренмә,
Кара елан кеби сән һәм урелмә [17].

Хәрҗем күп дәйүб сән ормагыл лаф,
Тәмам булмас мәгъшук — кәлтер инсаф.

Гаеп итмә укымакдин бу сүзгә,
Гаеп итеп ки, зинһар, орма йөзгә.

Сәңа яздым бу мәгъшук сыйфатыдин,
Ки, зинһар, саклана күр афәтедин!

Дучар [18] булдым бу мәгъшукның эшинә,
Нәсыйхәтдер боны укыган кешигә.

Бу эшне кыйлганым бәнем үземдин,
Бу мәгъшукның ахыры бер үлемдин [19].

Агач шартласа, аны сынды дип бел,
Хилаф сүз булса, адәм үлде дип бел.

Тамаша әйләмә, гариф, үзеңне [20],
Хатитмәгел бәнем әйткән сүземне.

Тиешсез урынга [21] сүзеңне катма,
Газиз гомрең юк эш берлән озатма.

Хараб булып гыйшык утындин уздым,
Янар утда тәхәммеллек лә түздем [22].

Дәмең булса бу гыйшыклык халендин,
Аерылып калырсың һәм малыңдин.

Зале нөктә [23] кеби булыр бу күз дә,
Гаҗәб мәгънә булыр, белгел, бу сүздә:

Зыйафәтдә [24] булыр гыйшык бу көндә,
Рийазәтдә булырсың ахырында!

Бу дөхтәрләр даим күрер күземдә,
Нә сүзләсәм, ки улды ул сүземдә.

Хәрҗем — чыгым, расход.
Хатитмәгел — хата итмәгел.
Дәмең булса — монда: тәэсир алган булсаң.
Зале нөктә ... күз — күрер-күрмәс... күз.
Дөхтәрләр — кызлар.